# КАЗАН УТЛАРЫ

1
ЯНВАРЬ-1972

БАЙЧУРАЛАР АРХИВЫННАН
ИЗ АРХИВА БАЙЧУРИНЫХ

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

1
ЯАРЬ
1 2

## Бу санда:

М. МӘҺДИЕВ. Фронтовиклар. Роман . . . . . 3
С. КУДАШ. Боерык. Шигырьләр . . . . . . . 36
М. ӘМИР. Балыкчы ялганнары. Повесть . . . . 40
Г. ЛАТЫЙП. Хатлар язар идем. Шигырьләр . . . 63
А. ГАНИЕВ. Сүзсез җыр. Повесть . . . . . . 68
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Гомер. Шигырьләр . . . . 99
К. СИБГАТУЛЛИН. Иргә чыкмый калган апалар. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 102
И. ТУКТАР. Җөмләләр . . . . . . . . . . . 106

ӘДӘБИ МИРАС

Г. АХУНОВ. Гомер буе үзе булып калган кеше . 107
И. ГАЗИ. Дүртәү. Беренче сыналу. Хикәяләр . . 113
Совет язучысының байрагы. Язучының гражданлык йөзе. Публицистик мәкаләләр. Язучының хатлары . . . . . . . . . . . . . . . 128

ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

Төркмән шагыйре Кәминә . . . . . . . . . 143

ОЧЕРКЛАР

Д. ВӘЛИЕВ. Хәрәкәттә бәрәкәт . . . . . . . 149

СӘНГАТЬ

З. ШАҺИМОРАТОВ. Ерактагы якты йолдыз . . . 156

ИСТӘЛЕКЛӘР

М. ТАҺИРОВА. Мәдәният йортында бер кичә . . 166

КПСС
ТАТА ТАН
ӨЛК
КОМ ТЫНЫҢ
ГАЗЕ ҺӘМ
ЖУР ЛЛАР
НӘШ ЯТЫ
КАЗ

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. МОСТАФИН. Җаваплылык хисе . . . . . . 169

Бәләкәй рецензияләр . . . . . . . . . . . . 182

ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

«Казан утлары»ның кыскача биографиясе . . . 185

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова,** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

---

Производствога бирелде 7/X-1971 ел. Басарга кул куелды 10/XII-1971 ел. ПФ 09106. Кәгазь форматы 70×108$^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 86346 экз. Заказ И-764. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1972 ел.

Мөхәммәт Мәһдиев

# ФРОНТОВИКЛАР

РОМАН

## I

Каты салкыннардан соң коточкыч дуамал буран башланды. Йортларның түбә кыегына кадәр кар өелде, коелар, чишмәләр күмелде. Күрше-күлән бер-берсенә кермәде, әйтерсең лә тереклек туктап калды. Ара-тирә кое тирәсендә су алып азапланганда, чишмә актарып ятканда очрашкан кешеләр генә үзара авыл хәлләрен сөйләп хәл белештеләр.

— Каюмныкыларны бүген казып алганнар. Чолан ишекләрен адәм ачарлык кына итмәгән буран...

— Бүген тагын төнгә кеше сорыйлар ди станцага җибәрергә. Ике көннән бирле чуен юлда гарасат — поездларның бер дә рәте-чираты калмаган, ди.

Салкын буран кешеләрнең җелекләренә үтте, өйләрнең җылысын суырды, карчык-коры сызланудан иза чикте. Сыерларның озынайган йоннарына бәс утырды, суынган абзарларда терлек-туар өзлексез дерелдәде.

Рушад ике атна инде көн рәтләнгәнне көтеп ята. Салкынны, буранны сылтау итеп, хат ташучы почта бүлегенә йөрми. Ягарга коры утын юк дип уку йортын ачмыйлар. Кенигсбергтан чыкканда ук аттестат белән юлга бирелгән бер котелок ак май да инде бетеп бара. Аның военкоматка учетка кереп кайтканнан бирле эшләгән бөтен эше бик гади: иртән ишекне каерып ачып, баскыч төпләрен чистарта. Чиләк, көрәк алып чишмәгә суга төшә. Чишмә авызын көри, ача. Аннары утын алып керә. Әнисе мич ягып җибәргәч, мич каршысына утырып, үзе белән алып кайткан бердәнбер китапны укый. Ул — «Кызыл Байраклы Балтик Флоты Бөек Ватан сугышында» дигән китап. Моны демобилизацияләнгән һәр кешегә Флотның Политидарәсе биреп җибәрә иде. Китапның титул битенә машинкада басылган бер кәгазь ябыштырганнар. Ул — Рушад исеменә.

«Икенче статья старшинасы, ВКП(б) члены агитатор Сулимовка. Кызыл Байраклы 4 нче Балтик Флотының Политидарәсе тыныч хезмәткә озатканда Сезгә бу китапны истәлек итеп тапшыра. Хәрби данга күмелгән Балтик флотында хезмәт иткәндәге кебек тыныч тормышта да алдынгы сафта булуыгызны Политидарә өмет итеп кала».

Бу сүзләрне Рушад инде яттан белә. Хәер, боларын гына түгел, китапның эчтәлеген дә.

Әйе, бу китап инде кат-кат укылган. Аның сүзләре канга сеңгән. Йөрәккә үткән. Шулай да әле моны тагын укыйсы бар икән. Ә буран өй түбәләрен чытырдата, өйнең җылысын суыра...

Китапның эчендә тагын бер документ бар. «Хәрби Диңгез Флотыннан демобилизацияләнгән, университетның элеккеге студенты Рушад Сулимовны Акбалык урта мәктәбенә тарих укытучысы итеп билгеләргә». Копия дөрес... Әйе, дөрес...

Фашист су асты көймәләренә каршы сугышта катнашып, торпедалар, дәһшәтле тирәнлек бомбалары белән эш иткән һәм Җиңү көнен Кенигсбергта каршы алган фронтовик Сулимовка бу приказны алганда нибары егерме яшь иде.

Сугышка барып фашистлар өерен күрермен дип ул башына да китермәгән иде. Дөрес, сугыш елларында педучилищеның бер курсын тәмамлагач, ниндидер бер хыял белән военкомат ишегенә барып карады. Ләкин ишекне шакып керергә йөрәге җитмәде. Иң дөресе — русча бик начар сөйләшә иде ул вакытта. Шул тоткарлады. Шулай кителми калынды. Аннан соң, малай-шалай белән нишләсеннәр анда? Гаврош шикелле патрон җыеп йөри торган заман түгел ләбаса. Училищены бетерде — унсигез яше тулмаган авыл малае белән военкомат кызыксынып та карамады. Хәер, унсигез яшь сентябрьдә туласы иде. Инде сугышның берәр елдан җиңү белән тәмамланачагы ачык иде. Рушад университетка керергә сынау бирде.

Сынау бирүчеләр арасында култык таяклы фронтовиклар, фронтта булган медсестралар, сыңар күзен кара тасма белән бәйләгән офицерлар, кулсыз солдатлар бар иде. Аларның күбесе математиканы уртачага язды. Рушад отлично алды. Физикадан да Рушадның бәхете басты: имтихан кабул итүче татар профессоры иде. Гальваник элементлар — анод һәм катод арасындагы ионнар хәрәкәте турында Рушад татарча ярды да салды. Тагын отлично. Чыгып киткәндә өстәл янында тоткарланды, гимнастерка кигән яшь хатынга параллель тоташтыруның схемасын сызып шпаргалка бирде. Орден таккан, егерме-егерме ике яшьләрдәге бу хатын кызарып, өметсезләнеп утыра иде — шпаргалканы алгач, озын керфекләрен күтәреп Рушадка карады, мөлаем карашы белән сүзсез генә аңа рәхмәт әйтте. Аудитория ишеге төбендә яшь бала күтәргән бер әби тора иде,— күрәсең, баланы имезер вакыт җиткән, ә әнисе схема да сыза алмый утыра. Ах, бу бала белсә иде әнисенең хәзер нинди кыен минутлар кичергәнен...

Тарихтан Рушадка «Боз өсте сугышы» эләкте — анысын чатлатып сөйләде, тик каушаудан «ухо» сүзен күплек санда «ухи», «принес» сүзен «принесел» дип (янәсе, хатын-кыз булса, «принесла» бит!) әйтеп кенә имтихан алучының көлүенә сәбәп булды. Югыйсә, боларны гына белә иде. Карт галим кет-кет килеп буыла-буыла ютәлләде. Шулай да тарихтан — «яхшы»! Соңгы имтиханны тапшырган көнне аны кабул итү комиссиясенә чакырып алдылар. Балл җитми!

— Я, туган,— дип сүз башлады профессор.— Хәлләр ничек?

Рушад эшнең бик катлауланганын инде аңлап бетергән иде, шуңа күрә курыкмады һәм исе китмәгәнгә салышты.

— Хәлләр корым кебек ак,— диде ул.

Профессорга бу ошады.

— Соң син башка факультетка күчәргә уйламыйсыңмы? Ну, әйтик, тарихка, әдәбиятка? Ә?

— Математиканы яратам бит мин, товарищ профессор,— диде Рушад.— Әтием дә математика укытучысы иде.

— Әтиең... Ә, әйе, әтиең. Хәбәрсез югалды, диген, ә? Таныш, таныш фамилия. Рабфакта вакытта мин аны белә идем. Бер бүлмәдә тордык.

Беләсеңме, ничек булды? Я, син утыр әле. Менә шулай. Әле тартмыйсыңмы? Ярый, әйбәт, иярләнмә.— Профессор стенадагы розеткадан папиросына ут алдырды.— Беләсеңме, бервакыт нәрсә булды? Университетка ниндидер бер чит ил делегациясе килде. Мин шунда банкетка чакырулы идем. Студентлар исеменнән. Котладылар, тостлар әйтештеләр. Ә синең әтиең — ул вакытта синең кебек яшь егет — тәрәзә артында торды. Банкет бетәр алдыннан мин ачык тәрәзәдән тегеңә әллә никадәр ризык озаттым. Башлы малай иде — камыш сумка белән килгән бит. Кыза китеп, дүрт ярты да шудырттым. Кайттык. Бер иптәшебез — Чабаксардан килгән Исаев дигән студент — бик яман салкын тидереп тешен-тешкә бәреп ята иде. Давай, без әйтәбез, сине терелтәбез. Салдык та бирдек тегеңә бер кружка аракы. Башыңа киттеме? дибез бераздан. Юк, ди бу. Тагын бер кружка салып бирәбез тегеңә. Инде, дибез, төрен дә ят, тирлә, иртәгесен лекциягә барасың — күр дә тор, дип өстенә ике-өч кат итеп пальтоларыбызны яптык. Төне буе тып-тын ятты. Башка төнне ыңгырашып җәфа чиктерә иде. Иртән тордык. Ну, без әйтәбез, әйдә, йокыны бүстерден, тор. Лекциягә китәбез, янәсе. Киттең, китми ни! Бер сәгатьтән безнең бүлмәдә следователь белән врачлар иде инде! Малаебыз капут төн чыкканчы. Кичтән үк үлгән булган мескен... Да... Менә шулай.

Рушадның әтисе тормышына бәйле булган бу тарихны беренче ишетүе иде, шуңа күрә үзенең монда ни өчен кергәнен бу вакытта онытып торды. Профессорның йөзе җитдиләнеп китте.

— Менә нәрсә, брат. Син соң нишләп механика бүлеген сайладың? Бераз гына җитеп бетми бит монда синең белгеләр... Әйтик, нигә сиңа тарихчы я әдәбиятчы булмаска? Яки, актык чутта, нигә, әйтик, зоолог булмаска? Амебалар, суалчаннар, дафниялар... Бөтенләй кызык бер дөнья бит...

Рушад эшнең нәрсәдә икәнен тәмам аңлаган иде, шуңа күрә ачыктан-ачык җавап аласы килде.

— Ә ни өчен миңа механика бүлегенә керергә ярамый? Минем белгеләр ул кадәр үк түбән түгел бит?

Профессор тагы да җитдиләнде. Урыныннан торып Рушадның янына ук килде. Авыр сулады.

— Их, сине, тишек борын... Ә мин синең белән ирләрчә сөйләшкән булам. Син әле малай гына икәнсең. Югыйсә, шундый сорау бирмәс идең. Фронтовикларны кая куярга кушасың? Ә? Әйдә, без болай килешик: сиңа укырга кирәк. Син менә хәзер үк гаризаңны күчереп яз. Тарих бүлегенә диген. Бүген үк приказ белән үткәрербез. Әйдә, әйдә. Механиканы, кызганычка каршы, калдырып торырга туры килер. Кстати, менә шушы гаризаңа ук төзәтеп кенә яз...

Рушад борынын тарта-тарта «Механика» дигән сүзне сызып, өстенә «Тарих» дип язып куйды. Профессор аны кул биреп озатты.

— Стипендия, тулай торак мәсьәләсе хәл ителгән булыр, борчылма,— дип калды.

Шулай да нинди игътибарлы булды Рушадка карата ул профессор!

Ул көнне мәшәкатьләрдән Рушадның башы шауллады, аның авылга кайтасы килә башлады. Аяклар үзеннән-үзе сорочий базарына өстерәделәр. Лавкалар арасында авылдашлары очрамасмы дип ул озак йөрде. Пешкән бәрәңге, бәрәңге кәлҗемәсе, шикәрдән эретеп ясалган конфетлар, слюдадан ясалган расческалар, кулдан ясалган тарак ширпылар сатучының исәбе-хисабы юк иде. Бер җирдә кап-кара ике малай гөрләтеп папирос саталар. Чиратка ирләр тезелгән. Ну бу Яңа бистә малайларын! Үзләре барысы да бер төсле чибәр булыр, бөтенесе кап-кара һәм бөтенесе менә дигән спекулянтлар... Телләре телгә йокмый — ялт-йолт! Бер сумга ике папирос. Рушадның да кеше төсле тө-

тенен йота-йота бер суырып карыйсы килде. Югыйсә, авылда иптәш малайларының бөтенесе тарта. Ул да чиратка басты. Кара малайларның берсе акча алып, икенчесе папирос биреп тора. Акчаны да бер сум, ике сум дип түгел, үз телләрендә атыйлар. Дүкәш, фәлән-төгән...

Чират тиз житте. Ялт! Рушадның бер сумы кара малайның күлмәк якасыннан корсагына төшеп китте. Малайлар үзара ниндидер бер жаргон әйтеп алдылар. Папирос биреп торучысы аңа бер генә данә ябык, бушаган папирос сузды. Рушад аңлашылмаучылык чыккан дип уйлап китми торды.

Шул вакыт малайларның олырагы, акча җыеп торганы, Рушадка кычкырды:

— Син, нәрсә, авызыңны күтәреп торасың монда, сала гыйбаты!

— Бүтән кешеләргә бер сумга икене бирәсез бит!

— Әһә, әле сиңа икәү кирәкмени? — Акчалы малай Рушадка якыная башлады.— Сиңа икәү кирәкмени авылдан килгән башың белән, ә? Кара син аны, фәлән итим, берне биргәнгә рәхмәт юк! Хәзер үк таймасаң, ияк астыңа берне баш белән бирәм бит!

Яңа бистә малаеның башы бик йомры иде, һәм, бәладән башаяк дип, Рушад бер читкә китте. Ул арада арттан да тавышлар көчәйде:

— Нәрсә анда сатулашасыз?

— Кем чиратсыз кергән? Теге авыл гыйбатымы?

Әле генә профессорның затлы кабинетында фән турында сөйләшеп, галимнең кулын кысып чыгып киткән авыл малаен базар шулай кабул итмәде.

Таза-таза кешеләрнең асфальтка утырып шнурдан элмәк ясап уйнаганнарын ул шактый гаҗәпләнеп карап торды. Иң кызыгы шунда — арадан берсе шул элмәккә бармагын тыга да бераздан бу кеше акча откан булып исәпләнә, һәм Рушад күз алдында гына берәү ике-өч кызыл утызлыкны отып та алды. Асфальтта утырган киңчә кызыл битле кеше горылдык тавыш белән Рушадка эндәште:

— Я, энекәш, бәхетеңне сынап карыйсыңмы? Тәмам бөлдерде бит мине әнә теге абыен. Иртәдән бирле оттырам бит, оттырам. Бөтен семьям ач кала бит — пальтомны саткан акчам бетә бит...

Ә нигә чыннан да бәхетне сынап карамаска!

Шәһәргә килгәнсең икән, шәһәрчә булсын! Менә бит кешегә санап отышлы уен уйнарга чакыралар. Бөтен кеше дә теге Яңа бистә малайлары төсле булмый бит инде...

Элмәк эченә бармагын куйганда Рушад отсалар отарлар, бер утызлыкны бирермен дә китәрмен дип уйлаган иде. Ләкин бармак элмәккә эләгеп калды. Кызыл битле кеше кор-кор килеп йөткеренде, пиджак кесәсеннән калын бумажник чыгарып, котсыз калын йөзлекләр төргәге арасыннан утыз сум алып Рушадка бирде.

Рушадның күңеле күтәрелеп китте. Менә ичмасам кеше! Иртәдән бирле оттыра, һаман кайтып китми үзе. Ә тагын бер мәртәбә бармакны куеп карасаң? Гаҗәп! Тагын бер утызлык аның кулына килеп керде. Куеннан чыккан акча җылы иде. Бичара кеше! Куеныннан бер-ике минут эчендә хәләл алтмыш сум акчасын чыгарып бер авыл малаена бирде... Инде китсәң дә ярар. Ашханәгә кереп бер туйганчы ашарга кирәк... Ләкин кызыл битле аңа әле тагын бер тапкыр оттырды. Ул арада тагын берничә таза кеше килеп чүгәләп утырдылар да Рушадның бәхетенә кызыгып сөйли башладылар:

— Ну, энекәш, осталык үзеңдә...

— Син абзаңны җәлләә бераз. Харап итәсең бит...

Уен кызды. Ләкин бераздан теге утызлыклар әкренләп хуҗасына кире кайта башладылар. Иң ахыргысы да ычкынды. Я, инде торып китсәң дә ярар. Тукта, бәлки тагын бер куеп карар гадыр?

...Рушад шәһәрдә тотарга дип кырып-себереп алып килгән акчасын-

нан бөртексез калды. Кызыл битле кеше, син мине отканда мин бер сүз әйтмәдем бит, ә нишләп син тыпырчынасың, дип аның кесәләрен актартты, үз илле сумын отып өч тәңкәсенә кадәр әлмәккә куйдыртты. Әше беткәч, аны куган кайсыдыр төртеп чыгарды һәм кызыл битле кеше икенче бер таза гәүдәлегә тагын оттыра башлады. Чү! Бу кеше бая гына кызыл битлене бик каты отып, куен тутырып акча алып киткән иде шикелле! Бу ничек була соң? Тукта, моны беткәнче карап торырга кирәк... дип уйлап бетермәде, дөп иттереп Рушадның муен тамырына суктылар. Ул тешен-тешкә бәреп сөрлегеп китте. Караса — баядан бирле шушы тирәдә тулганган кызмача таза бер ир икән.

— Әйдә бар, аттыр моннан ять кенә,— диде ул Рушадның җилкәсеннән эләктереп.— Әйдә, әйдә, бар, тизрәк таймасаң, бөтенләй китми калырга можешь,— дип куәт белән этеп җибәрде. Нәкъ шул минутта аркылы-буйлы каешка уранып кобура тоткан юан милиционер килеп чыкты. Рушад шатланып куйды: әһә, сез монда җыелышып отышлы уйнап утыручылар икәнсез әле, менә эләктегезме, дип шатланып, тегеләрнең ничек эләккәнен карарга бер читкә басты. Ләкин милиционер, берни дә күрмәгәндәй, Рушадның муен тамырына утырткан кеше белән кул биреп күреште, һәм алар көлешә-көлешә тәмәке кабыздылар. Рушадның гаҗәпләнгәне шул булды — бу тирәдәге бөтен кеше таза, кызыл битле, көр тавышлы иде. Менә бит авылда бер генә дә андый кеше юк хәзер. Бөтенесе хәлсез, арык...

Тагын, базарның бер почмагында ул ун-унбиш ир кешенең гармун сатулашканын күрде. Барысы да шау итеп ниндидер Абдулны әзлиләр, шуны көтәләр иде. Бераздан гармун базарындагы халык тынды, урталай аерылып кемгәдер юл бирде. Кечкенә гәүдәле, сыңар күзле, зәңгәргә ак юл төшкән күлмәгенең якаларын чишеп җибәргән кызмача берәү эре генә кыяфәт белән мәйдан уртасына юл алды. Күптәннән инде кулдан кулга йөргән бер венский гармунны, хуҗасына карамыйча гына, кулына алып, каешларын җилкәсенә киде, бөтен телләрен дә акрын гына кычкыртып карады, аккорд бирде. Ләкин бер көй дә уйнамады. Гармун хуҗасы — шинель кигән, сыңар аяклы, чандыр, ак йөзле берәү — күзләрен мөлдерәтеп зәңгәр күлмәклегә карап торды. Тегесе исә гармунны аңа кайтарып бирде һәм сүзсез генә юл ярып, халык арасыннан чыгып китте. Халык тагын аңа юл биреп калды. Зәңгәр күлмәкле шундагы «Закусочная» дип язылган такта хәрчәүниккә кереп китте. Инвалид, дәү гармунын култык таяклары арасында бутый-бутый, каешларын эләктереп азапланды. Шул чак ирләрдән бер төркем гөҗләп алды:

— Я, бар, нәрсә монда торна шикелле катып калдың?

— Ие! Авызын күтәргән! Гармуныңны яхшы хакка биетәсең килсә, әнә тегендә кереп сөйләшәсе аны!

— Кәнишне! Абдул бер сүз әйтте — бетте монда. Абдул хакын куйды — әше бетте. Бер кеше дә бер тиен кимәтә алмый. Әйдә бар — мәгәрич синнән... Абдулны бер ычкындырсаң, тотып булмый аны...

Инвалид гаепле кешедәй акланды:

— Соң бит минем кесәдә сукыр бер тиен дә юк. Мәгәрич бит ул саткач эшләнә торган нәрсә...

Ирләр гөҗләделәр:

— Их, син, мокытның да мокыты икәнсең. Бусы бит сатар алдыннан — сатышыр өчен. Абдул бит әле башта хакын әйтә сиңа. Саткач әле ул само сабой, монда гына котыла алмыйсың. Әле анысын без бергәләп. Әйдә, әйдә, күп такылдама, пока Абдул абыеңның әппитите бар чак...

...Инвалид култык таяклары белән эре-эре атлап «Закусочная»га таба китте. Халык арасында икенче бер тальян турында бәхәс кыза калды.

Шулай да университет аудиторияләрендә тормыш паграк, күнелгә ятышлырак.

Тизрәк лекцияләр башлансын иде...

...«Совет дәүләтенең һәм хокукының нигезләре» — бу фәнне юрист укыта иде. Рушад аудиториядәге кешеләргә игътибар итте. Күбесе олы яшьтәгеләр, таяклылар, кулларын асканнар, орден-медаль такканнар. Авыл малайлары өч-дүрт кенә күренә иде. Лекция башланыр алдыннан бер хатын кереп, староста сайлатып чыгып китте. Сул кулына хром перчатка киеп куйган бер олы кешене староста итеп билгеләделәр. Бераздан Рушад ул хром перчатканың ясалма кул өстеннән кидереп куелган икәнен белде. Кыңгырау чылтырады. Беренче лекцияне көткәндә студент никадәр саф күңелле, самими була! Моны лекция укырга керүче галим үзе беләме икән? Кем керер? Исәнләшерме? Нинди сүздән башлап китәр? Язып булырмы? Ах, студент кеше нинди бәхетле! Юк, дөньяда иң бәхетле кеше — аудиториядә лекция сөйләүче. Сине тынлыйлар, сиңа сокланалар, сиңа ышаналар...

Биек ак ишек салмак кына ачылды да кафедрага таба нәзек озын бер ир атлады. Рушад ак чәчле профессор көткән иде, бераз гына кәефе китте. Кырык яшьләр чамасындагы кеше — әлбәттә, бу инде профессор түгел. Чәче дә кап-кара, ялтырап тора. Өстендә — куе зәңгәр юл-юл трико костюм. Җилкәләре күпертмәле пиджагының биле кысып тора. Киң генә озын чалбардан. Ач яңаклы. Ике каеш белән бикләнгән иске портфеленнән кәгазьләр алып кафедра өстәленә җәеп салды. Тамак кырды. Хәзер беренче җөмлә чыгарга тиеш... Юк, дәшми, бәясен күтәрә. Тынлык. Шуннан ул, кулларын артка куеп, аудитория алдында акрын гына марш атлап йөри башлады. Атлаган саен идәндә чыгырт-чыгырт иткән тавыш чыга. Сугыш башланганнан бирле май заты күрмәгән паркеттан чыгамы ул тавыш, әллә бу киң балаклы купшы ирнең туза башлаган, ләкин пөхтә саргылт ботинкаларыннанмы?

Менә, ниһаять, беренче җөмлә алдыннан тагын бер тапкыр тамак кырылды. Ни әйтсә дә язарга кирәк. Тик бер генә тапкыр күтәрелеп карасын иде халыкка, мәгънәсез! Шыңгырдавыклы тавыш аудиторияне хәрәкәткә китерде:

«Фридрих Энгельс үзенең 1884 елда язылган «Семьяның, хосусый милекнең һәм дәүләтнең килеп чыгуы» дигән мәшһүр хезмәтендә борынгы ыруглык һәм кол биләүчелек җәмгыятьләре турындагы искиткеч күп материалларны фәнни яктан эшкәртеп — ә бу процесста ул бигрәк тә Америка этнографы Морганның хезмәтләрен файдаланды — тарихи материализм принципларына таянып, борынгы ыруглык җәмгыятенең барлыкка килүе, үсүе һәм таркалуы процессын тирән рәвештә ачып бирде».

Менә сиңа лекция! Бу күпертмә җилкәнең намус дигән нәрсәсе бармы икән!

Монда бит әле нибары ике-өч сүз язылды. «Фридрих Энгельс үзенең 1884 елда»...

Болай булмый бит инде, юньсез!

«Изү һәм эксплуатация мәңге булган һәм табигый дигән ялган буржуаз теориянең асылын фаш итеп, конкрет тарихи анализ белән Энгельс хосусый милек, сыйныфлар һәм дәүләтнең тарихи категория икәнлеген һәм аларның мәңгелек булмаганлыгын исбат итте»...

Кеше түгел икәнсең син! Кая чабасың? Син, юньле булсаң, бу аудиториядә кулсызлар, аяксызлар, күзсезләр һәм, һич югында, авылдан килгән өч-дүрт малай утыруын исәпкә алырга тиеш идең. Син үзең, бәлки, фәнни кешеләр семьясында туып, шулар арасында гомер кичерәсеңдер...

Беткән көе бетсен дигәндәй, күпертмә җилкәле кеше кесәсеннән тартма белән яхшы папирос чыгарды. Рушад алгы рәттә утыра иде

(хәер, авыл малайларының барысы да алгы рәттә иде), папирос тартмасының язуын укып алды: «Краснооктябрьские». Нүжәли аудиториядә үк кабыза бу моны? Бу бит дөньяда булган бөтен кешене мәсхәрә итү, санга сукмау дигән сүз. Рушадлар укыган училищеда кесәдән тәмәке вагы табылган өчен генә дә укудан куалар иде.

— Хуш... «Совет дәүләтенең һәм хокукының нигезләре» дигән программаның төп предметы һәм максаты (папиросын чыгарып йомшартты, тартмасына «шык-шык» бәреп какты, авызына кыстырды) мең тугыз йөз унҗиденче елның ноябрендә булган Бөек Октябрь социалистик революциясеннән башлап, ягъни дөньяда беренче социалистик дәүләт аппараты төзелгәннән башлап (папиросын кабызды — имансыз ук икән!) бүгенге көнгә кадәр булган дәүләт һәм хокук үсеше юлларын күзәтеп чыгудан тора.

Бүлмәгә сыек төтен таралды. Рушад авызын ачты да катты да калды. Менә икән ул шәһәр тормышы! Менә сиңа югары уку йорты! Тукта, кемдер әйткән иде, югары уку йортында лекцияне язсаң ярый, язмасаң ярый дип. Хәтта: лекциягә йөрсәң ярый, йөрмәсәң ярый. Ә күпертмә җилкә папиросын авыз кырыена гына кыстырып куйган да һаман атлый. Чыгыр-чыгыр. Чыгыр-чыгыр. Папиросын ул юри генә тарта, төтенен бөтенләй йотмый икән, хәйләкәр! Эффект өчен бу. Рушадка күрсәтер өчен бу: янәсе, менә син монда авылдан килгән башың белән фән өйрәнмәкче булып утырасың, ә менә без болай итәбез, безнең исебез дә китми, озын папирос капкан көе дә синең эше мокытларга белем бирәбез... Рушад дәфтәренә күз төшерде: бер сәгать чамасы барган лекциядән аның дәфтәренә унбиш-егерме сүз эләккән иде. «Фридрих Энгельс... 1844 елда... Семьяның... килеп чыгуы... ыруглык... борынгылык... ыруг, Энгельс...»

Һәр лекциясендә бер дә ялгыштырмыйча икешәр папиросны шыкшык итеп кагып, авыз кырыена кыстырып, студентларга бөтенләй карамыйча озын җөмләләр белән сөйләп, бу аристократ ай буе җанны каһәрләде. Аның өчен әллә син бар, әллә юк... Кара син бер күтәрелеп, әйт син бер җылы сүз, һич булмаса — бер ачулан син, эчендә җаның булса! Менә мин язмыйча утырам. Әнә бер кыз калын гына түшләрен өстәлгә терәгән дә башын иеп йокыга талган. Әнә бер фронтовик язарга өлгермәгән аркасында бөтенләй читкә карап сүгенеп мыгырданып утыра. Ник шуларга бер генә төгең селкенми?

Ләкин тормышта бер әйбер дә мәңгелек түгел икән. Бу бертөрлелек тә бер көнне чәлпәрәмә килде.

Физика факультетының өченче курсында Рушадның дус егете — училищеда бергә йөргән Гата укый иде. Гата квартирда тора, һәм Рушад белән алар университет коридорында атнага бер тапкыр, узышлый-барышлый гына, хәл-әхвәл сорашкалап алалар иде. Гата, гомумән, шәп егет. Гармунчы. Пөрәкле. Син уйлап торганчы, ул инде эшләп бетергән була. Гата поездда билет белән йөрми. Тотылмый да. Киноги да буш керә ала. Шәһәрдә йөрү аның өчен колхоз авеслегендә йөрү белән бер. Гатаның тамак та тук була. Кулы рәсемгә оста, ахрысы, ул иппи талоннарының да рәвешен китерә ала бугай.

...Гадәти кышкы иртәләрнең берсе иде. Иртәнге сигездә коридорлар бушап калды, аудиторияләрдә лекцияләр башланды. Юрист та (ә аның лекциясе һәр көнне иртән беренче) кеше язып бетерә алмаслык берничә җөмләсен сузып салгач, тыныч кына папиросын «шык-шык» итеп бәргәли башлаган гына иде... Чү! Кинәт кенә университет коридорында тальян тавышы ишетелде. Бу тавыш беренче башлап Рушад колагына килеп керде. Чөнки — коридорда янгыраган көй төп-төгәл «Мәрәле көе» иде. Рушад бер мәлгә тынсыз калды. Бетте баш, калды муен утырып! Ә гармун тавышы бик сизелерлек рәвештә бер дә ялгышмыйча

Рушадлар аудиториясенә таба якыная иде. Тавышны инде башкалар да ишеттеләр. Ул арада коридорда шау иткән җыр яңгырады:

Ай, без эчмибезме балны,
Ай, без сөймибезме ярны...

Коридорда ниндидер ыгы-зыгы башланды. Швейцар картның гырылдык тавышы ишетелде. Рушадның күз аллары карангыланды. Бу — һичшиксез, Гата иде. Тормышта мондый номерны бары тик Гата гына эшли ала. Бу — университет тарихында күрелмәгән хәл. Ихтимал, тальян тавышының монда беренче ишетелүедер. Америка этнографы Льюис Генри Морганның «Америка туземецларының йортлары һәм йорт тормышлары» дигән хезмәтенә озын-озын җөмләләр белән бәя биреп яткан юристның бу уңай белән ай ярым эчендә беренче мәртәбә чырае үзгәрде. Көтелмәгән бу хәлдән ул да югалып калды булса кирәк...

Болар барысы да, әлбәттә, берничә секунд эчендә бөтен кешене әсәртте һәм кеше аңына килгәнче аудиториянең биек ак ишеге дырк итеп кинәт ачылды да аннан Гата күренде. Дөресрәге, башта аудиториягә Гатаның актык хутына хәтле сузылган кызыл эчле тальяны керде. Гата үзе ишектән шактый газап белән кысыла-кысыла керде, чөнки аның җиңенә швейцар карт ябышкан һәм аны артка өстери иде. Гата ничек итсә итте, аудиториягә бәреп керде дә өзелеп калган җырын шактый матур тавышы белән җырлап бетерде:

Без сөябез шунд-дый ярный
Безд-дә күң-геле барный...

Рушад комачтай кызарды. Гата күзләре белән аудиториядән аны эзли иде. Харап кына булдык... Кулмәк изүен чишеп җибәргән, кып-кызыл янган Гата ул арада гармунын сузып:

— Һә-лә-лә-ләүүү! — дип сөрән салды.

Аудитория гөр килеп көлде. Юрист исә марш атлап йөргән жиреннән бер аягын басып, икенчесен атларга күтәргән көе каткан һәм телсез калган иде.

Кинәт Гата алгы рәттә посып утырган Рушадны күреп алды.

— Һу-у-у,— дип гөрләде Гата,— земеля! Ташла лекцияңне, әйдә! Мин повестка алдым. Абыең хәзер фронтовик! Бер сәгатьтән шалон китә, әйдә!

Швейцар карт шулай да Гатаны өстерәп ишектән чыгарды. Һәрхәлдә, азаплана торгач, Гатаны гармуны-ние белән ишеккә сыйдырды, ука лампаслы чалбары, көрәк кадәр сакалы, дәү итекләре белән буталып әле ишек арасында шактый көрәшеп маташты.

Рушад сүзсез генә урыныннан торып басты.

Юрист та жиңел сулап куйды. Ул күз карашы белән генә ымлап Рушадка чыгып китәргә рөхсәт итте. Колаклары ут янган Рушад дәфтәрләрен җыеп, башын аска иеп кенә чыгып китте. Үзенең бу аудиториягә икенче тапкыр нинди йөз белән киләсен күз алдына да китерә алмый иде ул. Коридорда исә жилкәсеннән эләктереп, этелеп барган Гата, гармунын бер дә кызганмыйча үкертеп, җырлый бирә иде:

Без алай да итмәгән,
Без болай да итмәгән.
Ничу кешедән куркырга,
Урлап Себер китмәгән...

...Хәрби эшелонны озатып тулай торакка кайтканда, вахтер хатын Рушадка бер кәгазь тоттырды. Военкоматтан килгән бу кәгазьдә беренче курс студенты Рушад Сулимовка кружка, кашык һәм бер көнлек ризык белән иртәнге сигезгә военкоматка килергә кушылган иде.

Гата артыннан чыгып киткәннән соң, ул инде аудиторияне дә, кү-

пертмә җилкәле укытучыны да башкача күрә алмады. Кронштадттагы кыска сроклы өйрәтү отрядына килеп кергәндә Рушадка унсигез яшь тулып ике ай гына киткән иде.

Шуннан бөтенләй икенче тормыш башланды. Тарих ашыкты, гомернең көннәре, айлары ашыктылар, кырык бишенче елның тугызынчы апрелендә тәмамланган мәшһүр Кенигсберг операциясенә кадәр көннәр йөгерделәр. Рушад шул йөгергән көннәр эчендә олы кешегә әйләнде, тәмәке тартырга өйрәнде, йөзләгән кешегә үлем алып килгән торпедаларны күрде. Үлем белән генә әллә ничә тапкыр йөзгә-йөз очрашты. Фашистларның терәк форты булган Пилаваның штаб йортында булды, дингезчеләр белән бергә китап шкафларындагы «Майн кампф»ның төрле басмаларын актарып туалетка ташлап йөрде. Ул әле шушы вакыт эчендә үзенең нәрсәләр күргәнен башына сыйдыра алмый иде һәм аңа монарчы булган тормыш — лекцияләр, Гаталар, базардагы отышлы уеннар — барысы да төштә күреп үткән истәлекләр булып кына тоелалар иде. Чын тормыш менә шундый икән. Менә фашистларның дистәләрчә чакрым озынлыктагы җимерек заводлары. Менә әллә ничә дистә чакрымнарга җәелгән хәрабәләр. Монда берәр исән йорт бармы? Менә урам почмаклары. Таш стеналарда кара буяу белән затлы итеп язылган исемнәр: Фридрихштрассе, Адольфштрассе... Бомбалар белән актарылган яр буенда, рейдта урталай өзелгән доклар, мәтәлеп чумган дингез краннары... Сугышны мондый булыр дип кем уйлаган? Егерме яшьлек егеткә боларны ничек аңларга? Ихтимал, боларны, теге еракта калган тормышка янадан әйләнеп кайтылса, хәтерне чигереп уйларга кирәк булыр. Шунсыз аңлап булмас...

Озакка сузылган салкын, буранлы көннәрдә, мич буендагы агач караватта болар турында уйланырга вакыт бар иде. Һәм баштан үткән хәлләр бер-бер артлы яңадан җанландылар. Газаплы, саташулы төннәр берсен-берсе алыштырдылар. Бер уй Рушадның миенә өзлексез тукып торды: яшьлек тегендә калган. Ул картайган. Яшьли картайган...

Ул караватыннан торды. Ни радио, ни термометр юк. Барыр урын да юк. Нииндидер авырлык, бушлык. Мәгънәсезлек. Моны чәченә ак кергән укытучы әнисе дә аңлый һәм дәшмичә генә улы белән бергә кичерә иде. Рушад иренеп кенә шинель төймәләрен чистартты. Бу эш аны беразга гына яшьләгенә кире кайтарды. Кайда сез, дуслар? Сез ничек яшисез, үткен телле, хәр күңелле матрослар? Сездән башка дөньяда бер кызык та юк икән бит. Сезнең белән бергә тарткан тәмәке кадәр тәмле тәмәке дөньяда бар микән? Сезнең белән бергә кубрикләрдагы асылмалы койкаларда ятканда сөйләшкән сүзләр кадәр йөрәккә якын сүзләр бар микән? Ничек алай булды соң әле? Без бит буш минут булган саен «гражданка»га, «тыныч тормыш»ка кайту турында сөйләшә, хыяллана идек. Менә мине сездән алда азат иттеләр. Укытучылар техникумын бетергәнем өчен. Илдә укытучы кадрлар житми, диделәр. Министрның махсус приказы чыккан көнне мин бик шатланган идем. Ә хәзер? Бушлык, бушлык...

Кичен ул кибетче Каюм янында уздырды. Тар кибетнең миче эссе итеп ягылган, Каюм агач аягын ишеккә таба сузып прилавка өстенә кырын яткан, тәмләп тәмәке суыра иде. Кибеттә әллә ни товар күренми — чүлмәкләр, янавычлар, күсе тәбеләре һәм балта саплары гына иде. Ләкин Каюмның һәрвакыт «фронтовик дуслар өчен генә» берәр сюрпризы була. Элек кергәндә бик тәмле селедка ашаганнар иде. Бусында да Каюм мәгънәле итеп елмайды, немецта эшләнгән агач тышлы фляганы мич артыннан гына тартып чыгарды һәм стакан алды... Монда ял итеп була, монда сөйләшеп була иде. Каюм бик яшьли сугышка эләгеп Сталинград янында аягын югалтып кайтты. Рушадның авылга кайтканнан бирле рәхәтләнеп сөйләшкән, кышкы озын кичләрне бергәләп уздырган бердәнбер кешесе шул иде.

Алар жылы кибетне биклэп кайтырга чыкканда төнге сәгать унберләр булган, утлар сүнгән иде. Буран басылган, һава бераз гына жылынып киткән. Мондый кинәт үзгәрештән саташып калган этәчләр кычкыралар иде. Озак салкыннардан җәфа чиккән карачкыл авыл тирән йокыга талган, бөтен кешесе, терлек-туары, кош-корты белән бергә, әйтерсең лә йортлар, агачлар, морҗа башлары, кар күмгән абзарлар тигез итеп сулыйлар иде.

Рушадның кәефе күтәрелде. Иртәгә ул эшкә чыгып китә ала иде. Әлек этисе белән энисе эшләгән мәктәпкә барачагын уйлап яту ана рәхәтлек бирде. Юрган астына кергәч, ул тиз генә ниндидер татлы бушлыкка таба очты. Ләкин, гадәттәгечә, тынычсыз йоклады. Кайдадыр дөп-дөп итеп двигательләр эшли. Колак пәрдәләренә ритмлы рәвештә сугып торган тигез, тонык тавыш. Әһә, ул су төбендә басып тора икән. Нигә соң бу су авызга керми? Тик суларга гына авыр. Су чайкала. Аның әйләнә-тирәсендә, баш өстендә әллә ничә метр калынлыгында яшькелт су массасы. Ул тирбәнгән саен Рушадны селкетә. Тукта, каршыга кемдер килә. Ул да су эченнән. Авыр атлый. Туктады. Әллә нинди тонык тавыш белән дәшә:

— Улым, ни хәл? — ди.

— Эти! Бу — синме? Мин синнән куркам.— Рушад кычкырмакчы булды, ләкин кычкыра алмады.

— Эти, эти, кирәкми, килмә! Син бит үле! Син инде юк бит...

Чайкалып торган гәүдә карлыккан тавыш белән дәште:

— Син кайларда йөрдең, улым, күренмәдең?

— Мин дә сугышта булдым. Мин ниләр генә күрмәдем, эти! Мин фашист Кохның резиденциясен күрдем. Безнең корабль фашист минасына эләкте. Без баттык. Круглар белән котылдык... Җиңү көнен мин Кенигсбергта каршыладым.

— Нинди җиңү ул, улым? Нишләп безгә аны әйтмәделәр?

Юк, бу кеше аның этисе түгел... Ул булса бер генә сүз белән әнисен сорар иде. Сорамый. Рушад тагын кычкырырга тотынды. Карачкыл гәүдә тагын чайкалды.

— Мин сиңа малай вакытыңда флотский күлмәк алып бирергә вәгъдә иткән идем, улым. Шуны үти алмадым. Вәгъдәмне үтәмәдем, үпкәләмә...

— Эти, мин аны үскәч кидем. Әле дә өстемдә менә шул.

— Ә әниең исәнме? Картайдымы? Син аны саклый күр! Мин теге якта үлдем. Минем кешелек намусым пакь. Мин булмагач, сиңа авырмы, Рушад?

Ах! Бу чыннан да этисе икән! Әнә су чайкалды, күләгә юкка чыга башлады. Эти, тукта! Тукта-а-а-а...

— А-а-а-а!

...Салкын тиргә баткан Рушадны әнисе кулыннан тотып селкетеп уятты. Өйдә инде ут алынган, Рушадның яшел капчыгына кирәк-яраклар тутырылган, мич алдында самовар кайный, керосинка өстендә чыжылдап нәрсәдер пешә иде...

## II

Алдагы көндә сине ниләр көткәнен бервакытта да анык белә алмыйсың... Бу авылда нинди кешеләр яши? Тәҗрибәсез, фронтовик егетне ниләр көтә? Ул авыл әле күренми. Ул авыл, янына килеп житкәч, калкулыктан кинәт күренергә тиеш. Ә хәзергә әле урман буендагы юлдан атла да атла.

Әнә кар диңгезенең күк белән тоташкан урыныннан тәгәрәп кенә кызгылт-сары кояш чыгып килә. Кояш жир йөзенә һәр көн үзенчә чыга. Ул үзенең төсләрен кабатларга яратмый. Бүген ул каты бураннардан

сон беренче мәртәбә күренә. Шуна, ахрысы, ул йончыган, арган кыяфәттә. Иртәнге салкынча жил иренеп кенә басу өстеннән кар сыпырып йөртә. Ул — кояш чыгуны тереклек дөньясына хәбәр итә. Кар дәрьясы өстендәге салкынча тыгыз һава аркылы узган кояш нурлары зәгыйфь, саргылт төскә кергәннәр. Кояш тирәсендә ниндидер бакыр божра. Ул божра офыктагы аксыл томанга асып куелган кебек...

Иртәнге жил кар өстендә имән яфракларын шудыртып йөртә. Имән яфраклары быел да коелып бетмәгәннәр икән. Халыкта: агач яфрагы коелып бетмәсә, ел авыр килә дигән бер сынамыш бар. Тагын нинди авырлык инде халыкка, сугыш беткәч? Хәер, ел авыр, бик авыр... Тик, хәзер инде үлем, кан кою юк. Ачлык та жиңелә бара. Шулай да әле авыр. Ике жәпле жилпәзәсенә ябышып өрәңге орлыклары очып йөри. Аэрочана кебек. Иртәнге жил аларны урман эченнән кырга алып чыккан. Орлыклар табигатьнең шул көченә бирелгәннәр дә шуалар да шуалар! Бичаралар! Сезнең барыгызга да зифа буйлы өрәңге булып үсеп утыру насыйп булмас. Жил сезне кырга алып чыгып китәр. Аннан бер үзәнгә хәтле сезне шудырып алып барыр. Сезне кар күмәр. Яз житкәч, ташу суы агызып китәр сезне. Агарсыз-агарсыз да бер жирдә ләмгә утырып черерсез. Ә ана — өрәңге — тагын да балалар чыгарыр — аларны тагын да очарга әзерләр. Иртәрәк өлгереп урман туфрагына төшкәннәре генә алдагы елда шытып чыгар. Хәер, бер сез генә түгел. Минә Рушад та кара шинелен жилгә жибәргән дә, казна капчыгын аркасына асып, кар диңгезе өстеннән жил белән бергә атлый. Ул да сезнең шикелле ләмгә батып черү өчен түгелме? Алда нилэр бар, нилэр бар?..

Каеннарның бозланып каткан ботаклары жилдә сызгырып утыралар. Аларның очлары күгәрчен тамагы төсенә кергән. Кызгылт-шәмәхә бозлы бөреләр. Каен — жиңел акыллы агач — ул инде кояшны күргәч яз килде дип уйлый. Әнә шуңа күрә бозлы ботаклар иртәнге кояш нурларына коенып, яз жырын көйлиләр.

Быел миләш сабагында калган. Ап-ак дөньяда, нәзек чыбык очларында күзеңнең явын алырлык миләш сабаклары. Күрәсең, каргалар миләш ашый торган атналарда я көчле салкыннар, я бураннар булган. Югыйсә, октябрь ахырларындагы бер атнада карга халкы урмандагы, бакчадагы миләшне бер-ике көн эчендә юк итә иде. Миләшләр бозга каткан кызыл тәлгәшләре белән иелми-бөгелми тын гына торалар. Аларга жилгә баш иярга ярамый. Югыйсә, көздән бирле саклаган матурлыгың, байлыгың коелып әрәм булыр...

Карт имәннәр салмак кына шаулыйлар. Жил имән очларына кагыла, ахрысы. Имән — тарихчы ул. Имән — урманның тарих укытучысы. Юкә, каен, миләш — алар жыр, әдәбият, рәсем укытучылары. Өрәңге кем? Белмәссең. Ихтимал, ул — физиктыр. Каты, конкрет. Бәлки — математик? Төгәл, эмоцияләр белән исәпләшми. Әнә шуңа күрә аның орлыгы кыш көне оча. Яңасе, аның үз вакыты бар. Ә кышкы суык рәхимсез — синең орлыкларың өшер. Имән — тарихчы, монысы бәхәссез. Әнә карт имәннәр тирә-юньне шаулатып нидер сөйлиләр. Сөйләгез, агачлар, сөйләгез! Бу якның халкы газаплы сугыш елларында нилэр күрде? Халыкның аһ-зарлары кайларга сеңде? Сезнең төпләрегездә өелеп яткан чикләвекләрегезне кемнәр жыйды? Кемнәр рәхимсез кышкы көннәрдә имән чикләвегенең күмәчен ашап ач үлемне жиңделәр? Хәер, сез сугыш вакытын гына түгел, революция елларын да сөйли алыр идегез. Сез, бәлки, мең сигез йөз алтмыш беренче елгы реформа вакытында ук инде шулай шаулап утыргансыздыр? Әлбәттә, ул вакытта сез яшь булгансыз... Ләкин кешедә яшьлек бик кыска гомерле була. Аны югалтуы да бик тиз икән. Сөйләгез...

Офык чистарды, имәннәр әллә нинди шом белән, әллә нинди ныклык, куәт белән, тигез хор булып шауладылар. Бу тавыш кешене

шагыйрь, философ, композитор итәргә мөмкин. Шаулагыз, имәннәр, тыныч тормышның беренче кышына мәдхия җырлагыз! Бу — бик зарыгып, интизар булып көтеп алган тынычлык шавы...

Урманга кереп-чыгып йөргән куян, төлке, бүре эзләре күбәйде. Бүре эзен эт эзеннән аеруы кыен түгел. Чын булса — бүренең аягында алты бармак, этнекендә биш бармак, диләр. Урман эченә таба кечкенә казыклар белән карга кадалган бер шнур кереп киткән. Шнурдагы кызыл чүпрәкләр карда җилфердәп яталар. Димәк, аучылар берәр бүрене эзәрлеклиләр. Хәзер шулай булыр. Сугыш вакытында бераз артыграк үрчеп киткәнсез түгелме соң сез, соры койрыклар? Димәк, бүген берегез чолганышта... Ә чолганыш начар нәрсә ул. Менә Рушад абыегыз япь-яшь көенчә Таллин чолганышына эләкте. Ярда — фашист, диңгездә — фашист. Озак яттылар. Корабның экипажы ачыкты — тәүлегенә йөз грамм ипи. Шуны өч тапкыр ашарга кирәк. Көннәр бер-берсенә охшаган, соры, томанлы, ач... Вахтада торырга кирәк. Корабның режимы кырыс. Карт мичман бар иде. Көндез сәгать унберләрдә тамак ачканга чыдый алмыйча бик күп малайлар бөгелеп төшәләр, сүгенәләр, бер-берсенә авыр сүз әйтә башлыйлар. Карт мичман нәкъ шул вакытта кубрикка керә, утыра һәм янчыгын чыгарып тәмәке төрә. Юан итеп төрә. Аннан барысы да төрәләр. Чыгып тәмәке тарталар. Мичман әйтә: шушы төтен үпкә юлларына керә, ди. Анда кан тамырларының башы каннан азык көтеп сулык-сулык итеп торалар, имеш. Ашказанының стеналарында да, имеш, шул хәл. Менә шул азык көткән тамырларга бервакыт нәрсәдер килә. Бу — никотин. Никотинны кабул иткән тамырлар бераздан исерешәләр һәм ашказаны инде борчылмый... Зарарлымы? Юк, чолганыштан чыккач барысына да компенсация ясыйбыз. Матрос паегын беләсез — во! Тик чолганыштан гына бәреп чыгарга иде...

Ә син, туган, соры койрыгыңны кысып кругта әйләнеп йөр инде. Билләһи, мин сине азат итәр идем. Чөнки кеше өчен иң зарарлысы — ике аяклы бүреләр... Әнә аларны Нюрнбергта судка тарттылар. Суд бара. Ә син табигатьнең бер мәхлугы — тугансың икән — яшәргә кирәк иде. Син бер-ике айдан кара борынлы, җылы мехлы, җелтер күзле бала табар идең, аларны агач астындагы тирән оянда имезер идең, уйнатыр идең. Ә хәзер синең эш — капут.

Рушад кесәсеннән пәке чыгарып, шнурны өзде дә, очларын аерып, агачлар арасына ташлады.

Күккә ашкан туп-туры төтеннәре белән Акбалык авылы күренде. Авыл, рәхимле бул! Синең урамыңа җиде ят килеп керде. Ул синнән сыену урыны, якты чырай өмет итә. Бу кара шинель астындагы йөрәк өмет белән тибә. Бәлки бу егет синең үзеңнеке булып китәр... Бәлки аны монда берәр сылу кыз үзенеке итәр. Бәлки монда аны гыйшкы көтә торгандыр... Гыйшык? Анысы нәрсә тагын? Ул — егет кешегә унҗидеунсигез яшьләрдә килә торган гаҗәп татлы, газаплы бер хис, дип әйтәләр... Хәер, Рушад әле аны белми. Чөнки сугыш тормышның хронологиясен җимерде, заманнар бәйләнешен бутады...

Мәктәпнең җылы коридоры. Тезелеп киткән класс бүлмәләре. Бишенче, алтынчы, җиденче, сигезенче «а», «б», тугызынчы «а», «б», «в». Шактый! Укытучылар да күптер. Менә унынчылар. Ике класс. Класс саен балалар тавышы. Кычкырып-кычкырып сөйлиләр. Кызларныкыннан аерып булмаслык малайлар тавышы.

«Хоккайдо утравының көньяк өлешендә субтропик климат. Анда муссон җилләре исә...»

Күрәсең, география дәресе. Икенче бер класстан шулай ук малайлар тавышы ишетелә. «Безнең кораб Африка ярлары буенда тора иде. Шул вакыт капитанның «коенырга» дигән командасы ишетелде». Ах, ничек матур! Җылы диңгездә җилкәнле кораб чайкалып тора. Җилкәннәрен җыйган. Матрослар җылы дулкыннарга сикерешеп төшәләр дә колач

салып йөзәләр. Ах, тормышта да шулай булса... Рушад та йөзде. Бушлат, күн итек кигән көе Балтик диңгезенең бозлы, кургаштай кара суына палубадан тау кадәр дулкын бәреп төшерде. Корабның борынын мина җимереп ташлаганда, егермеләп матрос гигант су тавы астында калдылар. Нибары җидесе коткарылды.

Диңгез — рәхимсез. Диңгез — ярдан карап торырга яхшы. Ә яр — диңгездән караганда тагын да яхшырак.

Алтынчы класс. Ишекләре ярым ачык. Яңгыравыклы тавыш белән бер кыз тел гыйлемен исбатлый:

— Хәл фигыльнең ясалышы: агач-әгәч; гач-гәч; кач-кәч,— дип аңлата. Әйбәт сөйли.

Тугызынчы «б» классы. Монда нәрсә? Чырык-чырык көләләр. Класс гөж килә. Хәрби хәзерлек икән. Әйбәт! Җылы класста, кызлар белән бергә, көлешә-көлешә... Военрукның юаш тавышы ишетелә. Ул шалтшолт винтовка агачына бәрә, затвор чыңгырдый. «Винтовканың төп чәсләре: винт уч (винт оси!), винт тупор (винт упора) дип сөйли...

Директор Сабир Ишмуратович дигән кеше икән. Рушад белән ул ике куллап күреште. Бер-берсенә сынаулы караш ташлап, дүрт-биш секунд тын тордылар.

Утырыштылар. Тагын сынаулы тынлык. Рушад кесәсеннән приказны чыгарып бирде. Приказны укыган арада Рушад директорның тышкы кыяфәтен өйрәнде. Йомры гына баш. Сирәкләнә башлаган, анда-санда ак йөгергән шома чәч. Сарык йонынннан бәйләнгән ак свитер өстеннән пөхтә генә пиджак киеп куйган. Түш кесәсеннән очлаган кызыл һәм гади ике карандашы белән озын гына баш тарагы чыгып тора. Сугыш вакытындагы тырыш хезмәт өчен медаленең колодкасы тагылган. Күзләре нигәдер майланып уйнап тора. Директорга кырык биш яшьләр булыр...

— Син элек бу мәктәптә укыткан Сулимовның берәр кешесе түгелме?

— Улы. Таныш идегезме әллә? (Рушад моныcын юри сорады.)

— Юк, ишетеп кенә беләм. Мин монда кырык беренчедән бирле.

Тынлык. Директорның җылы бүлмәсендә тек-тек итеп герле сәгать йөри. Гере — чыршы күркәсе төсле итеп эшләнгән. Тек-тек, тек-тек. Сигез тапкыр тек-тек иткәч, сәгать теле ике тапкыр шыгырдап елап ала. Почмакта — зур тәпән белән фикус гөле. Директор бер кәгазьгә нәрсәдер язды.

— Менә,— диде ул, кәгазь сузып.— Завхозга бирерсең. Хезмәт хакы ала башлаганчы ашарыңа кирәк булыр. Безнең тәҗрибә участогыннан кергән доходыбыз бар. Шуннан бер пот бәрәңге, алты кило он яздым. Заһир абыең шунда, укытучылар бүлмәсендә, подшивкалар актарып утыра — синең шикелле бер матрос бар әле миндә, завхоз булып эшли. Фатир ягын да ул карар.

Болай булса эш көйле. Ашау-эчү хәл ителә. Фатиры, шәт, анысы да булыр. Укытучы кирткән кешегә дүрт кубометр утын бирәләр ич! Ләкин ни шәбе — Заһир абыең ди бит! Матрос... Леонид Соболев ничек ди? Бер матрос — матрос, ике матрос — рота.

— Аракы эчәсеңме? Сезнең братны бик мактамый халык. Ул ягын кара. Ничек бик яшьли элэктең соң сугышка? Ә хатын-кыз ягы ничек? Тол хатыннар авылда — завались. Смотри. Коллектив зур. Андый эшләр ярамас, пнимаетели...

«Укыта беләсеңме? дип ник сорамыйсың!»

— Менә болай итик без алайса: бу атнага инде расписание төзелгән. Предметниклар житми, расписание атна саен төзибез. Буталып бетәбез. Килгән кеше тормый — шәһәрнекеләр качалар. Бу атнада син...

Директорга сүзен тәмамларга мөмкинлек булмады. «Дырк» итеп ишек ачылды да чаңгылар, таяклар күтәргән, җылы сырма, бумази

чалбар кигән юантык кына бер яшь хатын бәреп керде. Хатынның күзләре урынынннан купкан иде, сүз башлаганчы шулай да ул Рушадка сөзеп бер карап алды. Директор «ык» дип тә әйтергә өлгермәде — юантык хатын төкерек чәчеп тавыш чыгарды.

— Бу завычыңны тыясыңмы, юкмы, Сабир абый! Билләһи, иртәгә ук РОНОга барам жалу белән, билләһи, барам...

Директор бераз гына уңайсызлангандай итте:

— Туктале, Мәсрүрә, тотасың да бәреп керәсең, пнимаетели, күреп торасың кабинетта кеше барын...

Ләкин Мәсрүрә сүз тыңлаудан узган иде.

— Или мин шул завычны эшеннән кудыртам, или мин үзем китәм дә бөтен мәктәпнең астын-өскә китерәм. Икмәктер менә, кояштыр газим...

Директор каушый калды.

— Соң, я, нәрсә булды, пнимаетели?

— Нәрсә булсын: тугызынчы класс малайлары, пискультурадан кайткач, чаңгыларын моржа артына куйганнар. Завыч шул класста укытып ята, чаңгыдан кар эреп моржаны җебетә. Дәрес вакыты дип тормадым, малайларның чаңгыларын чыгарып аттым. Завыч, әдәм көлкесе, үзенә күрә түгел, артымнан чыгып сүгәргә маташа. Дәрес бозарга ни хакың бар, ди. Эшлисең килсә эшлә, эшләмисең икән — как хоти, ди.

Шул урында Мәсрүрә елап җибәрде.

— Как хотиләп сүгәргә ни хакы бар аның, ә? Нишләп мине андый сүз белән мәсхәрә итә ул, ә? Тол хатын дигәч тә... Ирем сугышта үлмәгән булса, мин дә болай кеше артын чистартып йөрмәс иде-е-е-м. Уһһу-һу-һу-у...

Директор ык-мык итте, тик авыз тутырып бер сүз дә әйтә алмады. Ул арада Мәсрүрә дә кинәт кенә елаудан туктады. Дәрте битенә бәреп чыккан бу яшь хатын эт кояшыдай ялт итеп кинәт кенә көләчләнде. Алъяпкыч итәге белән күзләрен, битләрен сөрткәләгән арада Рушадка мут кына итеп тагын бер карап алды. Директор да телгә килде.

— Я, я, бар, Мәсрүрә, бар... Моңарчы әйбәт эшләвеңне беләмен, юкбарга тавыш чыгарма. Аннан... беләсеңме нәрсә! Син инде, фчуҗтәки, әзрәк үзеңне тота бел. Директор, пнимаетели, яңа бер иптәш белән сөйләшеп утыра, ә син бәрәсең дә керәсең... Ярамый ул алай, Мәсрүрә...

Директор никадәр генә каты итеп ачуланырга тырышса да, булдыра алмады. Хатын чыланган керфекләре астыннан гына мут елмаеп, чаңгыларны күтәрде дә чыгып та китте.

Әмма директор өзелгән җепне тиз ялгады — Мәсрүрә бу кабинетта андый концертлар белән еш чыгыш ясый, күрәсең.

— Бу атнада син дәресләргә йөрерсең. Кер математикага — бик тәҗрибәле укытучы, өйрән. Хәрби хәзерлекне карап чык, анысын инде шушы авылның Хәкимҗан алып бара, сугышка киткәнче прицепщик булган, бармакларын өздереп кайтты да — нишлисең... Сүзсез, тыңлаулы егет. Кер, пнимаетели, биологиягә. Бераз тегеләйрәк кешесе (директор имән бармагы белән чигәдән өстәрәк башына тукып күрсәтте), но, как специалист — көчле. Тәҗрибә участогында чүт кенә виноград үстерми. Аннан соң... Кер рус теленә, шәһәрдән килгән һәйбәт бер кыз укыта, университет бетергән. Во! Тик борыны гына югары. Белеме белән масая. Чөнки — югары белемле кеше бөтен коллективта өч-дүрт кеше — әҗәл даруы урынына. И аннан соң... Кыскасы, өйрәнә тор, дүшәмбедән сиңа сәгатьләр. Егерме ике сәгать булыр. Ничава... Акчасы күп була аның. Тик синең белем. Урта гына? Университетның ике ае? Аннан сугыш? Соңгы икесе сиңа акча өстәмәс шул. Тарификациягә син урта белемле булып керәсең. Тәк...

Директор, чалт-чолт китереп чут төймәсен сала-сала, Рушадның айлык хезмәт хакын исәпләп бирде.

Беренче көн шулай башланды.

Завхоз Заһир кичке якта Рушадны су буендагы Галиәхмәт картларга китереп квартирага урнаштырды. Чукрак Галиәхмәт карт белән аның жор күңелле карчыгы Гайнелвафа квартирант егетне самовар куеп көтеп торалар иде...

Тыныч хезмәт — «гражданка»ның беренче көне — дингезгә бәйле бөтен тормышны, бөтен истәлекләрне пәрдәнең теге ягында калдырды.

III

Адәм баласы ниләр күрми...

Әле кайчан гына Кенигсберг диңгез крепостеның хәрабәләре, исән калган сарайларның эчендәге гүзәллек, кешесез калган бишәр чакрымлы урамнар һәм кара болыт кебек матрослар белән тулган порт күренешләре әледән-әле күз алдында чиратлашып торалар иде. Куәтле крейсерларның мазут исе бәреп салмак кына гүелдәп утырган дизельләре, ак киндер чалбар кигән матросларның складтан кәрзин белән бәрәңге ташулары... Үрдәк бәбкәләре кебек тезеләләр дә ике кулына ике кәрзиннең колагын тотып сафка басалар. Бу тоташ саф траплардан корабка керә, ул сафның бер башы әле яр буендагы складта, икенче башы инде палубадан бара. Кичен кино, ял көннәрендә — офицерлар йортында биюләр, ак шарлы бильярд өстәле...

Хәер, кичәге көннән башлап боларны ниндидер томан, пәрдә каплады. Хәзер менә йокыдан торырга иде. Кыска агач сәкедә бөгәрләнеп ятып аяклар сызлый башлаган. Торырга, физзарядка ясарга иде. Өйдә кемдер хәрәкәтләнә, кыштырдый. Күзне ачасы килми. Карт-карчык белән сөйләшеп озак утырылды — соң ятылды. Ишек янында ниндидер тавыш. Кемдер нәрсәдер ашый, озаклап чәйни. Картмы? Ни өчен ишек янында? Әһә, бозау икән. Иртә туган. Абзарга чыгарырга әле иртәрәк булыр дип сөйләнеп утырдылар. Ак сәдәф тояклы, елтыр кара тиреле акылсыз бер мәхлук. Беткәнче аңгыра. Ләкин сөйкемле. Әнә ул әнисе янына чыгарганны көтеп нәрсәдер чәйни. Нәрсәдер... Рушад урыннан сикереп торды: аның ак ефәк шарфының яртыдан мулы сәдәф тояк йоткан иде инде. Моны замполит Дроздов истәлек өчен дип үзенең чемоданыннан алып биргән иде. Диңгезче офицерлар гына муенга сала торган шарф. Ахмак бозау карусыз гына шарфны кире чыгарды. Хәер, аны суырып алырга туры килде. Зарар килмәгән кебек күренде. Шинельне монда элмәскә кирәк булыр... Юньсез хайван! Шарфка тотынганчы шинельнең итәкләрен чәйнәп караган икән. Ләкин каты калын сукноны йотарга көче житмәгән. Хәерле булсын. Бүген беренче эш көненең беренче минуты бозау бугазыннан шарф тартып алу белән башланды.

Иртән тозга ярып пешергән әмерхан бәрәңгене кара ипи белән сыптырсаң, бер-ике стакан сөтле чәй эчсәң — бу дөньяда бүтән берниләрең дә кирәкми. Көне буе күңел көр, тәндә куәт тулы була. Тик бүген дәрес башланганчы барып житеп булмады инде. Кырынып, чистарынып мәктәпкә барып кергәндә, озын тәнәфес житкән, коридорда ду килеп уйнышлар, сугышалар, укытучылар бүлмәсендә шыгрым тулы халык иде. Чыннан да коллектив зур икән. Берләнбер таныш кешесе — завхоз Заһир белән Рушад кул биреп күреште. Тегесе өстәл өстендәге подшивкаларны актарып утыра иде. Шау иткән коллектив бер мәлгә тынып калды. Хатын-кыз, бер-беренә мәгънәле караш ташлап, сүзсез генә сөйләшеп алды.

«Тарих укытучысы килә дигәннәр иде, шушымы инде?»

«Әйдә, коллективта егетләр бик кирәк иде».

«Бу егетне кайсы чукынчыгы үз тырнагына эләктерер икән?»

«Малайлык кыяфәте чыгып та бетмәгән, үзе инде сугыштан кайткан».

Укытучы хатыннарның бик күбесе диванга, урындыкларга тезелеп утырганнар, һәркем диярлек алдына тотып кына берәр телем ипи ашый иде. Бала итәкле озын күлмәк, олтанлы киез итекләр кигән бу хатыннар арасында шактый пөхтә һәм шәһәрчәгә якын киенгән ике-өч кыз бала күренә. Завуч өстәле янында барысыннан да аерым бер кыз утыра: озын аяклы, ясалган чәчле, кызыл иренле. Аягында биек үкчәле туфли. Ул ниндидер бер калын китап укый, кайбер җөмләләренең асларына сызып бара. Ирләр ишек янында тәмәке тарталар, уен-көлке сөйләшәләр.

Укыту бүлеге мөдире дигәннәре утыз яшьләр чамасындагы бер хатын-кыз икән. Рушад турысында ул инде барысын да белә иде. Үзе килеп исәнләште, Рушадны расписание янына алып килде.

— Бу ике көн эчендә сез инде теләгән дәресләрегезгә кереп мәктәп белән таныша торыгыз,— диде ул, арыган кыяфәт белән елмаеп. Елмайган вакытта аның авыз кырыйларыннан янагына нечкә генә җыерчыклар йөгерде. Картая башлауның беренче билгеләре... Үзе математик икән. Югары белемле. Димәк, директор әйткән әҗәл даруының берсе шушы.

Рушадның әнисе мәктәптә егерме биш ел чамасы укытты. Рушад кечкенәдән ишетеп үсте: әллә нинди тәҗрибәле укытучылар да, дәресләренә чит бер кеше кереп утырса, каушыйлар, ди. Инспектор да булмасын, хет берәр баланың ата-анасы гына кереп утырсын. Гомумән, дәресеңә кереп утырам дигән кешене укытучы халкы бер дә яратмый. Бер төрлесе дәрескә катыша, укучыга сораулар бирә — укытучыны тәмам эштән чыгара. Икенче бер төрлесе өзлексез язып утыра. Нәрсә яза икән, башы беткере? Тагын нинди сүзне ялгыш әйттем икән? Бер төрле инспектор, дәрестән чыккач, синең дәресеңә озаклап анализ ясап үзәгеңә үтә. Менә син фәлән сүзне әйтеп күрсәткәндә тавышың болайрак булды, алай түгел, менә болай ул, ди. Кыскасы, җаныңны каһәрли. Укытучы укытып картаймый, инспектор, завуч, директорның дәрескә керүеннән картая. Ачык дәресләр белән картая. Күпме түземлек кирәк. Рушадның әнисе Сафура апа, мәсәлән, РОНО инспекторы Хәмитов аркасында гына картаеп эштән чыкты. Бар шундый хатынша берәү. Сафура апаның өенә килеп, аның шәхси китапханәсендә ничә китап, ничә брошюра икәнлеген хисаплап йөрү дисеңме, нинди газета укый, нәрсәләр конспектлый, нинди кинофильмнар карый — шуларны төпченеп үзәгенә үтә. Дөньяда укытучыныкы кадәр берәүнең дә җанында казынмыйлар. Сора син: нәрсә ягасың, нәрсә ашыйсың? дип. Сора син, кеше булсаң, ирсез калып кеше өстендә фатирда йөрү читенме? дип... Юк, сорамый, хатынша... Имеш, дәреснең темасын тактага язганда өтерең аскарак төшерелде — бу исә укучыларда алак-шалаклык тәрбияли. Имеш, китабыңны өстәл почмагына турылап куймадың, болай гына салдың, укучылар шуннан күреп китапка саксыз мөнәсәбәткә өйрәнәләр. Имеш, Спартак восстаниесен телгә алдың, ә бүгенге көнгә бәйләп берни дә әйтмәдең... Әнә шулай итә-итә укытучыны тимер кыршау эченә тыгып бетерәләр. Әнә шуңа күрә алар бөтенесе бер төсле итеп алларына ипи телеме куйганнар да колхоз атлары төсле бөтенесе бер төрле хәрәкәт ясап, бер рәвешле күшиләр... Ничек инде, башың керсә, аягың кермәгән дигән кебек, кеше дәресендә буталып йөрергә? Ә өйрәнә, таныша торырга кирәк, бик кирәк... Әллә хәрби хезмәттән башларгамы? Монысы таныш бит! Ниндидер якынлыгы бар. Моннан таныш тормыш, яшьлек исе аңкый. Хәрби хәл — Рушадның яшьлеге.

...Кыска кара тун өстеннән каеш буып, җилкәсенә противогаз аскан Хәкимҗан расписание янына килеп Рушадны үзе үк «занятие»гә чакырды. Бу — сирәк була торган хәл. Укытучы үз дәресенә үзе кеше чакыра...

Хәкимҗанның тамак шәп. «Равняйсь!» дип кычкырган вакытта аның

кузләре нурланып китте. Ә «смирно!» командасы секундның йөздән бер өлешен алдымы-юкмы, шартлап чыкты.

— Һир-ра!

Якын-тирәдәге тал башларындагы каргалар сискәнеп очып киттеләр. Мәктәп түбәсенә чыпчык тотарга менгән мәчеләр шыбырдашып жиргә коелды.

Строй хәзерлеге өчен армиядә бу сыйфатлар бик кыйммәтле. Хәкимжаннан бик әйбәт строевик булыр иде. Булыр иде... Әгәр дә белеме булса. Хәер, аннан бик әйбәт укытучы да чыккан булыр иде... Әгәр дә укытучылык хезмәтенең кайбер үзенчәлекләрен белсә...

Агач мылтыкларын «на плечо» алган жиденче класс балалары ике рәтле колонна белән урам уртасыннан баралар. Хәкимжан киң балаклы чалбарын киез итек кунычларына көчләп тутырган, итекне егетләрчә сыдырып киезката кадәр генә калдырган, үзе строй янында кар ерып бер алга, бер артка төшә, йөгереп йөри. Кычкыргалап куя:

— Левой, левой!

— Ноги не слышу!

Строй тегермән буасындагы күпергә керер алдыннан Хәкимжан аеруча йөгеренгәләп йөрде. Димәк, дәреснең планы буенча шушы урында нинди дер бер «тактик алым» эшләнергә тиеш.

Рушад стройдан ун-унбиш адым арттарак бара иде. Күпергә керер алдыннан балалар да шатландылар. Димәк, тактик дәрес вакытында монда беренче генә килүләре түгел. Стройның яртысы инде күпергә кереп беткән иде. Хәкимжан юл читендәге бер калкулыкта башын артка ташлап ниндидер бер горурлык белән үзенең взводына карап тора иде. Кинәт кенә ул:

— Сәмәлү-ү-ү-үтт! — дип кычкырды.

Ярты секунд эчендә күпер тирәсендә бер бала калмады. Утызлап бала — малае, кызы, сәкедән коелган борчак шикелле, күпер астындагы тирән карга сикереп чумдылар. Тегермән тирәсендә тынлык урнашты.

Хәкимжан тирән канәгатьләнү белән Рушадка карады. Читен кызыл белән чиккән зур кулъяулыгын чыгарып, авыз-борынын сөртте. Тагын да зур канәгатьләнү белән:

— О-о-о-т-бой! — дип кычкырды.

Карга әвәләнгән бала-чага чыр-чу килеп күпер өстенә үрмәләде. Барысы да канәгать иде.

Тегермән янындагы таудан противогаз киеп йөгереп менделәр. Иң алда противогаз киеп чын автоматны кулына тоткан Хәкимжан үзе иде. Тауны менгәч, иксез-чиксез тигез кар басуы башлана. Строй «цепь»кә таратылды. Оборонага күчәргә кирәк иде. Киндер капчыклардан кечкенә агач көрәкләр алынды, балалар күз күреме жиргә таралып, каты карда окоп казый башладылар. Окоп алдына сузылып ятып, кар өеме аркылы агач мылтыкларын «дошман ягына» төзәделәр. Хәкимжан әле берсе, әле икенчесе янына барып, үкчәләрен яткырып йөрде. Ап-ак иркен яланда, саф һавада, тыныч күк астында, үз өеннән моржасыннан чыккан төтенне күрә-күрә, сугыш уены уйнау нинди күңелле! Рушадның да күңеле күтәрелеп китте. Юк, шәп укытучы бу Хәкимжан, юкка гына кичә директор аның турында аяныч тавыш белән әйтте.

Цепьнең иң кырыендагы бер малай, окобын казып бетергәч, бияләйләрен кар өстенә ташлаган да, чалбар төймәсен чишеп, кар өстенә фамилиясен язып маташа. Хәкимжан аны күреп алды, ерактан кычкырды:

— Жилгә каршы ярамый бит, Галәвиев!

— Нишләп, абый?

— Дөньядагы бөтен бозыклык шуннан килә инде. Киемеңә дә чәчри...

— Ярар, абый.

Шуңа күрә имза бераз түгәрәгрәк булып чыкты...

Кайтышлый колхоз фермасы янында туктадылар. «Разойдись!» дигән команда яңгырады. Һәм Хәкимҗан ферма өенә кереп китте. Бераздан ул аннан ике-өч хатын-кызны ияртеп чыкты. Ир балалар балта-көрәк алдылар. Кое янындагы бозны чаптылар. Хәкимҗан үзе, тунын салып, теге хатыннар яра алмаган бернечә түмәркәне ярып ташлады. Кызлар, йөгерә-йөгерә, кочаклап салам ташыдылар.

Аннары яңадан стройга тезелделәр. Балаларның битләре алма кабыгы төсле булып кызарган, бүрек, шәл асларыннан пар чыгып тора иде. Аерым-аерым күнегү үтәделәр: һәрберсе строй адымы белән кое сиртмәсенә честь биреп уздылар. Кайберләрен Хәкимҗан икешәр тапкыр уздырды. Галәвиев иң ахырдан Хәкимҗанның винтовкасын алып, силос башнясы очында утырган бер бәхетсез каргага винтовкадан атты. Кар өстенә соры йон очты, саф һавага шомлы коры ис — дары исе таралды. Дары исе кешегә бигрәк тә кыш көне, коры һавада, кар өстендә авыр тәэсир итә. Канаты имгәнгән карга очып китте, Хәкимҗан исә Галәвиевне орышты. Тегесе туры атуына шатланудан кызарынган, авызы актык чигенә кадәр ачылган иде.

— Ник, абый, карга бит ул, күгәрчен түгел.

— Ярамый, җан иясе ул. Һәр тере әйберне үтереп йөрү — фашистлар гадәте ул. Мин сиңа каргага атарга дип тоттырмадым аны...

Галәвиев шулай да шат иде.

Ике дәрес шулай күңелле, сизелмичә дә үтте.

Кызарып беткән, шат күңелле балалар, аякларын тигез басып, җыр җырлап урам уртасыннан кайттылар. Хәкимҗан да, чиксез зур шатлык кичергән бер кыяфәттә, элеккечә, стройның әле алдына, әле артына төшә иде. Бер җыр бетешкә ул икенчесен башларга команда бирде:

— Запевай!

Башын югары күтәргән Галәвиев, «дык-дык» басып, строй алдында бара. Җырны да шул башлый икән. Команда ишетелүгә ул ялындырып тормады, башлап җибәрде. Строй тигез тавыш белән җырны күтәреп алды.

Ордена недаром нам страна вручила,
Это знает каждый наш боец...

Җыр уртасында Хәкимҗанның көр тавышы яңгырап ала:

— Левой!

— Левой!

Строй таралгач, балалар теләр-теләмәс кенә мәктәпкә кереп киттеләр. Галәвиев исә Рушад ишетсен дип кычкырып ук әйтте:

— Их, атна буе ник воянный дело гына укытмыйлар икән...

## IV

Галиәхмәт карт — кызык кеше.

Авылда андый кешеләр күп булмый. Андый хикмәтле кешенең хатыны да бераз гына «тегеләйрәк», кызыклырак була.

Рушадның ял көне шулар белән үтте. Шимбә көн кичтән бирле планнарын карап утырды. Дүшәмбедә булачак дүрт дәреснең өчесе параллель классларда иде — нибары ике план төзеде. Бу дәрес планын төзүне кем уйлап чыгаргандыр? Һәрхәлдә, Ушинскийлар заманында плансыз гына укытканнар. Шунысы булмаса — укытучылык эшенә түзеп тә булыр иде...

Гайнелвафа карчык ял көне пәрәмәч пешерде. Аларның бер малайлары Норильскида яши, төпчек кызлары шушы авылда кияүдә иде — ялгыз калган картлар әдәпле сыман күренгән егетне квартирага төшергәч шатланыштылар. Боларда эш, вазифалар бүленеше бик төгәл. Акча тоту, әйбер алу, кыз бирү, кибеткә йөрү, кунак чакыру, малай өйләндерү, мал суйдыру, малайга хат язу кебек мәсьәләләрне хәл итү — кар-

чык кулында. Мал карау, кар көрәү, утын кертү, моржа ачу, көл түгү, тирес чыгару кебек эшләр — карт кулында. Вазифалар шул кадәр төгәл итеп бүленгәннәр ки, бу семья көйләнгән машина кебек тигез, гөрләп яши. Ир — баш, хатын — муен, дигән булалар. Пычагыма да кирәге юк. Һәркем үз сәләтенчә эшләсен һәм үз урынын белгәнчә генә сөйләсен. Боларда — барысы да үз урынында. Карт, дөм ук булмаса да, шактый чукрак. Бөтенләй ук булмаса да, шактый телсез. Дөресе — аз сүзле. Җөмләләре дә икешәр, иң күбе өчәр сүзле. Ул сүзләрнең дә араларында зур гына тәнәфес ясап сөйләшә карт. Рушад килгән көнне үк картның бу сыйфатына игътибар итте. Кичке караңгыда малларны карап бетергәч, Галиәхмәт карт маңгаен тотып керде.

— Нәрсә булды тагын? — дип сорады карчыгы эш арасында гына...

— Башны...— диде карт һәм тынып калды. Бишмәтен салып элде, ак шарфын мич буена куйды, киез итекләрен мич башына урнаштырды һәм, түбәтәен дөресләп, ишек катындагы урындыкка утырды. Кытыршы, бирчәйгән дәү куллары белән авыз тирәләрен бер сөртеп алгач кына, әлек башлаган җөмләсен тәмамлады:

— ...бәрдем.

Дәрес хәзерләү һәм китап уку өчен шулай итеп өйдә тынычлык тәэмин ителгән иде. Шулай да пәрәмәч пешкән көн итеп Гайнелвафа карчык картының гадәтләренә кагылышлы кайбер нәрсәләрне озаклап сөйләде. Карт самовар артында елмайган сыман дәшми тик утырды. Быел гына, әле күптән түгел генә, Галиәхмәт карт үзенең карчыгын суыкта харап итә язган икән. Гадәт буенча, төн уртасында карт-карчык тышка чыкканнар. Шул төнне генә нәрсәсенәдер иренеп фонарь кабызмый чыкканнар икән дә, караңгыда берсен-берсе күрмичә, карт кереп киткән һәм, карчыгын аннан да алда кергән дип белеп, ишекнең арасасын салган. Кергән, чишенгән һәм мич башына менеп тә киткән. Өстенә элеп кенә җинелчә чыккан Гайнелвафа шулай тышта калган. Чоланнар селкетерлек итеп ишек кагып караган — карт ишетмәгән. Күршеләрдән фонарь алып чыгып тәрәзәне яктырткач кына карт торып ишеккә килгән һәм:

— Бәрәч, син...— дип ишекне ачкан.

Карчык аны әрли-әрли арып беткәч кенә карт мич башыннан:

— Кермәгәниеңмени? — дигән.

Шуннан соң Гайнелвафа карчык бер атна чамасы авырып яткан.

— Һи-и-и, безнең картнын хикмәтләре! — диде Гайнелвафа карчык, пәрәмәчне Рушадның алдынарак этеп.— Монын белән мин генә яши алам. Бүтән кеше булса әллә кайчан моны ташлап җәяүләп җәһәннәм тишегенә чабар иде инде.— Шул вакыт карчык үзе самовар артында утырган картына искиткеч тирән мөлаемлык белән карап алды. Рушад уйлап куйды: юк, әби, бер җиргә дә китмисең син бу картыңны ташлап.

— Бердәнбер кызыбызның туена барганда, чанадан төшеп калып, җәяү барган кеше ул. Чана башында кучерыбыз борылып карамый, мине толыпка төреп утырттылар, мин дә күрмим. Баксаң, картыбыз капканы чыкканда ук бер чалуда төшеп калган икән. Кычкырмаган да, җүнсез. Бөтен авылны буран уйнатып үтеп, кияүләрнең капка төбенә барып туктасак — карт юк. Юк кына бит — җир тишегенә кереп кит. Урамга эзләргә чыгып киттеләр. Үзе җәе белән килеп ята ди...

Карт елмайган сыман кыяфәтен үзгәртмәде, шыпырт кына чәй чөмерде...

Дүшәмбе көн иртән беренче дәрес — алтынчыда тарих. Алтынчы, әйтүләре буенча, иң явыз, иң тәртипсез класс. Утыз биш бала икән. Утыз алты булса икегә бүләселәре икән — тәртип тә яхшырасы, сәгатьләр саны артып акча да шәбрәк төшәсе икән — нәкъ бер бала җитми. Шулай да военрук Хәкимҗанның күрше авылдагы апасының алтынчыга кергән малаен теге мәктәптән Акбалыкка күчереп караганнар.

Янәсе, Хәкимжанда тәрбияләнүче бала, тегендә әтисе юк, сугышта үлгән. Класста бала саны шулай итеп утыз алтыга житкән һәм шау-гөр килеп РОНОга отчетлар жибәргәннәр. Ике алтынчы ясап, расписаниеләр төзеп, эшне көйгә салганнар гына икән... теге бала качкан. Үз мәктәбенә, әнисе янына качкан. Хәзер ул «наемщик» вакыйгасын искә алырга бик яратмыйлар...

Звонок булды. Рушад, иртән иртүк торып, киң балаклы флот чалбарын күмер үтүге белән бастырган иде, тельняшка өстеннән күлмәк киеп, галстук таккан һәм чибәр генә пиджак киеп куйган иде. Болай рәвеш килде кебек. Инде класска керергә кирәк.

— Сез педагоглык хезмәтен алтынчыдан башлыйсызмы әллә? — дигәнгә Рушад сискәнеп китте.

Аның янында университет значогы таккан зифа гәүдәле, кызыл иренле рус теле укытучысы тора иде. Рушад бу сорауда ирония сизде.

— Бу — яхшымы, начармы? — диде ул. Жөмләсе, нигәдер, русчарак чыкты.

Рус теле укытучысы озын керфекләрен түбән төшереп, нурлы күзләрен бер секундка гына каплап алды. Юк, аның фикере явызлыкта түгел иде.

— Беләсезме нәрсә? Сезнең моңарчы укытканыгыз юкмы? Сак булыгыз. Ужасный класс ул. Аллам язмасын! Мин аларга бер атна кердем һәм моннан соң кермәячәкмен. Ачка үлсәм үләм, акча эшлим дип ул Троекуров псарнясына ике аягымның берсен атламыйм.

Коридордан алар бергә бардылар.

Рушад алданрак кереп китәргә тиеш иде.

Кызыл иренле (ул Нәркис исемле икән) Рушадка мәхәббәтле караш ташлады, наз белән елмайды.

— Нас мало, но мы в тельняшках,— диде Рушад та, аңа каршы елмаеп.

— Кырык биш минуттан карарбыз! «Моряк с разбитого корыта» була күрмәгез! Һәрхәлдә, мин сезгә яхшылык телим!

Нәркис бик белеп әйткән икән...

Гөж итеп торган умарта оясыдай класска кергәндә, Рушадның иң беренче эше каушау булды. Тузан болыты күтәрелгән, сугышып тирләгән малайларның күзләре урыннарыннан купкан иде. Хәзер исәнләшергә кирәк. Педагогика шулай куша. Юк, педагогиканың икенче бер төрлесе балалар тынычлангач кына исәнләшергә куша. Әйе, шәригать ике төрле... Берсе яшел тышлы китапта, икенчесе кызыл тышлысында. Тукта, башта журналны өстәлгә куярга кирәк. Аннан исәнләшергә дә дәресне башлап жибәрергә.

— Укучылар, мин сездә тарих укытачакмын. Миңа Рушад абый дип дәшәрсез. Мин сезнең белән...

Әйтми тор әле! Боларны әйттергәнче классны кулга алырга кирәк.

— Абый, син кайсы авылныкы?

— Абый, синең исемең ничек?

— Абый, синең хатының бармы?

— Ха-ха-ха!..

Рушадның күз аллары караңгыланып китте. Тамагы чатнады. Шул арада класста үзен жәлләүчеләр дә табылды.

— Я, малайлар, тавышланмагыз, берәр нәрсә сөйләсен.

— Сөйләсен, сөйләсен!

— Абый, син чукрак Галиәхмәтләрдә торасың бит, имә?

— Абый, син армиядә булдыңмы?

— Нишләп булмасын! Моряклыкта булган бит ул!

— Ах-ха-ха!..— Берсе, иң арткы партада утырганы, юри кычкырып көлде. Урыныннан ук торып басты.— Моряк, штаны горят! Моряк — сибиряк, растянулся как червяк!

Бу малай дөнья күргән булырга кирәк. Авыл малайлары, гадәттә, андый фольклорны белмиләр.

Рушад иң авыр, кульминацион ноктаны кичерде. Әле авыз ачып бер сүз дә әйтә алмады. Өченче ранг капитаны Дроздов язучы Гюго сүзләрен китерергә ярата иде: «Әгәр дә синең өстеңә үлем килә башлаганын күрсәң — каршысына үзең бар. Ул вакытта гроб капкачы коткару такътасына әйләнә».

Көтеп тору — харап булу дигән сүз иде. Рушад үзен тыныч тотарга тырышып болай диде:

— Сез тынычланмый торып, мин дәресне башламыйм. Ә дәресне барыбер уздырам.

Бу җөмлә классны бераз уйга калдырды. Ләкин янадан кинәт кенә гөҗләү башланды, тавыш купты. (Ах, Нәркис, Нәркис, син дөрес әйткәнсең бит!)

— Давай, башласаң башла, ату чыктык киттек булыр!

— Ие! Нәрсәгә киреләнеп торган буласың! Солдаттан кайтканнарны гына күргән бар!

— Давай, малайлар, шыпыртрак утырып карыйк әле. Армиядән кайткан кешеләр барысы да бер төсле була бит. Әнә безнең абый да настоящий үҗәт булып кайтты...

Нәкъ олы кешеләрчә сөйләшәләр!

Алгы рәтләрдә утырган алты-җиде кыз малайларга борылып-борылып нәрсәдер әйттеләр. Болар, һәрхәлдә, Рушад яклы иде. Болар белән союзга кереп, малайларга каршы атака башларгамы? Союзниклар бик сыек. Бала-чага. Ә малайлар — күбесенә инде мыек тибә башлаган. Күрәсең, класста өчәр-дүртәр ел утыручылар бар. Дөнья күргәнгә охшаганы Рушадтан күп булса өч-дүрт яшькә яшьрәктер. Рушад теге җөмләне тагын кабатлады.

— Сез тынычланмый торып, мин дәресне башламыйм. Ә дәресне барыбер уздырам.

Монысының тәэсире булмады. Малайларны бу җөмлә бераз кайнатып кына җибәрде.

— Җиденче дәрескә алып калмакчы буласыңмы әллә? Тот капчыгыңны, калды ди.

— Һи-и, кем тота ала! Алты дәрес бетүгә чыгам да китәм. Дүрт чакрым кайтасы да бар анда. Ярый ла, аның чукрак Галиәхмәтләргә генә кайтасы бар...

Кемдер бик астыртын яман сүз әйтте. Нәкъ олылар сөйләшкәндәге кебек итеп.

— Гөлчирә апаең, алайса, гел әниләрендә ятыр инде. Ирләрне бик ярата ул. Аулак өйгә дә килер, картлар берәр җиргә китсә...

Рушад бу коточкыч көрәштән бер нәрсәне аңлады: әгәр шушы көе дәресне башлап җибәрсә, ул бу класста беткәнче шул тәртипсезлеккә килешергә, шул хәлдә укытырга тиеш булачак. Бу — җиңелү булачак иде. Һәм әгәр хәзер җиңмәсәң, Нәркис кебек, бу класстан баш тартырга кирәк иде. Фронтовик! Балалардан куркып баш тартырга... Юк, җиңәргә, бүген үк җиңәргә кирәк. Ул сәгатенә карады. Дәреснең унбиш минуты калып бара иде. Сөйлисе тема исенә төште. «Англиядә Ал чәчәкләр белән Ак чәчәкләр сугышы». Ну, мин сезгә бирәм бүген чәчәкләр сугышын! Рушад болай юаш, тыныч егет. Ләкин билгеле бер чиккә җиткәнче. Аңа ычкынырга гына кирәк. Менә бүген, һичшиксез, ычкынырга кирәк. Үз авылларында булып узган бер хәл Рушадның хәтеренә төште. Училищены бетереп кайткан елы иде. Җәйге кич. Кызлар су ташый, чишмә тамагында бәрәңге юалар. Рушадның үсмер егет вакыты. Кызлар әле аны санга сукмыйлар. Шулай да инде бераз сәерсенеп карыйлар. Менә күршедәге ике кыз бакча киртәсе эченә кергәннәр дә яңа бәрәңге алган җирдә серләшеп утыралар. Икесе дә буй

житкән кызлар, чибәрләр. Берсе председатель кызы. Калага укырга китәргә йөри. Рушад инде бер генә метр булган тыкрыктан килә. Ике якта бәрәңге бакчасы. Килә... һәм күрә: тыкрыкның нәкъ уртасында председательнең бозавы. Үгез бозау. Әллә ничә кешене сөзеп екты инде бу җәйдә. Көздән туып калган бозау — инде тәртә арасына кертеп җигәрлек. Гадәттә, бу юньсезне әйләнеп узалар. Нишләргә? Үгез тыкрыкның нәкъ уртасына баскан, күзләрен алартып, башын түбән игән дә Рушадны көтә. Ә күрше кызлары, чырык-чырык көлешеп, булачак комедияне карарга әзерләнәләр. Үгезгә кадәр ун гына адым калды... Биш адым... Өч. Рушад аның мышнаганын ишетте. Үгезнең мышнавыннан җирдәге тавык үләннәре дерелдәп селкенә иде. Туктады. Ике кулы белән ике як киртәгә тотынды. Терәк булды. Хәзер иң хәлиткеч секунд! Гәүдәнең бөтен авырлыгын аякка күчереп, Рушад күз ачып йомганчы үгезнең борынына ботинка үкчәсе белән типте. Тыкрык дерелдәп куйды. Рушад аны-моны уйлап бетергәнче, үгез башын җирдән күтәрмәгән көе генә борылды да кызу-кызу урамга таба китеп барды. Рушад аның тоякларыннан чыккан шыртлау авазын гына ишетте. Аннан, берни дә булмагандай, бәрәңге бакчасындагы кызларга дәшеп узды:

— Сәлам күрше кызларына!

Председатель кызы шул көнне кичке уеннан кайтканда Рушад белән бергә кайтты...

Шулай да җиңелгән үгезне кызганудан йөрәк әрнеде.

Менә ул үгез — утызлаган юньсез малай күзләрен алартып тар тыкрыкта торалар. Хәзер тибәргә кирәк. Юк, хәзер түгел, бүген. Шунсыз мәктәпкә килеп тә йөрмә...

Звонок булды.

Класс «ахахай»лап көлеп калды. Класс журналын укытучы өстәленә дә куя алмаган, «исәнмесез» дип әйтә алмаган укытучы балалар янынннан чыгып китте. Укытучылар бүлмәсенә чыгуга, мич алдына килеп, завхоз Заһир белән кара яндырып тәмәке тарттылар. Нәркис берничә тапкыр аларга серле караш ташлады. Бу караштa ирония барлыгын сизү авыр түгел иде.

— Я, ничек,— диде ул, Рушадка карап,— тәмәке тартабызмы?

Рушад дәшмәде. Нәркис барысын да аңлады.

Өлкән классларда дәрес тыныч узды.

Алтынчы класста иң соңгы дәрес сызым икән. Соңгы дәрес бетәргә звонок булуга, Рушад класс ишеге төбенә барып басты. Ишек ачылып, аннан дәү транспортир, агач циркуль, озын линейкалар күтәргән, битебашы акбурга буялып беткән укыту бүлеге мөдире күренде. Рушад аннан класс журналын сорап алды.

— Сез рөхсәт итсәгез...

Тегесе берсүзсез аңлады.

— Әгәр шушы классны җиңсәгез, сезнең япь-яшь көе сугышта булуыгызга ышанам,— диде ул, саран гына елмаеп.— Никадәр көчле, сәләтле балалар бар анда. Берничә явыз аркасында әрәм булалар.

Бүрекләрен киеп, букчаларын асып яткан балалар, нәкъ баягыча тарих укытучысы кереп баскач, гаҗәпкә калдылар. Алай булмый торган иде моңарчы. Андый очракта класс җитәкчесе Хушият абзый кереп алдан әйтеп куя иде:

— Оланнар, бүген еденче дәрес була, алты сәгатьтән соң таралмагыз,— ди иде. Ә теге укытучы кергәнче, класста малайлардан җилләр искән була иде. Бүген исә Хушият абзыйның заты да юк...

— Бүген без сезнең белән,— дип сүз башлады Рушад,— «Англиядә Ак һәм Ал чәчәкләр сугышы»н өйрәнәбез. Мин дәресне бары тик барыгыз да чишенеп, сумкаларыгызны урнаштырып, китапларыгызны өстәлгә куйгач кына башлыйм...

Акрын гына, өстерәлеп кенә чишенә башладылар. Хәзер бик нык салкын канлылык кирәк иде. Кечкенә генә саксыз бер сүз ычкындырсаң, ачуы килгән малайлар дәррәү кубып бәреп чыгып китүләре мөмкин иде. Мөмкин кадәр сак булырга. Мөмкин кадәр... Ул демонстратив рәвештә сәгатенә карап куйды.

— Сез чишенеп урнашып беткәч кенә мин дәресне башланган дип саныйм һәм кырык биш минутны шуннан исәплим.

Монысы да батты.

Нәрсә булыр икән дигәндәй, класс тынды.

Бу дәрестә үзеннән матур, кызык сөйләвең белән укучыларны җәлеп итү турында уйларга да ярамый иде. Монда тәртип бозган өчен шук малайларны интектереп дәреснең үзе белән җәзаларга кирәк иде. Ә кызлар? Алар да җәзаланырга тиеш. Әйе, алар да. Гаепләре булмаса дамы? Әйе, булмаса да. Ни өчен? Шундый компаниядә булуларының авырлыгын сизсеннәр өчен. Киләчәктә жиңеллек булу хакында. Әйе, шул хакка.

Ачыккан, җәфаланган кызлар эчләрен тотып бөгелеп төштеләр. Шук малайлар да өметсезлеккә бирелде. Берсе дә тынламый иде. Рушад аның саен җансыз, төссез җөмләләр белән аларны каһәрләде. «Ланкастерларны мөстәкыйльлек тарафдарлары булган төньяк феодаллары яклаганнар...» Бер усал малай йөзен җыерып партага капланды. Галиәхмәт бабайның кияүдәге кызы турында шул лыгырдаган иде. «Йорклар ягында исә көньякның эре феодаллары торган.» Иң явыз малай, «моряк, штаны горят» дип кычкырганы, чыдый алмыйча йөзен чытты, өметсезлек белән тәрәзәгә борылды. «Эдуард IV нең тәхеткә утыруы да Ак һәм Ал чәчәкләрнең сугышын туктатмаган, сугыш дәвам иткән».

Җәза дәресе тәмамланды. Рушад гадәттән тыш салкын кан белән болай диде:

— Бүгенгә кайтасыз, ә икенче дәрестә класс шулай чүпле булса, идәнен себертеп юдыртам.

Тонык кына зарлану, янау тавышлары ишетелде.

— Армиядән кайткан кеше белән эшең төшмәсен!

— Бар икән күрәчәкләр! Икенче каламмы соң мин өстәмә дәрескә! — диештеләр.

Шулай да Рушад аяк астының шактый ныгыганын сизде.

«Бүген яки беркайчан да!» — дип уйлап алды ул кинәт кенә һәм иң арттагы, мыек тибә башлаган таза малайны үз янына чакырды. Авызын ерып «штаны горят» дип кычкырып утырган таза малай зур кызыксыну, ләкин бераз шикләнү белән өстәл янына килде:

— Нәрсә, абый? Әллә сигезенче дәрескә апкалмакчымы? Шаярма! Детдомнан качкан Закиров мин!

— Сау булыгыз! Сау булыгыз! — ди-ди, Рушад тиз генә балаларны озатты. Ишекне ачып, коридор буенча чыгып киткәннәрен карап торды. Аннан ишекне япты. Бик тиз хәрәкәт итәргә кирәк иде. Чөнки ишек алдына чыккач, балалар, һичшиксез, нәрсә бар икән дип карарга тәрәзәгә киләчәкләр. Хәзер барысын да тизлек хәл итә. Тик кызып китмәскә генә кирәк.

Закиров, шактый оятсыз рәвештә күзләрен тасрайтып, иң алдагы парта артына кереп утырган иде.

— Чык! — дип җикеренде Рушад. Аңа үз тавышы ят булып тоелды.

— Чык, бас!

— Ә чыкмасам?

Нибары бер секунд вакыт барын да хәл итте: Рушад оятсыз малайның күлмәк изүеннән чытырдатып кысып алды да (билгеле, күлмәк астындагы арык тәннән дә учка бераз эләкте) малайны парта арасыннан суырып чыгарды. Закиров һич тә моны көтмәгән иде. (Юаш күрен-

гән иде бит бу укытучы беренче дәрестә!) Кысып тоткан көе, Рушад явыз малайны селекте:

— Икенче дәрестә ничек булырсың син, ә?

Малайның башы, каурый курчак башы кебек, нечкә муенында бер алга, бер артка мәтәлде. Үзе ап-ак булды. Иреннәре күгәрде. Күзләрен курку алды. Рушад соңгы алымны кулланды:

— Әгәр дә алдагы дәрестә тагын бер генә тапкыр телеңне озайтсаң,— диде ул, тешләрен кысып,— мин сине нишләтергә белермен. (Нишләтер иде икән? Ул анысын белми иде.)

Тагын бер тапкыр бик нык селкеп, ул малайны каршысына утыртты. Малайның ияк асты, бугаз чокыры кып-кызыл булган иде. Хәзер тавышны йомшартырга кирәк. Югыйсә, бу малайның холкын белмәссең. Өстенә ташлануы бар. Хәзер артистка әйләнергә кирәк. Ләкин моны сурәтле кәгазь белән алдый алмассың. Шулай да елмаерга кирәк. Әнә класс тәрәзәсен балалар басты. Борыннарын пыялага терәгәннәр. Ә болар кара-каршы тыныч кына утырганнар.

— Я, берне төреп тартабызмы?

Закиров сискәнеп китте. Саргаеп каткан бармакларын яшерде. Шулай да югалып калмады.

— Тартмыйм мин... абый.

— Ә, чуртым, ялганлап утырма егет башың белән. Син әле куркак та икәнсең, ә мин синең белән көч сынашкан булам. Белмәдем, кулымны пычратмаган булыр идем.

Балалар тәрәзәдән көлештеләр.

Рушад бик тыныч кына тәмәке төрде.

— Я, ярар, бар кайт,— диде ул елмаеп.— Тәмәкегә тилмереп йөрмә — мин бирә алам. Минем әле Көнчыгыш Пруссиядән алып кайткан яхшы сортларым бар.

Закиров монысын ук, әлбәттә, көтмәгән иде.

Класста ниләр булганын иптәшләренә ул әйтмәячәк иде. Чөнки егеткә инде уналтынчы киткән икән. Ничек инде, мине тотып якадан селектеләр дип сөйләсен?

Идән щеткасы, чиләк белән су күтәреп кергән Мәсрүрә укытучы өстәле артында тәмәке тартып утырган Рушадны күреп телсез калды.

— Әле бу чукынчык белән утырасың икән, кем икән дип торам...

Ул, дөбер-шатыр, парталарны мәтәлдереп себерергә тотынды.

Рушад Закировны коридор ишегенә кадәр озата барды. Ашыйсы килә, баш чатный иде.

— Бик озак,— дип каршы алды аны ишек алдында себеркегә таянган Галиәхмәт карт. Чолан баскычыннан йөгерә-йөгерә кергәндә генә Рушад җөмләнең ахырын ишетте:

— Йөрдең...

## V

Бу атна бик күңелсез һәм мәшәкатьле булды. Җыелышлар, көтелмәгән борчулар, әллә каян гына килеп чыккан, тиз хәл ителергә тиешле мәсьәләләр көнне төнгә, төнне көнгә ашыктырып алмаштырдылар. Рушад алтынчы класс белән тагын бер тапкыр бәрелеште: тарих дәресе ул көнне соңгы дәрес иде — гадәттән тыш чүпле, пычранган класс идәнен укучыларга юдыртмакчы булды. Бәлки, бу эш барып чыкмас? Нигә ул кадәр булырга. Артык таләпчәнлекне берәү дә өнәп бетерми бу дөньяда. Әнә директор ни сәбәптәндер Рушадның бу номерларын күрмәмешкә салышып йөри башлады. Алтынчы класстагы хәлләрне укыту бүлеге мөдире аңа сөйләгән, билгеле. Ләкин директор ни яхшыдан, ни яманнан бер сүз әйтми. Рушад яныннан «Һм-һм» дип уза да китә, уза да китә. Дөрес эшлиме яңа укытучы? Ялгышмы?

Ялгыш булса, ник туктатмыйсыз? Алтынчының класс житәкчесе Хушият карт та, үз койрыгын тешләгән эт шикелле, класс белән директор арасында әйләнчекләнеп йөри — Рушадка ләм-мим сүз әйтми. Югыйсә, мәктәпкә Рушад килгәннән бирле генә үз дәресендә тәртип урнаштырырга дип ничә тапкыр шыпырт кына директорны чакырып алды. Коридорда йөргәндә бер вакыт Рушад үзе дә Хушият картның алтынчыда ничек итеп дәрес алып барганын ишетеп таң калды — нәрсә дип шундый шартларда укытып йөрмәк кирәк? Березлексез зарлану, балаларга ялыну. «Закиров, урыныңа утыра беләсеңме син, юкмы, алланың каһәре суккан!» «Житте инде сиңа, Ганиев, чисти чәчләремне син генә агарттың бит инде». Шундый зарланулардан соң бер-ике минутка балалар тыныч торалар. Шул тынлыкта дәресен сөйләүче бер кыз баланың тавышы ишетелә:

— Афзал Шамовның... Афзал Шамовның... Шамовның бу... бу хикәясендә мичче Шәрифулла... мичче образы... Шәрифулла образы... образы бирелә.

— Я, я, шуннан соң ничек була? Я, я...

— Мичче образы... Шамовның...

— Я инде, Әскәрев, тик кенә утыр инде, алла хакы өчен. Оят дигән нәрсә бармы синдә, юкмы?

Теге кыз хикәяне ерып чыга. Соңга таба хәтта кызурак та сөйли башлый. Хушият карт та җанлана. Сөйләүчене бүлдереп үк куя.

— Тукта әле, тукта, әле Шәрифулланың мич янында бөтерелеп йөрисе бар бит әле,— ди.

Менә шул кеше класста зур борылыш ясарга тотынган яңа укытучы янына килеп тә карамады. Рушад көрәшкә ялгыз ташланды. Хәер, ялгыз ук түгел. Иң беренче союзник — укыту бүлеге мөдире — үзенең гомерен дә, матурлыгын да, бәхетен һәм бәхетсезлеген дә мәктәпкә бәйләгән, шуңа багышлаган, олайган кыз Бәлкыйс иде. Бәлкыйс: «Әгәр шушы классны җинә алсагыз, япь-яшь көе сугышта катнашканыгызга ышанам»,— диде. Ул моны өмет белән, ышаныч белән әйтте. Димәк, бер теләктәш бар. Аннан завхоз Заһир беренче көнне үк мич янында тәмәке тартканда үзенең позициясен сиздереп куйды: «Алтынчы классны Хушият абзый гына бозып бетерде, анда шул буталып йөри»,— диде. Бусы булды — ике. Директор юлга аркылы төшми. Һөҗүмгә барганда сиңа аяк чалмаучы — үзенә күрә шулай ук союзник ул. Нәркис — күзәтүче: шулай да теләктәшлек белдерде. Шулар хәзергә житеп торыр. Инде һөҗүмгә күчәргә кирәк.

...Звонок булды, укучылар кузгалыштылар.

Рушад тыныч кына болай диде:

— Укучылар, мин сезгә узган дәрестә, әгәр идәнне болай пычратсагыз, үзегезгә юдыртам, дип әйткән идем. Сез минем сүзне оныткансыз, ахрысы, шуңа күрә, бүген идәнне үзебез юабыз...

Бер мәлгә класс телсез калды.

Ләкин гомуми ачу тиз бәреп чыкты:

— Сез нәрсә! Әллә моны армия дип белдегезме?

— Менә шушында тәгәрәп үлим, кулыма мунчала алмыйм түлкә...

Ул арада, алдан сөйләшенгән буенча, ишектән Мәсрурә килеп керде. Аның кулларында пар чыгып торган ике чиләк су иде. Икенче керүендә ул щетка белән ике-өч кисәк идән мунчаласы алып керде. Аның йөзендә явыз елмаю чаткылары сизелә иде, һәм, шул шатлыгын яшермичә, ул чиләкнең берсен Әскәрев партасы янына китереп тә куйды. Әлек үк шикләнеп йөргән бер фикеренә Рушадның ышанычы тагы да артты. Явызлыкның башы Закировта түгел, Әскәревтә булырга тиеш иде. Мәсрурә чиләкне аның янына очраклы рәвештә генә куймады...

Класста сынаулы тынлык урнашты.

Кем кемне? Я алар, я Рушад.

Әгәр җинелсә, Рушад бүген үк авылдан чыгып китәчәк. Бернинди сөйләшүсез, документсыз. Ә җиңәргә кирәк...

Кызлар җиңнәрен сызганып әзерләнә башладылар. Рушад аларга карап елмайды. Кыз балаларны җиңү — җиңү түгел. Аларны Хушият карт та тыңлата. Аннан соң алар әйләндермәгән бит классны дуңгыз абзарына.

— Кызлар, сез киенегез дә техничка йортыннан су ташырсыз,— диде Рушад.

Бу яңалык классны тагын тынсыз итте.

Малайлар сүзсез генә, явыз карап утырдылар.

Рушад бүген юри Закировны күрмәмешкә салышты. Әгәр аңа тагын бәйләнсәң, ул үзенә каныга икән дип белеп, Әскәревләр, Ганиевләр барында, әлбәттә, тыңламаячак, егетлеген күрсәтәчәк. Монда Әскәревне җиңәргә кирәк. Чөнки иң пычрак парта асты — аныкы. Анда кәгазь чүбе дә, салам да, көнбагыш кабыгы да, чүбек тә бар. Кара түгелеп идән бөтенләй шәмәхә төскә кергән. Вак-төяк зарарсыз малайлар ул арада этешә-төртешә идән себерә башладылар.

— Я, егетләр, керешәбезме? — диде Рушад, юри Әскәревкә карап. Бите тулы сипкелле, баш түбәсендә ике бөтеркәле бу кара чәчле малай исе дә китмичә авыз тутырып күши иде.

— Һи-и,— диде ул, тынын чак алып.— Син, абый, бигрәк инде. Менә шушында чәчрәп үлсәм үләм, но идән юучы түгел мин.

Нык булырга охшый бу чикләвек!

Закиров көтмәгәндә ярдәмгә килде. Ул шыпырт кына Әскәревкә болай диде (Рушад, әлбәттә, бу сүзләрне ишетмәмешкә салышты):

— Шәйхенур, лутчы каршы килеп маташма. Барыбер үзенекен итә ул, кулың калмас...

Әскәревнең реакциясе башкаларга да көчле тәэсир итте. Төрлесеннән төрлечә каршы авазлар ишетелде. Актык чара кала! Давыдов чарасы. Әйе, әйе, Давыдов та тельняшкадан булган. Җирне үзе сөреп күрсәткән. Тик ачуланмаска гына кирәк хәзер.

— Их, сез,— диде Рушад,— мин сезне флотка җибәрерлек егетләр дип уйлаган идем. Юк икән сездән, юк. Сезгә — кырда әрем җыярга. Каз көтәргә! Ә менә флотта без болай эшлибез...

Рушад, күз ачып йомганчы, пиджагын, галстугын салып урындык аркасына элде. Күлмәген салып ташлады. Тельняшкадан калгач, идән юу — физзарядка сыман бер эш. Ул бөкрәеп зур мунчаланы кайнар суга тыгып алды да киң алдырып юа башлады. Малайлар өчен бусы да көтелмәгән удар булып чыкты. Ләкин хәзер Рушад нишлисен белә иде инде.

— Эшләргә теләмәгән укучыларга кайтып китәргә рөхсәт итәм,— диде ул, тавышын юри калынайтып.— Бар, кайтыгыз, бар! Ә син, Әскәрев, бар тизрәк тай, ачыкказсыңдыр...

...Иң башта идән мунчаласын кулына Закиров алды. Аннан җирәнеп кенә башкалар да тотындылар. Бу — шулай булырга тиеш иде, монысы план буенча иде. Ә менә Әскәрев бик тыныч кына торып сумкасын аркасына асты да әшәке елмаеп чыгып китте. Их син, педагогика! Нинди ысулларың бар тагын? Мондый очракта нишләргә? Җавап юк.

Әскәрев киткәч, башкалар иркенләбрәк эшкә тотындылар. Ниндидер җиңеллек килгәндәй булды. Рушад та мунчаласын Ганиевкә бирде.

— Я, тагын кайсыгыз кайтып китә?

Рушад кычкыра башлаган икән.

— Барыгыз, марш өегезгә! Кемнең эшлисе килми? Я?

Барысы да шыпырт кына эшлиләр.

Рушад тельняшкадан гына коридор буйлап китте. Мәктәп бушап калган, бары тик өлкән классларның берсендә генә концертка хәзерләнеп яталар иде. Рушадның исәбе — малайларга тагын бер чиләк кайнар

су китерту иде. Коридорның караңгы башында ул ишек артына шым гына кереп качкан бер шәүлә күрде. Аны сизмәгәнгә салышып, янына килде. Сизмәгәнгә салышып, ишекне ачты. Стенага сөялеп, саргылт тешләрен ыржайтып, Әскәрев тора иде. Авызы тулы ипи. Бөтен җиреннән йорт ипие исе аңкып тора. Озак уйлап торырга ярамый иде. Рушад малайның изгеннән тотып стенага терәде. Кечкенә, ярым караңгы класста берәү дә юк иде, Әскәревнең изгеннән тоткан көе, Рушад үрелеп кенә сул кулы белән ишекне япты. Малайга шул җитә калды. Ул авызындагы ипине дә йота алмаслык дәрәҗәдә каушап:

— Абый, зинһар, җибәрә күр, икенче алай булмам,— диде. Рушад салкын елмайды.

— Ә мин сине бер ни эшләтергә дә уйлаганым да юк әле, Әскәрев,— диде.— Син бик начар малай. Мин үзем егет кешеләр белән эш итәргә яратам...

Әскәрев моны көтмәгән иде. Ул, әлбәттә, укытучы аны кыйнар дип уйлаган иде. Ул югалып калды.

— Абый, кереп идән юа башлыйммы?

— Юк, Әскәрев, син хәзер үк тай моннан. Мин алдагы дәрестә синең тәртибеңә карармын әле. Идән юарга лаеклы егетме син, юкмы — карармын. Әйе, карармын... Ә без анда хәзер җыр өйрәнәбез. Беләсеңме — шундый җыр бар диңгезчеләр турында. Ә син кайт өеңә, бар, бар, йөрмә...

Ләкин Әскәрев кайтмады. Коридорның әле бер, әле икенче почмагында эштеренеп йөрде. Алтынчы классның ишеге төбенә инде мунчалалар, щеткалар, чиләкләрне чыгарып куйдылар. Рушад әйтеп торып җыр яздырды. Әскәрев монысын да ишетте. Техничка йортыннан йөгереп кызлар килеп җиттеләр. Туп-туры класска уздылар. Ә бераздан класста җыр яңгырады.

Наверх, вы, товарищи! Все по местам!
Последний парад наступает.
Врагу не сдается наш гордый «Варяг»,
Пощады никто не желает.

Ничә ел йөреп бер вакытта да шушы мәктәп бинасыннан Әскәревнең шулай басынкы күңел белән чыкканы юк иде. Ә бүген нигәдер елыйсы килә. Бу тарих укытучысы да тәмам каныкты бит. Әнә, җитмәсә, тамагын киереп җырлап маташа, юри, Әскәрев ишетсен дип суза.

Пощады никто не жела-а-а-е-т...

Барысы да, җылы саубуллашып, чиста класстан чыгып киттеләр. Рушад класс тәрәзәсеннән аларны карап озатып калды. Каяндыр, бәдрәф артыннанмы, чыгып, иләмсез зур киез итекләр кигән Әскәрев тә иптәшләренә кушылды. Аның чырае шәптән түгел иде. Әскәревнең идән юудан баш тартуы Рушадның тагын бер җиңүе булды. Петр Беренченең сүзләре Рушадның күңеленә килде: «Гәрчә бу чикләвек гадәттән тыш каты булса да, аллага шөкер, бик яхшы кимерелде».

Шулай да бүген атнаның иң авыр көне булырга охшап тора. Сәгать өчтә педсовет башланырга тиеш иде, аннан кичкә агитаторлар җыелышы да буласы икән. Өйгә кайтып тегеләй-болай гына капкалап чыгып йөгерергә туры килде. Педсоветка укытучылар инде җыйналган, айның егермесе көне — укытучыларның хезмәт хакы ала торган көннәре, директор районнан акча алып кайткан. Директорның районда булганлыгы әллә каян күренеп тора — аның чәч артын кыртлап алганнар, авыл районнарында гына була торган арзанлы одеколон белән кереңдергәннәр иде. Рушадның әле бөтен укытучыларны иркенләп күргәне, танышканы юк иде — утырышка зур кызыксыну белән килде. Педсовет башланыр алдыннан мәктәпнең дәү генә венский гармунын тартып

чыгардылар, военрук Хәкимҗан аны гөрләтеп алды. Тик, сул кулының ике бармагы өзелгән булганлыктан, ул гармунның бакаларына гына баса алмый иде. Хәкимҗан гармунны хис белән, йөрәк белән уйный, кешегә карап түгел, тәрәзәдән ишек алдына таба карап уйный. Кулына гармун килеп кергәч, аның күзләре моңсуланды, ул күзләргә яшь катыш нур тулды. Көйнең кайбер авыр борылышларында Хәкимҗанның борын тишекләре киңәеп китә, көйнең бака белән көчәйтеп җибәрәсе урыннарында ул чыдый алмыйча ыңгырашып, «ыһ-ыһ» дип ала. Шулай да исән калган чәнчә бармагы белән ниндидер бер тавышны өстәп-өстәп куя. Ул озак кына итеп «Кайту» көен уйнады, укытучыларның бер ишесе диванга чумып, бер төрлеләре зур тәрәзә янындагы газета подшивкалары өйгән өстәл янына җыелып, дөньяларын онытып, гармун тавышын тыңладылар. Бу минутта барысының да башыннан газаплы дәресләр, төн утырып тикшереләчәк кочак-кочак дәфтәрләр чыгып торды, дөнья явызы — кара эчле Әскәревләр, усал Закировлар, вак хулиган Ганиевләр дә күңелнең әллә кай җирендәге ниндидер сихри бер пәрдә белән капландылар, алар да үзләренең укытучыларга моңарчы мәгълүм булмаган балаларча күркәм сыйфатлары белән ерактан елмайдылар...

Директор, карандаш белән графинга кагып, кешеләрне сихри дөньядан матди кырыс дөньяга кайтарды:

— Иптәшләр, рөхсәт итегез Акбалык урта мәктәбе укытучылар коллективының икенче чирек йомгакларына багышланган педсовет утырышын башлап җибәрергә. Көн тәртибендә, иптәшләр, төп мәсьәлә булып чирек йомгаклары буенча класс җитәкчеләренең һәм предметникларның информацияләре тора. Информацияләре тора. Дальше дә безнең карап үтәячәк төрле мәсьәләләр, төрле мәсьәләләр бар...

Төп мәсьәләдән башладылар. РОНОда бүген булып үткән киңәшмәдә Акбалык урта мәктәбен өлгерешне түбән бирү ягыннан телгә алганнар икән. Директор үзенең чыгышын бүгенге киңәшмә материалларына корды.

— РОНО мөдире иптәш Шәмсетдинов кат-кат кисәтте, иптәшләр. Акбалыкка бер барып чыгабыз бригада белән, диде, и бер фронтальный тикшерү үткәрәбез, диде. Анда, диде, без белмибез түгел, беләбез, что зарплата өчен генә эшләүчеләр барын. Егерменче число өчен яшәүчеләр бар, диде. Буквально шулай дип әйтте: егерменче число өчен, диде. Аннан соң, иптәшләр, бездә тәртип мәсьәләсе дә шәптән түгел. Карагыз ул алтынчы классны. Ничәмә-ничә мәртәбә дәрес өзелде анда узган чиректә. Ни өчен шулай? Предметниклар җитәрлек эшләми. Класс җитәкчесенә аударабыз барысын да. Бездә кайвакыт шулай була: укучы, пнимаетели, чаңгысын күтәреп класска керә. Мич артына сөяп куя. Моржа жеби — класста тәртипсезлек...

Бу урында Рушад елмаеп куйды, укыту бүлеге мөдире Бәлкыйс коры гына итеп директорга карап алды, директор исә карашын укытучылардан күтәреп шкаф өстендәге глобуска юнәлтте. Рушад директорны бик игътибар белән тыңлады. Директор җайлап кына, фамилияләрне атамыйча гына сөйли башлады. Бу нәрсә, куркаклыкмы? Тактмы? Әйтүе кыен. Ләкин чыгышның ахырында директорның Рушад өчен бөтенләй көтелмәгән ягы ачылды.

— Иптәшләр,— диде ул,— менә мин мәктәптә булган гомуми кимчелекләргә тукталдым. Болар, әлбәттә, как директор, минем гаеп, минем кимчелекләр. Моның өчен мине сугәргә тиешләр, и, мин уйлыйм, иптәш Шәмсетдинов шулай мине сүгеп дөрес тә эшли, мине әле, ихтимал, тагы да катырак сүгәргә кирәктер. Чөнки, как директор, мин үз эшемә җитәрлек әһәмият биреп бетермим, күрәсең, әйтәм бит, монда төп гаеп — миндә. Фчужтәки, миңа тырышыбрак эшләргә кирәк иде, мин күпчелек иптәшләрне начар эшлиләр дип әйтә алмыйм...

Бу чыгыш педсоветның бөтен барышын алдан ук хәл итеп куйды. Шуннан инде бертөрле генә, хиссез генә, күңелсез генә информация башланды. «Минем класста фәлән бала, шуның фәләне өлгерми, бу була — фәлән процент, отличниклар саны фәлән, иң зур процент өлгермәүчелек фәлән предметка төшә һ. б.» Җыелышта бары тик Хәкимҗан гына телгә алынды. Иң югары өлгереш биргән кеше, әлбәттә, ул иде. Аның өч фәненнән — физкультура, хәрби хәзерлек, рәсемнән өлгермәүчелек бөтенләй юк иде. Бәлкыйс аның турында сөйләгәндә Хәкимҗанның дәрес планнарына игътибарсыз каравына озак тукталды. Дәресенең бер планын хәтта мисалга да китерде. Хәкимҗан тугызынчы класста физкультура дәресенең бер планын, мәсәлән, болай төзегән:

Дәреснең темасы: чаңгы шуу.

Максаты: таудан шуарга өйрәтү.

Дәреснең материалы: чаңгылар, Сафыйлар тавы.

Дәреснең барышы.

1. Чаңгылар өләшү — 5 минут.
2. Тауга бару — 5 минут.
3. Шуу — 20 минут.
4. Кайту — 7 минут.
5. Чаңгыларны тапшыру — 5 минут.
6. Йомгак — 5 минут.

Бәлкыйснең сөйләвенә караганда, Хәкимҗанның шушы бер үк планы теләсә кайсы класска, теләсә кайсы көнгә ярый икән. Бер дәрескә керер алдыннан Бәлкыйс шушы планы турында Хәкимҗан белән сөйләшкән. Ул аңа өч сорау биргән:

1. Тугызынчы класс малайларын таудан шуарга өйрәтәсе бармы, өйрәтелсә, нинди алымнарга өйрәтелә? Трамплиннан сикерергәме? Таяклар утыртып куеп, шулар арасыннан бормалап шуаргамы? — Хәкимҗанның җавабы: таудан егылмыйча шуарга өйрәтергә.

2. Дәрес дөрес бүленгәнме? Ни өчен тауга баруга биш минут җитә, кайтырга җиде минут? Җавап: кайтканда әкрен кайталар.

3. Ни өчен сезнең дәрес кырык җиде минутлык булып килеп чыга? Җавап: аны кем алай бүлеп тора инде, план бит ул минем өчен түгел, «бармы — бар», шуңа гына. Безнең физкультура, изо, муза[1] — плансыз да шәп уза!

Бу мәсьәлә буенча тагын директор катнашып китте.

— Менә Хәкимҗан ул яңа укытучы, аның тәҗрибәсе җитми, бу — тагы да минем гаеп,— диде.— Мин тиешенчә күзәтмәгәнмен, укыту бүлеге мөдиренең аннан башка да эше бик күп, бер Хәкимҗан гына түгел. Ә монысы, әйтәм бит, иптәшләр, турыдан-туры минем гаеп...

Саф татарча, төзек, дөрес җөмләләр белән Нәркис сөйләде. Рус теле буенча өлгереш шактый начар иде, ләкин Нәркиснең бу хәлгә бик аек караганы сизелде. Ул өстәл янынннан чыгып, уртагарак басып сөйләде — бөтен киеменең пөхтәлеге, сыланып торуы, бик төз гәүдәсе, кызыл иреннәре, биек үкчәле туфлилары һәм чәчен төзәткәләгән саен сирпелеп киткән затлы хушбуй исе белән ул бала итәкле, изелгән киез итекле, бумази чалбарлы укытучыларның барысыннан да аерылып тора иде. Аның бөтен кыяфәте, сүзе, үткен, ләкин нурлы күз карашлары «Менә мин сезгә иш түгел, үзегезнең арада мин булу сезнең өчен бәхет» дияләр сыман иде.

— Рус телен балаларыгыз бик начар белә,— дип тәмамлады ул сүзен,— балалар гына түгел, укытучылар, сез үзегез дә рус телен белмисез. Я, әйтегез, кайсыгыз бүгенге көндә рус телендә әдәбият укый? Ә? Әйтә аласызмы? (Укытучылар карашларын түбән төшерделәр.) Ә менә

[1] Изо, муза — рәсем, җыр.

мин ни өчен татар әдәбиятын укыйм? Мина нигә ул? Мин бит татар әдәбияты укытмыйм. Нигә мин өстәлемдә Гейне шигырьләренең немецча басмасын тотам? Русларда бер мәкаль бар: каков поп — таков приход, диләр. Балалар — укытучыларына охшаган. Мин менә уку елы беткәнче эшләп карыйм, аннан ташлап китәм. Минем университетта алган белемемне бирергә монда җирлек юк. Карагыз ул быелгы сигезенчеләрне. Мескеннәр. Сарык көтүе бит. Гәрәевтән сорыйм: «Ты по-русски что-нибудь понимаешь?» — дим. Авызын ахмакларча ерган да мина карап җавап бирә: «Понимаешь»,— ди. Миннебаевны тактага чыгардым. «Пахать» дигән фигыльне хәзерге заманда күплек санда төрләндер, дим. «Мы пахаем, вы пахаете, они пахают» дип сөйләп йөрәгемне боза. Беләсезме, болай булса мин нишлим? Тиздән валерианка эчә башлыйм...

Нәркиснең сылу гәүдәсе чайкалып китте, тавышы ватылды. Аның күзләрендә яшь күренде. Ләкин бер секундтан ул элеккеге хәленә кире кайта алды һәм салмак хәрәкәт белән чәчләрен күз өстеннән күтәрде дә горур гына үз урынына барып утырды.

Гүзәл, бик гүзәл бу Казан кызы!

Чыннан да, адашкан тутый кош бу!

Иң ахырдан Хушият абзый сөйләде. Хушият абзый — заманында зур эшләрдә эшләгән кеше. Кайчандыр ул волкомда мәгариф бүлеге мөдире булган, Акбалыкта директор да булган, авыл Советы председателе булып та эшләгән, сугыш вакытында мәктәптән китеп торган — кладовщик булган. Аның кайчан нинди уку йортын тәмамлаганын бер ходай үзе белә! Гомер буе житәкче эшләрдә эшләгән кеше булгангадырмы, нигәдер Хушият абзый һәр җыелышта әле дә булса йомгаклау сүзе сөйләү аның бурычы дип саный һәм йомгакламыйча калмый. Теләсә нинди җыелышта ул бары тик иң зур дәрәҗәле кеше янында гына утыра һәм, һичшиксез, иске блокнот, тышының лагы купкан гади карандаш чыгарып нәрсәдер яза. Какшаган иске күзлеге борын очына гына эленгән булыр, тышын таракан кимергән күзлек тартмасы, һичшиксез, өстәлдә булыр. Аннан соң ул теләсә кайсы җыелышның сәяси ягына юнәлеш бирүне һәрвакыт үзенең изге бурычы дип саный һәм гомуми тигезлектән, гомуми юнәлештән аз гына тайпылулар була калса, аларны төзәтми калмый. Директор аның йомгак сүзе сөйләү гадәтенә инде күнегеп беткән иде — бүген дә каршы килмәде. Саргылт-чия толстовка кигән Хушият абзый акрын гына торып басты, бөтен кешене күзлек өстеннән бер кат сөзеп карап чыкты.

— Иптәшләр... Барыгызга да мәгълүм, совет педагогикасы безнең укытучылар армиясе алдына гаять зур әһәмиятле бурычлар куя. Бу бурычларны без барыбыз да бер булып, җиң сызганып, көчебезне кызганмыйча эшләсәк кенә намыс белән үтәп чыга алаячакбыз...

Дөп-дөрес, ап-ачык фикерләр. Рушад сәгатенә карады. Кич булган, ашар вакыт житә иде. Диванда утырган берничә укытучы кыз аңа записка җибәрделәр:

«Тарихчы иптәш, сәгать ничә?» Рушад бармаклары белән күрсәтте: биш. Кызлар мутланып башларын селекteләр, рәхмәт әйттеләр. Бичаралар! Кайчан кыз булып йөри аласыз соң сез! Кичен тагын бер җыелыш бар бит әле.

Ә Хушият абзыйның кич чыгасы юк, аңа җыелыш булсын, аңа сөйләргә мөмкинлек бирсеннәр. Мер-мер итеп ул тезде дә тезде...

— Начар укучы юк, начар укытучылар гына бар, иптәшләр...

Нәркис шул вакытта бер җыерылып куйды. «Шерт» итеп күн сумкасын ачты да Гюгоның «Отверженные» дигән китабын алып битараф кыяфәт белән укый башлады. Хушият абзыйга, гомумән, монарчы Нәркиснең әле үзе башлап сүз катканы юк иде. «Исәнмесез — исәнмесез»дән узганы юк иде.

— Иптәш Шәмсетдинов бик дөрес әйткән, иптәшләр, минем дә үзебезнең коллектив турында кайбер фикерләр әйтәсем килә...

Ничектер шулай килеп чыкты, нәкъ шул секундта Рушад тамагын кырды. Хушият абзый сискәнеп шул якка карады, һәм аларның караш-лары очраштылар. Хушият нигәдер каушап калды, сүзенең әргәсен югалтты, буталды.

— Безнең арада да тиешенчә эшләмәгән кешеләр юк түгел дип әйтәсем килә минем. Белмим, бәлки, мин ялгышамдыр, ялгышсам, иптәшләр төзәтерләр, ләкин укучылар белән эшләүдә кайбер җитешмәгән яклар очраштыргаламый түгел дип әйтер идем мин, иптәшләр...

Речь тәмамланды. «Төрлеләр»гә күчелде. Шәмсетдиновның күрсәтмәсен нигез итеп алып, өченче чиректә кайсы класс нинди өлгереш бирү турында сүз башладылар. Ләкин директор «нинди өлгереш» дигән сүз белән бөтенләй килешергә дә теләмәде — сүз бары тик йөз процент өлгереш турында гына барырга мөмкин, диде. «Йөз процент» сүзен ишеткәч, Нәркис тагын бер тапкыр җыерылып алды, тагын сумкасын «шерт»ләтеп ачып япты.

Директор һәр предметникны аягүрә бастырып йөкләмә алдыртты.

— Только йөз процент, иптәшләр, шуннан бүтәнне ишетәсем дә килми,— диде.

Иң башта «йөз процентны» Хушият абзый бирде. Тагын бер кыска речь тотты:

— Иптәшләр, мин әйтер идем, быелгысы елны, кайсыдыр ки, балаларның инде тамагы ач түгел, шушындый елны өлгерешне йөз процент итү гайре табигый хәл булмас дип әйтәсем килә минем. Иптәш Шәмсетдиновның күрсәтмәсен нигез итеп алып, мин татар теленнән һәм әдәбиятыннан мәктәп күләмендә йөз процент өлгереш бирергә өстәмә алам һәм минем примеремә башкалар да кушылсыннар иде дигән изге теләкне белдерәсем килә минем, иптәшләр. Бәлки, мин ялгышамдыр, ялгышсам, иптәшләр төзәтерләр...

Рушадның шул вакытта сабырканаты сынды. Урыныннан сикереп торганын сизми дә калды. Ләкин ник торды? Моны үзе дә белмәде. Барысы да аңа борылып карадылар. Директор аңа сорау катыш караш ташлады. Нәрсәдер әйтергә иде бит!

— Мөмкин булса, мин тәмәке тартып керер идем, Сабир Ишмуратович! Мин шулай ияләнгән инде — дүрт сәгатьтән дүрт сәгатькә. Һәр вахта ахырында...

Укытучылар елмаештылар. Рушадка ияреп коридорга Хәкимҗан, тагын ике-өч ир кеше чыкты. Аларның берсе — яшел галифе белән ак фетр кигәне Рушад белән әле генә танышты. Биолог Мостафа икән.

Укытучылар бүлмәсенең ишеге янына куелган партага тезелешеп, педсовет барышын тыштан тыңлап утырган техничкалар шыбырдашып таралыштылар. Кайсы чиләк, кайсы щетка тоткан булып классларга таба сибелделәр...

Бераздан йөкләмә бирергә тәмәкечеләрне дә чакырып керттеләр. Рушадның коллектив алдында беренче сөйләве иде — сүзен кыска тотты:

— Укучылар белән танышып чыкмыйча торып, бернинди йөкләмә өстәмә алмыйм,— диде.

...Рушад җыелышның кичкесенә соңга калды. Гел йөгереп булмый бит инде.

...Өстәл янында авыл Советы председателе Бибисара белән район вәкиле утыра. Пальто өстеннән кожан, башына кызыл күн бүрек кигән ферма мөдире Һадиулла төкерек чәчрәтеп кулын болгый-болгый сөйли. Фермада малларга азык җитми. Терлек биналары сугыш вакытында бик туздылар. Абзар ишекләре асылынды — күгәннәре өзелгәләп бетте. Тимерчелектә моңа яраклы тимер юк. Бәпкә-киштәләр череде. Сыер

абзарлары быелгы яздан калсалар — шөкер диярсең. Өрлек башлары черегән, аларны төзәтергә кирәк. Нибары ике казанда чи утын белән су жылытыла. Бер Һадиулла гына боларны ничек җиңеп чыксын? Аңа ярдәм кирәк.

— «Район терлекчеләренә «Мәгариф» колхозы колхозчыларының мөрәҗәгате»н өйрәттегезме? — дип бүлдерде аны район вәкиле. Һадиулла бер мәлгә тынып калды. Юк, әле өйрәтелмәгән.

— Менә җитешсезлекләр шуннан башлана ул,— дип, сүзгә кушылды Бибисара. Һадиулла аңа гаҗәпсенеп карады.

— Һи-и-и, председатель иптәш, сез дә шулай дип торгач, белмим инде. Мөрәҗәгать дисез сез. Мөрәҗәгать... «Мәгариф»нең нәрсә аның? Аларның фермасына керсәң — манфактур кибетенә кердем дип белерсең. Утыны, саламы, курмысы — мин сиңа әйтим — бөтенесе китерелгән, өелгән. Безнең кызлар шикелле анда көн саен чи усак түмәркәсен калун белән төйгечләп азапланмыйлар. Вәт сиңа мөрәҗәгать. Аларга, кәнишне, була нәрсә дип күтәрелсәләр дә...

Һадиулла кызды. Күрәсең, бу җыелышта кузгатылган мәсьәләләр күптәннән аның җанын каһәрләп килгән иде, аны туктата алмадылар. Бер читтә моңаеп кына Нәркис утыра...

Һадиулланың сүзләре аның бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга. Бу нинди тормыш соң бу? Нигә болай бу? Университетта вакытта Нәркис моңа әзерләнмәгән иде. Ә монда нәрсә? Һадиулланың бөтен өс киеменнән сыер тизәге, дуңгыз исе килә. Аның бите җилдә ярылган, чуен китегә тәсле булган. Сакалын кырмаган. Ихтимал, ул сакалга юк-бар пәке үтми дә торгандыр. Бер якта — хыялый дөнья, бөек идеаллар дөньясы. Икенче якта — Һадиулла, өрлеге черегән фермалар, «Муму» белән күңеле кузгалмаслык укучылар. «Муму»ны узганда Нәркис үз гомерендә иң зур аяну, өметсезләнү хисләрен кичерде.

Бер бала Мумуны батыргач Герасимның нишләгәнен белми йөдәтте. Ә бит Нәркис нинди дулкынланып сөйләгән иде аны узган дәрестә. Дәреслектә дә бар бит ул бүлек...

— Я, әйт, Герасим шуннан соң нишли? — дип өзгәләнде шунда Нәркис. Читкә карап шактый пошмас кыяфәт белән басып торган кыз тыныч кына:

— Шуннан соң Герасим шәһәрдән колхозга китә,— дип җавап бирде. Нәркис ул көнне квартирына кайтты да ашап-эчеп тормастан караватына егылды. Инде бүген сыер абзарлары.

Һадиулланың тавышы яңгыравыклы. Чит нәрсәләр турында никадәр генә уйларга тырышсаң да, Һадиулла тавышы ярып керә:

— Бездә хәл ничек? Менә ул ничек: бозауларның эче китә — бу булдымы бер. Дуңгызларның илле проценты гына каплатылган — бу булдымы ике...— Татарчаны яхшы беләм дип йөргән Нәркис «каплатылган» сүзенең мәгънәсен анламады. Һадиулла бу сүзне берничә тапкыр кабатлагач, Нәркис сумкасыннан блокнот чыгарып, бер бит ертып алды да нәрсәдер язып, янында гына йокымсырап утырган Хәкимҗанга сузды. Хәкимҗан карага каккан каеры туны эченнән башын чыгарды, язуны укыды.

«Хәкимҗан абый! «Каплатылган» нәрсә дигән сүз ул?» Хәкимҗан ни дип язарга да белмичә катты да калды. Нәркис исә аңа борылып, матур күзләрен сирпеп, аннан җавап көтә иде. Хәкимҗан, әлбәттә, ничек дип язасын бик яхшы белә иде — ләкин бу шәһәр кызы бигрәк нәфис, бигрәк затлы шул. Сүзнең ниндидер берәр матур формасын табарга уйлады Хәкимҗан. Шуңа күрә ул телдән генә аңлатырга булды:

— Слышь,— диде ул, Нәркиснең тамчылы гөл чәчәге кебек матур колагына иелеп,— бу инде ни дигән сүз була: значит, ата дуңгыз белән бергә йоклаган дигән сүз.

Шундый эдәби итеп аңлатып бирүенә куанып, Хәкимҗан тирән генә мышнап куйды, Нәркис тә нәрсәдер аңларга тырышып уйга калды.

— Билгеләнгән агитаторларның барысы да йөриме фермага? — Бибисара, карандаш белән графинга кагып, үз сүзенә игътибар таләп итте.

— Сүзнең дөресе кирәк, иптәш председатель, килгәлиләр. Ләкин соңгы атнада фермага газит-журнал тотып грамм кеше килгәне юк.

— Агитаторлар сезнең эшегездә зур файда китерәләрме? — Монысын район вәкиле сорады. Һадиулла уйга калды. Тамагын кырды.

— Алардан зарар юк,— диде ул. Вәкилне бу җавап чыгырыннан чыгара язды.

— Монда зарар турында сүз булуы мөмкин түгел, файда бармы дип сорыйм мин,— диде.

— Соң инде, иптәш палнамучи, әлбәттә, кеше килүгә бик шат без. Килә бирсеннәр. Халыкара хәлләр, тегесе-монысы. Менә, әйтик, Нюрнберг процессы турында бик әйбәт булыр иде. Лекция-фәлән. Ә болай укытучылардан зарланыр хәлем юк, ярдәм итәләр. Әнә газит укып кына түгел, тегенди ярдәмгә дә мохтаҗ мин. Пример, укытучы Хәкимҗан атнасына өч-дүрт тапкыр кереп чыга. Балалар белән. Аларның ярдәме дә бик зур...

Йомгаклау сүзе белән Бибисара чыкты.

Арып-талып соң гына таралыштылар.

Иртәгесе өчен планнар төзисе, дәрескә хәзерләнәсе бар иде. Рушад җыелыштан тәмам алҗып кайтты. Җиделе лампа сүндерелмичә кысып кына куелган, өйдә ярым караңгы, мич астында мунча сиерчыгы сайрый иде. Өйдәге хәрәкәтне сизеп, ишек катындагы бозау да уянды. Торып басты, койрыгын чәнчеп, озак итеп киерелде, тәнен дерелдәтеп алды. Аннары озак, бик озак итеп идәнне юешләде... Рушад өстәл янында аз гына вакытка башын куллары белән тотып, күзен йомып утырды. Кенигсберг... Өченче ранг капитаны Дроздов аерылышыр алдыннан аңа әйткән иде:

— Укытучы кадрлар да бик кирәк, беләм. Ләкин синдәй укымышлы егетләр флотка да бик кирәк. Монда да кешеләрне укытасы бар. Синең кебек яшьлегем булса, мин, һичшиксез, хәзер үк Ленинградтагы Хәрби Диңгез училищесына китәр идем. Ленинград, беләсеңме, ул нинди шәһәр? Аның Невский проспектыннан бер узу — үзе бер гомер. Аның Смольный, Кышкы Сарай кебек җирләрен күргәнең юкмы? Минем үземнең дулкынлануданн анда тыным тамакка менә. Исеңдә тот — хәзер тарихи чор башлана. Европа илләренә азатлык яулап алып биргән Совет Кораллы Көчләренең дәрәҗәсе, абруе хәзериксез-чиксез. Совет Кораллы Көчләренең офицеры булу дөньядагы иң почетлы, иң югары миссия ул. Ә диңгез офицеры...— Дроздов шаяртып та алды: — Невский проспекттан, мин сиңайтим, барасың — үтүкләнгән чалбардан, ялт иткән төймәләр, лентаң җилдә уйный, кырынган, чәчләр төзәтелгән — нәкъ кияр шикелле. Барасың: бер ягыңнан бер кыз уза, сине күрә — гөрс! Асфальтка егыла. Күрәсең: каршыңа икенче бер гүзәлкәй килә, күзләрегез очраша — гөрс! Аңысы да барып төшә. Шәп бит, ә?

Болар исенә төшкәч, Рушад елмаеп куйды.

Ләкин дәрескә әзерләнергә кирәк иде. Иртәгә авыр тема — «Кызылкашлар белән Сарычалмалылар восстаниесе».

Шулай да никадәр күңелсез уза гомер!

Шул булдымы яшьлек? Шул булдымы хыялда көткән тыныч тормыш, «гражданка»? Күңелдә бушлык, бушлык. Ичмаса, бу мунча сиерчыгы сайрамаса иде. Ихтимал, Дроздов киңәшен тотарга кирәк булгандыр...

*Дәвамы бар*

## Сәйфи Кудаш,

Башкортстанның халык шагыйре

### Боерык

Корабымның тузганын да күрәмен,
Җилле чакның узганын да беләмен.
Өметләрдән яматтырып җилкәнен
Боерык бирә йөрәгемә теләгем:

Кораблар бит йөзәр өчен төзелә
Туры карап упкыннарның күзенә.
Тиеш түгел ярда ятып черергә,
Әйләнгәнче йомычкага, йөрергә!

1971

### Үземнеке

Башкалардан чүпләттереп чүпләмен
Мин өстемә дан чикмәне текмәдем.
Үзем чәчтем, үзем җыйдым сүсләрен
Һәм эрләдем аркау, буйлык җепләрен...

Я Акмулла, я Тукайдан өлге алып,
Чүпләмнәрен үземчәләп чүпләдем.
Үзем кистем.
Үзем типчеп җөйләдем...
Ни булса шул, үземнеке теккәнем!

1971

### Әгәр дә

Узсаң озын сукмакларны,
Ярып тездән баткакларны,
Пычраклары йокмый булмас,
Кичсәң ташлы чокырларны,
Чәнечкеле чытырманны —
Тәннәреңне ертмый булмас...

Тән яраларын бәйләрсең,
Кием пычрагын уарсың.
Әгәр вөҗданың тапланса,
Аны ни белән юарсың?

1971

## Куркам

Кышкы урман тынган җырдан...
Сырган да энҗе юрган —
Бөркәнеп шуны башыннан
Татлы йокыга чумган...

Шыңгырдатмаска тырышам
Кышның көмеш кыңгыравын.
Бүлдереп тылсымлы төшен,
Уятырмын дип куркам...

1970

## Урманда

Шу... итеп китте йөрәгем
Күргәч карга урманын.
Ташландык авыл шикелле
Шомга күмелеп торганын.

Тәрәзләре томаланган
Өйдәй тора оялар.
Соң, кайчан бу ояларга
Кошлар килеп оялар?

Кышлы булса булсын урман,
Кошсыз тормасын икән.
Каргалар булса да анда
Шаулап җырласын икән!

1971

## Дәрәҗә

Таудай авырлыктан егылмады,
Күтәрде.
Ядай кайгылардан сыгылмады,
Үткәрде.
Таң калдырды, шулай, күпләрне.

Бер илегә генә үскән иде,
Башы әйләнде.
Тик бер касә бәхет эчкән иде,
Теле бәйләнде.
Менә шул аны күтәреп бәрде!

1971

## Җилләр искәндә

1

Җилләр иссә әгәр җилкәдән,
Җиңел булыр алга барырга.
Үрмәләргә өскә, үрләргә,
Килмәс сиңа һич тә авырга...

Нинди булуыңа карамас,
Бәхетләргә табан этәрер.
Һичбер төрле түләү сорамас,
Тәхетләргә чаклы күтәрер...

2

Җилләр каршы яктан искәндә,
Гәүдәңне кирегә эткәндә,
Күзләреңә тузан сипкәндә,
Башыңны түбәнгә бөккәндә; —

Алга табан атлап кара син!
Чайкалдырмый өмет корабын,
Ялгыз якынайтып кара син
Йөрәк белән теләк арасын!

1971

## Каршылый да белер әле

Беләгем алып беләккә,
Йөрәген салып йөрәккә
Озатты ул мине юлга.
Ялгызлыктан боегырлык,
Иблис-фәлән сыенырлык
Калмады буш урын анда.

Беләктә тоям беләген,
Йөрәктә — типкән йөрәген.
Күземдә моңлы күзләре.
Кайтыр юлга карый-карый,
Кавышу көнен саный-саный
Каршылый да белер әле...

1970

## Сөйләмә син

Сөйләмә син миңа үлем турында.
Көйләмә һич аның көен җырыңда.
Кундырма котсыз шәүләсен сыныңда.
Асрама салкын хәнҗәрен кыныңда!

Исраф итеп урынсызга көчеңне,
Шыкырдатма барлы-юклы тешеңне.
Сакла, ичмасам, киләсе ел яз көне
Орлык булып җиргә чәчелер көшелне!

Сына калсаң — корыч кебек чыңлап сын.
Тына калсаң — ташкын кебек гөрләп тын.
Сүнеп китсәң — метеордай дөрләп сүн.
Үлеп китсәң — Тукай кебек җырлап үл!

1970

## Бакчама кем керде икән

Бакчама кем керде икән,
Гөлләрем күшеккәннәр.
Гөлләремне күшектереп
Кемнәр соң үчеккәннәр?

Гөлләргә ни булды икән,
Сөйләшмиләр гөлләрем.
Кемнәр тотлыктырды икән
Гөлләремнең телләрен?

Кем шулай карады икән,
Күз тигән гөлләремә.
Кемнәр соң көнләште икән
Гөл кебек көннәремә?

1970

## Булмаса

Карап торсам үткән еллар ягына,
Икәү узган юлларымны сагынам.

Арулардан баш авырткан чагында,
Дару сузган кулларыңны сагынам.

Әгәр бүген шатлыкларга абынсам,
Кайгыларны җиңгән чакны сагынам.

Артта калган кичләремне актарсам,
Сине күргән төшләремне сагынам.

Зар булганда шатлыкларның таңына,
Син яктырткан төннәремне сагынам.

Ялгызлыкның газабына тарысам,
Бик сагынган чакларымны сагынам.

Сагыныр мәлең, табыныр ярың булмаса,
Тордың ни син, тормадың ни дөньяда!

1971

◇◇◇◇◇◇◇◇◇

**Мирсәй Әмир**

# БАЛЫКЧЫ ЯЛГАННАРЫ

ШАЯН ПОВЕСТЬ

**САНСЫЗ БҮЛЕК**

## Такыр башлы кеше



— ...

— Бу урын буш түгелме?

Миннән сорыйлар. Ишетмәгәнгә салышып, «Казан утлары»н укып утырган булам. Күренеп тора ич, портфель куелган, димәк, урын буш түгел. Ләкин сорау бирүче кеше шактый әрсез булып чыкты. Мин игътибарсыз утыргач, портфель белән сөйләшергә тотынды.

— Әй, син кем фортфеле?

Кемдер көлеп тә җибәргәч, тагы әрсезләнә төште бу.

— Ник дәшмисең,— ди портфельгә.— Телеңне йоттыңмы әллә? Юк, телеңне түгел, ярты пот бәрәңге йоткансың син.

Үзем дә көлеп җибәрә яздым. Күрәзәлеге дә бар икән шайтанның. Шулай да һаман ишетмәгәнгә салынып утырам әле. Янәсе, журнал белән мавыгып, бөтенләй әйләнә-тирәмне онытканмын. Оныту кая инде? Күңелемдә ачу кайнап утыра. Бердән, вакытында килеп җитмәгән өчен Мөхәммәтшага ачуым килә. Икенчедән, менә бу әрсез алабай. Сөйләндереп тормыйсы иде, әрләп кенә җибәрәсе иде дә бит үзен,— булмый. Миңа поездда әрләшергә ярамый. Бигрәк тә таныш булмаган пассажирлар белән бервакытта да сүзгә килешмәскә ант иткән кеше мин. Ачы тәҗрибә нәтиҗәсе инде, кат-кат авыз пешү нәтиҗәсе. Берсендә шулай әрләшкән кешем мине чакырган дустым тарафыннан ук дәшелгән кунакташым булып чыкты. Бер үк табында бер-беребезнең исәнлегенә чәкешеп утырырга туры килде. Икенче бер вакыт, олы-олы кешеләр аяк өсте барганда, яшь кенә бер егетнең җәелеп утырып баруына бик ачуым килде. Шулай да, үземә урын бирмәве өчен дәшми түзгән идем әле, янына бер йөкле хатын килеп баскач та гамьсез утырып баруына чыдый алмадым, әрләп ташладым.— Күсәк, дидем, оятсыз, дидем. Җитмәсә, ата-аналарын да телгә алдым. Ачу килгәндә сөяксез

тел ни генә әйтми... Күсәк дигәнем бик якын һәм хөрмәтле танышларымның сөекле уллары, имеш. Өченчесендә, бер купшы гына ханымга каты сүз әйтеп хурлыкка калдым: хатынымның кыз чагында бергә укыган иң якын дусты булып чыкты. Хәтта азагында мондый күңелсез хәл килеп чыкмаган чакларда да кеше белән әрләшеп канәгать калганым юк минем. Ни өчен дисәң, әрләшә белмим. Иң кирәкле зәһәр сүзләр соңыннан, эш үткәч күңелгә килә дә, ах, шулай дип әйтмәгәнмен бит дип, үкенеп йөрим. Булып үткән хәл турында берәрсенә сөйләргә туры килсә генә, вакытында әйтә алмый калган сүзләрне дә әйттем дип, кирәген бирдем дошманның дип, үз-үземне юатырга тырышам...

Шундый ачы тәҗрибәләрдән соң, ун гына ел бардыр инде, поездда берәүгә дә тавыш күтәргәнем юк. И рәхәт. Тәмәке ташлаган кеше сымак йөрим. Кайвакыт менә шушындый бәйләнчекләргә карата тел кычытып-кычытып куйса да, түзәм, дәшмим. Әле дә менә шулай түзеп утырам, берни ишетмәгәнгә салынып, журнал укыган булам. Такылдар, такылдар да, игътибар итүче булмагач, китәр дип өметләнәм. Юк, китми, һаман портфель белән сөйләшүендә дәвам итә.

— Ә-ә-ә, алаймыни, авызың бикләнгәнмени? Шуңа сөйләшмисең? Ачкычың кемдә соң синең?

Тагы көлделәр. Кайсыдыр, ачыктан-ачык миңа ымлап, әйтеп тә куйды.

— Менә бу ак башлы абыйныкы ул...

Эш болайга барып җиткәч, ишетмәгәнгә салынып утыру ярамый иде инде. Барыбер ышанмаячаклар. Сискәнеп киткән булдым:

— Ә? Нәрсә?..

Каршымда гадәттән тыш таныш кыяфәтле берәү басып тора. Башында берет булгангамы, шул ук вакытта ул миңа бөтенләй җиде ят кебек тә күренә. Компотта пешкән чия төсле күз алмаларында ниндидер зәһәр генә ачу чаткысы да бар иде шикелле. Ләкин ул чаткының ялт итеп юкка чыгуын гына шәйләп кала алдым. Күтәрелеп каравыма әрсез юлдашымның чырае яктырып, ничектер тагын да таныштрак булып китте.

— Сумкагызны алсагыз, әллә мин дә бераз утырып торыр идем. Иптәшегез килгәнче генә булса да?

Мондый нәзакәтле үтенечкә мин дә күркәм җавап бирергә тырыштым.

— Әйе шул,— дидем,— рәхим итегез, утырыгыз. Бәлки ул килмәс тә әле...

Бәрәңге йөткән портфель (теге әйткәнчә, ярты пот ук түгел, әлбәттә, биш кенә кило) күз ачып йомганчы челтәр шүрлеккә менеп кырын ятты. Аның урынына, бик ләззәтле көрсенеп, әлеге әрсез юлдашым үзе җәелде. Кызгылт-көрән төстәге болони төймәләрен ычкындырып җибәрде, беретын салып, тап-такыр башын җилләтергә керешә. Мондый жылы көндә, өстәвенә, берсеннән-берсе кайнар тәнле кешеләр белән шыгрым тулган вагон эчендә, капрон плащын белә генә салса яки капчыгына ук тыгып куйган булса, әлбәттә, үзе өчен дә, аның янында утырып баручыларга да җиңелрәк булыр иде. Шулай да, гөнаһсына кермик, плащ эченнән бөркелгән җылы пар мин көткәнчә хәтәр булып чыкмады. Бары тирә-якка татлы ванилин исе генә җәелде. Балыкчы икән, шайтан, әйтәм, таныш күренә.

— Кайдан чыга бу халык?! — диде такыр баш.— Кая баралар? Кая тыкшыналар? Егермедән артык поезд, кайсына төшсәң дә, әз генә соңга калдыңмы, утырырга урын табармын димә.— Җавап бирүче булмагач, үзе үк нәтиҗә дә ясап куйды.— Азды халык, культуралашты. Табигать кочагында ял итүнең тәмен белмәгән кеше табып кара син хәзер?— Җиңен кайтарып, сәгатенә карап алды.— Бәй, кузгалырга вакыт җитте түгелме соң? Көткән иптәшең әллә чынлап та килмәскә итә инде?

— Килмәсә дә гаҗәп түгел, шундыйрак кеше инде ул минем адаш.

«Адаш» дигәнем Мөхәмматша исемле бер иптәш. Ни өчен «Адаш»?— анысы тора-бара аңлашылыр. Дустым дияргә дә була. Сөйләшеп утыру өчен бик күңелле кеше. Тик мин яратып бетерми торган гадәтләре бар. Беренчедән, дөньяда намуслы кеше барлыгына ышанмый. Намус дигән нәрсәнең һәркемдә шәхси мәнфәгать таләп иткән күләмдә генә булуы мөмкин, дип хөкем йөртә. Җәмәгать интересын үз мәнфәгатеннән өстен куйган кеше дөньяда юк аның өчен. Булуы мөмкин дә түгел, дип бәхәсләшә. Икенчедән, вәгъдәсезлеген яратмыйм. Менә бит, килмәде. Ә кичә без аның белән нәкъ менә шушы Васильево поездында, нәкъ менә шушы — арттан икенче вагонда очрашырга сүз куешкан идек. Алдан килгән кеше урын алып куярга тиеш иде. Алган урыным әнә кем өчен булып чыкты. Хәер, килмәве яхшырактыр да әле. Аның җыен тузга язмаган әкиятләрен тыңлап утырганчы, ичмасам, укып барырмын. Кулымда журналым бар. Ләкин... күзем «Казан утлары»нда, ә күңелем һаман шул адашымнан аерыла алмый. Нигә килмәде икән? Нәрсә дип акланыр икән? Мөгаен, тагын берәр анекдотка охшаган вакыйга уйлап табар әле, пошляк. Пошляк? Әйе, бу минем аны, гаепләүдән бигрәк, үз итеп, яратып әйтүем. Туп-туры үзенә дә әйтәм. Ачуланмый, көлә генә.

— Әшәке сүзне сөйләүче генә түгел, аны тыңлаучы да пошляк! — ди.— Димәк, син дә,— дип куя миңа һәм сыны катып көлә. Мин дә көләм. Ә бит чынлап та әшәке сүз сөйләүне гаеп саныйбыз, шуның белән бергә аны тыңларга да яратабыз. Җае туры килгәндә үзебез дә телебездән килгән кадәр сөйләргә тырышабыз. Гади халык кына түгел, укымышлылар да, җаваплы эшчеләр дә, хәтта укытучылар да. Хәтта, гафу итегез, хатын-кызларыбыз да... Нигә алай икән ул? Әллә, ялгышып, бөтенләй гаепсез, гөнаһсыз сүзләрне әшәке дип, оятсыз дип йөртәбез микән? Туктале, бу бит бик...

Күзләрем белән журнал битләренә йотылган хәлдә шундый кызык уйларга чумып, филология фәне буенча бер ачыш ясыйм мәллә дигәндә, зиһенемне бүлделәр. Шул әлеге дә баягы такыр баш. Аның кемнәр беләндер һаман гәпләшеп, өзлексез диярлек сөйләнеп баруы баядан бирле колагыма кереп тора, тик иләнелгән тәгәрмәч тавышлары шикелле, зиһенемә кагылмый үтә иде. Бара торгач, тегенең турыдан-туры миңа төрттереп сөйли башлавын сизенеп, айнып киткәндәй булдым. Күрәм: миңа карап елмая бу. Шундый мәгънәле итеп елмая, әйтерсең минем нindidер бик яшерен серемне белә.

— Укымыйсыз бит,— диде бу миңа, елмаюын җыеп алырга да кирәк тапмыйча.— Күреп торам, укымыйсыз. Укыган булып кыланасыз гына. Нәрсә, безне күрәсегез дә килмимени? Бигрәк тә мәхәббәтсез күренәммени?

Әнә бит нинди нәтиҗә ясый кеше! Ничектер уңайсыз булып китте. Андый чакта дөресен әйтеп кенә котылсаң котыласың.

— Дөрес,— дидем,— укымыйм, укысам да, күзем генә укый, күңелемә барып җитми. Ләкин сезне күрәсе килмәгәннән түгел, күңелемне бүтән уйлар читкә алып киткән.

— Алай да була. Беләсезме, бервакыт мин шулай, күршеләремне ишетмәгәнгә салышып, укып барган булып, нинди уңайсыз хәлгә кала яздым?

— Белмим шул. Ничегрәк булды соң?

Җитә калды такыр башка. Бик җитди эшкә хәзерләнгән кебек сөйләргә җыена башлады.

— Менә моны әнә шунда, баш очыгыздагы чөйгә элик әле башта.— Ул ике тез арасына кыскан җәенке төпле, цилиндр фасонлы, кабыргасына кисәләр тегелгән, каеш баулы зәңгәр капчыгын тартып чыгарды. Мондый капчыкны ул елларда, кагыйдә буларак, яңа гына мөгез чыга

башлаган яшь үгез кебек төксе чырайлы үсмер егетләр йөртә иде. Шундый нәрсәне инде пенсия яшендә булган бу карт кулында күрү мина бик сәер тоелды. Шаяртмый булдыра алмадым.

— Мин әле сезнең болониегыз белән беретыгыз гына яшь дип уйлаган идем. Капчыгыгыз тагын да яшьрәк икән.

Җәберсенмәде тагы.

— Шулай кирәк ул,— диде.— Без, юләрләнеп, яшьләрнең үзебезгә охшавын телибез, безнеңчә булырга өйрәтеп аларны да азаплыйбыз, үзебез дә азапланабыз. Уйлап карасаң, бик күп мәсьәләләрдә үзебезгә яшьләрдән өйрәнергә кирәк икән. Кием-салым ягын гына алып карагыз, әйтик, берет. Дөрес, бездә яшьләрдән башланды. Ә бит картлар өчен бигрәк тә кулай. Туңа башладың — башыңа киден; эсселәдең — алып кесәнә тыктың. Кепканы да, эшләпәне дә алай итеп булмый бит. Безнең татар түбәтәен дә булмый. Формасы бозыла. Шуңа күрә хәзер беретны картлар эләктереп алды да... Яшьләр кия торган пальтоларны кара син. Синтетика, очып тора! Җиңел! Ә безнең буын күтәреп йөргән берәр потлы драп пальтолар? Кыш көне өстеңә кигән киемнәреңне бер төенгә җыеп бәйлә дә җәйге челләдә шуны аркаңа күтәреп, бер генә квартал үтеп кара. Безнең буын кешеләренең ярты энергияләре нәрсәгә әрәм булганын, ә кайбер кордашларыбызның ни өчен срогыннан алда теге дөньяга киткәннәрен аңларсың. Шуңа күрә хәзер яшьләрдән өйрәнәм мин ничек киенергә. Капчыгымда кара күзлегем дә бар, тик анысына гадәтләнеп житә алмыйм әле. Ә шуны кимәү аркасында йөз җыерыла. Әһә, әнә үзе, әнә, әнә... кара тизрәк...

Тәрәзәдән карадым. Аракчино тукталышы иде бугай. Площадкада, тыз-быз үтеп йөрүчеләргә игътибар итмичә, күзгә бәрелерлек дәрәҗәдә кызык киенгән өлкән бер кеше басып тора. Башында киң кырыйлы соры эшләпә, киң җилкәле, кулбашлары туры почмаклы итеп тегелгән соры макентошы аяк йөзеннән, арт яктан җиргә тиеп торган киң чалбар балагы астыннан сары шиблетының тупыйк борыны гына күренә. Әйтерсең ул чын тормыштан түгел, театр сәхнәсеннән урамга чыгып баскан бер персонаж...

— Күрдеңме? — диде такыр башым.— Шәп киенгән бит! Юк, мин чынлап әйтәм. Әле кайчан гына болай киенү безнең мечта иде. Ә хәзер?.. Мин үлүдән курыкмыйм, әмма берәр вакыт үзем дә әнә шул кеше хәленә төшмәсәм ярар иде дип куркам...

Чынлап та кызык кеше мәллә бу Такыр? Нәрсәдер сөйләргә җыенган иде, онытты, ахры. Исенә төшерергәме әллә?

— Җә! — дидем мин, аның ниятен исенә төшерергә теләп.

Аптырабрак калды.

— Ә?

— Капчыкны элеп куйдык.

— Ә, әйе шул. Нәрсә димәкче идем әле?

— Китап укып барып, оятка...

— Ә, әйе, әйе... Болай булды... туктале, мәгез әле, монысын да элеп торыйк әле.— Ул плащын салып миңа сузды. Капчык өстенә эләргә җайсыз иде. Бераз арырак — күрше урын турындагы буш чөйгә элдем.

— Ераграк элендә инде дә...

— Зарар юк,— диде,— беркая да китмәс. Күздән яздырмыйм мин аны. Плащ кына түгел, мечта бит ул! Әйе, әйе. Беләсезме, шушындый, үзе җиңел, үзе юка, үзе су үткәрми торган бер кием турында гомер буена хыялланып йөрдем. Дөньяда шундый материал эзләп табарлык кына да акыл ияләре юк микәнни, дип таныш-белешкә сөйләгән чаклары да күп булды. Бар икән бит, таптылар бит! Молодец итальяннар. Безнекеләр дә молодец, буржуй уйлап чыгарган нәрсә дип, куркып тормыйлар, ала бирәләр кирәк нәрсәне. Яратып киям. Валлаһи менә, хәзер

шуңардан да кадерлерәк киемем юк. Шагыйрьләр әйтмешли, гашыйк мин бу болонига! — Хәзер ул кыска җиңле, күкрәк турындагы кесә капламалары өстенә ак төймәләр тагылган һәм чалбар өстеннән чыгарып киелгән ике чабулы шотландка күлмәктән генә иде инде.— Тагын бер мечтам бар әле,— диде ул, татлы елмаеп.— Караватурында. Ничек итеп, мин әйтәм...

— Туктагыз инде, абзый кеше,— дидем.— Бая уйлаганыгызны сөйләмәдегез бит әле.

— Ә, әйе шул. Нәрсә турында иде соң әле?

— Китап укып баруыгыз, оятка калуыгыз...

— Әһә! Болай булды. Нәкъ менә сезнең кебек, әйләнә-тирәмә игътибар итмичә, китап укып барам. Займище тукталышында бугай, шаугөр килеп, бер өер яшьләр керде. Урыннар буш иде, күрәсең, янәшәмә дә, каршыма да утырыштылар. Шатлыклары эчләренә сыймаган кебек кыланалар. Берсе сөйләгәнне икенчесе тыңлап та тормый, бары да кычкыра. Мине, ягъни тыныч кына китап укып барган олы кешене, бар дип тә белмиләр. Бу хәлгә минем бераз кәефем кырылды. Шулай да игътибар итмәгән булам. Шулай җитди укып баруымны күргәч, бәлки тынарлар дип уйлыйм. И шунда берсе, минем уемны аңлагандай, иптәшләренә әйтеп тә куйды.

— Бик шауламыйк, егетләр,— диде.— Папаша бик кирәкле нәрсә укып бара бугай, комачауламыйк...

Бүтәннәре дә тынып калгандай булды. Ләкин тынлык бер секундтан да артык бармагандыр; берсе миңа суктырып әйтеп куйды:

— Папаша үзе дә бервакыт яшь булгандыр,— диде.— Ник безнең көлешкәнгә каршы килсен ул, ә?

Бу сүзләрне ул шундый тон белән әйтте, турыдан-туры үземә төбәп, «шулай бит, папаша?» дип сорыйсы гына калды. Мин исә аны сорамыйча аңлап, «әйе шул» дип җавап бирергә тиеш. Аңлавын аңладым, мәгәр аңлаганлыгымны сиздереп җавап бирергә ашыкмадым. Ишетмәгәнгә салышып, укып утыруымда дәвам иткән булам. Ошамады бит бу кыланышым тегеләргә. Ачыктан-ачык мыскыл итеп сөйләшә башладылар.

— Тимәгез,— дигән була берсе.— Ул бик зур галим булырга тиеш. Алар шулай, укыганда дөньяларын оныта торган булалар.

— Әйе шул,— диде икенчесе,— ни өчен башы такыр дип беләсез? Акылга тыгыз булганга бер чәченә дә урын калмаган.

— Хәзер аны уйларыннан аеру өчен я колак төбендә кыңгырау шалтыратырга кирәк, я таяк белән лепкәсенә кундырырга...

Һаман ишетмәмешкә салынып утырам. Ләкин күңелемнән үкенә башладым инде. Ничек боларны туктатырга да, ничек итеп чынлап та ишетми утырдым дип ышандырырга? Ә тегеләр һаман суктыралар.

— Җитәрегез инде,— берсе, бүтәннәренә ачуланган булып.— Бәлки ул берәр ачыш ясап утыра торгандыр. Әйтик, атом энергиясеннән дә көчлерәк...

— Әйе шул. Күз сал әле, Марс, укыган китабына, ни турыда икән?

Гөнаһ шомлыгына каршы, «Декамерон» дигән китапны укып барам икән. Шул инде, олыгайгач кына мәктәп күргән кешенең бәласе. Яшьрәк чакта укылмыйча казага калган китапларны укып гомер уза. Теге тышына карамыйча ук танып алды бит.

— О-о-о! Боккаччо! — диде бу.

— Боккаччо?! — дип гаҗәпкә калган булды тегеләре... Аңлашыла. Я әле, иптәш эрудит, әйтеп җибәр, Гораций турында Маркс нәрсә дигән әле?

— Старый похабник!

— Ай-яй, папаша!

Болар инде турыдан-туры үземә бәрә башлады.

— Папашаның ни гаебе бар? — дигән була тегесе.— Маркс бит Гораций турында әйткән.

— Ә папаша Горацийдан хужемени?

— Анысы дөрес. Шулай да, хәзерге заманда, житмәсә, безнең совет илендә, олы кешегә шундый китап уку килешәме? Өстәвенә, шулай, дөньясын онытып.

Нишләргә? Бәхәскә керергә дә җай юк. Хәзер болар минем ишетми баруыма ышанмыйлар да ышанмыйлар инде. Ни дә булса әйтергә, бу кыен хәлдән чыгарга кирәк бит. Шунда башыма бер идея килде. Чукрак булып кыландым. Тегеләрне бөтенләй ишетмәгән кыяфәт саклап, капыл гына башымны күтәрдем дә, тәрәзәгә күз салып:

— Бу нинди станция әле? — дип сорадым.

— Лагерьная,— диде берсе.

Учымны җәеп колагыма куйдым да, шактый каты кычкырып:

— Ә? — дип сорадым. Теге миннән дә катырак кычкырып:

— Лагерьный! — дип кабатлады.

Телсез калдылар. Мин сумкамны тотып, тиз генә ишеккә таба китеп бардым.

Шаркылдап көлүләре миңа еракtан гына ишетелде. Үз-үзләреннән көләләр. Шулай кызык иттем мин аларны...

Без дә көлештек. Чынлап та кызыклы карт күренә бу.

— Карале, абзый кеше дип әйтимме, кордаш диемме, кем буласыз сез? Кайдадыр күргән кебек тә булам бугай үзегезне?

— Күргәнегез бардырмы, белмим,— ди такыр башым.— Ишеткәнегез булса, гаҗәпләнмим: яман аты чыкмаган кеше түгел.

— Шулай укмыни? Кем дип белик соң?

— «Чаян»ны алдырасызмы?

— Укып барырга тырышам.

— «Склероз» дигән хикәяне укыганыгыз бармы?

Сагая калдым. Шаярта бугай бит бу мине? Димәк, мине белә, юри белмәгән булып, сөйләндерергә тели. Ярый, белмәгән булсын, без дә белдермәгән булыйк.

— Укыганым бар,— мин әйтәм,— ул хикәяне.

— Укысагыз, әнә шундагы Латыйп карт булам инде мин...

Юк, эш болайга киткәч кереш сүз язмыйча ярамас. Серне ачарга туры килә.

## Кереш сүз

Сер дигәнем шул: мин бу китапны үз исемемнән түгел, гадәттәгечә, уйлап чыгарылган берәр әдәби персонаж авызыннан сөйләтеп чыгарга ниятләгән идем. Менә бу Латыйп карт ниятемне үзгәртеп җибәрде. Укучылар беләдер дип уйлыйм (белмәүчеләр булса, белсеннәр); «Склероз» дигән хикәяне язучы кеше — мин үзем. Үз китабымда үз хикәям турында чит кеше авызыннан сөйләтеп торсам, кайбер дусларым мине тыйнаксызлыкта гаепләр дип куркам. Яхшысы үзем булып сөйлим. Үзем дигәч тә, бу китапны авторның биографик әсәре дип кабул итә күрмәгез. Бу очракта мин язучы Мирсәй Әмир түгел, балыкчы Михаил. Ни өчен Михаил? — Анысы тора-бара аңлашылыр. Ни өчен балыкчы? Бусы инде болай да аңлашыла: чөнки мин чынлап та балыкчы. Дөрес, һәвәскәр генә. Һәвәскәрнең дә шәбе дип мактана алмыйм. Буш садок белән кайткан көннәрем күп була. Ләкин ялганлау өчен балыкчының яхшысы булу мәҗбүри түгел. Шуңа таянып, китабымны «Балыкчы ялганнары» дип атадым да. Оят булса да, тагын шунысын әйтим: мондый исем табуыма бик куандым. Һәр әдәби әсәрдән мотлак дөреслек таләп итүче усал тәнкыйтьчеләрне алдан ук коралсызландырып куям дигән сүз. Әйе,

үзем әйтеп торам: бу китап гел ялганнан гыйбарәт. Дөреслек эзләгән кеше укып та тормасын. Ләкин шуны да онытмагыз: яхшы ялган (мин, әлбәттә, ялганым яхшы булсын дип тырышам) дөреслеккә нигезләнгән була дигән сүз дә бар.

— Болай булгач,— дию мөмкин бәйләнчек дусларымнан берәрсенең,— Нигә бу турыда башта ук әйтмәдең? Нигә дип, әдәбият кануннарын да, полиграфия кагыйдәләрен дә бозып, кереш сүзеңне китабыңның уртасына күтәреп керттең?

— Бусы инде, туганкайларым, мода мәсьәләсе. Газета-журналларыбызны алып карагыз. Бер дә без белгән полиграфия законнары белән исәпләшеп тормыйлар. Мәкаләнең исемен, ягъни башын, баш урынына түгел, текстның я уртасына, я бөтенләй азагына — аяк урынына тыгып куялар. Башын тапсаң азагын, азагын тапсаң башын таба алмый аптырап бетәсең икән, берни кылыр хәл юк. Мода! Безнең яшьләр матбугатыннан яки «Азат хатын» журналыннан гына чыккан дип булмый. Башкала матбугатын карагыз! Шул ук «Литературка», хәтта «Журналист» журналы үзе! Газета-журналлар гынамы? Экранга күз салыгыз. Фильмның яртысын карап беткәч кенә исемен китереп чыгаралармы? Чыгаралар. Мәскәүгә каян килеп керүе дә безнең заман укучысы өчен сер түгел. Беләбез, бөтен дөньяны баскан мода! Шулай булгач, нигә безгә генә калышып торырга? Латыйп карт әйтмешли, үлемнән курыкма, иске мода кешесе булып күренүдән курык!

...Латыйп карт димәктән, кем соң әле ул? Үзе әйтүен әйтте дә бит, «Склероз» хикәясендә сурәтләнгән Латыйп карт булам мин» диде дә бит... укучылар арасында ул хикәяне белмәүче кешеләр дә житәрлектер. Аны әллә кайдан, җыентыклардан, «Чаян» яки «Лит. Россия» битләреннән эзләтеп азапланганчы, шушында кертик тә җибәрик. Укымаган кеше укыр, укыганнары актарып кына үтәр. Күләме зур түгел. Менә ул.

## «Склероз»

Яшең житеп, пенсиягә чыгу — ул әле картаеп эштән чыгу дигән сүз түгел икән. Кемгә ничектер тагы, мин үзем, мактанып әйткәнем булмасын, гомеремдә ял йорты күргән кеше түгел. Җәен ял айларымда Идел буена чыгып шалаш корам да ятам шунда балык тотып...

Ял йорты кая! Врачка барырлык итеп чирләгәнем дә юк. Бәлки анысына барган да булыр идем, клиникаларда чират торуны яратмыйм. Аның өстенә тагын бик яхшы бер күршем бар. Күптәнге дус. Кадермәт кордаш. Әмма дару ярата торган кеше инде. Клиника, больница тирәсендә йөрергә дисәң, аны куш. Һич иренмәс. Көн саен өч-дүрт төрле дару эчмәсә, ашы аш түгел, йокысы йокы түгел. Белмәгән авыруы, белмәгән даруы юк. Берәр жирем авырткандай булса, шуннан гына сорыйм. Авыруымның исемен дә әйтеп бирә, даруын да кесәсеннән үк алып эчерә.

Шулай булса да, картлык шатлык түгел дип, бер дә юкка әйтмәгәннәр, күрәсең. Яшькә олыгаю («картаю» дип әйтәсе килми), әйе, яшькә олыгаю ничек булса да үзен сиздерми калмый икән. Мина да сиздерде бу: хәтер начарлана башлады.

Башта мин үзем моңа игътибар да итмәгән идем. Әлеге кем, Кадермәт күрше эләктереп алды.

— Латыйп дус,— ди бу мина бер заман.— Карап карап торам да, хәтерең чуала башлаган сыман тия,— ди.— Вакытында дәваланырга кирәк,— ди.

— Юкны сөйләмә,— мин әйтәм,— хәтер начар дип докторга барамыни кеше? Адәм көлкесе.

— Көлке түгел,— ди Кадермәт.— Хәтер начарлану — ул склероз билгесе,— ди. Шунда ук склерозның нәрсә икәнлеген бик хәтәр итеп аңлатып та бирде.

Шулай да мин аның киңәшләренә колак салмадым. Хәтер начарланган, имеш. «Кадермәт!» диясе урында мин ана, ялгыш, хатынының исеме белән «Кадрия!» дип дәшкәнмен, имеш. Минем әти мәрхүм берәребезгә дәшә башласа, ялгышып, рәттән җиде баласының исемен кабатлап чыга торган иде. Әллә кайчан үлеп беткән агай-энеләрен исенә төшерә иде. Бер дә докторга бармады. Сиксәнгә кадәр яшәде. Сугыш какшатмаган булса, ачлык еллар килеп басмаса, шәт, әле дә исән булыр иде...

Шулай дип үземне юаткан идем дә, юкка киреләнгәнмен булып чыкты. Безнең әтиләр заманында бәлки чынлап та ул хәтер дигән нәрсәнең әллә ни кирәге булмагандыр. Ә хәзерге заманда...

Хәзерге заманда дигәннән, башта шунысын әйтим әле: малай чактагы теләкләрне олыгайгач тормышка ашырырга туры килсә, бик кызык хәлләр килеп чыга икән ул. Бигрәк тә техника мәсьәләсендә.

Ни хәл итәсең. Хәзер генә бит ул җаның ни теләсә шул бар. Ә без яшь чакта... Хәер, нигә искә төшереп торырга. Ярый әле, безнең буынга хет, олыгайгач булса да, эләкте. Бездән өлкәнрәкләр бит әле әнә дөньяда пылесос дигән машина барлыгын да белми үлеп киттеләр.

Соң булса да уң булсын, дидем дә, иллеДән узгач велосипед алып җибәрдем. Өемдә электрлашмаган җирем калмады. Электр самавыр, электр җылыткыч, электр суыткыч кебекләре турында әйтеп тә тормыйм. Электр белән кырынам. Электр белән кер уабыз. Электр белән идән себерәбез, сызлаган, сыкраган урыннар булса, электр грелка белән генә җылытабыз...

Алтмышка житеп килгәндә фотоаппарат белән мавыгып киттем. Магнитофон белән җенләнеп йөрдем... Алмаган нәрсә калмады инде техника затыннан. Нигә алмаска, магазинда булгач! Акчасын үзебез табабыз...

Шулай да әлеге Кадермәт күрше әйткән авыруны искә алмыйча булмый шул. Әйе, склероз... хәтерне чуалта торган авыру. Теңкәгә тиде бит!

Шуның аркасында велосипедтан егылып кулсыз кала язуларым, демонстрациягә чыкканда фотоаппаратның объективын ачмыйча рәсемгә төшереп йөреп, халык алдында көлкегә калуларым турында әйтеп тормыйм. Кызыгы алар түгел.

Кызыгы болай булды.

Минем йөрәкне иң нык җилкендергән нәрсә көймә иде. Анысына да ирештем. Тик мин көймәле булганда, Идел диңгезгә әйләнеп өлгергән иде шул инде. Балык белән шашкан кешегә нәрсә ул хәзер гади ишкәк? Моторсыз барып чыкмый хәзер. Икешәр километр араны җилгә каршы ишеп барырга туры килгән чакларда аеруча үзәкләрне өзеп искә төшә ул мотор. Әйе, мотор кирәк, мотор!.. Җитмәсә шунда син җан тирләреңне чыгарып, дулкын белән көрәшеп азапланганда, трусик кияр яшькә дә җитмәгән ниндидер бер малай актыгы тырылдатып яныңнан үтеп тә китсә... юк, моторсыз булмый...

Магазинга чыга торган әйбер булгач, анысы да әллә кая китә алмый икән. Ярты ел акча җыйдым, ярты ел сагалап йөрдем дә эләктердем мин моны. Менә дигән мотор. Биш ат көчле. Тик бу вакытта минем пенсиягә чыкканга да бер ел узып киткән иде шул инде.

Менә шунда инде мин хәтер дигән нәрсәнең безнең заманда олыгайган кешегә дә бик кирәк әйбер икәнлеген аңладым. Бигрәк тә мотор тирәсендә чуалган кешегә. Акыллы киңәшкә вакытында колак салмау аркасында, шул Кадермәт күршенең үзе алдында ук адәм көлкесенә калдым бит.

Беркөнне мин аны кунакка чакырдым. Дөресен генә әйткәндә, дөньяда дарудан башка нәрсәнең тәмен белмәүче күршем алдында мактанасым килгән иде. Чынлап та, пенсиягә чыккач, минем эшләр тагын да җанланды. Җәй башында ук Идел буена чыгып, фанердан өй салып куйдым. Агач күләгәсендә генә өстәл. Ятып аласың килсә, карама төбендә җыелмалы караватт. Барыннан да әһәмиятлесе — әлеге моторлы көймәм.

Ул мотор дигәнне кулга иялэштергәнче күпме азап чигүләрем турында әйтеп тормыйм. Кызыгы анда түгел. Хәзер мин аны үзләштереп өлгергән идем инде. Шулай да, кунагым алдында уңайсыз хәлгә калмыйм дип, Кадермәт киләсе көнгә бик җентекләп тикшереп, инструкциясен тагын бер кат күздән кичереп чыктым. Моторның «шәм» дигән бер әкәмәте бар аның. Чәнчә бармак буе гына бер ак нәмәстә шунда. Әмма капризный инде үзе. Әз генә артык майландымы — ярамый. Зазоры үзгәрсә инде — бетте, миллиметрның уннан берен дә сизә.

Шуңа күрә бу көйсез детальне мин алдан ук хәзерләп куйдым. Зазорын тикшереп, бик әйбәтләп корыттым, киптердем дә, яңадан майланмасын дип, моторга беркетми торырга булдым: өй артындагы таш өстенә — кояшка салып куйдым.

Оныта торган гадәтем барлыгын искә алып, балык тоту кораллрымны көймәгә үк төшереп куйган идем дә, моторны беркеткән вакытта я өсләренә басылыр дип, кире яр буена чыгардым.

Ярар. Кунаклар килде бер заман. Исәнлек-саулык, якты чырай, кайнар чәй... Алары вак мәсьәлә. Тизрәк балыкка китәргә кирәк.

— Әйдә, Кадермәт дус, төшке ашка бер-ике чуртан тотып кайтыйк әле.

Кадермәт ничек каршы килсен инде? Кунак — хуҗаның ишәге. Ә мин үзем балыкка дигәндә кукуруз күргән сыердан ким түгел. Көймә белән өй арасындагы сукмак өстендә өермә уйнатабыз. Мин йөгерәатлый моторны алып төшеп, көймәгә беркеткән арада Кадермәт тә тик тормады. Балык тоту кирәк-яракларын, ишкәк, якорь кебекләрне көймәгә ташып куйды. Тиз генә кайтырга туры килмәсә дип, ашарга-эчәргә алырга да онытмадык. Яңгыр-фәлән ихтималына дип, плащлар да да чыгарып салды. Хатыннар көлгән була бездән:

— Житәрегез инде,— диләр.— Котыпта кышларга җыенмыйсыздыр бит!

— Чынлап та,— мин әйтәм,— әйдә, күрше, алтын вакытны әрәм итмик.

Үзем ишкәккә утырдым. Кунак пока түрдә. Мотор янында. Чөнки затонны чыкмыйча, моторны кабызу хәтәр. Бераз ишеп барырга туры килә. Бусы минем өчен уен гына инде.

Барлы-юклы йөз метр ара — нәрсә ул? Балык дәрте белән ярсыган йөрәк — «э» дигәнче узып та киттек. Алдыбызда җәелеп яткан диңгез ачылуга, мотор янына үзем күчтем, ишкәкләрне кунакка бирдем.

— Ишеп азапланма,— мин әйтәм.— Шуны гына кара: көймә ярга таба борылмасын. Мин хәзер моторны ходка җибәрәм...

Иң тантаналы, шуның белән бергә иң җаваплы минутлар! Бөтен борасы винтикларны бордым, ачасы тишекләрне ачтым. Маховикны әйләндереп җибәрү өчен махсус түгәрәккә чорналган киндерәне тартасы гына калды. Бер... ике... һап!..

Гадәттә бик авыр тартыла торган иде. Бу юлы, әллә кунагым алдында сынатмыйм дип тырышканга көчем артып киткән инде, ничектер бик җиңел әйләнгән кебек булды. Аңа карап мотор кабынып китмәде, әлбәттә. Бер тартуда кабыну минем практикада булган хәл түгел. Өчдүрт тартканнан соң «пыт-пыт» итеп куйса, бик шөкер инде. Тагын бер тарттым, тагын... тагын...

«Пыт-пыт» итмәве шикләндерми. Артык җиңел тартылуы күңелгә шом салды. Карасам... Ах, юләр!.. Шәмне урынына борып куярга оныткамын бит! Ә шәм?.. Кайда соң әле ул? Ах, карт юләр!.. Мин бит аны, коры торсын дип, өй буендагы таш өстенә куйган идем...

— Бор,— мин әйтәм,— күрше, көймәне ярга! Иш! Син шушында көтеп торырсың. Мин хәзер йөгереп кенә барып, шәмне алып килим...

Кадермәт көлә:

— Менә нишләтә сине склероз! — ди.

Ләкин кызыгы бу түгел әле.

Кадермәтем көлә калды. Ә мин яр буйлап йөгердем. Үзем йөгерәм, үзем күңелдән теләк телим: хатын күрмәсә генә ярар иде... Көлә торган гадәте бар. Үзе көлеп кенә калса бер хәл. Минем хур булуларым турында көлә-көлә кешегә сөйләргә ярата.

Теләгем кабул булды. Хатын өй тирәсендә күренми. Кунагы белән чөкердәшеп, агач күләгәсендә чәй эчеп утыралар, ахрысы. Әйдә, рәхәтләнсеннәр...

Мин яр астыннан үрмәләп кенә менеп, су анасының алтын тарагын урлаган малай шикелле, таш өстендә яткан шәмне тиз генә эләктердем дә кире чаптым...

Кадермәт көлә:

— Нигә хәзерге заманда картлар арасында сакал йөртү мода түгел икән? — ди.

— Сакалның... Уф... монда ни катнашы бар?.. Уф..

— Нигә? Иске заманча йөртсәң, синең хәзер көрәк кадәр чал сакалың булыр иде,— ди Кадермәт.— Шундый сакаллы Латыйп картның, детсад баласы кебек, трусиктан килеш Идел яры буйлап тыр-тыр чабып йөрүе бигрәк тә күңелле булыр иде.

— Заманы ул түгел шул, күрше. Менә хәзер карап тор син Латыйп картыңны!

Бу арада мин көймәнең түренә — мотор янына кереп басканмын, көймә, борыны белән суның уртасына таба карап, кузгалган иде инде. Озак җилләп коп-коры хәлгә килгән шәмне үз урынына борып куйдым.

— Әйе,— мин әйтәм,— Кадермәт күрше. Менә хәзер карап тор.

Бик әйбәтләп кенә киндерәне кирәк җиренә урадым. Кызыграк булсын өчен, бисмилла иррахман иррахим дигән булдым. Аннары бөтен көчкә киерелеп тартып җибәрдем. Тәк... зарар юк. Бер тартуда гына була торган эш түгел. Беләм. Икедә түгел, өч тартуда да нәтиҗә булмавы бик табигый. Хәтта дүртенче тарту да җәл түгел. Әйдә, мотор җылына төшсен. Ә менә бишенчесе, карап тор. Һәрхәлдә, «пыт-пыт»ы булмый калмас. Раз, два, һап!.. Тукта. Никтер булмады әле. Бераз күңел кырылды минем. Шулай да сынатмыйм. Мондый хәлләр дә таныш безгә. Биш тә тартасың, ун да тартасың. Каһәр суккан нәрсә ул көймә моторы. Кайчак егерменче тартуда гына пырылдый башлый. Шуңа шүрә өметемне өзмим, тартам да тартам. Ун тартам, унбиш... Уф!.. Актыккысы... егерме!.. Юк, пытылдамый. Болай булгач, шәмне яңадан чистартып, зазорын үзгәртеп куймыйча эш чыкмый... Моторны яны белән әйләндереп, шәмне алып карыйм дисәм... шатлыгымнан кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым.

— Ах, карт юләр! Ха-ха-ха!..

— Соң, шәмне урынына борып куйганмын, ә икенче башында ток бирә торган шнурны беркетергә оныткамын.

— Шулай итә ул склероз.— ди Кадермәт.— Күрсәтер әле ул сиңа.

— Болай гына булгач, мин бик шат инде.

— Аңа нигә шатланасың?

— Шатланмыйча! Иң кирәге — тоткарлыкның сәбәбен табу. Ә та-

былгач, мондый гына тоткарлыкны мин аны! Һи... менә, шуның белән эше дә бетте!

Кирәк жиренә шнурны беркеттем дә моторны турылап куйдым.

— Кара көймәнең башын!.. Ррра с!..

Мотор мескен үзе дә тәмам очкынга зар булган икән, бер тартуда гөрли дә башлады. Полный ходка жибәрдем бер заман! Алда көймә борыны бара һавага күтәрелеп, артта минем борын! Уртада Кадермәт. Авыз ерылган тегенең. Ябык нәстә, мин сиңа әйтим, чуртан авызымыни! Нәрсәдер кычкыра бу миңа, тик мотор тавышы аны ишеттерми. Ләкин ишетмәсәм дә аңлыйм: шатлыгын белдерә. Үземнең дә шатлык эчкә сыймый. Кычкырып жырлап жибәргәнемне сизми дә калам шундый чакларда.

Әй, рәхәт! Күңел шундый көр! Әйтерсең табигатьнең иң мәкерле серләрен жиңеп, бөтен галәмне үземә буйсындырганмын! Белмим, атом бозваткычының капитаны боз диңгезен ерып алга барган чакларында бу кадәр шатлана ала микән?

Моторны ходка жибәрә алмыйча ике сәгать азапланган. калуы. күзгалып киткәч, өч-дүрт километр араны ун минут эчендә узып, кирәкле жиргә, ягъни мин алдан чамалап куйган чуртан оялыгына барып та життек. Үзем теләп, әйе, ишетәсезме, үзем теләп! Моторны туктаттым. Ишкәк ярдәме белән боргалап, көймәне нәкъ кирәк ноктага китердем дә якорь төшердем. Яңа якорь. Югыйсә, моңарчы якорь урынына иске үтүк уләксәсе тагып йөртә идем. Кунак алдында килешмәс дип, Кадермәт килүгә махсус ясатып алдым. Менә дигән дүрт тырнаклы тимер якорь. Бавын да алыштырмакчы идем дә кире уйладым. Аның нинди бау икәнен Кадермәт белми ич.

Булды бу.

— Я әле,— мин әйтәм,— Кадермәт кордаш, шул чиләктән кармаклар салган калайны алып бир әле миңа.

— Монда андый калай күренми,— ди Кадермәт.

Йөрәгем «жуу» итеп китте. Шулай ук булыр микәнни? Каһәр суккан склероз!.. Ышанасы килми. Чиләкне үзем алып актарырга тотындым. Чуртан авызын киерә торган корал бар. Кармак ычкындыра торган корал бар. Кыскыч, ачкыч, боргыч, чүкеч кебек кораллар да бар. Ә иң кирәге — кармаклар, блесналар салган калай юк. Мин бит аны, дөмеккерене, онытылмасын, күзгә бәрелеп торсын дигән булып, көймә бәйләгән төпсә өстенә алып куйган идем.

— Син дә инде, Кадермәт күрше, бигрәк тә йоклаган кеше булып чыктың. Шуны да күрмәдеңмени соң?

— Ул склерозыңны дәвала дип, сиңа былтыр ук әйткән идем түгелме? — ди Кадермәт.

Тагын көлкегә калдым. Ләкин кызыгы бу түгел әле.

— Ярар,— мин әйтәм,— кайгырмыйк. Әле мотор суынып житмәгән. Хәзер кире кайтып алып киләбез.

Әйтүем булды, киндерәне тартуым булды. Мотор чынлап та суынмаган икән, тырылдап эшли дә башлады. Көймә үземнән битәр ашыгып алга омтылды...

Тик... бу ни хикмәт тагы? Көймәм мин теләгән якка борылмый, читкә тарта! Шаярма! Жан ачуым белән койрыкны борам. Ул арада көймә, борынын күтәреп, кинәт алга атылды. Янәшәдән генә су өстенә озын ак бау калкып чыкты да көймә астына кереп югалды. Шул ук секундта мотор да шып туктады. Барын да берьюлы аңлап алдым. Якорьны алырга онытканмын икән. Бик нык эләккән булган, күрәсең, биш ат көче белән тартуга чыдый алмыйча, бау өзелеп киткән дә, өскә калкып, моторның винтына чорналган. Кем белә, бәлки мотор да бөтенләй эштән чыккандыр. Хәл еларлык кына инде. Ә мин шатланып азапланам:

ярый әле якорь белән бергә бау да өзелеп калмаган. Хатынның кер элә торган бавын алып торган идем.

Ә Кадермәт моны белми. Һаман үзенекен тукый:

— Сина мотлак дәваланырга кирәк, Латыйп кордаш,— ди.

Ләкин кызыгы бу түгел әле.

Чынлап та, эш бу кадәргә житкәч, Кадермәт күршенең киңәшенә колак салырга булдым. Жил тискәредән искән (ягъни балык эләкми торган) көннәрнең берендә шәһәргә кайтып киттем. Клиникага бардым. Халык күп. Чиратым житкәнче ничек чыдармын дип, борчыла башлаган идем, чиратташ күршем белән танышкач, эшләр жайланды: ул да балыкчы булып чыкты. Бер чыннга биш ялган кушып, су өстендә күргән кызыклар, тотылган һәм тотыла язган зур-зур балыклар турында онытылып сөйләшә торгач, чират житкәнне сизми дә калганмын. Хәтта сүзнең иң тәмле жирендә бүлдергәннәре өчен бераз кәефем дә кырылды әле. Чират житми торган булса да яраган икән, дим. Ләкин берни эшләр хәл юк. Кердем.

— Рәхим итегез,— ди яшь кенә, матур гына бер ханым врач.— Якынрак килегез,— ди. Шундый ягымлы сөйләшә.

Янына ук барып бастым.

— Утырыгыз,— ди.

Утырдым.

— Ягез, тыңлыйм,— ди ханым врач, иркәләп кенә.— Хәлегез ничек? Нәрсәдән зарланасыз?

Аптырый калдым.

— Ничава,— мин әйтәм.— Хәл ярыйсы. Алай зарланырлык эш юк. Инде врач дигәнем аптырый калды.

— Гафу итегез, мин сезне аңламыйм,— ди.— Кай жирегез авырта соң? Нигә килдегез?

Тәмам аптырадым бит шунда! Кай жирем авыртсын соң минем? Юк. Нигә килдем докторга? Һич искә төшерер хәл юк. Онытгым!

Менә нишләтә бит ул склероз.

Ләкин иң кызыгы бу да түгел әле. Иң кызыгы... Әйе, иң кызыгы... иң кызыгы... тукта, иң кызыгы нәрсә иде соң? Менә әле генә хәтеремдә иде бит... Онытгым. Валлаһи газим, оныттым. Иң кызыгын оныттым! Тфү, чәнчелеп киткере, шул инде, склероз!..

## Онытылган «мечта»

Каршымда утырган такыр баш әйтә: «Әнә шул хикәядәге Латыйп карт мин», ди. Тәки күңелгә шик кертте бит, шаяртамы, әллә чынлап та шулмы? Мин бит аның үзен күреп түгел, әлеге Мөхәммәтшадан ишетеп кенә язган идем. Үзе өйдә туры килмәде, туган ягына — Башкортстанга киткән дигәннәр иде. Күбесен уйлап чыгарырга туры килде. Тукта, тагы нәрсә ялганлар икән (чынлап та ялганлавы булса)?

— Ә ул хикәянең авторын күргәнегез бармы соң?

— Күрсәм, бирер идем кирәген.

— Ни өчен?

— Ялганлый, булмаганнарны яза.

— Алайса ул, бәлки, сезнең турыда түгелдер?

— Минем турыда. Мотор белән жәфалануларым дөрес. Врачка баргач, нигә килгәнлегемне онытып торуым да дөрес. Якорь өздерүем дә булды. Әмма ләкин хатынның кер бавы турында, объективны ачмыйча демонстрациядә рәсемгә төшереп йөрүләр... Һәммәсе ялган.

— Бәлки, сезнең фотоаппаратыгыз да юктыр әле?

— Бар аның. Хәтта объективны ачарга оныткан чагым да булды. Тик демонстрациягә чыкканда түгел...

— Шулай булгач?

Мин аңа, әлбәттә, хикәя язуның серләре, сәнгатьнең үз дәреслеге булуы, авторның тормышта булганнар өстенә үзеннән уйлап чыгарырга да хакы барлыгы турыларында әйтеп тормадым. Ул моны үзе дә аңлый иде бугай.

— Анысы шулай,— диде.— Ялганлый бирсен. Язучының кәсебе шул. Ә менә тормышта чынлап та бар кеше турында исеме белән атап язасын икән, нигә башта аның үзен күреп сөйләшмәскә? Сөйләшкән булса, бәлки иң кызыгын онытмаган да булыр иде.

— Иң кызыгы ничек иде соң?

— Булды инде. Ә хәзер Латыйп карт дигәнең бөтенләй икенче кеше. Моторым гөрләп эшли хәзер, шундый итеп көйләдем, бер генә тартам. Бетердем мин ул «склероз»ны.

Нәкъ шул минутта поезд йөрешен әкренәйтеп туктый башлады да, карт сискәнеп, сикереп торды. Ашыга-ашыга капчыгына үрелде.

— Миңа бит үткән остановкада төшәргә иде, ах, карт лыгырдык,— дип сөйләнә-сөйләнә, ишеккә таба йөгерде. Ничек төшеп өлгергәндер, поезд туктaлыр-туктaлмастан кузгалып та китте.

— Плащын онытты бит! — диде берәү.

Бетергән икән склерозны! Хет яңадан бер хикәя яз. Тик ничек табарга икән үзен? Мин әлеге берәүгә мөрәҗәгать иттем.

— Сез белмисезме, кайда тора икән бу карт?

— Балыкчылар утравында яши.

Әһә. Алыйм әле мин аның «мечта»сын...

### БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

## Казан Иделе

Тагы бер-ике минут узуга — мин төшәсе тукталыш.

Безнең күз алдында юктан бар булган, әле исеме дә кушылмаган сабый шикелле, номер белән 774 нче километр дип кенә йөртелә торган платформа хәзер бу юл өстендәге иң җанлы урын. Сәгать саен килеп төшүче яки утырып китүче йөзләр, меңнәр арасында кемнәр генә юк? Иң гади каравылчыдан башлап академикка кадәр — кемне телисең? Инженер, шофер, врач, язучы... дип һөнәрләре буенча саный китсәң, иңе-буе бер километрлы кәгазь кирәк булыр иде. Кәгазь дигәнен күренекле язучыларыбызның тулырак җыелмаларын чыгарырга да җитми әле монда. Аннары бит әле һәрбер аерым кешенең үзендә әллә ничә төрле һөнәр. Әйтик, поездда чакта ул пассажир, поездан төшкәч— бакчачы. Иделгә чыкса — балыкчы, Казанга кайтып эш урынына барса — министр.

Сыбызгыга тартым нечкә генә гудок белән кыска гына хәбәр биреп дизель поезд килеп туктауга, бөтен вагоннардан бүселгән пассажирлар, нәкъ рәсемдәге кояш нурлары кебек [1], тимер юл сызыгыннан сулга таба сибеләләр: берәүләре рельслар буйлап алга — көнбатышка таба кыеклый, берәүләр — артка, ә берәүләр туп-туры көньякка таба атыла.

Идел тарта үзенә барысын да. Идел! Эх, ул җәйге Идел! Бигрәк тә Казан Иделе! Табигатьнең шуннан да гүзәл урыннары... бардыр барын, ләкин алар минем өчен түгел. Җәй көннәрендә үзеннән беркая җибәрми мине Идел. Әйтеп тә караганым бар үземә: һаман бер урынга

[1] Офык артыннан чыгып килгән кояш рәсемен күрмәгән, хәтта аны үзе дә ясап карамаган кеше безнең илдә юктыр дип беләм.

ябышып ятмаска иде, җәйнең ямьле көннәрендә дөньяның башка урынnарын да күрергә кирәк иде, дигәнем бар. Юк, җибәрми. Дөньяның матурлыгын бишкә арттырып күрсәтә торган сихерле көзгесен кояшка каршы ялтыратып җибәрдеме — эретә дә төшерә.

Һәм менә быел тагы мин аның янында. Кунагы да мин аның, хуҗасы да, колы да...

## Мөхәммәтша

Вагоннан төшүгә каршыма, авызын, Атилла Расих әйтмешли, «беткәнче» җырып[1], Мөхәммәтша килеп басты.

— Нихәл, адаш,— ди,— юл буе мине әрләп килгәнсеңдер әле?

— Юк,— мин әйтәм,— сиңа дип алган урынга синнән дә кызыклырак кеше килеп утырды.

— Ә мин кем белән утырып килдем, беләсеңме? Синең янга килә алмавым да шуның аркасында.

— Кем соң ул?

— Әйдә, сөйлим.

Ул арада яныбызга күптәнге дустым Таҗи килеп чыкты. Кулында кәкре башлы таягы, аркасында буаз сарык хәтле биштәре. Ул инде тәмам азуы җиткән балыкчы. Исәнлек-саулык сорашып тормады, беренче сүзеннән үк, рус әйтмешли, үгезне мөгезеннән эләктерде.

— Иртәгә кырабыз, егетләр, балыкны,— диде.— Шундый шәп чебен корты таптым, дуңгыз баласы кебекләр.

— Ул шахшы миндә дә җитәрлек,— диде Мөхәммәтша.— Хур итә язды мине, кабахәт.

Без өчәүләп Идел ягына таба юл тоткан идек инде. Мөхәммәтша ни өчен вәгъдә итеп тә минем яныма керә алмавы турында сөйләргә керешТе.

— Киләм синең турыда уйлап,— ди бу.— Күрәм, алдымда бер краля бара. Ул фигура, мин сиңа әйтим, кабахәтнең! Ул аяклар! Шундый төзек, шундый тыгыз балтырлар, һич күзне алырлык түгел. Шуңа карап барып, икенче вагонны узып киткәнмен, әкәмәт, өченче вагонга барып кергәнмен. Туры килүен әйт син, каршына ук барып та утырганмын бит. Нәкъ күз алдымда дөнья байлыгы. Якыннан бигрәк тә тәэсирле күренә моның аяклары. Пәрәме җылысы бәрелеп тора, хәшәп! Йөзенә карыйм, артык матурдан түгел түгелен, бик яшь дип тә булмый. Ну, нәфис. Менә дигән мал чагы тегенең. Мондый чакта комплиментның тәмен тоя инде ул хатын-кыз. Әзрәк тегенди-мондыйрак сүзләрне дә елмаеп кына үткәреп җибәрә белә. Юл кыска, мин әйтәм эчтән генә, яшь гомернең дә көннәре санаулы. Вакытны әрәм итмим әле, әйтим үзенә бер әр матур сүз. Юбкасыннан башлаган булдым.

— Ниһаять, мин юбка дигәннәренең мәгънәсен аңладым,— мин әйтәм.— Гүзәл аяклы кеше өчен чыгарылган мода икән.

Тиз генә көлеп җибәрми, хәтта елмаймый да, йөзен чыткан була.

— Гафу итегез, мин әйтәм, һич сезне җәберләргә теләвем түгел. Күрәм, кемнәрдер, үзләренең фактураларын белмичә, мини юбка киеп, бамбук таягы кебек ботларын күрсәтеп йөргән булалар. Кемгә тансык аларның буыннары сыеклыгын күрү... Ә менә сездә! Шулкадәр килешә, акча түләп, билет алып карарлык. Балет караган кебек.

Йөзе яктыра төште.

---

[1] Элегрәк ул авызының зурлыгын яшерү өчен иреннәрен бөребрәк кала торган иде. Соңгы елларда зур авыз модага кереп киткәч, хаклы рәвештә бөтен көченә киереп ача.

Мин дә әрсезләнә төштем.

— Гафу итегез, мин әйтәм, күңелемдәген яшерми әйтүем өчен... Сезгә бу аяклар белән, мондый фигура белән балерина гына буласы...

Телгә килде бит.

— Әллә сез балет яратасызмы? — ди.

— Балетны яратмаска мөмкинме соң! — мин әйтәм.— Берсен дә калдырмаска тырышам.

— Балериналардан сезгә кемнәр ошый? — ди.

Ә мин, дөресен генә әйткәндә, аларның Розалиевадан башкасын белмим дә. Күбрәк белгән булып күренү өчен, аны да фа́милиясе белән түгел, исеме белән әйттем.

— Тамара ошый, мин әйтәм.

— Ә сезнең аны күргәнегез бармы?

— Булмыйча!

Үзем күргән балетларны санап чыктым. Берничә тапкыр концерт номерларында күрүемне әйттем.

— Шулай да сез ялганчы,— ди бу миңа.

Менә сиңа кирәк булса!

— Ул кадәр күргән булсагыз, сез мине таныр идегез, ди.

Шул Тамара үзе булып чыкты, хәшәп! Ә мин нәрсә дияргә белмим. Юләр димә син аны! Әйтегез инде: балет тамаша кылганда нинди дурак балеринаның йөзенә карый икән? Үзенә алай дип әйтеп булмый бит. Шулай да аптырап калмадым.

— Димәк, сез бик оста гримлана беләсез. Сәхнәдә сезнең чын йөзегезне күреп булмый.

— Артистканың чын йөзе сәхнәдә генә күренә,— ди.

— Бусы инде фәлсәфи фикер...

Шулай культурный гына сөйләшеп барганда әлеге шул хәшәрәт тәмам хур итә язды бит. Бер заман балеринам үзенең сөрмәле күзләре белән текәлеп минем күлмәк итәгенә карап торды да капыл куркынып кычкырып җибәрде:

— Ой! Нәрсә ул сезнең өстегездә?!

Карасам, чебен корты, кабахәт! Кәгазь пакетка төреп кенә күлмәк кесәсенә салган идем шахшыны. Сикереп тордым, сыпырып идәнгә төшердем. Куршемдә утыручылар, котлары очып, урыннарыннан кузгалдылар. Бәхеткә каршы, Тамараның исе китмәде. Рәхәтләнеп көлде генә. Үзенең кемедер: иреме, дустымы — балык җене кагылган кеше икән. Хәлне аңлады. Балыкчы маҗаралары турында сөйли башладык. Безнең Фәнилне яхшы белә икән...

— Фәнил димәктән... кайда безнең Фәнил?

Мөхәммәтша кулын гына селтәде.

— Һәй, аңа ышансаң! Балыкчымыни ул?

— Юк. Ул бүген обязательно барам дигән иде. Үзе шалтыратып әйтте. Вәгъдәсез егет түгел бит. Нигә килмәде икән?

Мәсьәләгә Тажи ачыклык кертте. Гадәтенчә бик тыныч кына, бик гади вакыйга турында хәбәр иткән кебек кенә итеп, әйтеп куйды:

— Ваня кайткан бит.

— Нинди Ваня?

— Теге, боз астыннан чыккан мәетне оныттыңмыни?

— Китсәнә! Ничек инде ул?

— Берничек тә түгел, көпә-көндез, чираттагы «Ракета»га утырып, кайткан да төшкән.

— Исән? Димәк, теге мәет бүтән кешенеке?

— Фәнил шул эш белән танышып йөри,— диде Тажи.

— Күңелемә килгән иде шул, бу мәет чынлап та Ваня микән соң дип шикләнгән идем.

— Татар акылы,— диде Мөхәммәтша һәм үзенчә нәтиҗә ясап куйды.— Димәк, Фәнилдә безнең кайгы түгел. Синең чабагың белән нишләсен ул? Шундый зур җәен эләктерергә мөмкин булганда?

Фәнил — өч йолдыз яктысында безнең арада яшь кеше. Хәтта ул кайчандыр Таҗиның шәкерте дә булган. Шулай да утызның өс ягында инде. Сугыш елларының ачысын тылда татыган малай. Шуның нәтиҗәсе булса кирәк, начар йоклаудан зарлангач, врачлар аңа эш турында артык борчылмаска, күбрәк һавада йөрергә киңәш биргәннәр.— Ин яхшысы — сезгә балык тоту белән шөгыльләнергә кирәк, дигәннәр. Моны ишеткәч, Таҗи абыйсы куанган.

— Бик шәп, дигән, үзебезнең компаниягә алабыз. Шундый балыкчы итәрбез үзеңне, бөтен кайгы-борчуларыңнан җилләр исәр. Атаң-анаң гына түгел, хатыныңда исенә керми торган булыр. Хәтта журналистлыгыңны да онытырсың, дигән.

Барыбыз да яраттык бу егетне. Безгә аеруча ошаган ягы шунда: барыбызга да «абый» дип кенә дәшә, авыррак, мәшәкатьлерәк эшләрне үз өстенә ала, бездән эшләтмәскә тырыша.

Кыш иде әле. Ул көннәрдә без Фәнил белән күбрәк ашханәдә очраша идек. Аңа балык тотуның гаять күңелле һәм мажаралы эш булуы турында сөйләп, байтак вакыт уздырдык. Дәртләнеп-дәртләнеп, дөреслекнең үз кәче генә җитмәгәндә ялган белән куертып сөйләгән сүзләребезгә яшь дустыбызның артык исе китмәде. Без аны көлдерергә телибез, я куркытмакчы, шомландырмакчы булабыз. Ә ул көлми дә, шомланмый да. Сизәбез, хәтта күңеленнән безне кызганып утыра: бу мескеннәр өчен дөньяның шуңардан башка бер кызыгы да калмаган микәнни инде? — дип уйлый бугай. Ин дөресе, әлбәттә, аны хәзер боз өстенә алып чыгу булыр иде. Балык чиртүнең тәмен белеп алса, үзе атлыгып торыр иде. Ләкин мин үзем балыкка кыш көне йөрмәскә карар биргән кеше. Боз астыннан тотуны яратмаганнан түгел, принципиально бармыйм: чөнки балык белән мавыккан чорда башка эшкә күңелем төшмәүчән. Адашка әйтеп караган идем дә, ул да шул сөйләргә генә:

— Миндә Таҗи аягы юк! — дип кенә җавап бирде[1].

Һәм чынлап та Таҗи иренмәгән, үзе ук белеп, Фәнилне бер-ике тапкыр Казанка өстенә алып чыккан. Ләкин, кызганычка каршы, балык чиртми торган көнгә туры килгәннәр. Фәнилнең врач киңәше белән генә кузгалган барлы-юклы дәрте дә сүрелгәндәй булды.

Гадәттәгечә ашханәгә җыелган идек, шунда ишеттек:

— Кармак салып утыру миңа бернинди тынычлык бирми,— дип сөйләнә башлады бу.— Киресенчә, теге эшем кала, бу эшем эшләнмәгән, дип, ә мин монда юләр кебек бушка вакыт әрәм итеп утырам, дип борчылам...

— Син сабыр ит әле, Фәнил...

— Чынлап, Таҗи абый,— дип бүлдерде Фәнил.— Үзем өчен генә түгел, шунда боз өстендә йөзләп, әллә тагын меңләп утырган кешеләр өчен дә борчылам мин. Сәгатьләр буена нәкъ тумба шикелле катып утыралар бит. Нәрсә хакына диген? Хәтта төн буе шулар турында уйланып ятам. Миңа сиңа тыныч йокы!

— Юк, юк, Фәнил,— диде Таҗи,— йокың да начар булгач, балыкны кире кагарга ашыкма әле син. Сабыр ит. Менә хәзер көннәр җылына. Март балык өчен иң шәп ай...

Ниһаять, янybызга калфаклы официантка килде. Таҗи да меню белән танышып өлгергән иде инде.

---

[1] Таҗиның бер аягы дерестән дә үзенеке түгел. Шулай да арабызда иң күп йөрүче кеше ул. Шәһәр тирәсендә генә түгел, Союз күләмендә шулай. Хәтта чит илләргә чыгып керергә дә өлгерә.

— Болай булгач, бик үк татарча булмаса да, әзрәк китертәбез инде, егетләр,— диде.— Борын башына йөзәрдән булсын...

Врачлар, бигрәк тә хатыннарыбыз киңәшенә колак салсак, шулай үк җыелышларда үзебез үк әйтә торган яхшы сүзләрне дә истә тотсак, беребезгә дә эчәргә ярамый. Шулай да Таҗиның тәкъдименә каршы килүче булмады.

— Нәрсә китерим? — диде калфак.

— Әлбәттә, коньяк [1].

— Нindиен?

— Әйдә, биш йолдызлысы булсын.

— Юк,— диде Мөхәммәтша,— өч йолдыз житәр.

Фәнил белән мин кайсына да риза идек.

Өч йолдыз җиңде. Калфак яныбыздан киткәч, Мөхәммәтша үз тәкъдимен шәрехләп бирде.

— Беренчедән,— диде,— мин үзем өч йолдыз белән биш йолдыз арасында бернинди аерма тапмыйм. Хәтта КВ дигәне дә минем өчен барыбер. Коньякмы? — Коньяк. Биш йолдызга акча түләтеп, өч йолдызны салып китерсә, ни әйтә аласың? Сез мена аерасызмы?

«Аерам» дип әйтергә беребезнең дә батырлыгы җитмәде.

— Менә шул шул! — диде адаш.— Икенчедән, беләсезме ул йолдызлар турындагы анекдотны?

Таҗи белән миңа берничә кат сөйләгән иде инде ул аны. Бу юлы яныбызда Фәнил дә булгач, тагын бер тапкыр тыңларга каршы килмәдек.

— Коньяклар ярышында өч йолдызга премия биргәннәр, ә биш йолдызга — юк. Начальство сорый икән коньяк заводы директорыннан:

— Ничек болай сынаттың? Ни өчен биш йолдызга премия ала алмадың?

— Үзем дә гаҗәпләнәм,— дигән теге.— Икесен дә бер үк мичкәдән салган идек...

Ахрысы, Фәнил өчен дә яңа булмагандыр, кычкырып ук көлмәде, елмаеп кына куйды...

Өстәл яныннан торганда барыбыз да бер фикергә килгән идек инде. Таҗи Кама буендагы бер авылны белә икән, каршысында гына иң балыклы урын, ди. Мөхәммәтша белән мин бу тәкъдимне берсүзсез хупладык. Фәнил генә, Кама турында ишеткәч, курку катыш гаҗәпләнеп, кычкырып җибәрде.

— Кама? — диде.— Алтмыш километрга?!

— Алтмыш ул Кама тамагына хәтле,— диде Таҗи тыныч кына.— Ә безгә аннан ары тагын утыз-кырык километр барасы.

— Бу бит командировкага китүдән дә болайрак. Ә транспорт?

— Курыкма, без анда турыдан суктырабыз. Лаеш тракты буйлап. Минут саен машина уза. Теләсә кайсы утыртып алып китә.

Фәнил, әлбәттә, курыкмады. Хәтта күңеленнән үзе нидер өстәп, сөенеп тә куйды шикелле. Аның ризалыгын күреп, без дә куаныштык. Куанмыйча! Андый юлга чыкканда янында яшь кеше булу бик әһәмиятле мәсьәлә ул.

Кыскасы, ял көненә каршы сәфәр чыгарга дигән карарга килеп, өйләребезгә таралыштык...

Кыш көне балыкка йөрмәскә дигән карарымны, бер юлга гына дип, бозасым калмаган икән. Эш өстәлем янында бик аз утыра башладым. Җыелышка яки берәр кичәгә чакырсалар да, вакытсыз борчыйлар дип, ачуым гына килә. Төн йокыларымның рәте китте. Күңелемдә һаман шул

[1] Ул вакытта коньяк кыйбатланмаган иде әле һәм аны безнең Казанда бары ресторанда гына туры китереп була иде.

балыкка бару кайгысы гына. Алары бер хәл иде, баруыбыз уңышлы чыкса, бер юлга әллә ни зур югалту булмас иде. Шундый ямьсез күренешкә тап булырбыз дип кем уйлаган бит?

## Машенька



Юл азапларын язып тормыйк, шунысын гына әйтим: һәрхәлдә, бүтән берәр житдирәк, жаваплырак эшкә булса, очраклы машинага исәп тотып, кичкә каршы кышкы юлга чыгып китәргә тәвәккәллек житәр иде микән? Балык дәрте әллә нишләтә ул кешене: сызлаган, сыкраган жирләреңне дә оныттыра, ничә яшьтә икәнеңне дә... Машинадан төшкәч, ике-өч километр чамасы араны жәяүләп уздык әле. Караңгыда! Шуннан соң гына Тажи әйткән авылга барып життек. Кибет каршындагы фонарь баганасында гына электр уты янып тора. Ә өйләрнең барысының да диярлек тәрәзәләре караңгы иде инде... Шулай да, Тажи дустыбыз безне кирәкле йортка туп-туры алып барды. Ярым ачык калган капкадан ишек алдына кердек. Урам тәрәзәләре капланган булган икән, ян тәрәзәдә балкып ут яна иде. Өйалды да ачык булып чыкты. Тышкы ишекнең биксез икәнен Тажи белгән, күрәсең, шакып-нитеп тормады, үз өенә кайтып кергән кебек, кыю ачып жибәрде. Барыбыз да эчкә уздык. Тик такта белән генә бүленгән алгы якта тукталып калырга мәжбүр булдык. Түр бүлмәдәге зур өстәл тирәсендә дүрт-биш ир бик кәефле кызып, ашап-эчеп утыралар иде. Безгә игътибар итүче булмады. Тажиның моңа бер дә исе китмәде. Үз хатынына дәшкән кебек тыныч кына: «Машенька!» дип тавыш бирде. Шундук мич алды ягыннан, тулган ай кебек балкып, таза гына бер хатын килеп чыкты. Фәнил күзлегеннән караганда ничектер, әмма миңа өстенә чәчәкле сарафан гына кигән бу хатынның ялангач беләкләре дә[1], ачык чырае да бик яшь күренде.

Тажины күрүгә, ул тагын да ачыла төште:

— Рәхим итегез, Тарас Григорьевич!

Без Тажи дустыбызның мондый исеме дә барлыгын белми идек әле. Бер-беребезгә карашып, елмаешып алдык. Мөхәммәтша, әлбәттә, бу уңай белән бер сүз дә әйтми кала алмады, хужа хатынга аңлатмыйча, үз телебездә генә Тажига ымлап: «Шевченко буласың гына калган икән»,— дип куйды.

Тажи моны илтифатсыз уткәреп, Мөхәммәтшаның үзен Машага тәкъдим итте.

— Таныш булыгыз, бу минем дустым Мухаметша!

— Русчасы ничек була инде? — диде Машенька.

Мөхәммәтша әз генә дә уйланып тормады:

— Михаил Юрьевич! — дип, Машаның кулын кысты.

Тажи аңа тантаналы караш ташлап алды: «Менә син дә Лермонтов була яздың!» ди иде аның күзләре.

Минем үземдә дә мондый очраклар өчен күптән сайлап куйган икенче исемем Михаил иде. Шулай итеп, без Мөхәммәтша белән «адаш» булып чыктык.

Фәнил үзен «Федя» дип кенә таныштырды.

— Мамаша ни хәлдә? — диде Тажи.

— Исән-сау. Әнә үзенең мич башында.

Тажи түрдә шау-гөр килеп утыручы ирләргә ияге белән генә ишарәләп:

— Кемнәр? — дип сорады.— Әллә Ваняң кайттымы?

Маша өметсез елмаеп, кулын генә селкеп куйды.

---

[1] Минем урында Фатих Хөсни булса, әлбәттә, аның тертәеп торган күкрәкләре турында да язмый калмас иде.

— Сезнең кебекләр. Ә Ваня суга баткан кебек юкка чыкты. Бер хәбәре дә юк.

— Кайгырмагыз, начар хәбәре булмагач, кайтыр.

— Тапкандыр инде үзенә бүтәнне, яшьрәкне.

— Алайга китсә, сез дә табалмаслык түгел. Кем сезне яшь түгел дияргә батырчылык итәр?! Ә? Синеңчә ничек, Михаил Юрьевич?

— Мин бу өйгә килеп кергәннән бирле сездән күземне ала алмыйм, Машенька,— диде Мөхәммәтша.— Ничек итеп кеше хатыны шулай яшь тә, чибәр дә була икән дип шаккатам.

Аның болай арттырыбрак җибәрүен Маша яратып ук бетермәде бугай. Ничектер җитдиләнә төште.

— Ярар, ярар,— дип, сүзне икенчегә борырга ашыкты.— Чәй эчәсезме? Теләсәгез әнә мичтә ботка да бар, сөт тә...

Өйгә кергәч бик шәпләп утырырга ниятләп килгән идек тә, безгә хәтле килеп, яп-яхшы ук ямьсезләнеп өлгергән икенче компания булгач, дәртебез сүрелде. Көчтәнәчкә дип, ыслаган колбаса алып килгән идек, Тажи аны да Машага тантанасыз гына тоттырды. Аннан-моннан капкаладык та, иртә торасы бар дип, тизрәк яту ягын карадык. Рәтләп чишенеп тә тормыйча, шунда — алгы бүлмәдә генә тәгәрәштек. Минем адашның хуҗа хатын белән тәмләбрәк гәпләшергә дәрте кузгалмакчы иде дә, Тажи кырт кисте:

— Кирәкми, андый хатын түгел ул,— диде.

— Көнләшә бит бу миннән,— диде Мөхәммәтша, авызын бер дә җәлләмичә ерып,— валлаһи, көнләшә! Менә сиңа Тарас Григорьевич. Бар боларның арасында хикмәтле роман, бар. Ничек булмасын! Беләкләр нинди бит, хәшәп, күкрәкләр!..

— Пошляк!

Бу «комплиментка» адашның шулкадәр кәефе килде, ул бик озак авызын җыеп ала алмады һәм әйтергә теләгән сүзен әйтә алмый азапланды. «Өсте... өсте...» дип, биш-алты тапкыр кабатлаганнан соң гына, ниһаять, көч-хәл белән әйтте: «Өстенә бастым» дияргә азапланган икән.

Мөхәммәтша бераз тынычлануга, Фәнил сүз кузгатты. Аны Машаның югалган ире кызыксындыра иде. Нигә чыгып киткән икән ул? Чынлап та, хатыны алай ташлап чыгып китәрлек түгел бит.

— Хикмәт шунда, бер-берсен бик яратып торганнар. Ә Ваня артык көнче, ди. Беркөнне шулай эчеп кайткан да, болай яшәгәнче Камага батып үлүем яхшы, дип, чыккан да киткән, и юк.

— Күптәнме?

— Узган көздә.

— Димәк, бер дә юкка гына түгелдер.

— Юкка гына буламы соң? — диде Мөхәммәтша.— Хатын-кызның гөнаһсыз кыяфәтенә бер вакытта да ышанма!

— Ә бу алай бозык хатын түгел,— диде Тажи.— Өстәвенә, менә дигән доярка.

Мөхәммәтша авызын гына ерды. Фәнилнең исә бу гаилә тарихын нечкәләбрәк беләсе килә иде.

— Шулай да кызык,— диде ул.— Үзе белән сөйләшеп карыйсы иде.

— Тик бүген түгел. Кире кайтканда тагын керербез, шунда иркенләп сөйләшерсең...

Бу вакытта Маша без яткан бүлмә аша тышка таба узып бара иде, ахрысы, йокламый утыруыбызны ишетеп, тагын сүз кушты:

— Теге иптәшегез килмәдемени, Тарас Григорьевич?

— Кем иде икән ул?

— Харитон дигән идегез, атасының исемен оныттым.

— Юк,— дип кенә куйды Тажи.

Маша кабат сорамады. Без дә тәпченеп тормадык. Тажи дустыбызның, балык дигәндә, теләсә кем белән, теләсә кая китәргә һәрвакыт

әзер торуын белә идек. Харитон дигәне я берәр Хисами булгандыр инде шунда, я Хәмит...

Барыбыз да тынып калдык. Түр яктагыларның үзлексез сөйләнүләренә колакларыбыз иялэнеп житеп, йокыга да китә башлаган идек. Шунда берсе ямьсез исерек тавыш белән акырып җырларга тотынды.

— Па-а-роход идет, Анюта-а-а...

Сискәнеп уянып киттек. Тажи түзмәде:

— Әй, егетләр, сезнең иртүк торып балыкка барасыгыз юкмыни? — дип кычкырды. Тегеләр җавап биреп өлгермәде, Машаның кырыс һәм кисәтүле тавышы яңгырады:

— Житте сезгә,— диде.— Тавышыгыз чыгасы булмасын. Югыйсә, куам да чыгарам. Яңадан бу өйдә эзегез дә булмас!

Шундый ышандырырлык итеп, үкчәләргә барып житәрлек куркыныч итеп әйтте Маша бу сүзләрне, тегеләр шым булдылар. Һәм яңадан тавышлары чыкмады. Хәтта сөйләшүдән дә туктадылар. Без дә тындык. «Молодец, Маша!» дип әйтәсем килсә дә, минем дә авыз ачарга батырлыгым житмәде. Тик күңелдән генә уйланып яттым. Чынлап та кайдан килә кешегә мондый характер? Халык йолаларының көчен әйт син! Бу Маша бит инде, күренеп тора, совет заманында гына да түгел, социализм чорына кергәч дөньяга килгән кеше. Кимгә куйганда сигез еллык белеме бар дигән сүз. Ә телендә ниндидер патриархальлек калдыклары. Безгә, рус телен күбрәк китаптан өйрәнгән кешеләргә, бу аеруча нык сизелә. Житмәсә, татар исеменең русчасын сорый. Моны сәлперәйгән карчыклардан ишетү бер хәл, ә менә монардан? Замана техникасы биргән байлыклардан да файдалана белә үзе. Өендә электр. Егерменче елларда безгә могжиза булып күренгән «Ильич лампочкасы» гына түгел, холодильнигы зырылдап утыра. Почмагында телевизор, ә телевизор артында — өстәрәк иконасы... Менә дигән доярка? Колхоздан килере начар булмаска тиеш. Ә без нигә кирәк аңарга? Ул эчеп утыручыларны нигә өенә кертә? Күңел кинлектәнме? Акча өчен генәме? Борын башына илле тиен бирәбез, диде Тажи. Юмартрак кешеләр берәр сум яки өчәр тәңкә тоттыралар икән, Маша анысына да каршы түгел, ди. Ире белән аралары бозылуы да әллә шул нигездә микән?..

Кайчан йоклап киткәнмендер, кабыргама төрткәнгә уяндым. Тажи, чыгарга вакыт, ди. Таң беленгән...

## Җан тетрәткеч вакыйга

Ниятләгән жиребезгә барып житкәндә, көн тәмам яктырган иде инде. Тажиның «авыл каршында гына» дигәне дә, «иң балыклы урын» дигәне дә гадәттәгечә күпертелгән булып чыкты. Беренчедән, шактый ерак киттек. Икенчедән, иң балыклы урын икәнлеген дә сизмәдек. Дөрес, боз калын булса да, тишүгә күп вакыт әрәм итмәдек. Әзер бәкеләр дә житәрлек иде анда. Теләгәнеңне сайла... Тик, жим капчыкларыбызны төшергәнгә ярты сәгатьтән артык вакыт узып китсә дә, куандырырлык берни дә юк иде. Ярты сәгать, әлбәттә, күп түгел. Чиргү дигән нәрсә озаграк көттереп килсә дә, бик канәгать буласың. Ике-өч сәгать вакыт сизелми дә үтеп китә. Балык эләкмәсә дә, берәү дә тик кенә утырмый, әле жимен алыштыра, әле кармагын... Ә безнең Тажи исә бигрәк тә тик торырга яратмый. Бер урын белән генә дә канәгатьләнми. Үз кормушкасын бәке төбенә төшергәннән соң ул Фәнилгә булышты, балык тотуны ничек дәвам иттерү турында аңа консультация бирде дә ялтыравык беркетелгән өч ябле кармакларын актарырга тотынды.

— Кормушкага балык иялэшә торсын,— диде.— Ә мин Хисами бәкесенә барыйм әле. Ул аннан биш килолы чуртан тоткан иде.

— Тажи бизмәне беләнме? — диде Мөхәммәтша.

— Шаярма. Ул чуртанны чыгарыр өчен бәкенең авызын зурайтырга туры килде. Җан тиргә төштек.

— «Тажи бизмәне» дигәнебез нәрсә соң ул?

Фәнилгә Мөхәммәтша җавап бирде:

— Бер килоны ике кило итеп күрсәтә.

— Мин ясаган бизмән түгел. Харьков заводы гаепле,— диде Тажи ачуланмыйча гына.— Өстәвенә, арттырасың: ике йөз граммга гына артык күрсәтә.

Мөхәммәтшаның тагы авызы колагына җитте.

— Хикмәт бизмәндә генә булса икән.

— Лыгырда инде, лыгырда.

— Лыгырдау түгел, тарихы бар аның. Сөйләрмен әле. Хәзер вакыты түгел...[1]

Тажи сөймәнне дә үзе белән алып, арырак китте. Һәркайсыбыз үз бәкебезгә кадалып, тынып калдык.

Күпме вакыт узгандыр, Тажиның, тавышын күтәрмичә генә, безгә дәшкәне ишетелде.

— Егетләр, килегез әле.

— Нәрсә бар?

— Үзем генә чыгара алмыйм.

Тавышының тынычлыгына караганда, әлбәттә, чуртан түгелдер. Артык ашыкмыйча гына янына бардык. Тажи, боз астына таба бик нык тартылган кылын тоткан килеш, иләсләнгән күзләре белән безгә карап утыра иде. Димәк, юкны сөйләми, нәрсәдер бар.

— Нәрсә, бәкегә сыймыймы? — диде Мөхәммәтша.

— Сыймый шул.

— Әллә бер потлы җаен?

— Хуже.

— Карале, нишләдең син, нигә күзләрең аларган?

— Аларыр.

Барыбыз да бәке өстенә иелдек.

Бу бәке чынлап та башкаларга караганда сизелерлек зур уелган иде. Ләкин анда берни дә юк, бары Тажи кулыннан боз астына агымга түбән тартылган калын кыл гына күренә.

— Кая, нәрсә бар?

Тажи тавышын бераз әкренәйтә төшеп:

— Кеше эләктердем,— диде.

Юк, чираттагы шаярту гына түгел иде бу. Шулай да ышанасым килмәде.

— Шаяртмасана,— дидем,— нәрсә сөйлисең син?

— Нинди шаяру, чынлап та мәет эләкте. Нишләтәбез?

Мөхәммәтша да ерылган авызын тиз генә җыеп алды.

— Булмас ла!

— Менә, кара!

Тажи кылны әкрен генә үзенә таба тартты. Бәке авызында коңгырт сары чәчле кеше башы калкып чыкты. Өч япьле кармак аны хәрби яшел якасыннан эләктергән иде.

— Кисеп җибәр тизрәк! — диде Мөхәммәтша.

— Што син?

— Тукта, кармагыңны ычкындыр. Блеснаң китмәсен.

---

[1] Бервакыт Тажиның садогы агып китә. Тажи зарлана, садогым белән бергә өч кило балыгым китте, ди. Садогы күрше көймәдә утыручыга барып эләккән икән. «Әллә синеке микән дип уйлаган идем, болай булгач, синеке түгел инде, балыгы бер кило да юк», ди бу. «Тажи бизмәне» дигән сүз шуннан телгә кереп китте.

— Синдә блесна кайгысы, дурак.
— Эзең калмасын дим, дурак.
Очраклы рәвештә килеп эләккән билгесез мәетне кире ычкындырып җибәрү турында минем күңелемә дә киләсе түгел иде. Мөхәмматшаның шундый тәкъдимен ишеткәч, аптырап киттем. «Ни сөйлисен син?!» дип әйтмәкче идем, өлгермәдем, авызымнан тартып алган кебек, шул ук сүзне Фәнил кычкырып җибәрде. Әллә нишләде шунда ул егет, моңарчы һаман барыбызга да «абый» дип, кечелек күрсәтеп килгән кеше кинәт кырыс командирга әйләнеп китте.
— Ни сөйлисез сез! — диде ул усалланып.— Нинди ычкындыру ди ул! Давайте, боз өстенә чыгарыйк. Тизрәк!
Шулай да Мөхәмматшаның үз сүзен бирәсе килмәде.
— Яшьлегеңә барма әле син, Фәнил,— диде ул.— Хәзер бит без бу эшкә бәйләнеп китсәк, скандал. Шаһит итеп, әллә кайларга чакырып бетәчәкләр.
— Чакырсыннар!
— Балык тотасыбыз бар ич безнен. Балык тотмаганда да үз эшебез үзебезгә җиткән. Ычкындырыйк та котылыйк. Белмәдек тә, күрмәдек.
— Юк инде, күрдек тә, белдек тә...
— Фәнил хаклы! — диде Тажи да.
Мөхәмматшаның җиңелми хәле юк иде.
— Теләсәгез нишләгез, — диде ул юашланып, — мәетнең барыбер тереләсе юк, бәласенә кермик дип кенә әйтүем иде.
Фәнил, аның сүзләренә колак салмыйча, тыелгысыз бер тәвәккәллек һәм кыюлык белән бәкегә үрелеп, ялангач куллары белән мәетне якасыннан эләктереп алган иде инде. Тажи белән мин аңа ярдәмгә ашыктык.
Мәетнең өстендә погоннары алынган солдат киеме, ә йөзе, озак яту-дан бозылганмы, әллә су җәнлекләре шул хәлгә китергәнме, чәченнән башка, кешегә охшаган урыны калмаган иде.
— Мин авылга кайтыйм,— диде Фәнил.— Сельсоветка...
Көн уртасы якынлашканда бу бәхетсез кешенең гәүдәсе авыл Советы янына кайтарылган иде инде. Тиз арада аның тирәсенә халык җыелып өлгерде. Сорашулар, төрле юраулар китте. Суга батуга бәглаңышлы төрле вакыйгалар сөйләргә тотындылар. Барына да колак салып бетәрлек түгел иде.
Шунда безнен өчен җан тетрәткеч бер вакыйга булды. Халык арасында безнең кичәге ягымлы хозяйкабыз — Маша күренде. Өстендәге сырмасының төймәләрен эләктермәгән, башындагы кыек яулыгы артка төшеп, сары чәчләре кабарып чыккан Кичә шундый ачык, алсу күренгән чырае агарынган.
Ул дөньясын оныткан кыяфәттә, төркемне ерып, уртага омтылды. Чанада печән өстендә яткан мәет янына килеп чыккач, кинәт тукталып калды. Текәлеп карап торды-торды да йөрәк яргыч тавыш белән кычкырып җибәрде:
— Ул! Ваня! Милай!..
Ул, ихтыярын югалтып, мәет өстенә ауды, аның гәүдәсен кочып, елый-елый такмакларга тотынды.
— Нишләдең син, Ваня? Нишләдем мин, дура! Кемгә калдырып киттең син мине, милый мой! У-у-у! Хәсрәтем син минем, туйдыручым минем...
Аның шулай бөтен әйләнә-тирәне онытып өзгәләнүен, газаплануын күреп, минем дә күземә яшьләр килде. Тажи да үзен шулай хис итте, ахрысы, ул да читкә борылды. Мөхәмматша тынычрак иде. Безне дә тынычландырырга теләгәндәй, янибызга килеп сөйләнергә тотынды.
— Хатын-кызның елавына ышанма син, бу инде бигрәк хәтәр кыла-на. Йола буенча да еларга ярата инде алар.

Ләкин аның сүзләре безне юата алмады. Бездә яңадан боз өстенә төшәрлек дәрт калмаган иде инде. Тизрәк актларына кул куярга да олы юлга чыгарга ашыктык. Кайда соң безнең Фәнил? Ул да шунда икән. Тик хәзер аның өчен дөньяда без юк. Мәет бар аның өчен, милиция кешеләре һәм Маша белән Ваня трагедиясе.

— Сез инде, Тажи абый, балыкка үзегез генә төшегез,— диде ул.— Мин монда калам әле.

Без аңа кайтып китәргә җыенуыбыз турында әйткәч тә, үз карарыннан чигенмәде.

— Кайтыгыз алайса,— диде.— Мин монда калам. Бу тарих белән ныклабрак танышасым килә...

Без аның белән яңадан өч көннән соң гына очраштык. Шактый нәрсә белеп кайткан иде. Ваня суга үзе ташланмаган, кемдер аны батырган, яки үтереп суга ыргыткан. Мәетнең яныннан бернинди дә документ-мазар чыкмаган. Җинаятьчене эзлиләр икән. Тик озак вакыт үткәнлектән, тотынып җир табу бик кыен, ди. Фәнил хәбәрләшеп торырга сөйләшеп кайткан. Маша өендә поминка уздырганнар, Ваняның туган-тумачалары җыелган.

Фәнилгә шунысы ошаган: Ваня турында төрле истәлекләр сөйләгәннәр. Бик колоритный фигура булган егет.

Бу гаилә турында ярыйсы бай эчтәлекле мәкалә чыгар, дигән иде журналист. Тик аның тикшерү нәтиҗәләрен көтәсе бар иде әле.

Хәзер инде ул вакыйгага өч айдан артык вакыт узды. Шуннан соң без боз өстенә чыкмадык. Җәй башлангач кына Фәнил белән очрашкан чакларда искә төшергәләсәк тә, җинаятьчене эзләү буенча бернинди яңалык та юк иде әле. Менә хәзер, ишетмәсәң ишет: Ваня тере, имеш! Ярар, ни булганын Фәнил кайткач сөйләр әле. Хәзергә миндә аның кайгысы түгел.

*Ахыры бар*



## Галимҗан Латыйп

### Хатлар язар идем

Хатлар язар идем дә бит сиңа,
Почтальоннар илтеп бирмәсләр.
Бер туйганчы сөйләшәсе килә,
Бирер идең миңа киңәшләр.

Адресыңны белмим,
Ичмасам, мин
Чәчәк илтер идем үзеңә.
Әрнетәләр җанны кайчакларда,
Мохтаҗмын шул, әткәй,
Бик мохтаҗмын,
Җылы бөркеп торган сүзеңә.

Каһәр суккан
Сугыш бутады шул,
Адресларны бик нык бутады.
Безнең өчен хатлар йөрсәләр дә,
Сезнең өчен хатлар тукталды.
Бик кыенга туры килгәндә дә
Түзәбез без,
Әткәй, дәшмибез.
Күңел һаман үзенекен итә,
Гел өметләр белән яшибез.

Күтеп яшәве ул
Көтмәгәнгә
Караганда артык тоела.

Резедалар утызынчы язын
Каршыларга инде җыена;
Көтеп яшәүләре кыен ла.
Син кайтырсың кебек бу елда.

## Ирдәй ирләр

Башка бүрек кигәннәр
Барсы да ир булмыйлар.
Ир кешенең ирлеген
Утта-суда сыныйлар.

Чын ир кеше, билгеле,
Сабыр булыр, көйрәмәс.
Әйткән сүзе бер аның,
Ике тапкыр сөйләмәс.

Ирдәй ирләр һәр җирдә
Хаклык өчен таш ярыр.
Ир кешенең ирлеге
Бишектән үк башланыр.

Ир-егетләр ир булса,
Булмый алар җилкуар.
Ирдәй ирләр һәр җирдә
Җиң сызганыр, бил буар.

Ирдәй ирләр давылда
Бөгелмәс һәм сыгылмас.
Дошманнары алдында,
Үлсә үләр, егылмас.

## Шатлык һәм кайгы

Йортыңа яу килгәндә,
Күршең билен бумаса,
Кайгы туйга җыена,
Шатлыкларың елаша.

Кайгы авыр аяклы,
Аска тарта иңнәрне.
Оча кеше кош булып,
Килсә шатлык җилләре.

Шатлык шатлык инде ул,
Менә зәңгәр күкләргә.
Аны кеше бергәләп тә,
Ялгызы да күтәрә.

Ә кайгыны беркем дә
Күтәрәлми бер үзе.
Чөнки кайгы төбендә
Ята елан мөгезе.

Син әгәр дә кешегә
Кояш китерсәң башлап,
Бәхет кошың беркайчан
Китмәс ул сине ташлап.

## Кылычым—яманнарга

Мин колы да, солдаты да
Түгелмен «аллаларның».
Кемгәдер таш аттырырга
Яраннар ялламадым.

Вак җанлы адәмнәр белән
Итмәдем алыш-биреш.
Яраттым җирне, күкләрне
Саф килеш, аек килеш.

Очраса юлда эт, бүре,
Юк, кире чигенмәдем.
Дошманым кылыч селтн дип,
Булмады иелгәнем!

Юл биргәннәргә юл бирәм,
Кул биргәнгә кул бирәм.
Тәкәбберга мин тәкәббер,
Кулда корыч дилбегәм.

Кешегә, җиргә, дөньяга
Изгелек кылганнарга
Табынам аллам итеп мин,
Кылычым — яманнарга!

## Базы буе бөдрә тал

Базы буйкайлары,
Әй, бөдрә тал,
Базы буйкайлары куаклык.
Күңелләрне суыталмый икән
Вакыт белән ара ераклык.

Юлда йөреп,
Рәхәт кыен күреп,
Чәчләргә чал кергән, арылган.
Тик шулай да
Мине туган ягым
Онытмаган,
Бик нык сагынган.

Әллә кайчан,
Чаналарга салып,
Алып киткән чакта юлларым,
Елмайгандыр дөнья,
Мин көчле дип,
Олактырам диеп ир җанын.

Сагынырдайларны онытмыйлар,
Кайталмыйча ятып калса да.
Ирдәй ирләр түзә барысына,
Утны-суны кичә, таш яра.

Андыйларның кайта исемнәре,
Мәңге үлмәс данга төренеп.
Исемең дә булсын исәннәргә
Горур басып җирдә йөрерлек.

Базы буйкайлары,
Әй, бөдрә тал,
Чабаклары уйный таң белән.
Сиңа булган кайнар мәхәббәтем
Малай чагымнан ук кабынган.

Базы буйкайлары,
Әй, бөдрә тал,
Үткәнеңнән үзең гыйбрәт ал!

## Шагыйрьләр килгән авылга

Шагыйрьләр килгән авылга,
Өр-яңа шигырь алып.
Шыгрым тулы урыннар,
Ни әйтер икән халык.

Утырмый алар бу залда
Кызык һәм мәзәк өчен.
Сыный ул олы накалда
Шигырьнең тарту көчен.

Юк монда тамак аралау,
Шаккатмый исемеңә.
Гөнаһны дуслык хакына
Теләми кичерергә.

Төсләрне таный, күрә ул,
Чүп-чарны ата читкә,
Халык ул шагыйрь, олы дип,
Әйтмәгән Тукай тиккә.

Селкенми тыңлый шигырьне
Бер җан, бер кеше булып.
Кайчакта ташып чыга ул
Ярлары аша тулып.

Ә кайчак
Шигырь белән зал
Тоташа алмый сүнә.
Пегаслар төшә әйләнеп,
Пегаслар ятып үлә!

## Әнкәем минем

Шатлыкларым минем — синең шатлыгың,
ә кайгыларым — синең дә кайгың.
Балам, балам дип,
йөрәгең синең күпме сызлаган.
Йөзеңдә гүя — дөнья картасы,
укып бетмәслек — тирән сызмалар,
Әнкәем минем!

Кара чәчләрең — ап-ак сөт кебек,
аяз күк кебек — тора җемелдәп.
Бу алтын куллар күпме оеклар,
күпме бияләйләр
кидергән безгә бәйләп, егерләп,
Әнкәем минем!

Кулыңнан синең җир исе килә,
күпме изгелек кылган ул җиргә.
Сабый чагымнан — син минем күгем.
Дөньямны көйлим,
матурлыйм диеп
гомер буеңа яндың да көйдең,
Әнкәем минем!

Син яккан уттан күпме җылылык,
күпме көч алдым.
Ләкин аларны үземә түгел,
мин кешеләргә өләшә бардым,
Әнкәем минем!

Бер ләйсән яңгыр
нихәтле шифа китерсә җиргә!
Бер елмаюың — шул яңгыр кебек,
көч бирә миңа,
күңел кошымны төшерми җиргә,
Әнкәем минем!

Беләм мин, беләм,
балам кайтыр дип,
мичең ягулы, ашың салулы.
Көтәсең иртән,
көтәсең кичен,
белмисең бер дә ару-талуны,
Әнкәем минем!

Аллаларга тиң,
хөрмәткә лаек
җир йөзендәге барлык аналар.
Чөнки мин беләм,
аналар җаны
гел изге уттан гына яралган,
Әнкәем минем!

## Йөрәк

Читлек эчендәге арысландай
Тыпырчына йөрәк.
Әй мөкатдәс, олы, якты дөнья,
Ворчылырга өйрәт.

Сөйләсәләр, әйдә сөйләсеннәр,
Миңа кагылмый, дип,
Тыныч кына, борчулардан читтә
Йөрүче дә бар бит.

Яхшы белән яман буталмасын,
Бутаучылар булыр.
Түбәнлектән саклана күр берүк.
Бул, йөрәгем, горур!

## Сынап карый

Севастополь ярларына
Юл тота безнең кораб.
Сапун тау итәкләренә,
Бастионнарга карап.

Көлешеп бара идек без,
Җырлашып бара идек.
Күкрәккә диңгез һавасын
Тутырып ала идек.

Кузгалды көчле дулкыннар,
Ишелеп килә өскә.
Штурман безнең гәүдәне
Аударымый тота көчкә.

Су чыга аяк астына,
Батабыз кебек тоела.
Юк, сынап кына карый ул...
Куркакның җаны коела.

## Азат Ганиев

# СҮЗСЕЗ ҖЫР

ПОВЕСТЬ



Виктор Иванович Дудин, хезмәт кенәгәсен яңадан бер кат актарып, карап чыкканнан соң, кул аркасы белән аның ачык битенә «шап» итеп сугып:

— Ни өчен сезне болай бер эштән икенче эшкә куып йөртәләр? — дип сорады.

Хезмәт кенәгәсенең иясе — озын чәче алдан маңгаена, арттан муенына ук төшкән «стиляга» кыяфәтле егет — ваемсыз гына:

— Кумадылар, мин үзем,— диде.

Ул моны иренеп, шундый бер йокылы тавыш белән әйтте, Виктор Ивановичның хәтта сәбәпсезгә ачуы кабара башлады.

— Әкият сатмагыз,— диде ул,— мин моның ничек эшләнгәнен беләм. Алдыңа кәгазь-каләм куеп: «Үз теләгем белән китәм, дип гариза яз, яки кырык җиденче статья белән куам!» — дип әйтәләр. Шулаймы? Шулай! Юк, туганкаем, мине алдый алмассыз...

Виктор Ивановичның сүзен бүлеп, өстәл өстендә бохар песиләренә охшап ятучы төрле төстәге телефоннарның берсе «мр-р-р-р» итеп куйды. Дудин аны сыртыннан күтәреп авызы кырыена китерде. «Ыһы! Ярый-ярый!» «Шулай» дия-дия, очып барган кошны күзәткәндәй, күзләрен түшәмдә йөртте. Ул өлкән яшьләрдәге тулы гәүдәле кеше иде. Күз кабаклары җыерчыкланып, салынып беткән тора: бала йоны кебек юка, аксыл чәчен бик тырышып артка тарап куйган. Трубканы урынына куйганнан соң, ул бер тын уйланып торды. Каршысындагы егет күзенә чалынгач, әлеге хезмәт кенәгәсен кулына алып:

— Шулай да, яшермичә, дөресен генә әйтегез әле, ни өчен куалар иде? — дип сорады.— Эшкә аламмы, юкмы, анысы башка мәсьәлә: минем беләсем килә.

Егет кисәк кенә башын күтәрде. Шул чак аның озын чәчләре астыннан киң ак маңгае ачылып калды. Ул, һич уйламаганда, дустанә эчкерсез елмаеп:

— Эшкә алыгыз, белерсез,— диде.

Виктор Иванович Дудин, көләргә җыенгандай, авыр гәүдәсен урындык аркасына ташлады. Әмма зур ачылган авызыннан бары тик «Хо!» авазы гына бөркелде.

— Юморны мин дә яратам,— диде ул.— Ә менә сез җилкуар бер ялкау булып чыксагыз?

Виктор Ивановичка художник кирәк иде. Әгәр борын төбендә 1 Май демонстрациясе тормаса, югары начальниклар килгән саен: «Ни өчен сезнең предприятие ташландык хәлендә? Плакатлар эленмәгән, күрсәткечләр тактасы да юк?!» — дип, теңкәсенә тиеп тормасалар, үзен артык бәйсез тотучы бу егетне ул күптән борып чыгарган булыр иде. Бәладән башаяк! Виктор Ивановичның моннан ике ай элек куып җибәргән художнигы да үтә хәйләкәр бер ялкау булды. Эшкә вакытында килә иде үзе. Эшем няседәй мастерскоен ачып, буяуларын чыгарып сала иде дә, күз ачып йомганчы әллә кая югала иде. Бервакыт Виктор Иванович, карый килеп, аның артыннан ук мастерскойга керде. Керсә — беркем юк. Тәрәзә дә бикле. Стена аша чыгып китә алмый бит инде кеше! Дудин шикләнеп ачылмалы өстәл астына күз салды һәм анда художникның фуфайка җәеп йокларга әзерләнеп маташуын күрде. Бу егетнең дә озын чәчләре Виктор Ивановичны шикләндерә иде. Ләкин предприятиегә художник кирәк.

— Рәсем ясарга, ничек? Үзегез өйрәндегезме?

Егет идәнгә караган килеш:

— Художество училищесын тәмамладым,— диде.

— Ыһы, монысы ярый.

Дудин бармаклары белән өстәлгә суккалап тора башлады. Ниһаять, тәвәккәлләп, әмма үзенә-үзе каршы килгәнлеге аермачык сизелеп торган тавыш белән:

— Ярый, алам мин сезне эшкә,— диде. Аннары эшлекле мөгамәләгә күчеп:— Өйләнгәнме? — дип сорады.

— Юк.

— Әле кайда торасыз?

— Танышыма туктаган идем.

— Әлмәтнеке түгел, димәк. Анысы кыен икән. Тулай торакка урнаштыруы да бер бәла бездә. Урын юк. Алдан ук әйтеп куям. Ул елсыз да квартир вәгъдә итә алмыйм.

Виктор Иванович Дудин, өстәлен күтәреп китәргә җыенгандай, кулларын як-якка җәеп:

— Менә шулай,— диде һәм артистлык чалымы сизелеп киткән бер хәрәкәт белән урыныннан торды.

— Әйдәгез, мин сезгә нинди эшләргә кирәклеген күрсәтәм. Исемегез ничек әле?

— Габделхак.

— Ыһы. Әйдәгез.

Виктор Иванович ишек алдына чыгу белән, шигырь сөйләргә җыенгандай, кулын җилпеп, йөз метрларга сузылып киткән цех корпусына ишарәләде.

— Менә. Урам як фасадына әллә каян күренеп торырлык итеп биш-алты панно ясарга кирәк. Мәсәлән, тарихи үсешне чагылдырган тема, ди. Беренче панного Аврора крейсерын, прожекторлары белән. Икенчесенә граждашнар сугышы, аннары тыныч төзелеш. Боларны кәгазьгә сызгалый-билгели барсагыз иде.

Габделхак кәгазь-каләм алырга дип рюкзагының авызын чиште. Һәм шунда, ничектер, тышкы дөньядан аерылып, үз-үзе белән калгандай булды.

Ул башын күтәрде һәм үзе эшләячәк предприятиенең барак тибындагы килбәтсез биналарын, кыштан соң җыештырылмаган шыксыз ишегалдын күрде. Әнә ашханә ишегеннән чибәр генә ике кыз чыгып килә. Киенә белеп киенгәннәр: шакмаклы кофта, өрфия косынка һәм тар балаклы чалбар. Ә күктә яз кояшы.

Ашханәдән кетмәгәндә чыркылдашып тагын бер төркем килеп чыкты. Аларны тузган чәчле шаян егет өркеткән икән. Ул әле һаман көлешеп торган кызларга тешен елтыратып алды да, берни булмагандай,

шунда гына торган йөк машинасының ишеген ачып кабина эченә чумды һәм, кинәт борылып, Виктор Ивановичның йодрыгы астыннан капкага таба томырылды. Габделхак рюкзагыннан альбом, ретуш каләм алган иде инде, ары киттеләр. Дудинның илһамы килгән чак булган, күрәсең, берничә сәгать эчендә Габделхакны муеннан эш белән күмеп ташлады.

— Менә шулай, иптәш Гайнуллин,— диде ул, нәтиҗә ясап.— Ялкауланмаска! Үзебезнең предприятиене үрнәк булырлык итеп бизәргә! Әһә! Без мастерскойны карамадык бит әле. Әйдәгез.

Әлегә эленке-салынкырак йөргән Габделхакка җан керде. Ул таныш кешесенең исемен ишеткәндәй җәһәт кенә Виктор Ивановичка карап алды. Аның өчен иң мөһиме мастерской иде.

Цех эченә керделәр. Төш вакыты булганлыктан, иясез калган станоклар зур тәрәзәләрдән төшкән кояшта җылынып утыралар. Эшчеләр прораб бүлмәсендә домино сугалар икән. Виктор Иванович баш кагып исәнләшкәннән соң, тәмәке төтененә йөзен чытып:

— Ну, иптәшләр, һич югы, тәрәзәне ачар идегез,— диде. Мастерларыдыр, күрәсең, башкалар кебек спецовка түгел, ә костюм кигән ир уртасы кешегә мөрәҗәгать итеп:

— Хисам Гыймадиевич, мастерскойны ачыгыз әле. Менә яңа художникка күрсәтик,— диде.

Габделхак бу Хисам Гыймадиевич дигән кешенең ике кашы белән туры борыны зур «Т» хәрефенә охшавына игътибар итте. Гомумән, караңгы чырайлы төмсә кеше иде бу. Домино шакмакларын да ул ниндидер могҗиза белән кечкенә йонлач кулына җидесен берьюлы сыйдыра алган иде. Дудин дәшкәч, урыныннан торып, доминоларын өстәлгә ташлады да, күтәрелеп карамастан, кесәләрен капшый-капшый, ишеккә таба атлады.

«Плюшкин!» — дип уйлады Габделхак.

Мастерской цехның аргы башында икән. Ул төрле сорт банка, чиләкләр, рамнары сынган плакат, лозунглар белән яртылаш тулган иде. Габделхак чалбарын буямаска тырышып (ә аның чалбары бик хәтәр, сырына кагылсаң, бармагыңны кисәрлек итеп үтүкләнгән. Атып бәрсәң стенага барып кадалырлык очлы борынлы ботинкалары ялт итеп тора) сакланып кына эчкә үтте.

Бүлмә шактый зур, һәм Габделхакка иң ошаганы — тәрәзәләре төньякка карый иде. Димәк, яктылык көннең-көн буена бер төрле булачак.

Габделхак стена буендагы өстәлнең рәсем ясар өчен махсус авышрак итеп эшләнгән өслеген кулы белән сыйпап:

— Өстәле әйбәт икән,— диде.

Ишек төбендә кызыксынып карап торучылар дәррәү көлеп җибәрделәр. Бер яшьрәге, эчен тотып, прораб бүлмәсенә йөгерде. Бераздан анда да кайтаваз сыман көлү яңгырады. Бу предприятиенең Габделхакка кадәр эшләгән художнигы шушы өстәл астында йоклап тотылган иде. Дудин көләргә дә, көлмәскә дә белмичә, шикләнеп, Габделхакның йөзенә текәлде. Ләкин аңарда мәкер-фәлән сизелми, хуҗаларча кайгыртучанлык кына иде.

* * *

Виктор Иванович юкка хафалана иде. Ялкаулану Габделхакның уенда да юк: кушылган эшләрне тизрәк бетереп, күптән уйлап йөргән картинасын киндергә төшереп карарга ашкына иде егет. Ул беренче көнне үк мастерскойдан барлык иске-москыны чыгарып атып, түшәм, стенасын тузаннан, үрмәкүч ояларыннан арындырды, тәрәзәләрен су белән коендырды, чип-чиста итеп идәнен юып чыгарды. Аның боларны

һич иренмичә, хәтта тәм табып эшләве күренеп тора; спецовканың җиннәре сызганылган, борынына бөрчек-бөрчек тир чыккан иде. Аннары ул буяуга каткан банка, чиләкләрне тимерче мичендә яндырып чистартты. Элекке художник әйберләреннән бары тик шулар гына бүлмәгә кире кайтты. Калганнарын Габделхак чүплеккә ташлады. Шунда Хисам Гыймадиевич һаман бәйләнә торды.

— Менә бу рам гел ярамаслык түгел, Габделхак энем. Сынган. Ну что ж! Бер-ике кадак бәрдең куйдың, тора ул. Кая китсен!

Габделхак, ачуланышырга теләмичә, аның һәр сүзен җөпләп, «ярар», «ярар» дип торды. Чөнки ул әйберләрне Хисам Гыймадиевич күрмәгән арада да илтеп ташларга була иде. Ләкин теге китәргә ашыкмый, Габделхак ташлаган бер әйберне кире алып, бөтен сыйфатларын тасвирлап чыга иде.

— Бу ягы пычранган, ну что ж, икенче ягына ясарга була. Калдыр син моны, Габделхак энем. Ашарга сорамый ул. Бер кирәге чыгар.

Габделхак тәмам гаҗиз булды. Ахырда түзмәде: «Ярар», «Ярар» ди торгач:

— Ярарсана!! — дип кычкырганын сизми дә калды.

Берничә көннән соң Габделхакның мастерскоеннан тылсым юлы белән барлыкка китерелгәндәй, ике-бүе бишәр-алтышар метрлы паннолар чыга башлады. Кызыксынып карап торучылар аның янынннан өзелми иде. Габделхак үзе канәгатьсез, ачулы йөри. Чөнки ясарга җайлы бу плакатлар белән кулын игътибарсызлыкка өйрәтүен, акрынлап халтурщикка әйләнә баруын сизә иде. Ипиең шул булгач, ясамыйча нишлисең? Габделхак алардан тизрәк котылырга тели, шуңа күрә каударланып һәм күпләп ясый иде. Ләкин Виктор Иванович яңадан-яңа эшләр табып кына тора. Габделхакның: «Артык чуар да килешми»,— дип бәхәсләшергә маташуына ул:

— Ярый, ярый. Ботканы май бозмый. Сиңа нәрсә, барыбер түгелмени? Буявың бар, пумалаң кулыңда, яса да яса, яса,— дия иде.

Ике көнлек ялның да Габделхакка әллә ни файдасы тимәде. Ял көннәрендә мастерскойга керә алмый ул. Эчендә кыйммәтле производство җиһазлары булганлыктан, цехны ял көннәрендә биклиләр, өстәвенә, каравылчы куялар. Тулай торак бүлмәсенең тәрәзәләре көньякка караганлыктан, яктылык гел үзгәреп тора, аннары анда ясарга рөхсәт тә итмәсләр иде. Бүлмәдә болай да кысан. Ике көнлек ял этюдка йөрергә кулай аны. Габделхак авылларына кайтып та этюдлар ясаштыргалый. Ләкин этюд инде ул зур картинага әзерлек кенә.

Дудинның бетмәс-төкәнмәс эш кушуларыннан ничек тә котылырга кирәк иде аңа.

Беркөнне Габделхак Виктор Иванович янына ватман кәгазь төргәге күтәреп керде.

— Предприятиенең гомуми күренешен ясаган идем,— диде.— Югыйсә, безнең плакатлар, лозунглар артык күбәеп китте. Аларны бөтенесе бер композиция тәшкил итәрлек бер тәртипкә салырга кирәк.

Габделхакның шулай боргалап-сыргалап сөйләве Дудинны башта гаҗәпсендерде.

— Кызык бу! Яле карыйк,— диде ул.

Өстәл өслеге кадәрле кәгазьне җәеп җибәрүгә, Виктор Ивановичның күз аллары әлҗе-мөлҗе килеп торды. Тел тидергесез пөхтә итеп ясалган оҗмах бакчасын күрде ул. Шул ук вакытта бу аның — үзенең предприятиесе иде. Әнә цех корпусы, контора, ашханә, склад һәм башка йортлар.

— Монысы нәрсә?

— Күрсәткечләр тактасы.

— Миңа ошый бу! Што син! Чыннан да шушылай итеп ясап куй-

сан, ә? Модерн, яңа стиль сизелә монда. Урынын да дөрес сайлагансың. Ләкин тукта әле, бу урында безнең туалет тора ич.

— Виктор Иванович, мин сезгә күптән әйтергә җыенып йөри идем. Туалетның урыны монда түгел. Аннары ул яртылаш тимер-томыр белән күмелгәнлектән генә аумый тора. Ишектән чыгу белән, үзегез дә сизеп йөрисездер, аннан хлор исе һәм тагын шундыйрак ис килә. Бульдозер белән эттереп, бу урынга юкә агачлары утыртырга кирәк. Шул агачлар каршына менә рәсемдәгечә күрсәткечләр тактасы урнаштырырбыз. Ә менә монда, цех каршындагы буш урынга, каен агачлары...

— Ярый, ярый, агачларың торып торсын. Күрсәткечләр тактасы ясарсын. Сварочный агрегат, ярдәмгә ике кеше бирәм, иртәгедән тотын.

Габделхакның күзгә күренеп күңеле сүрелде.

— Аны ташландык җир уртасына, җитмәсә, туалет каршысына ясап куйсаң, ыштансыз билгә каеш бау булачак. Башта агачларын утыртырга кирәк,— диде ул, һәм бераз уйланып торганнан соң:— Бәлки, бу предприятие монда вакытлычадыр? — дип сорады.

Виктор Иванович Дудин арыган бер кыяфәттә көлемсерәп куйды, өстәленә таба китеп барышлый:

— Предприятие вакытлыча түгелдер, ә менә дәүләт планы өзелсә, минем вакытлыча булуым бар,— диде, өстәл почмагына җитәрәк Габделхак ягына борылып: — Миннән бит ничә төп агач утырттың? — дип сорамыйлар. Давай, юк белән баш катырмыйк. Күрсәткечләр тактасын яса. Анысы кирәк,— диде.

Габделхакның хәйләсе барып чыкмады.

* * *

Һәйкәл тирәсендәге утыргычлар Габделхакның арыган аякларына ял вәгъдә итеп ерактан ук чакырып алдылар. Чемоданын, этюдникгын утыргыч кырыена куйганнан соң ул кулъяулыгы белән маңгаена, борыны өстенә бөрчек-бөрчек булып чыккан тир тамчыларын сөртергә кереште. Шул чак кемдер аңа исеме белән дәште. Борылып караган иде, үзеннән берничә адымда укытучы-остазын — Мөнир Хәертдиновичны күрде. Мөнир Хәертдиновичның юка күзлек пыяласы аша дөньяга игътибар белән караган күзләре, Һади Такташныкы кебек кабарып һәм як-якка төшебрәк торучы чәчләре, гомумән, таныш, бик таныш килешкилбәте: «Сез таралышып беттегез, мин генә сезнең үткәннәрегездә яшим»,— дия иде сыман. Габделхакның колагына студент елларының шау-шуы ишетелгәндәй, борынына майлы буяу исләре килеп бәрелгән кебек булды.

Мөнир Хәертдинович белән Габделхак сүзсез генә кул кысышып һәйкәл кырындагы мәрмәр ташлар өстенә утырдылар.

— Я, ничек, тормышыңнан канәгатьме?

Габделхак, остазының бу соравына капылт кына җавап бирә алмаганлыктан, башын кыңгырайтып уйга калды.

Гадәттә шулай була. Укучы белән укытучы очрашканда, укучы үзен шат күңелле итеп күрсәтергә тырыша: зур эшләр башлавы, тиз башкарачагы турында сөйләргә тотына. Янәсе, менә күр, син нинди кеше тәрбияләп чыгардың, синең тырышлыкларың бушка китмәс, янәсе. Мөнир Хәертдинович үз гомерендә андый егетләрне күп очратты. Тик алар тормышның бетмәс-төкәнмәс тармакларына кереп китеп, кайлардадыр сенеп кала тордылар. Мөгаен, җылы почмак табып, гаилә корып җибәргәннәрдер...

Карт укытучы бу турыда беренче тапкыр гына уйланмый һәм: «Арада талантлылары бар иде бит»,— дигән кайнар пошыну да аның йөрәк маен беренче мәртәбә генә сызмый.

Габделхакка өмете зур иде аның. Диплом эше өчен ясаган картинасы белән чын-чынлап сөендергән иде аны Габделхак. Картинаның темасы, композициясе гади генә: сөт бидоннарын юарга дип инеш буена килгән кыз. Ул, эшкә тотынганчы, яулыгын әйбәтләбрәк бәйләргә теләп, кулларын баш артына күтәргән һәм кояшка үрелүче гөлгә охшап алгы планда басып тора. Ул эш аты гына түгел, ул — кеше! Үзенчәлекле характерлы кеше. Мөнир Хәертдинович ул картинага озаклап карап торган чакларда татар көйләрен ишетә башлагандай була һәм: «Бу инде начар түгел. Бу — егеттә табигый рәссами сиземләү бар дигән сүз. Шул сиземләве аны, үзенчәлекле милли форманы, колоритны нәкъ менә шул халык көйләреннән эзләргә этәргәндер»,— дип уйлый иде. Ул чагында Габделхак үзе моны аңламый иде әле.

Мөнир Хәертдинович, дәрескә хәзерләнми килгән укучы мисалында, гаепле бер кыяфәттә утыручы Габделхакка карап алганнан соң: «Әле дә аңламаган, ахрысы,— дип уйлады.— Кайчан да булса ул моны йөрәге аша кичерер әле, үзенә үзе ачыш ясап тетрәнер әле. Бу турыда аңа мин әйтсәм, бер колагыннан кереп икенчесеннән чыгачак. Габделхак моны газаплы эзләнүләр аша үзе тапсын иде. Чын әсәрләр шундый чакта туалар да».

— Яшәвең кайда? — дип сорады Мөнир Хәертдинович.

Габделхак калкыныбрак утырды.

— Хәзергә Әлмәттә. Аңынчы төрле җирдә, төрле эшләрдә эшләргә туры килде. Ничек итсән дә уңайсыз. Майлы буяулар белән ут яктысында эшләп булмаганлыктан, төнге сменага да күчеп карадым. Кая! Йокламагач баш түнгән була...

Саран, ярым-йорты әйтелгән бу сүзләр Мөнир Хәертдиновичка күпне сөйләделәр. Ул Габделхакның үзеннән аерылып киткәннән соңгы тормышын күз алдына китерде.

Габделхак, укытучысының игътибар белән тыңлавын күреп, ачыла төште.

— Вакыт житми. Вакытны аннан-моннан йолыккаларга туры килә. Моның өчен, билгеле, эш урынында рәхмәт әйтмиләр. Бер мактәп директоры миңа: «Син сөтен биреп бетерми торган усал сыер кебек»,— ди иде.

Шул чак Кремль сәгатьләре үз эшләрен бик белеп, ашыкмый гына кичке алтыга суга башлады. Габделхак, тымызык болытлы караңгы күк йөзенә кадалып кергән ап-ак Казан Кремленә бер тын карап торганнан соң: «Искитәрлек сырлары, челтәрләре дә юк, әллә нәрсәсе белән сөйкемле шушы»,— дип уйлады.

Чаң авазлары һавага таралып, эреп бетәр-бетмәс үк, Мөнир Хәертдинович:

— Хәзер ни эшләргә ният? — дип сорады.

— Башымда туып килгән темам бар. Мөмкинлек булса, киндергә төшереп карар идем.

Мөнир Хәертдинович канәгатьсезләнеп җәһәт кенә күзлегенә кагылып алды.

— Туып килгән темаң турында кешегә әйтергә ярамый. Үз тәҗрибәмнән беләм. Самими сафлыгымы, серлелегеме югала да күңел кайта. Кеше күрсә, йорт куяны яңа туган баласын үзе ашый. Ни хикмәттер, монда да шул хәл. Мөмкинлек булса, киндергә төшереп карар идем, дисең. Мин сиңа мастерской табарга булыша алам. Ләкин, беләсеңме, синең яшьтә мастерскойга бикләнеп эшләү куркыныч нәрсә ул. Табигатьтән, тормыштан аерылуың бар, тәрәзә төбенә күчереп утыртылган гөлгә охшап калуың бар.

Һич уйламаганда, борыннан кан киткәндәге тойгыны уятып, мыштым гына җылы яңгыр ява башлады. Бу яңгырның тамчылары үзгә иделәр; туп-туры, әмма гадәттәгедән акрын төшәләр һәм, киемгә сең-

мичә, терекәмеш сыман ялтырап тәгәрәшәләр иде. Габделхак малайлар кебек авызын ачып, күзләрен кыса төшеп, өскә карады.

— Ләйсән яңгыр! Ләйсән яңгыр бит бу, Мөнир абый!

Мөнир Хәертдинович үзалдына елмая-елмая урыныннан торып:

— Яусын әйдә, сиңа файдалы ул, чәчең үсәр,— диде. Әле мин дә һава суларга чыккан идем. Әйдә безгә, Зәйнәп апаң чәй белән сыйлар үзенне.

Габделхак та торып басты.

— Юк, рәхмәт,— диде ул.

Габделхак укытучысының үз-үзен тотышыннан яңа картина өстендә эшли башлаганлыгын сизенгән иде инде, вакытын алып бимазалап йөрүне яхшысынмады.

— Я, ярый алайса,— диде Мөнир Хәертдинович.— Хуш иттек,— диде һәм ашыгып китеп тә барды.

Габделхак аның җиңел аяк тавышларын тыңлаган көе:

— Бирешми әле,— дип уйлады.

Баядан бирле аның аркасына талгын җил кагылып тора иде, шул якка карамыйча булдыра алмады. Анда Габделхак борылышларда ялтырап-ялтырап әллә кайларга китеп югалган Иделне, Иделне генә түгел, чал тарихны күрде. Шул яктан искән җил дә җил түгел, үткән заманның сулышы иде сыман.

* * *

Беркөнне төшке ял вакытында Габделхакның мастерскоена Шамил килеп керде. Токарь егет ул. Куе кара чәчле, кызларныкыдай чибәр, каратут йөзле. Эчми, тартмый, спорт белән шөгыльләнә, әмма ләкин кызлар артыннан чабып карый инде үзе дә.

Шамил, Габделхакның тын мастерскоен калын күкрәк тавышы белән җанландырып:

— Әйдә, ашханәгә киттек,— диде. Һәм өстәл өстендәге буяулы банка, линейка, каләм, пумалачыкларны бәрәм-бәрәм тотып, кайберләрен хәтта тешләп карап урыннарыннан кузгатырга керешә. Аның гадәте шулай.

Габделхак кер сабыны белән кулын юып тора иде.

— Мин шәһәр ашханәсенә барам. Монда начар хәзерлиләр,— диде.

— Һәй, синдә ашау кайгысы! Безнең ашханәдә яңа кыз эшли башлаган. Күрсәң, малай, чибәрлеген. Егыласың. Хотя художникны егарга күп кирәктер. Ну шулай да чибәр инде каһәр.

Шамил үзенекен итте. Калын тавышы белән гөрли-гөрли Габделхакны тәки күндерде.

Ашханәдә кеше күп иде. Барысы да диярлек егетләр. Шамил белән Габделхак та чиратка бастылар. Үзен күрмәс борын ук Габделхакның ул кызга ачуы килә башлады. Башка егетләрнең һәм үзенең юләрләр сыман нәкъ менә аны күрергә җыенгандай чират торуларынадыр, бәлки.

Чибәрлеккә чыннан да чибәр икән. Тәмле аш исләреннәнме янаклары алсуланган. Маңгае, керфекләре, урталай теленгән чиядәй иреннәре дымланып тора. Зәңгәр күзле, кояштай сары кыз. Кар кебек ак халатының җиңнәрен сызганып куйган да: «Менә мин шундый матур инде»,— дигәндәй үзалдына елмая-елмая аш бүлә.

Өстәл янына килеп утыргач, Шамил:

— Я ничек? — дип сорады.

Габделхак авызына котлет тутырып өлгергән иде, җавап биреп тормады, башын кыңгырайтып, җилкәләрен генә җыерып куйды.

Габделхак атнага якын Альбинага сүз катарга кыймый йөрде. Гапгади инде, югыйсә, ашханәгә кеше юктарак керепме, эштән кайтканда-

мы, киногa, я пляжга барырга чакырасы гына, югыйсә. Искергән алым бу, ләкин башка мөмкинлек юк.

Альбина аны кире какты. «Бу киноны караган идем».— диде. Икенче тапкырында кирәк кадәр ягымлы, гафу үтенгән тонда сәбәбен ышандырырлык итеп:

— Габделхак, зинһар, башка вакытта, яме. Мин авылга кайтып килергә булган идем,— диде.

Габделхак Альбинаның тәҗрибәле кыз булуын, нәрсә эшләгәнен белеп, алдан исәпләп эш итүен сизенде. Альбина хәзер Габделхакның горурлыгы кимсетелгәнлеген һәм шуңа күрә кире чигенмәячәген аңлый иде, күрәсең.

Өченче тапкырында ул кире какмады. Зәвык белән, киенә белеп киенә икән. Кояш кунып, бронза төсенә кергән озын аяклары тулы, матур һәм ул һич тартынмыйча тездән югары итеп аксыл-сары юбка кигән. Кофтасы да, карыш киңлеге поясы да ак. Шулар өстеннән чәче төсле сары юка нейлон плащ. Альбина беренче очрашуда ук йомшак канаты белән кагылгандай Габделхакның ачу, үпкәләрен сыпыртып алды. Ләкин рәссам егетнең сизгер күңеле аның мөнәсәбәтендәге ясалмалыкны тоя иде...

* * *

Габделхак сварщикның тимерне тимергә ябыштыруына кызыгып карап тора. Тотынса үзе дә эшли алыр сыман һәм бик тә эшләп карыйсы килә. Сварщик тәмәке тартырга туктаган бер арада ул түзмәде:

— Эшли торыйммы? — дип сорады.

Сварщик агай киң күңелле кеше икән.

«Җаен беләсеңме соң?» — дип сорап тормады.— Эшлә, диде. Һәм менә Габделхак кара пыяла аша тимернең кайнавын күрә, электродның эреп баруын кулы белән генә түгел, җаны-тәне белән тоеп хозурлана. Рәсем ясагандагы кебек үк рәхәт аңа. Электроды эреп бетүгә, Габделхак масканы маңгаена күтәреп эшенә сокланып карый-карый янасын беркетә. Җөйләре каләм сызгандай тигез чыга аның: сварщик агай килеп карады да:

— Үзең дә мачтыр икәнсең ләса. Ничәнче разрәт? — дип сорады.

— Беренче мәртәбә кулыма алуым,— дигәч, Габделхакка ышанмый торды. Аннары гына:

— Һәй, энем, әрәм булып йөрисең икән! Тумыштан сварщик ласа син,— диде.

Габделхак яңадан эшли башларга торганда, Хисам Гыймадиевич килеп чыгып:

— Сине директор чакыра,— дип китте.

Габделхакның бу эштән аерыласы килми иде. Үзен мәҗбүр итеп кенә конторага таба атлады.

— Чакырган идегезме?

— Әйе. Әйдә, кер, утыр.

Виктор Иванович өстәле артында кояш кебек балкып утыра иде. Ул, Габделхакка гадәттән тыш куанычлы хәбәр әйтергә җыенгандай, урыныннан калка төшеп, көр тавыш белән:

— Менә нәрсә, Габделхак: мин сине курортка ялга җибәрәм,— диде һәм һәр мизгелдә көлеп җибәрергә әзер булып Габделхакка карап тора башлады. Габделхак исә бик үк ышанып җитмичә: «Нинди чебен тешләгән моны?» — дип уйлап утыра иде.

— Унбиш көнгә,— дип дәвам итте Дудин.— Курортның да ниндие әле! Подшефный колхоз! Ха-ха-ха!

Алдана язуына карамастан, Габделхак та рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Юморны, җанлы, шаян тонда сөйләшүне ярата иде ул.

— Юк, чынлап, бу синең өчен әйбәт булачак,— диде Виктор Иванович көлә-көлә.— Хезмәт хакың тулысынча саклана. Сөт эчәрсең, кояшта кызынырсың. Анда аларның хәзер урак өсте. Кайбер плакатлар, лозунглар кирәк икән, ну, сиңа ул берни тормый. Ризамы?

Йомшак җәеп катыга утыртуларын аңласа да, Габделхакның әллә ни кәефе кырылмады. «Нигә бармаска, авылда хәзер ямьле чак. Сәяхәт итәргә дисәң, мин беркайчан да каршы түгел. Яңа тәэсирләр, яңа кешеләр»,— дип уйлады ул.

Һәм менә аның колагы төбендә мотор тавышы, тәрәзә артында баганалар чабыша. Икешәрләп-өчәрләп тотынышкан каеннар бөтерелә, алда юл тасмасы...

Тукта! Киткәндә Альбина белән саубуллашмады ич ул! Бүген аның эш көне иде. Ашханә яныннан ничәмә-ничә мәртәбә үтте, ә кереп чыгарга башына килмәгән. Башына килмәгән! Башына килмәгән?.. Каеннар бөтерелә, алда юл тасмасы. Габделхак өчен үзе яши торган бүлмәсенә карый да таныштрак, күнегелгәнрәк күренеш. Хәер, бармыни соң аның үзенең бүлмәсе?! Ә аңа инде егерме сигез яшь. Беренче мәхәббәте Раушания бик ерак, томан артында калды. Хәтта уй кораблары да аның янына барып җитә алмыйлар. Кайда ул хәзер!..

Юл уйлары. Һай бу юл уйлары. Бер кереп чумсаң, юлдан читкә тайпыла алмаган кебек, алардан да котыла алмыйсың.

...Габделхак авыл сабан туена өлгерергә ашыгып төнге поезд белән кайтып төшкән иде. Сабан туеннан да бигрәк Раушанияне күрергә дип ашыкыган иде ул. Иртән ак күлмәгенең якаларын торгызып куеп, көзге каршында галстугын бәйләгәндә дә ул гел Раушания турында уйлады. Авыл мәктәбендә бергә укып йөргән чакларын исенә төшерде. Тәнәфес вакытларында, линейкада басып торганда ул һәрвакыт Раушаниянең зур күзләрен эзли иде. Ә Раушания яңа туган колын кебек кыюсыз, җитмәсә, коточкыч арык иде. Яңакларына йөгергән алсулыкны озын керфекләре белән каплап түбән карый иде. Габделхак шул җан иясенең күңелен табар өчен генә ниләр эшләмәде?! Ул үзендә шундый бер көч, куәт тоя иде, әгәр кешеләрдән оят булмаса һәм үзенең яратуын җырга салып бер җырласа, аның уенча, хәтта таулар да башларын түбән иеп тыңларга тиеш булырлар иде. Әгәр Раушаниягә тел тибрәтеп берничә генә сүз әйтсә, Раушания янып кара күмергә әйләнер иде сыман аңа.

Габделхак шуларны искә төшереп, үзалдына елмая-елмая, галстугын бәйләп торганда, ачык тәрәзәдә Раушаниянең тавышы ишетелгәндәй булды: тәрәзәгә капланды һәм чыннан да Раушанияне күрде. Ләкин Раушаниянең кайчандыр ут чәчеп карый торган кара күзләре гаять мәрхәмәтле һәм тыныч карыйлар иде, авызы чак кына ачылып тора, йөзен тимгел баскан, киң билле, эре парчалы үзбәк күлмәге кигән, ят бер ирнең беләгенә таянган иде. Габделхак ни өчендер ишеккә ташланды, идән уртасында аңгыраеп туктап калды, яңадан тәрәзә янына килеп басты. Шактый вакыт бер нәрсә турында да уйлый алмады ул. Күз алдыннан үткән күренешләр аның башында урын таба алмый иде. Габделхакның әти-әнисе, абыйсы, сеңелләре: «Озак бизәнә бу кала егете, Рәмзия булып Рәмзия киенеп бетте»,— диешә-диешә сабан туена киткән иделәр инде. Габделхак берниндн максатсыз, теләксез капка төбенә чыкты. Кайдадыр җырлашалар, гармун тавышлары. Габделхакның тирләгән ачык маңгаен салкынайтып йомшак җил кагылып үтте. Куе зәңгәр күк йөзендә аккошлардай купшы болытлар йөзә икән. Габделхакның уйлары шул киңлекләргә китеп таралаштылар. Яман уйлар, бүреләр сыман, кешегә көндез тимиләр, алар төнлә-кичен һөҗүм итәләр.

Габделхак сабан туена барса да барды, бармаса да барды. Раушанияне ул тагын берничә мәртәбә күрде. Соңгы күрүендә Раушания мәйданның кеше аз ягында — керәшне әби-бабайлар яшел чирәмгә

утырып, малай-шалайлар гел корсакларына ятып карый торган төшендә — үзе генә басып тора иде. Габделхак кыенсынып кына аның янына килде.

— Исәнме, Раушания,— диде.

Раушания авыр керфекләрен җилпеп, күтәрелеп карады, күзләре җанлана төште; ачык йөз белән сөйләшергә теләп:

— Исәнме, Габделхак,— диде.

Шулай да сүзсез калдылар.

— Мәктәптә укыганда мин сине яратып йөри идем, Раушания.

Бу сүзләр Габделхакның авызыннан өлгергән җимешләрдәй үзләреннән-үзләре коелдылар. Раушания гаҗәпләнмәде, белгән булган, күрәсең. Мәйдан уртасына төбәлгән килеш, ерак истәлекләр эченнән дәшкәндәй:

— Унынчы класска кадәр бергә укымавым өчен үкенеп бетә алмыйм,— диде.

— Беләсеңме, Раушания, әгәр ул чакны китмәгән булсаң, синең белән бер класста укыр өчен, юри күчми калырга уйлаган идем. Син бер класс түбән идең бит.

— Ике диген.

— Чынмы?!

— Әйе. Син тугызда чагында мин җидедә генә идем әле.

— Алайса бер класста ике ел утырасы булганмын икән.

Алар икесе берьюлы көлеп җибәрделәр. Бу көлү аларны шунда ук чиксез якынайтты.

Раушания нидер әйтергә ымсынып, Габделхакка күтәрелеп карады, оялды, оялуын яшерер өчен озын керфекләрен түбән төшерде. Габделхак аның шушы гадәтен кайчандыр үлеп ярата иде. Кайчандыр...

Бу вакыт алар халык диңгезе уртасында бары бер-берен генә күрәләр һәм икесе дә: «Менә кайчан аңлаштык без. Соң, бик соң аңлаштык без»,— дип уйлыйлар иде.

Габделхак яралы бөркет сыман туган авылыннан читкә атылды. Кайларда гына булмады ул?! Акчасы бетсә, берәр шәһәргә туктап, эшләп ала иде. Шулай итә-итә ул Чукоткадан Каспий диңгезенәчә, Урал тауларыннан Кавказга кадәр араны аркылыга-буйга үтте. Ләкин барыбер Раушанияне онытып калдыра алмады. Габделхак акылына колак салса, акылы аны: «Җүләр син! Адәм көлкесе! Әйтерсең дөнья аңа гына терәлеп калган. Үткән эш кире кайтмый. Кара аны, үткәннәргә үкенә торгач, үкенечкә калма!» дип тирги. Ә күңелендә бер моң бар. Кемдер скрипкада уйный кебек. Смычогы белән скрипка кылларына түгел, турыдан-туры аның йөрәгенә сыза сыман.

* * *

Авыл тау итәгенә сыенган. Буа суы ялтырый. Казлар оча. Биек-биек талларның һәм тауның кара-кучкыл яшел фонында алар ап-ак төркемнәр булып әйләнәләр: «Кыйгак-кыйгак» килеп буа өстенә төшәләр. Кайберләре әйләнә-әйләнә югарыга ук күтәреләләр, ялтырып килгән күк йөзендә кинәт каралалар, ә калкулык өстендәге иген басуына кунгач, яңадан агаралар. Шунда ук — калкулык түбәсендә — бер-бер артлы ике комбайн иген урып йөри. Габделхак, бу як басу кырында, шулай ук комбайн штурвалы артында утыра. Аларның комбайннары ватылды.

Өлкән комбайнчы кирәкле детальләрне алырга авылга киткән иде, Габделхак аның кайтуын көтә. Бик иртә, сәгать өчләрдә үк уянып торган иде ул: йокысы туймаган. Керфекләре ябышып интектерә башлагач, Габделхак, әвен-тәвен килеп, түбән төште. Тимер култыксалар сап-сал-

кын һәм чык белән юешләнгән иде. Габделхак комбайн алдына бер кочак салам җәеп йөзтүбән капланып ятты. Бинибая матур иртәнге тынлык һәм шушы тынлыкка ятышлы яңгыравыклы каз тавышлары Габделхакның эчке дөньясына бөтен тәне аша үтеп керә, күңеленә якты нур һәм шундый ук иркенлек, киңлек, тынлык утыра. Бер кырмыска аның муенын кытыклап йөри башлады, күлмәк эченә үк кереп китте. Габделхак кузгалырга иренә. Тешләмәсә, йөри бирсен.

Комбайн тирәсендә камыл кыштырдады, малайларның сөйләшкән тавышлары ишетелде. Габделхак аларның һәркайсын исемнәре белән белә. Идарәдә плакат язган чагында ук алар килеп йөри иделәр. Аннары Габделхак комбайнга күчте. Бу авылда кеше җитми икән. Бригадир: «Энем, кеше табылганчы, бер-ике көн эшлә инде. Комбайн тик тора бит»,— дип үтенеп сорагач, Габделхак үзенең сау-сәламәт килеш уттай кызу эш өстендә күләгәдә плакат язып ятуыннан оялып ук куйды. Бригадир Габделхакны кырга мотоциклы белән алып китте. Алар килеп житкәндә, комбайн борчак жире өстендә туктап тора иде. Барабаны тыгылган. Бернәрсә турында сөйләшмәделәр, килү белән тимер чыбык кебек тыгызланып уралган борчак саламын ломнар белән каерырга тотындылар. Ярты сәгатьләр этләнгәннән соң гына барабан бераз бушангандай булды. Чиләнгән кайнар саламны ялан кул белән сүтеп алдылар.

Габделхак төшкә кадәр комбайн алдыннан йөгереп йөрде. Барабанны тыгылдырырлык калын полосаларны кыска таяк белән комбайнның авызына аз-азлап өзгәләп сала барды. Ә ул, каһәр, комсыз. Уралып-уралып яткан борчакны бишәр метрдан суырып ала да бугазы төелеп «го-о-онк» дип көчәнә. Андый чакларда өлкән комбайнчының да, Габделхакның да тыннары кысылып кала.— Тыгыла күрмәсен. Чияләнеп ятканчы, болай йөрүең хәерлерәк. Төшке аш килгәнче туктамый эшләделәр. Ашны, ат җигеп, интеллигент кыяфәтле пөхтә киенгән бабай алып килде. Аның арбасына бер кыз да утырган иде, ләкин ул якын килмәде, жир башында төшеп, китеп калды. Арба янына уникеләп комбайнчы жыелды. Аларның йөзләре дә, киемнәре дә бер үк төсле соры, тузанлы иде. Араларында чит кеше булгангамы, тавыш-тынсыз гына ашый башладылар. Габделхак ачыккан иде. Зур-зур ике-өч телем ипи белән итле ашны йотлыгып ашады. Тагын сорап алды. Шуны гына көтеп торгандай, комбайнчылар берьюлы телгә килеп сөйләшә башладылар. Аш бүлүче бабай да бер чиләк ашны ашап бетерә ала торган кордашын искә төшереп, мәзәк сөйләп алды. Габделхакка:

— Аша, улым, аша. Ашаган малда өмет бар,— диде.

Җил исеп куйгандай, Габделхакның күңеле күтәрелеп китте. Димәк, аны үз итеп кабул иттеләр.

Яңадан комбайн янына барганда, Габделхак өлкән комбайнчы Әюптән:

— Нинди кыз ул? — дип сорады.

— Кая?

Габделхак жир башында басып торучы кызга күз карашы белән ымлап күрсәтте.

— Ә-ә. Исәрләнгән ул. Укытучы Мансур абзый кызы,— диде Әюп. Тәмәке кабызып, авызыннан, борыныннан төтен чыгарганнан соң, тәфсилләбрәк сөйләп бирде:

— Унынчы класска кадәр гел бишлегә укып килде. Беркөн шулай контроль мәсьәлә чишеп утырган жиреннән тиктомалга: «Чишелеш нульгә бетә»,— дигән дә аңгыраеп класстан чыгып киткән. Шуннан бирле укымый. Башына авырлык килгән, диләр.

Габделхакның уйларын үзеннән бер читтә жыелып утырып тыныч кына гәп коручы малайларның тавышлары бүлде. Малайлар авыл хәл-

ләрен тикшерәләр иде. Председательләре гел район үзәгендә ята икән. Аның үз өе дә шунда икән. Авылга килеп-китеп кенә йөри икән.

— Кичә кайтып килүен күрсәң,— диде малайларның берсе.— Машинасын Гариф абыйлар тыкрыгыннан ук кычкыртып килә. Капканы ача торсыннар, янәсе.

— Минем абый читкә шул имансыз аркасында чыгып китте инде.

— Соң, безнең җизниләр соң!

Бу авылның кешеләре председательләрен яратмыйлар иде. Габделхак монда килгәннән бирле шуны ишетә. Ул киерелеп чалкан әйләнеп ятты.

— Нигә алыштырмыйсыз соң сез аны? — диде, торып ук утырды.

— Алыштырырсың! Районда аның әллә кемнәре бар.

Кояш чыккан иде инде, аргы як калкулыкның түбәсеннән туп-туры күзгә карап тора. Бер комбайн нәкъ шул турыга якынлашып килә: кояш алдыннан узганда, эчке әгъзалары челтәр сыман булып күренде. Габделхакның кулы кычытып куйды. «Ясыйсы иде шушы күренешне»,— дип уйлады ул. Ә нигә?! Габделхак җиңел генә урыныннан сикереп торды.

— Малайлар, хәзер рәсем ясыйбыз,— диде ул. Аның янында буявы да, пумалачыклары да, кәгазе дә юк иде. Әмма кинәт кабынган теләк миен шашындырып эшләтте. Комбайнда әрҗә өстен каплаган катыргы кәгазь бар! Пумалачык? Габделхак малайларның чәчләренә күз йөртеп чыкты.

— Кил әле, Сәлим. Юк, синеке артык йомшак. Синеке ат кылы сыман. Менә синеке бара. Кемдә пәке бар?

Малайларда пәке булмыймы соң? Барысы берьюлы кесәләренә тыгылдылар. Габделхак үткенрәген сайлап алып Рашатның чәчен кисә башлады. Йолкына иде, авыртадыр, тик Рашат шыңшымады, башын иеп тик торды.

— Сәлим, син чиләк белән су алып мен. Җәгъфәр, комбайн өстеннән катыргы кәгазьне алып төш. Ә сез яр буеннан кызыл балчык алып килегез. Төптәнрәк алыгыз, үзле булсын.

Малайлар кушылган эшләрне үтәргә торып йөгерештеләр.

Ашыгырга кирәк иде. Кояш югары күтәрелгәнче өлгерергә кирәк иде. Габделхак Рашатның башыннан кисеп алынган чәчне җеп белән кечкенә көлтә сыман итеп бәйләде, аннары агачтан сап юнып шуна беркетте. Очы очлаеп торган, менә дигән пумалачык килеп чыкты. Катыргы кәгазьне малайлар аның каршысына авышрак итеп беркетеп куйдылар. Буяу кирәк. Һич югы, кара тушь булсын иде. Ә нигә?! Лай! Су кушып җаның теләгән куелыкта төшереп булачак. Габделхак кызыл балчыкны учында нык кына әвәләгәннән соң, аңардан чәй тәлинкәсе сыман ике савыт ясады. Берсе белән яр буеннан дегет кебек кара лай алып менде. Икенчесенә кирәк кадәр лай, кирәк кадәр су сала-сала эшли башлады. Башта ул күк буласы урынны сыек кына итеп юып төшерде. Тигез төшә, канәгать иде ул. Кояш әле түбән, тауның бер ягында әле күләгә ята. Иң кырый йорт акшарланган стеналы иде, аңа ялт итеп кояш төшкән, өй артында күләгә, шулай ук тал агачларыннан да озын-озын күләгәләр сузылган. Капка турыннан буага таба борыласарыла ялгыз сукмак төшә. Күләгә һәм кояш, күләгә һәм кояш. Бу капма-каршылыкны бирү гаять җиңел иде. Этюдка баштан ук җан керде. Иртәнге һаваның үтә күренмәлелеге сиземләнә башлады. Каракучкыл таллар һәм күләгә төшкән тау фонында очып баручы казлар һава тирәнлеген бигрәк тә тирәнәйттеләр. Малайлар инде сөенешеп кулларын кесәләрендә уалар, чырык-чырык көлешәләр иде.

Габделхак үзе дә бәләкәй чагында әнисенең чигү чиккәнен карап утырырга ярата иде. Бервакыт әнисе аллы-гөлле әтәч рәсеме чикте. Күзен куйганда, әнисе юри күрсәтебрәк тиз-тиз типчеп алды. Кинәт

этәчкә җан керде, ишек алдындагы этәч кебек Габделхакка тәкәббер караш ташлады. Габделхак башта өнсез калды, аннары көлә башлады, күзләреннән яшь килгәнче көлде ул. Әнисе куркынган да, сөенгән дә бер халәттә улын кочагына алып, тынычландырырга тырышты. Әтәчне алар икәүләшеп сәгать астына кагып куйдылар. Шул чак әбиләре кайтып керде. Коты чыгып:

— Һай, килен! Ни эшең бу?! Өйгә сурәт элгәнсең бит! Сурәт ясау гөнаһ. Үлгәч җаныңны сорап килер. Ай алла! Ай алла! — дия-дия, әтәчне умырып алып, идәнгә салып таптады. Ләкин ул Габделхакның күңеленә җуелмас эз салып, изге бер теләкне уятып өлгергән иде инде.

Этюд тәмамланып килә. Габделхак соңгы эш итеп алгы планда көзгедәй тынып яткан буаны ясады. Малайлар гаҗәпкә калдылар. Баксаң, буа төбендә яр буендагы талларның һәм тауның шәүләсе ята икән. Этюд кояшлы, якты булып чыкты.

— Лайдан кояш булды бит, ә?!

Габделхак борылып карады. Моны әйтүче зур, уйчан күзле Камил исемле малай иде. Малайлар этюдны кемгә бирү турында бәхәсләшә башладылар.

— Сиңа ди! Ул безнең өйне ясады. Миңа бирә ул аны.

— Аңа калса, безнең бакча башы да элэкте шул.

— Габделхак абый, Рашатка бир. Пумаланы аның чәченнән ясадык бит.

Бер сулыш белән ясалган һәм җанының бер кисәге булган этюдтан Габделхакның үзенең дә аерыласы килми иде. Ләкин болайга киткәч, саранлана алмады. Камилгә бирде ул аны. Камил башта ышанмыйчарак торды, аннары көнләшеп карап торучы иптәшләренә гаепле сыман карый-карый ике куллап күтәреп алды.

— Озак саклансын өчен ни эшләргә кирәклеген беләсеңме? — дип сорады Габделхак.

— Беләм, абый. Щетиналы щетканы аертылган сөткә манчып, тимер сеткага ышкый-ышкый, рәсем өстенә вак янгыр яудырырга кирәк. Кипкәч ул пыгып кала.

— Дөрес, Камил.

Габделхак Камилнең дә рәсем белән кызыксынуын аңлады: бу малайны да газаплы эзләнүләр, уңышсызлыкка очрап үз-үзен куралмас дәрәҗәгә төшеп өметсезлеккә бирелүләр, кыска вакытлы шатлыклар белән тулы авыр да, кызыклы да тормыш көтүен күз алдына китерде. «Күңелендә шундый теләк уянган икән, ул инде башкача яши алмаячак»,— дип уйлады.

Ат белән өлкән комбайнчы килеп туктады.

— Әй! Картуны кая алып киттегез! — дип кычкырды ул кайтырга чыккан малайларга. Малайлар сагаешып Камил тирәсенә җыелдылар.

— Габделхак абый аңа рәсем ясады бит,— диде берсе.

Әюп алар янына барып картинага бераз карап торганнан соң:

— Әрҗәне капларга башка әйбер алып кил! — диде.

— Ярар.

— Рашат, китми тор. Атны кайтарып куярсың.

Габделхак белән Әюп солидоллы кәгазьгә төрелгән тешле тәгәрмәчләрне шкиф каешларыннан бушатканнан соң, малайлар арбага төялеп кайтып киттеләр.

Ремонтлап бетереп бодай кырына төшкәндә, башка комбайннар, гигант үткләр сыман, саргылт-яшел буй бизәкле калкулык итәкләрен тигезләп йөриләр иде инде. Бодай тезмәләре борчак покослары кебек калын түгел, барабанны тыгылдырмый. Әюп штурвалны Габделхакка бирде дә: «Бераз тамак ялгап алам»,— дип төшеп калды.

Үзе эшләп карамаган кеше, комбайнчы штурвалны боргалап кына бара, дип уйлый. Кайбер шагыйрьләр хәтта: «Җырлый-җырлый ашлык

суга кыр корабында Миннулла»,— дип тә жибәрәләр. Жырларсың! Бункердан, жилгәргечтән бөркелгән тузан авызыңны түгел, күзеңне ачарга да ирек бирми, киемгә сеңеп, тәнгә үк үтеп керә, колак эчләренә тула, теш араларында шытырдый. Жыелган саламны вакытында төшереп калдырырга кирәк, карабрак бармасаң, таш я агач төбе килеп керәсен көт тә тор.

Шулай да жил каршыдан искәндә, күз аллары ачылып китә. Иркенләп сулап куясың. Тезмәләр үзләре үк чаңгы юлларыдай алга ымсындырып, чакырып торалар. Чыннан да кораб сыман зур машинаның күндәм буйсынуын тоясың да, күңелдә шигърият сыман нәрсә дә кузгалып куя. Габделхак бер тын онытылып эшләде. Аннары аны Әюп алыштырды. Комбайннан төшүгә дөнья кинәт тып-тын булып калды. Габделхак, үзендә кешене хужаларча олыгайта торган арганлык тойган хәлдә, якындагы бер чүмәлә өстенә барып ауды. Ефәк сыман шома, сыгылмалы алтын салам аны жай гына үз кочагына алды. Бәйсез кыр жиле хәзер Габделхакка тия алмый, чүмәлә кырыеннан шаулап үтә, кайчагында чүмәләнең артыннан кисәк кенә этеп жибәрә, алай да эш чыгара алмагач, салам очларында озын, нәзек итеп сызгыра башлый. Сары камыл өстендә ялгыз зәңгәр чәчәк чайкала. Габделхакның нигәдер ятим бала кебек үксеп-үксеп елыйсы килеп китте. Ата-бабаларын туендырган шушы борынгы жиргә ятып, эченә жыелган бөтен моң-зарларын сөйли-сөйли елыйсы килде аның. Ә ялгыз зәнгәр чәчәк сары камыл өстендә һаман чайкала да чайкала. Алла да юк, тәмуг та юк, ожмах та юк. Күп гасырлар буе әллә кемнәрнең аягы астында тапталган жир бар, зәңгәр күк бар, Габделхак үзе бар.

Ул бераз черем итеп алды. Бу ярым онытылу күпме дәвам иткәндер, Габделхак гажәеп яхшы ял итеп, башы жиңеләеп уянды. Күк бермәбер биегәйгән, ерактагы күгелжем урман якынайган сыман тоела аңа. Әюп комбайнны туктатып кепкасын болгап тора иде. Төшке аш килгән икән. Габделхак ерактан ук арба янында әлеге исәрләнгән кызны күрде. Бүген ул комбайнчылар янына якын ук килгән иде. Покос өстендә утырып, ул бабасының эшен бетергәнен көтеп тора. Габделхак коштабагына аш бүлеп алып, аның янына барып утырды.

— Ашыйсың киләме? Әйдә, бергә ашыйбыз,— диде.

Кыз дәшмәде. Аннары гел уйламаган жирдән:

— Син молекулалардан торасың,— дип куйды.

Габделхакның йөзендә бер мускул да селкенмәде, ә тузгыган, бодай кибәкләре кунган чәчләре астындагы башында уйлар өермәсе иде.

«Син молекулалардан торасың...»

«Чишелеш нульгә бетә...»

Бу кызның уйлар агымы кая алып бара? Чыннан да исәрләнгәнме ул? Әллә бары тик заманыбызның каршылыклы уй-хисләрен чишә алмыйча иза чигәме? Габделхак сынап карарга булды. Зур гына ит калжасын чәйнәп йотып жибәргәннән соң, ул исе китмәгән кыяфәттә: «Торса ни»,— диде, кызга күтәрелеп карады һәм өнсез калды. Аның алдында көн кебек якты йөзле, төндәй кара озын чәчле, бүген тотып кияүгә бирерлек буй житкән кыз утыра иде. Кай төше беләндер Раушаниягә охшаган. Габделхакны жылы дулкыннар күмеп киткәндәй булды. Йөрәге күптәннән булмаганча сулкылдап тибә башлады. Димәк, аның йөрәге исән икән әле. Ә ничә еллар ул болай гына, тереклек итәр өчен генә типте.

Кызның күзләрендә гажәпләнү иде. Күрәсең, ул: «Син молекулалардан торасың»,— дип, Габделхакны шаккатырмакчы булгандыр. Күрәсең, бу аның үзе өчен бик мөһимдер. Ә Габделхакның моңа бер дә исе китмәгәч, үзе гажәпкә калгандыр.

— Син бит тузан бөртеге генә. Син түгел, жир шары да галәм

кинлекләре белән чагыштырганда тузан бөртеге,— диде кыз ашыга-ашыга.

— Шулай шул,— диде Габделхак, аның белән килешеп.— Галәм бик киң бит ул. Чиксез киң. Ә син чиксезлекнең нәрсә икәнен беләсеңме? Минә күз алдыңа китер. Би-и-и-ик ерак, ди, әйеме. Аннан соң да барып була әле. Тагы да, тагы да, тагы да барып була. Чиксез.

Башка кешеләр Хәятны кызганалар иде, аның сүзләреннән көлмәскә тырышып читкә борылалар иде. Ә бу тузанга батып беткән егет аның белән... Әйе, кайчандыр әти-әнисе дә, башка кешеләр дә Хәят белән менә шушылай тиң күреп сөйләшәләр иде. Аннары ни булды соң?! Кешеләр Хәятны аңламый башладылар. Бервакыт әнисе күрше хатынга елый-елый: «Хараплар булды инде балакаем»,— диде. Нишләп харап булсын ул?! Аның бер җире дә авыртмый ич. Тик менә күңелсез. Бөтен нәрсә аның өчен гап-гади. Җир балчыктан, минераль матдәләр катнашмасыннан тора. Ай да шулай ук каты күк җисеме. Бөтен нәрсә аяк астындагы кебек гап-гади. Хәятны гаҗәпләндерә алырлык бер нәрсә юк. Һәм шуңа күрә бик күңелсез аңа.

— Ә сиңа беркайчан да тормыш мәгънәсез нәрсә булып тоелганы юкмыни? — дип сорады Хәят.— Менә миңа унсигез. Тагы кырык, илле елдан әби булачакмын, үләчәкмен. Элегрәк кешеләр үлгәннән соң оҗмахта, һич югы, тәмугта гына булса да яшәргә өмет иткәннәр. Ә мин өмет итмим. Чөнки моның кем тарафыннандыр уйлап чыгарылган матур әкият булуын ап-ачык аңлыйм. Котылгысыз үләсеңне белә торып ничек яшәргә кирәк?!

— Ошамаса асылынасың,— диде Габделхак,— ә менә миңа ошый. Чөнки минем бөтенләй тумавым да мөмкин иде. Миңа дөньяда яшәргә насыйп булган икән, бик рәхмәт. Гарип булып тусам да, рәхмәт әйтер идем. Бөтенләй булмаганга карый анысы да әллә ни.

Габделхак көтмәгәндә:

— Ә нигә син бер җирдә дә эшләмисең? — дип сорады.— Колхозыгызда кеше җитми, ә син тик йөрисең,— диде.

Хәят аңа каш астыннан усал итеп карап куйды.

— Миңа шулай ошый. Синен катышың юк.

— Кул-аягы исән кешегә болай йөрү килешми дип әйтүем генә.

— Син дә безнең әни сымак икән,— диде Хәят, ирен чите белән мәсхәрәле елмаеп.— Болай килешми, тегеләй килешми, кызым, алай утырма, син инде олы кыз... Син эшлисең, болар эшлиләр. Шуннан нәрсә? Сез урган бу икмәкне кемнәр ашый дип беләсең?! Атом бомбасы ясаучы кешеләр ашый, кеше үтерергә өйрәтелүче меңләгән әрәмтамаклар ашый. Сез барыгыз да атом бомбасы ясаучылар. Зинһар, син дә Хәят акылдан язган икән дип уйлама. Мин аңлыйм. Атом бомбаларын ясарга кирәк, солдатларны да асрарга кирәк, чөнки башка илләрдә дә шулай эшлиләр. Аларның безгә һөҗүм итүләре бар. Ләкин барыбер сез бөтенегез бергә җир шарына үлем хәзерлисез. Сезнең бөтен эшегез шуңа кайтып кала. Сез миңа киләчәккә ышанып яшәргә ирек бирмисез.

Күрәсең, Хәят кеше акылы ирешә алырдай нәрсәләрнең бөтенесен аңладым дип уйлыйдыр. Габделхак аның шушы беркатлы үҗәтлеген какшатырга, торгынлыкка кереп туктаган уйларына юл ачарга теләде.

— Хәят, син әйтәсең, бөтен нәрсә аяк астындагы таш кебек гади, мине гаҗәпләндерә алырлык бер нәрсә дә юк дисең. Алайса, әйтеп кара: «Менә бу кап-кара җирдән ничек итеп ап-ак чәчәкләр, зәңгәр, кызыл, сары чәчәкләр үсеп чыга ала? Менә бу бөҗәк нигә тере? Без бер-беребезне ничек күрә алабыз? Бу могҗиза түгелме? Аяк астындагы таш кебек гади дисең. Бу таш гади түгел. Моның эчендә, беләсеңме, нинди серләр бар?»

— Я, әйтеп кара. Нинди серләр бар ул таш эчендә? — диде Хәят, елмаеп.

Габделхак кыз көнелендә кызыксыну уяна башлавын сизде. Хәзер аның эчке дөньясы белән бу бәйләнешне өзмәскә, ул белмәгән берәр ачыш ясап, дөньяны танып белүнең чиксезлеген күрсәтергә кирәк.

Хәят, аны үртәп:

— Я, я! Әйт инде,— дип ашыктырды. Күрәсең, ул таш эчендә бернинди дә сер булмавына нык ышана иде. Габделхак ташны ике бармагы белән генә тотып күзләре турысына күтәрде. Диккатьле, җитди кыяфәте, аякларын бөкләп утыруы белән ул тылсымчыны хәтерләтә иде.

— Бу таш...— диде Габделхак һәм аптырабрак калды. Моны күреп Хәят көлеп үк җибәрде. Хәятның бабасы комбайнчыларга чәй бүлеп тора иде.

— Габделхак улым, чәй эчмисеңмени? — диде. Башка комбайнчылар да елмаешып Габделхакка карап торалар иде. Хәятка берәр уен өйрәтә дип уйлыйлардыр, күрәсең.

— Бабай, бүлеп куй, суына торсын,— дип кычкырды Габделхак. Ә Хәятка:

— Ерма авызыңны, игътибар белән тыңла,— диде.— Күз алдына китер. Бу ташны мин кисәккә бүлдек, ди. Бүлеп буламы?

Хәят «була» дип башын селкеп куйды.

— Әлбәттә, була. Булган әйберне бүлмәскә. Хәзер шул миңгә бүленгәннең бер кисәген алабыз. Бик кечкенә калды, күзебезгә дә күренми. Чөнки безнең күзләр артык зур. Тагын миңгә бүләбез. Кечерәйгәннән-кечерәя, кечерәйгәннән-кечерәя, ләкин ул һаман да бар һәм без аны, гомеребез буе бүлсәк тә, бүлеп бетерә алмаячакбыз. Чиксез бүленә. Ышандыңмы?

— Ә мәктәптә безгә: «Материянең иң кечкенә кисәкчекләре бар, бөтен әйберләр дә шул иң кечкенә кисәкчекләрдән төзелә», дип өйрәттеләр,— диде Хәят.

— Ләкин ул иң кечкенә кисәкчекләр дә материядән, тагы да кечерәк кисәкчекләрдән төзелмәгәнмени?

— Чыннан да!! Алайса, химия, физика дәреслекләрендә дөрес язылмаган?!

— Күрәсең,— диде Габделхак.— Мин сиңа моны катлаулырак юл белән дә аңлатыр идем. Тик син Энштейнның «Чагыштырмалар теориясе»н белмисеңдер.

— Нишләп белмим, ди. Мин аны үзлегемнән өйрәнгән идем. Ярыйсы гына катлаулы ул, ә төп фикере болай: без, әнә ул салам эскерте тик тора, ә бу кош хәрәкәт итә, оча, дип уйлыйбыз. Асылда салам эскерте дә Җир шары белән бергә Кояш тирәсендә әйләнә. Кояш та тик тормый, үзе тирәсендәге планеталарны ияртеп, галактика үзәге тирәсендә әйләнә. Галактикалар да хәрәкәт итәләр. Галәмдә тик тора дип уйларлык бер нокта да юк. Әйберләрнең хәрәкәт тизлеген без чагыштырмача гына беләбез.

— Дөрес, Хәят. Нәкъ шулай. Хәзер тыңла. Материянең чиксез бүленә икәнлеген шушы теориягә нигезләп аңлатам. Җисемнәрнең хәрәкәт тизлеген үлчәгәндә чагыштырып карарлык, тик тора торган бер нокта да юк. Аларның хәрәкәт тизлеген без чагыштырмача гына беләбез. Җисемнәрнең күләмнәре, зурлыклары белән дә шундый ук хәл. Әнә ул салам эскерте аның өстендә кунган каргадан зур. Салам эскертенә карый Җир шары зуррак. Шулай ук анардан зуррак җисемнәр дә бар һәм бу чиксез. Бусы иң зур, бусы иң кечкенә дип уйларлык бернәрсә юк. Галәм чиксез зур гына түгел, чиксез кечкенә дә. Яшәү серләре әнә шунда, чиксезлеккә яшеренгән дә. Бу таш эчендә безнең Кояш системасындагы кебек планеталар, галактикалар бар...

Хәят ташны Габделхакның кулыннан тартып алды да китәргә җыенып йөрүче бабасы янына йөгерде. Шуннан соң ул икенче көнне дә, башка көннәрдә дә кырга килмәде.

* *
*

Мансур агай кызы Хәятның күлмәген үтүкләргә җыенып йөрүенә куанып куйды, хатынын ак өйгә чакырып алып:

— Иртәгә беренче сентябрь, кара аны, Хәятка уку турында сүз ычкындырасы булма! — дип кисәтте.

— Кая ул, әйтәмме соң? — диде Гайшә апа.— Бу арада балакаем, күз тимәсен, аруланып тора сыман. Бәгыремне телеп, күзен бер ноктага тери дәката иде. Хәзер, аллага шөкер, әйткәнне аңлый кебек, кул арасына керә башлады. Шулай итик, Мансур, үзенең укыйсы килмәсә укымасын. Качмас. Әллә кая өзлегеп куюы бар. Инде аңына килеп терелеп китсә генә ярар иде.

Томырылып Рәшат кайтып керде. Ул керә-керешкә:

— Апа, минем күлмәкне дә үтүклә,— дип кычкырды. Апасы андыймондый сүз әйткәләгәнче, күлмәген, элеп куйган җиреннән алып, китереп тә бирде.

Хәят энесенә караган иде, көлеп җибәрде.

— Әни, кара әле, Рәшатның чәчен кискәннәр,— диде ул.

Гайшә апа алгы өйдән куркынып кына чыкты. Өйдәге көтелмәгән шау-шу, теләсә нинди яңалык аның котын ала иде. «Аһ» итеп:

— Кем кисте болай чәчеңне?! — диде.

Рәшат учы белән ялт кына чәчен сыпырып алды да мактанып:

— Рәсем ясадык без,— диде.— Күрсәң матур чыкканын. Әни, ашарга бармы?

Гайшә апа аңламыйча:

— Саташасыңмы әллә? Чәч белән рәсем ясыйлармыни?! — диде.

Рәшат, энисенең шуны да аңламавына ачуы килеп:

— Ясамыйча,— диде.— Әюп бабай комбайнында эшли торган художник абый ясады. Авыл башындагы буа янын. Безнең тыкрык та әләкте әле.

Гайшә апа һаман төшенеп җитә алмыйча:

— Шушыларның бер!.. Җүнләп сөйләсәң телең калырмыни? Барыгыз да шул...— дип тиргәнә башлаган иде дә, кызына авыр бәрелерлек сүз ычкындыра язуын абайлап телен тешләде. Ә Хәят энисенең сүзләрен ишетмәде дә бугай. Энесенә якынрак килеп, Габделхакның кулы тигән урынга текәлебрәк карады да көлеп җибәрде, энесенең чәчен тузгытып куйды.

Эчкәре өйдән бу якка чыккан этиләре эшнең нәрсәдә икәнен белгәч, көр тавышы белән өй эчен тутырып:

— Юкка борчылма, анасы. Без аны хәзер тигезләп алабыз. Бар, улым, машинка алып мен,— диде.

Рәшат ак өйдән машинка алып чыгып, этисе идән уртасына куйган урындыкка менеп утырды. Малайның кечкенә башы этисенең зур куллары арасында югалып калгандай булды. Мансур агай, бармакларының акрын кыймылдавын тоеп: «Картаю микәнни? — дип уйлады.— Бардыр, пенсиягә чыгарга ике генә ел калды бит», дип уйлады. Аннан да бигрәк кызы Хәят картайтты аны. Шушы алты ай эчендә чәчләре бөтенләй агарды.

Мансур агай, Рәшатның чәчен алып бетергәч, болдырга чыгып тәмәке кабызды. Кызының нидән болай булып китүен Мансур агай, төгәл үк белмәсә дә, аңыша иде. Хәят очар кош кебек еракка карап, күп нәрсә белән кызыксынып яши иде. Очар урынын тарсынды микәнни? Нидән генә каерылды икән аның канатлары? «Хәзерге яшьләргә дә авыр шул. Өсләре бөтен, тамаклары тук булу белән генә түгел бит».

Ишек ачылды. Кызы Хәят икән. Клубка чыгып барышы, күрәсең, зәңгәр күлмәген кигән. Этисеннән кыенсынып мы, кыюсыз атлап капкага

таба китте, жинелчә сөрлегеп тә алды. Гайшә апа ишектән башын тыгып:

— Кызым, ялгыз йөрмә. Санияләргә кер башта,— дип калды. Тагын нидер әйтергә дип авызын ачкан иде дә, иренең ачуланып борылуын күргәч, әйтмәде, кереп китте.

«Әнисенең шулай адым саен бәйләнеп торуы да борчый аны,— дип уйлады Мансур агай.— Гайшә дә инде өйдә ята-ята чәвчәләккә әйләнеп бетте».

* * *

Хәятның адымнары клубка якынлашкан саен акрыная барды. Анда күптәннән булмаганга, хәзер ятсына иде ул. Ләкин урам уртасында туктап кала да, тиктомалдан борылып китә дә алмады. Капка төпләрендә утыручы кешеләрнең әллә ни уйлаулары бар. Хәят, арттан китереп сугуларын көткәндәй, иелә төшебрәк бара бирде. Башы әйләнгән сыман булып китте. Үзе белән менә-менә нидер буласын сизенде ул.

Кечкенә чагында озак китап укыса, аның күзе алышына, әйберләр үзләреннән-үзләре ерагая, зурая башлыйлар иде. Өстәлнең ялан кадәр киңәеп китүен, мич кырыена эленгән чаршауларның йөзәр метрга ераклашып киң панорамага әйләнүен күзәтүе аңа кызык тоела иде. Ләкин бераздан шөбһәләнә башлый, болай булмаска тиешлеген, озакка сузылса үзенең нидер югалтасын, моның табигый хәл булмавын аңлый. Ләкин әйберләр үз урыннарына кайтырга теләмиләр. Бу аны тагын да куркытарак төшә: «Яңадан озак укымас идем»,— дип чарасызлана. Урыннан торып йөренә башлый. Идән киң, күпме барса да очына чыга алмас кебек. Ә өч-дүрт адым атлауга стенага барып төртелә. Мондый чакта, ачык һавага чыгарга, күккә карарга кирәклеген исенә төшереп, ишек алдына чыгып китә. Йолдызлар беркайчан да үзгәрмиләр. Аларга карасаң, күзеңдәге киеренкелек бетә. Күз карасын өй кыегына күчерсә, өй кыегы яңадан дөньяны каплап зурая башлый. Хәят әле күккә, әле өй кыегына карый. Ниһаять, әйберләр үз урыннарына кайталар. Хәят, икенче бер дөньядан килеп төшкәндәй, бер тын хәйран калып тора.

Хәзер дә Хәят шундыйрак бер халәт кичерде. Тик күзе түгел, ә эчке дөньясы үз хәленә кайтты аның.

Клуб эченә килеп керүгә, яшьләр барысы да аңа борылып карадылар. Хәят үзен ничек тотарга икәнен белә инде. Аның өстендә турыга тегелгән, кыска итәкле, килешле зәңгәр күлмәк. Кысып бумаса да, биленең нечкәлеге күзгә ташланып тора. Поясы җиз бөжрәләрдән тезеп ясалган. Аны Казан университетында укучы Ирек абыйсы бүләк иткән иде. Дус кызы Сания йөгереп килеп аны кочаклап алды. Вальс уйный башлады — шул уңайдан биеп тә киттеләр. Икенче вальс вакытында аның янына Җәвад килде. Ул Хәяткә күз атып йөри иде. Биергә чакырды. Хәят: «Ардым»,— диде. Арыймы соң? Җәвадка ачу итеп кенә шулай диде ул. Хәзер генә кирәк булган икән?!

Хәят урамга чыкты. Искиткеч җылы, айлы, серле төн иде. Хәят дөньяда Габделхак исемле егетнең барлыгын исенә төшерде. Дөресрәге, ул һәрвакыт аның исендә, хәзер бары тик менә үзе янында шул егетнең булуын бик теләде ул. Үзалдына уйланып бара торгач, Хәят авыл башына чыкты. Кыр түрендә тоныкк кына комбайн тавышлары ишетелә. Габделхак шундадыр. Ул тиз генә кайтмас, кайтса да клубка чыкмас, алар бит төнге берләргә кадәр эшлиләр.

— Габделхак, киләчәктә тормыш ничек булыр икән?

— Шуны да белмисеңме? Җир шарында бернинди дәүләт чикләре калмас, безнең планета кешеләре бер гаилә булып яши башларлар. Ул чагында гаскәр дә, сугыш кораллары да кирәк булмаячак. Һәр кеше ике

телдә сөйләшә белер. Үзенең туган телендә һәм барлык кешеләр өчен уртак интернациональ телдә.

— Интернациональ тел рус теле буламы, әллә инглиз, я башкамы?

— Юк, алар берсе дә түгел. Хәзергә үле тел дип исәпләнүче грек-латин теле булачак. Бөек Гомер теле. «Илиада» белән «Одиссея»ны укыганың бармы?

— Әйе, укыган идем. Ә шуннан соң кешеләр нинди максат белән яши башларлар?

— Бервакыт урманда мин гаҗәеп бер хәлгә тап булдым. Август башлары иде. Этюд ясарга кызыклырак урын эзләп йөргәндә, бер кырмыска оясына күзем төште. Ояны ниндидер канатлы бөҗәкләр сырып алган иде. Югыйсә, кырмыскалар усал халык, моңа ничек түзеп торалар икән дип якынрак килдем. Дикъкатьләбрәк карасам, канатлы бөҗәк дип уйлаганым шул ук кырмыскалар булып чыкты. Аларның барысы да канатлы булмыйча, оя өстендә йөгереп йөри торган гади кырмыскалар да күп иде. Алары җир асты юлларыннан чыгучы канатлы кырмыскаларны сыпыргалыйлар, канатларын җайлыйлар. Аннары, команда бирелгәндәй, барысы берьюлы аз гына читкә тайпылалар. Канатлылары шунда ук һавага күтәреләләр иде. Соңыннан кырмыскалар тормышы турында язылган бер китапны укыгач, очып киткән кырмыскаларның яңа урынга төшү белән, канатларын кимереп ташлап, оя кора башлаулары турында белдем.

Җир кешеләре дә билгеле бер үсеш баскычында үз вәкилләрен башка планеталарга очырырлар. Чөнки безнең планета мәңгелек түгел, вакыты җитеп бер җимереләчәк. Ләкин моның өчен җир шары кешеләренең бер гаилә булып яшәүләре кирәк. Аерым илләрнең генә мондый зур эшне башкарырга көчләре җитмәячәк...

Хәят авыл башындагы сөзәк калкулык өстенә килеп чыкты. Төнге кыр түрендә прожекторларын кабызган комбайннар әрле-бирле килеп йөриләр. Ә күктә тулган ай. Ана инде кеше аяк басты. Хәят аны яктылык сирпүче түгәрәк итеп кенә түгел, галәмдә үз урыны, орбитасы булган күләмле җисем итеп күрде. Ул үзе дә гади авыл кызы гына түгел ич. Планетабызның бер вәкиле — Җир кызы ич ул.

Якындагы салам эскерте кырыенда ниндидер кара нәрсә селкенеп куйды. Кыштырдаган тавыш та ишетелде. Җир шары вәкиленең җаны табанына төште. Ул, борылып карый-карый, авылга таба йөгерде. Капкалары турына җитәрәк сулышы тигезләнгәнне көтеп, бер тын тик торды. Әнисе йокламаган идеме, әллә ут кабызганга уяндымы, ак өйдән:

— Кайттыңмы, кызым? Тамагың ачса, ашап ал, мич алдында,— диде.

Хәят яңакларының кызышуына түзә алмыйча учлары белән кысты. Көзгегә караган иде, анда йөзеннән, күзләреннән нур сирпеп торучы искиткеч гүзәл бер кызны күрде; ышанмыйча борталанып алды. Бармагы белән борын очына басып карады. Бу — ул, Хәят иде. Чишенеп ятар алдыннан, ул исенә төшереп, сумкасына үрелде. Аннан таш кисәге алып, Габделхак кебек, ике бармагы белән генә тоткан килеш, күзләре турына күтәрде. «Беләсеңме, бу таш эчендә нинди сер бар?»

* * *

Габделхак, тузанлы салкын киемнәрен мунча өйалдына салып калдырып, эчкә үтте. Җылы. Иң беренче шуны тойды ул. Куыксыз лампа яна. Габделхак ләүкәгә менеп утырып, пар өстәде. Ташы кайнар икән. Чыжлый. Әле генә аның колагы төбендә мотор тавышлары иде. Күз алдында прожекторларын кабызып кара төн эчендә таралып йөрүче комбайннар иде, салкын һәм тузан иде. Кинәт шундый тынлык, сөякләрне җебетә торган парлы җылы. Габделхак тирләп үк чыкты. Аның йөзен-

нэн, күкрәкләреннән лайлы кара тасмалар ага башлады. Беренче кат юынганда көрән, аннары зәңгәр су акты аның тәненнән. Ике-өч кат сабын күбегенә күмелә-күмелә юынганнан соң гына чиста су ага башлады. Бу авылның суы әйбәт, сабынны күбекләндерә, чәч соңыннан кабарып, елкылдап кала. «Шушындый берәр авылда яшәргә, ә? Начар булмас иде»,— дип уйлады Габделхак. Капшана-капшана, Нигъмәтулла абзый керде. Аның күзләре көндез дә начар күрә. Врачлар: «Күз алмасына элпә үскән, операция ясарга кирәк»,— дип әйтәләр икән. Нигъмәтулла абзый гомергә колхозда эшләгән. Кәтү көткән, бригадир булган. Габделхак кайчан кайтмасын, уяу була. «Эшләмәгәч, йокы да юк, ашау да үтми»,— дип зарлана.

— Янгыр җиле исеп тора, янгыр яумагае әле,— диде Нигъмәтулла абзый, капшанып тәрәзә буендагы тактага утырганнан соң.— Минә, чиста күлмәкләреңне шушында куям. Эссесе бармы соң, матурым?

Ул хатынына да, балаларына да, Габделхакка да, ишек алдындагы эткә дә гел шулай «матурым» дип кенә дәшә.

— Сабан кырын бетерә алмагансыздыр әле?

— Бетте. Кичке алтыда ук бетердек. Хәзер Артыш буена күчтек.

— Һәй! Коры тоткансыз! Кара син, ә!

— Бүген уникe комбайн эшләде бит. Күрше авылдан өч комбайн килде.

— Ә-ә-ә. Безнең шул инде. Гомергә хәерче кебек теләнү булды, алланың рәхмәте. Халык качып беткәч, эшләр кешесе юк, техникасы да бар, югыйсә. Кая, аркаңны ышкыйммы?

Габделхак мунчаласын сабынлап Нигъмәтулла абзыйның кулына тоттырды, борылып утырды.

— Сөбханалла, сөбханалла! Аркаң гына да бер гектар чамасы бар икән. Әйтәм җирле, бер дә талчыкмагансың. Хикмәте бар икән шул. Маладис, матурым, шулай кирәк. Таза-сау кешегә эшләү берни түгел ул. Минә безнең кебек гарип-горабага кыен, алланың рәхмәте. Чыгып китәр идем үзем дә кырына да.

— Ничево, Нигъмәтулла абзый, менә операция ясарлар, күзең ачылыр.

— Шулай булсын, матурым, шулай булсын. Кара әле, машина да йөртә беләсең икән, комбайнны да биш бармагы кебек белә, дип сөйлиләр, каян өйрәнеп бетердең син аларны?

— Минем әти комбайнчы бит,— диде Габделхак, кызган тәненә салкынча су коя-коя.— Җәйге каникул вакытларында гел бергә эшли идек.

— Ә-ә-ә. Шулайдыр шул.

Габделхак коенып сөртенде дә җиңеләеп калган, иркен сулыш ала башлаган тәненә ак күлмәк, чиста чалбар киде. Өйгә керделәр.

Нигъмәтулла абзый алгы өй житкереп маташа иде. Бөтенесе әзер, мич кенә чыгарасы калган иде.

— Мич чыгаручы бүген дә килмәде, алланың рәхмәте. Башка авылга китеп эчеп йөри икән, хәерсез,— дип зарланып алды Нигъмәтулла абзый.

Габделхак сусаган иде. Кайту белән катыклы әйрән ясап эчте. Ул арада Нигъмәтулла абзый өстәлгә итле шулпа китереп куйды. Мунчадан соң Габделхакның бик үк ашыйсы килми иде. Шуны сизеп, ахрысы, Нигъмәтулла абзый мич чыгаручыга дип алган ак башны китереп куйды. Өйдәге башка кешеләрне уятмас өчен пышылдап:

— Әйдә, матурым, үзең кара. Мунчадан соң әйбәт була ул,— диде.

— Нигъмәтулла абзый, үзең дә,— диде Габделхак, шулай ук пышылдап.

— Юк, миңа ярамый. Врачлар операциягә кадәр эчмәскә куштылар. Белми сөйләмиләрдер, аларны да тыңларга кирәк.

«Утлы» судан соң Габделхак тирли-тирли бәрәңгеле, итле шулпа ашады. Дөньясы түгәрәкләнгән, бөтен нәрсәдән канәгать бер халәттә иде ул.

Габделхак иртән бик соң, сәгать сигезләрдә уянды. Яңгыр ява иде. Ул янадан йоклап китте һәм уннар тирәсендә тәмам йокысы туеп күтәренке күңел белән уянды.

Яңгыр һаман ява, бүген туктар исәбе юк, күрәсең. «Кич клубка чыгарга булыр. Хәятны күрермен, бәлки»,— дип уйлады Габделхак. Ашап алганнан соң, ул лавсан чалбарын, күлмәген үтүкләп киеп куйды. Аннары болдырга чыгып, яңгыр шыбырдавын тыңлый-тыңлый, Нигъмәтулла абзый белән тәмәке тартып керде. Алай да вакыт күп әле. Маһруй апа фермага, малайлар мәктәпкә киткәннәр иде. Нигъмәтулла абзый да: «Тәннәр авыраеп тора»,— дип, аралык ягына кереп ятты. Габделхак бер үзе. Өй эче ярым караңгы. Тын. Сәгать тыкелди. Габделхак этюдларын караштыра башлады. Портретлар, табигать күренешләре. Шулар арасыннан Альбинаның сангина белән ясалган рәсеме килеп чыкты. Альбина...

Беркөнне шулай Габделхак, күрәсе килеп, Альбина яши торган тулай торакка китте. Төнге унберләр тирәсе булгандыр. Дежур торучы хатынның кәефсез чагы иде, күрәсең, кертмәде. Габделхакның: «Чакырып чыгарыгыз, алайса»,— диюенә, ул, бөтенләй ачуы килеп: «Юк ул, чыгып китте»,— диде. Габделхак сүзләшеп тормады, Альбина яши торган бүлмәнең кайдадыр бишенче катта булырга тиешлеген исенә төшереп, ишек алдына чыкты. Тулай торакның утлы күзләрендә кешеләр кайнаша. Альбиналар тәрәзәсендә дә ут яна һәм хәтта балкон ишеге дә ачык иде. Өйдә икән, таныш профиле тәрәзә өлгеләрендә шуып узды. Балконнар икенче катка кадәр тезелеп төшкәннәр. Габделхак күз карашы белән балконнар арасын үлчәде. Буй җитәр сыман. Ишек алды ярым караңгы, тәрәзәләрдән төшкән нур белән генә яктыртылган иде. Якын-тирәдә кеше-кара да күренми. Габделхак башта беренче каттагы тәрәзәнең тупсасына менеп басты, аннан икенче катның балкон читлегенә куллары белән асылынды. Турникта уйнагандай тартылып менеп тә китте. Дүртенче катның балконында аңа ике егет очрады. Папирос капкannar.

— Син кая?

— Ары.

— Шырпың юкмы?

Юк иде. Габделхак бишенче катка күтәрелде.

— Мөмкинме?

Бүлмәдәге кызларның берсе сызым сызып утыра, икенчесе йокларга әзерләнә, ә Альбина койкасында, ярым яткан килеш, китап укый иде. Барысы да авызларын ачып калдылар. Ниһаять, Альбина «Син кая?» дип әйтерлек хәлгә килде.

Габделхак кыенсынып маңгай чәченә кулын тигезде.

— Менә, үтеп бара идем, юл уңаеннан кереп чыгарга булдым,— диде. Альбина эчтән генә көлеп бер як җилкәсенә иелеп алды. Бу рәсемне Габделхак шул кичне ясаган иде. Күпме кыйналып та җанлы итә алмады. Рәсем, мода журналларындагы чибәр һәм бары тик чибәр генә кызларга охшап чыкты. Бу, бәлки, Альбинаның эчке дөньясын аңламаудандыр. Аның кем булуын, нинди омтылышлар белән яшәвен Габделхак әлегә белми.

Менә ике кашы белән туры борыны зур «Т» хәрефенә охшаган, төмсә йөзле Хисам Гыймадиевичның портреты. Кызыклы гына кеше. Бервакыт ул Габделхакка:

— Энем, Габделхак, мин веранда ясаткан идем. Шуны буяп бир әле,— диде.

Габделхак, бу кешенең өендә күңел кайтаргыч күренешләргә тап буласын алдан ук сизенеп, барасы килмичә:

— Аны үзең дә буйый аласың инде,— диде.

— Алай түгел ул, энем Габделхак. Аның краскасын әллә куе итәргә, әллә сыек итәргә? Аннары рам араларын буярга зур осталык кирәк бит ул. Тыңла инде, энем Габделхак, буш итмәм,— диде.

Үзеннән өлкән кеше шулай үтенеп сорагач, Габделхак бармыйча булдыра алмады.

Хисам Гыймадиевич шәһәр читендә алты почмаклы зур агач йортта тора икән. Каралты тирәләре ыхтымат, чиста иде. Габделхак боларын ошатты. «Бәлки, Хисам Гыймадиевич алай ук начар кеше түгелдер»,— дип уйлады. Хисам Гыймадиевичның үз «Москвич»ы бар икән. Өй эче дә бай җиһазлы. Телевизор, диван, көзгеле шифоньер. Боларына да тел тидереп булмый. Кеше житкелекле, бай яшәргә тиеш.

Әмма кечкенә бер күренеш бу йорт эчендәге тормышның бөтен асылын ачып салды.

Хисам Гыймадиевичның унҗиде яшьлек бердәнбер улы бар икән. Мәктәптән ашыгып кайтып керде дә:

— Әти, безнең чыгарылыш кичәсе. Баянны алып барыйм әле, иптәшләр көтеп калдылар,— диде.

«Т» хәрефенең өске өлеше җыерылып бер-берсенә кысылды. Ул өйгә кереп китте. Улы да ана иярде. Озак чыкмый тордылар. Нишләптер тавыш-тын да ишетелми. Бу тынлык Габделхакка хәвефле тоелды. Чирек сәгатьләр үткәннән соң, кинәт өй эченнән күк күкрәгәндәй яман аваз бәреп чыкты.

— Ничу! Әндри казнасы юк монда, үзең акча таба башлагач хуҗа буларсың. Пока мин хуҗа бу йортта!

Өйдән Хисам Гыймадиевичның куркынган кыяфәтле хатыны чыгып, куләгәдәй, Габделхак янынннан үтеп китте. Башын түбән игән килеш, күз кырыйларын сөртә-сөртә, улы да чыкты, күтәрелеп карамастан, капкага таба китте. Ә төш вакытында хатыны чәй эчәргә шикәр алып кайткач, Хисам Гыймадиевич бер сумнан калган унөч тиенне санап алды.

«Расчуты юк, Габделхак энем». Бу сүзне Габделхакка Хисам Гыймадиевич әйтте. Үзара сөйләшеп утырганда, Габделхак, җаен туры китереп, аңардан:

— Башка балаларың юкмыни? — дип сорагач иде.

Хисам Гыймадиевичның бу сорауга җавап бирәсе килмәве йөзенә чыккан иде. Ләкин сорау бирелгән, бөтенләй эндәшми калырга җай юк. Хисам Гыймадиевич: «Аңласаң аңла, аңламасаң, үзенә кара»,— дигәндәй:

— Расчуты юк бит аның, Габделхак энем,— диде.

Габделхак аңлады. Ничек кенә аңлады әле. Расчуты юк. Чөнки аның картлык көне болай да тәэмин ителгән. Пенсия алачак, үз өе, бакчасы, кроликлары бар. Нәрсә дип бала-чага белән иза чиксен ул? Хәзерге балаларда иман бармыни?! Хисам Гыймадиевичның үзенең рәхәт яшәп каласы килә...

Габделхак ишекле-төрле йөренә башлады. Ясаячак картинасында бу кешенең урын алачагын сизенде ул. Хәзер аның өчен ярым караңгы авыл өе дә, аңгыр да юк. Габделхакның күңелендә әле моңарчы беркем ясамаган, һәм ул ясамаса беркем дә ясый алмаячак картина формалаша; уңай, тискәре геройларның үзара мөнәсәбәтләре, аерым композиция детальләре ачыклана иде. Аның уңай герое үзенең җилкәсендә хәзерге тормыш шартларында яшәргә, көрәшергә мөмкинлек бирә торган яңа идеяләр, карашлар алып килергә тиеш. Ул диннән азат. Ә диннән чынчынлап азат булу үзе генә дә кешенең эчке дөньясын тамырдан үзгәртә. Диннән азат булу өчен аек акыл, белем һәм батырлык... Әйе, әйе! Нәкъ менә батырлык кирәк! Хәят әнә куркып калган бит әле. Котылгысыз

үләсеңне, үлгәннән соң янадан беркайчан да булмаячагыңны белә торып ничек яшәргә кирәк? — дип сыкрана ич әле.

Диннән азат булуның икенче ягы да бар. Өстәге бөтенесен күреп, ишетеп торучы, яхшылык эшләгәннәрне оҗмахка, явызларны тәмугка олактырып торучы «Алла» дигән нәрсәнең юклыгына инанганнан соң, кешеләр бәйдән ычкынган этләр кебек кыйнала башламаслармы? Юк. Чөнки нәкъ менә шушы дин кабыгы астында күп гасырлар дәвамында кешеләр арасында кешелек мөнәсәбәтләре формалашкан. Ул мөнәсәбәтләрнең өлгереп җиткән урыннарында дин кабыгы үзеннән-үзе җимерелә. Хәзерге вакытта кешелек, борын төртеп, ачык күз белән яшәү чорына чыгып килә. Диннән арыну табигый һәм котылгысыз. Менә мин дингә ышанмыйм. Аңа карап кешелегемне югалтмадым ич. Начарлык эшләмим икән, бу минем тәмугтан куркуымнан түгел. Яхшылыкны да оҗмахка эләгер өчен дип эшләмим.

Матурлыкка — чиксез мәхәббәтем,
Явызлыкка — чиксез нәфрәтем.

* * *

Кино-фәлән булмаса да, бүген клубта кеше күп. Яшьләр бииләр, бер башта бильярд сугалар. Габделхак һаман нишләптер күренми. Яңгыр булганлыктан бүген комбайнчыларның эшләмәвен, Габделхакның авылда икәнлеген Хәят белә иде. Шуна күрә борсаланып: «Җаны түзеп ничек өйдә ятадыр!» — дип уйлады. «Әнә ул!»

Габделхак керә-керешкә очраган егетләр белән кул биреп күрешә барды. Монда аны барысы да белә, күрәсең, ул үзен өйдәге сыман иркен тота. Хәят өчен клуб эче яктырыбрак, ямьләнебрәк киткәндәй булды.

Габделхак күзләре белән кемнедер эзләде. Хәятны күрүгә, танцы мәйданы аркылы ашыкмый гына аңа таба атлады. Хәят дулкынлануын ничек тә иптәш кызларына сиздермәскә тырышты, ә йөрәге Габделхакның адымнарына ярашып типте, әйтерсең Габделхак аның йөрәгенә басып килә иде. Габделхак килеп җитеп Хәятны биергә чакырды. Ә Хәятның, уч иткәндәй, аяклары тыңламый, ул аларның барлыгын да сизми кебек. Шулай да торып басты. Егетнең лайдан кояш ясый ала торган пакь кулларының биленә ятуын тойды һәм аны әйтеп бетергесез шатлык, күңел күтәренкелеге биләп алды. Вальстан соң сигезле күмәк бию биеделәр. Аннары бер төркем кызлар түгәрәк уртасына Әюпне тартып чыгардылар. Ул бераз назланган булды да, гармунчы янына барып, аның колагына нидер әйтте. Габделхакның бәгырен телгәләп «Беренче мәхәббәт» көе яңгырый башлады. Әюп, кешеләрнең башлары өстеннән караган килеш, җиңел генә алып китте. Сулышы иркен икән.

Хәтердә ул тыныч авылы кичләр,
Хәтердә бормалы су юлы.
Онытылмый беренче саф мәхәббәт,
Онытылмый Агыйдел сылуы.

Хәят Габделхакка күтәрелеп караган иде, аның йөзендәге үзгәрешне күреп коелып төште. Егетнең уйларын, хәзерге халәтен Хәят аңлады. Аңламыймы соң? Дөньяда бер Хәят кынамыни?! Һай, беләсе иде, кем икән аның күңелендә...

Ул мине утларда яндырды да,
Тилмертте аерылу газабы.
Нигә соң чәчәктәй яшьлегемнең
Кавышу булмады азагы?!

Юлыгызда киртәләр очратсагыз,
Күңелегез булса нык яралы...

Җыр башында Габделхак Хәятка карады. Сагыш белән өртелсә дә, давылдан соң аязып килгән күк йөзедәй якты, җылы иде аның карашы. Хәятның йөрәге кыюсыз өмет белән сулкылдап алды.

Сез искә алыгыз яшьли сөйгән,
Беренче яраткан ярларны.

Җыр бетүгә шаулашып кул чаптылар. Кайсыдыр:
— Кунак егетен дә җырлатыйк,— дип куйды.
Уен оештырып йөрүче кызлар:
— Нинди кунак булсын ул. Үзебезнең егет ул.— дип юмалый-юмалый. Габделхакны уртага чыгарып бастырдылар. Барысы да тыныбрак торган арада Габделхак:
— Сезнең алда җыр җырларга сандугач теле кирәк. Ачуланмагыз, моряк биюен биим,— диде.
Түгәрәк киңәя төште. Габделхакның өстендә буена ятышып торган зәңгәрсу-кара костюм-чалбар иде. Кызлар аның башына бескозырка да кигергәч, бөтенләй морякка охшады да калды. Ул арада гармунчы егет кирәкле көйне эзләп тапты. Габделхак салмак, әмма яшерен эчке дәрт сизелеп торган килешле хәрәкәтләр белән биеп китте. Түгәрәктәгеләр:
— Афәрин!
— Шулай бас!
— Килештерә бит, ә?! — дип, аны дәртләндереп тордылар.
Габделхак соңыннан түгәрәкне бер әйләнеп чыкты да Хәят каршына килеп «тып» итеп басып куйды. Шунда клуб эчендә шикле тынлык урнашты. Хәятның савыга башлавы турында сүз таралса да, күрәсең, күпләр моңа ышанып житмиләр иде, һәм мөгаен: «Бу кыз килешмәгән эш эшләп, авылыбызның йөзенә кызыллык китермәсме?» — дип уйлыйлардыр. Ләкин бу тынлык бер мизгелгә генә сузылды. Хәятның дус кызлары:
— Һай, белеп бастың.
— Күптән ишеткәнебез юк иде Хәятның җырлавын,— дип, шау-гөр килеп, Хәятны уртага алып чыктылар. Сания, аның югалыбрак калуын сизеп, шаян җыр әйтеп бирде:

Уртада басып торасың,
Әйләнмиме башларың?
Сандугачка мисал икән
Синең кара кашларың.

Ул арада Хәят, үзен кулга алып, күңеленнән җыр сайлады.

Чылтырап аккан чишмәгә
Суга дип килгән идем.
Тиз генә әйләнеп өйгә
Кайтырмын дигән идем.

Өздереп нигә карадың,
Ник тоттың чиләгемнән.
Суларым түгел, ялкыным
Түгелде йөрәгемнән...

Алкышлап калдылар. Хәят түгәрәктән йөгереп чыгып китте. Габделхак аны тыкрык башында куып житеп:
— Кайтасыңмы, озатам...— дия генә башлаган иде, Хәят һич уйламаганда борылып аны үбеп алды. Бу шундый тиз һәм җиңел булды, әйтерсең Габделхакка Хәят түгел, ә хуш исле болын җиле генә кагылып узды. Аңына килгәндә, Хәят юк иде инде. Габделхак аны куа китте. Хәят нәрсәдер үзен белештермичә йөгерә иде. Әнә аның балтырлары

карангылык эчендә, калкулык итәгендә жемелди, энә күздән дә югалды. Габделхак калкулыкны турыдан үтеп Хәятның каршысына төшә башлады. Моны күреп, Хәят читкә тайпылды, ялан кырга чыгып китте. Куып житәргә күп калмаган иде инде, Хәят салам эскерте артына борылды. Габделхак аның эскерт тирәли әйләнеп чабасын аңлап, икенче яктан каршысына йөгерде. Хәят тик тора иде. Габделхак та туктады. Йөрәге, аңа сулыш алырга ирек бирмичә, күкрәгеннән бәреп чыгардай булып типте. Хәят, куллары белән йөзен каплаган килеш, чайкалыбрак эскерт кырында басып тора иде. Габделхак якынрак килде. Кызның чәчләре тузгып, йөзен дә, йөзен каплаган кулларын да күмеп киткән. Габделхак аларны сак кына артка кайтарып куйды, Хәятның кулларын түбән төшерде, Хәятның йомылган күзләрен үпте, тозлы күз яшьләрен тойды; яңакларыннан, иреннәреннән үпте. Аннары кисәк кенә кочагына алып, сылу гәүдәсен чатырдатып кысты...

* * *

Берничә атна үткәннән соң, Габделхакны идарәгә чакырып алдылар.

— Виктор Иванович сагынган сине,— диде бухгалтер.— Минә, художникны кайтарыгыз, үзебезнең октябрь демонстрациясенә әзерләнәсебез бар», дигән,— дип, конвертлы язу сузды. Габделхак аңа күз дә төшермәде. Кайдадыр ниндидер Виктор Иванович дигән кешенең булуы аңа сәер тоелды. Әйе, ул монда вакытлыча гына иң. Ә Хәят? Алар бернәрсә турында сөйләшмәделәр. Ул чакны алар ике табигать баласы гына иделәр. Ә монда ниндидер язулар, әнә бухгалтер счет төймәләрен шалтырата.

— Менә шушында кул куй,— ди.

Габделхак кулына ручка алды, карага манды. 85 сум. Алдаганнар...

Бухгалтер кая кул куярга икәнен бармагы белән төртеп күрсәтте. Күзләре майлы. Габделхак ручкасын өстәлгә ташлады. Бухгалтер пошаманга төшеп, ишек төбендә, мич буенда тәмәке тартып утыручыларга күз кырые белән карап алды.

— Менә шушы турыга кулыңны куй.

— Нишләп 85 сум гына?

Тәмәке тартучылар сагаешып тынып калдылар.

— Минем комбайнда беренче көн эшләвем түгел,— диде Габделхак.— Сез акчаны гектар исәбеннән генә чыгаргансыз. Центнер исәбе кая? Мина төп-төгәл 246 сум 50 тиен тиешле. Яңадан исәпләгез. Әгәр шулай чыкмаса, үзем исәпләп күрсәтәм.

Бухгалтер боргалана-тыргалана урындыгына авып төште, ул бөтенләй кечерәеп калды. Шулай да сөйләшә әле.

— Син болай, иптәш, безнең колхозны бөлдереп китәсең бит.

— Менә шулай алдап, колхозыгызны сез үзегез бөлдерәсез. Ә мин үземә тиешле хезмәт хакын гына таләп итәм.

Тәмәке тартучыларның тәмәкеләреннән төтен чыкмый башлады. Бухгалтер, председатель белән киңәшергә дип, күн тышлы ишек артына кереп китте. Бу вакыт Габделхак кашларын жыерып идән уртасында басып тора иде, озын буеннан кыенсынып урындыкка утырды. Тәмәке тартучылар каршында ул үзен ничектер гаепле тоя иде. Ни өчен икән? Хәят өченме? Хәятка ул бернинди вәгъдә белән бәйле түгел. Габделхак өчен гөнаһ, алла дигән нәрсәләр дә юк. Мөнәсәбәтләрен ул үзе, үзенең намусы кушканча хәл итәргә тиеш.

Бухгалтер күн тышлы ишек артыннан чыгып сүзсез генә урынына килеп утырды. Счет төймәләре шалт-шолт, шалт-шолт итә. 246 сум 50 тиен.

Габделхак урамга чыкты. Авыл өстендәге репродукторда иртәнге концерт бара. Жырның көе дә, сүзләре дә Габделхакны әзәрлекли иде.

Син кал, иркэм, бездэ, китмэ, китмэ.
Дустың сине сөеп иркәләр.
Монда атты синең бәхетең таңы,
Монда туды матур иртәләр.

Син кал, иркэм, бездэ, китмэ, китмэ...

Авылда көн иртә башлана. Габделхак кайтып кергәндә, Нигъмәтулла абзыйның кече улы Илдус мәктәпкә барырга җыенып кына йөри иде әле. Габделхак та чемоданын карават астыннан сөйрәп чыгарды. Нигъмәтулла абзый, күрми торган күзләре белән аның башы өстенә төбәлгән хәлдә, капшанып ишек кырыендагы тәбәнәк урындыкка утырды.

— Китәргә булдыңмыни, матурым?

— Эш урыныннан чакырганнар...

— Шулайдыр инде...

Мәгыйшә апа коштабак белән өстәлгә ярмаланып пешкән бәрәңге китереп куйды.

— Башта ашап ал, Габделхак, аннары җыенырсың,— диде ул.

Тышта салкын аяз иртә иде, өй эче җылы, тәрәзә пыяласындагы пар тамчылары энҗе бөртекләредәй җем-җем итәләр. Яран гөле тәрәзәгә ятыбрак, үрелеп, көзге буш урамны күзәтә.

— Салкыннар да житте, моржа чыгара алмый калабыз, ахры, алланың рәхмәте. Тәки алдалап йөртте бу исерек баш. Моржачыны әйтәм.

Мәгыйшә апа:

— Тамагыңа ятып аша инде,— дип, Нигъмәтулла абзыйны орышып алды.

Габделхак үз уйлары белән мәшгуль. Бу гаиләнең хуҗалык мәшәкатьләре аңа кагылмый.

Мәгыйшә апаның яргаланган, сөялле бармаклары юка пыяла стаканны самовар борыны астына китереп куйды. Шыбырдап су ага башлауга, стаканның өске өлеше парланып тоныкланды, ә аскы өлешендәге, кызларның күз яшедәй кайнар, чиста суга кояш нуры төшкән иде. Ул кыныдан чыгарылган кылыч сыман ялтырый. Нигъмәтулла абзыйның күп мәртәбәләр кискәләнгән калын, каты тырнаклы бармаклары икмәкне капшанып таба. Икмәк өстенә майны ул гаҗәпләнерлек дәрәҗәдә җыйнак итеп яга. Ә Илдусның бармаклары нәфис тиреле, эчтән яктыртылган сыман үтә күренмәле. Бәрәңгене ул озак тотып тора алмый, бер кулыннан икенче кулына күчергәли дә өстәлгә төшерә. Аннары иелеп вак тешләре белән китеп ала. Нәзек алсу иреннәре кайнар бәрәңгегә тигәндә, кара күзләре кысыла төшәләр.

— Каймак салыйммы, Габделхак?

— Варенье белән эчәм, Мәгыйшә апа.

Стакандагы су инде ак түгел, гәрәбәдәй саргылт-яшел. Җиләк вареньесын салгач, ул вино сыман куе булды. Аңардан хуш ис аңкый иде. Кабып карамас борын ук Габделхакның авызына су җыелды.

— Кышкы суыкларда сыкылап, түшәме, стеналары каралып бетәр инде, алланың рәхмәте.

Нигъмәтулла абзый һаман алгы өенә мич чыгара алмый калуына борчыла.

Габделхак аңардан:

— Нинди мич чыгарырга уйлаган идегез? Плитәлененеме? — дип сорады.

— Түгел, турыга гына. Бу өйнеке плитәле безнең.

— Һәй, Нигъмәтулла абзый, үзем чыгарып бирәм, алайса. Илдус, син дә мәктәпкә бармассың.

— Бәрәкалла, бәрәкалла! Чынлап әйтәсеңме, матурым? Моржа да чыгара беләсеңмени шулай?

Габделхак исе китмичә:

— Нәрсәсе бар аның, өясең дә меңгерәсең,— дигән булды.— Нигъмәтулла абзый, син миңа алъяпкыч тап. Кирпеч китә торган чүкеч, мастерок, отвес кирәк булыр.

Габделхакның белеп, ышандырып сөйләве Мәгыйшә апаны да кузгатты.

— Тәвәккәллибезме соң әллә, атасы? — диде ул.

— Габделхак җилгә сүз сөйләмәс. Габделхак, матурым, ни, мин аның инструментларын апкайтып куйган идем инде. Чүкече дә бар, мастиругы да бар. Аллага тапшырдык, алайса.

Ашап-эчеп туйганнан соң өйдәгеләр мәш килеп эур эшкә әзерләнә башладылар. Габделхак Нигъмәтулла абзый белән Илдуска измәне ничек ясарга икәнлеген өйрәтте. «Кызыл балчыкны өч чиләк комга бер көрәк кенә салыгыз, күп салсаң, ярылучан була»,— диде. Үзе биленә алъяпкыч бәйләп мич казнасы эченә кирпеч ватыклары тутырды, аннары ком салып тигезләде. Кирпечләре стандарт, завод кирпечләре иде. Җае җаена килеп кенә тора. Тыштан караганда үз эшенең остасы сыман күренсә дә, Габделхак дулкынлана иде. Аның беркайчан да мич чыгарганы юк, карап торганы гына бар. Ләкин бу рәссам егетнең күңелендә сәер бер ышану яши, кеше эшли ала торган теләсә нинди эшне булдыра алуына ул һич шикләнми иде.

Төтен юлларының йөреше аның күз алдында, онытмаган икән. Ә тышкы ягын ул күз күреме белән дә кыл белән тарттыргандай тигез өя ала. Шулай да мич көймәсен әйләндергәндә Габделхак тирләп чыкты. Эшнең авырлыгыннан түгел — баш ватасы нәрсә күп иде монда. Мич көймәсе биек булса да, тәбәнәк булса да — ипинең йөзе килмәячәк. Габделхак кайнар мич эчен һәм анда пешеп яткан күмәчләрне күз алдына китерде, мич көймәсе күпме югарылыкта булса кызулык ни дәрәҗәдә бәреп торасын чамалады. Кучкар тирәләренә җиткәч, эш кызурак китте. Кояш баегандарак ул түбә өстендә иде инде. Монда өясе дә өясе. Кирпеч биреп торучылар гына җитешсен. Илдус инде арыды. Шулай да сиздермәгән була. Егет кеше бит.

Урамда эштән кайтып килүче Хәят күренде. Ул әле Габделхакны күрми. Үзенең бөтен урамны ямьләндереп килүен дә белми, иптәш кызлары белән шым гына ни турындадыр сөйләшә. Илдус түбә астыннан:

— Тагын кирпеч кирәкме, Габделхак абый? — дип кычкырды.

Биленә алъяпкыч бәйләгән, балчыкка буялып беткән Габделхакны күреп, кызлар көлешеп алдылар. Кайсысыдыр:

— Армый эшлә, морҗачы агай,— диде.

Бер мизгелдә Габделхак белән Хәятның күзләре очрашты. Шул арада сөйләшеп алдылар.

— Сине бүген китә дигәннәр иде.

— Менә, эш килеп чыкты бит. Хәят, бүген дә килерсеңме?

— ...

Яна мичкә ягып караганда өй эченә күрше-күлән кереп тулды. Төтен алга килми, ялкын да, артка кайтарылып, мич көймәсен ялмап юллыкка кереп китә иде. Дөнья күргән агайлар:

— Сөйләшеп яна, мичегез килешә болай булгач.

— Тәмле ризыклар пешәргә насыйп итсен,— диештеләр.

Шунда бер апа ашыгып килеп керде дә:

— Кая яңа морҗачы? Миңа да морҗа чыгарып бирмәсме икән? — диде.

* * *

— Күзеңне ач, дөнья бу.

Габделхак бу илаһи авазны йокы аралаш ишетте. Хәят аны гел шулай уята. Габделхак, аның тән җылысын тойган хәлдә, күзләрен ачты. Төндәй кара чәчләр Хәятның яңакларыннан, иңбашларыннан, сөт өстен-

дәге кубекләрдәй нәфис имиләреннән Габделхакның күкрәгенә таралып төшкәннәр. Хәят аның күз карашыннан оялмый, тын гына шул килеш утыра бирә. Серле елмаю кунган йөзе дә тыныч.

— Дөньяда синең булуың нинди әйбәт, Хәят. Алиһәм минем.

Хәят, чәчләреннән хуш ис аңкытып, гөл сыман-аның күкрәгенә иелә төште, кайнар тыны белән:

— Яктырып килә, тор инде, сиңа китәргә вакыт,— дип пышылдады. Алар салам эскерте эчен уеп кергән куышта ягалар. Эскерт дымлырак чагында өелгән булса кирәк, җылы бәреп тора.

* * *

Ферма авылдан бер читтә, калкулык итәгендә. Юл үргә каршы булса да, Хәят очып баргандай җиңел атлый. Ләкин менә ул туктап калды. Кулы белән эчен кысып җиргә чүгәләде. Күз алдында гына юл өстендәге вак ташлар, кантарлы-кантарлы яргаланган каты балчык. Хәят һәр үлән бөртеген аерым-аерым күрә. Җирнең шулай якын торуы сәер. Башы шаулый. Ул үзенең балага узуын аңлады, авыл ягына күз төшерде. Моннан авыл уч төбендәгедәй күренә. Әнә тыкрыкта олы юлга таба кулына чемодан тоткан, җилкәсенә этюдник аскан Габделхак бара. Олы юлда зәңгәрле-сарылы автобус тора. Репродуктордан скрипка моңнары агыла. Заһид Хәбибуллин уйный. Әнә Габделхак автобус эченә керде, кузгалып та киттеләр. Ә авыл өстендә скрипка моңнары өзгәләнә.

Юк, Хәят үкенми. Габделхакны ул үзенә карый да яхшырак аңлый. Габделхак гомерен зур бер максатка буйсындырган, ул шуңа омтыла, Хәят аны шундый булганы өчен яратты да. Хәят үкенми, ул Габделхакка ышана. Үзенең Габделхакка, Габделхакның үзенә кирәк булуын белә һәм кайчан да булса барыбер кавышачакларына ышана. Әгәр күңелендә шундый ышану булмаса, ул үзен әти-әнисе, авылдашлары алдында гаепле тояр иде, бу эше өчен үзеннән-үзе җирәнер иде. Ә бу — мәхәббәт, тормышның үзе бу.

Әйе, Хәят Габделхакка бер сүз дә әйтмәде. Чөнки сүзләр гупас. Хисләргә сүз кирәкми.

* * *

Ишектә Габделхак күренү белән Виктор Иванович Дудин, телефон трубкасын урынына ташлап:

— Һо! Кайттыңмы? Без монда сине дүрт күз белән көтәбез,— диде.— Ну, ничек, курорттан канәгатьме? — дип сорады. Соравына җавап көтеп тормастан, Габделхак сузган путевка язуларын карый башлады.

— Ике көн аерма чыга икән, син чәршәмбедә үк кайтырга тиеш булгансың. Нигә болай?

Габделхак җавап эзләп түшәмгә текәлде.

— Я, ярый, ижат итеп азапланма,— диде Виктор Иванович.— Әллә ни зур бәла түгел. Җайларбыз,— диде.— Менә нәрсә, Габделхак. Безнең предприятие оформление буенча беренче урынны алды. Синең белән хәтта горком кешеләре кызыксындылар. Һәм, беләсеңме, шәһәрнең үзәк мәйданын Октябрь бәйрәменә бизәүне безнең предприятиегә йөкләделәр.

Виктор Иванович өстәл өстенә куйган кулларына текәлеп сөйләп торган җиреннән бер як кашын югары чөйде һәм шул як күзен дә зуррак ачып, Габделхакка күтәрелеп карады.

— Бу синең өчен дә начар булмаячак. Үзәк мәйданны тиешле дәрәҗәдә бизи алсаң, сиңа алтынчы разрядны бирергә дә мөмкин булыр,— диде.

Виктор Иванович, Габделхакның куанмавына, сөмсере коелып утыруына гаҗәпләнеп:

— Син нәрсә, канәгать түгелсеңме? — дип сорады.
Габделхак сүрән генә:
— Рәхмәт,— диде.
Предприятиене ул, чыннан да, бәйрәмгә әзерләп бетерел киткән иде, кайту белән үзенең картинасын ясый башларга уйлаган иде. Палитрасын, буяу пумалаларын кулына алмаганга ни гомер бит инде. Соңгы вакытта Габделхак аларны төшләрендә күрә башлады.
Конторадан чыгып барганда, аны Хисам Гыймадиевич туктатты.
— Габделхак энем, ни... Теге веранданы буяган идең бит. Нишләптер буявы һаман кипми,— диде.
Габделхакның исенә төште: Хисам Гыймадиевич аны чәй белән генә сыйлаган иде. Габделхакның тамагы туймады, ашханәгә барып тамагын туйдырып килергә туры килде. Шуның ачуыннан ул буяу чиләгенә бер банка чамасы машина мае салып болгаткан иде. Буяганда сизелми ул, буяуның төсен дә үзгәртми, ләкин озаграк кибә. Сигез-тугыз айлардан соң гына йокмый башлый. Бу әле көннәр кояшлы, җиләс торса шулай...
Габделхак, Хисам Гыймадиевичның сары буяуга буялган җиңнәренә, иңбашларына караган килеш:
— Күпме вакыт үтте соң әле? — дип сорады.
— Ни инде, Габделхак энем, ай ярымнар булды инде.
— Да-а...
Габделхак тулай торакка кайтып кергәндә, аның белән бер бүлмәдә торучы Шамил, җилкәсенә тастымал салып, юынырга чыгып бара иде. Ягымлы күкрәк тавышы белән гөрләп:
— Әйдә, өс-башыңны алыштыр, берәр ресторанга барып утырабыз. Юл тузаннарын юарга кирәктер, шәт. Альбинага да шалтыраттым. Минем Әлфия белән сигезгә «Россия» клубы янына килергә булдылар,— диде.
Габделхак:
— Альбина? — дип куйды.
Шамил ана аптырап бер тын карап торды да көлеп җибәрде.
— Син нәрсә?! Космостан төштеңме әллә? Син, вообще, авылдан үзгәреп кайткансың.
Шамил башын чайкап алды да юынырга чыгып китте.
Кичке Әлмәт. Янгыр явып узган һәм көз булса да җылы. Төнге утлар, неон реклама язулары асфальт юлдагы, тротуардагы чиксез күп күлләвекләрдә чагыла. Кешеләр, машиналар упкын өстендә, реаль булмаган бушлыкта йөриләр, стеналар аша да үтеп чыгалар сыман. Тротуарлар тулып ага. Киенеп-ясанып чыккан кешеләр үзләрен күрсәтергә тырышып һәм башкаларны да күзәтә-күзәтә ашыкмый атлыйлар. Ә яшьләр тынычсызланып бер-берләрен эзлиләр.
Шәһәр кешеләренең үз-үзләрен тотышлары көннең төрле вакытында төрлечә була. Иртән әле йокыларыннан уянып җитмәгән булалар, йөзләре тыныч, күпләрнең ирен кырыйларына елмаю кунган була. Чөнки колакларына әле шау-шу тулмаган, эш урынындагы көндәлек низаглар белән нервлары бозылмаган. Төш вакытында алар йокыларыннан уянып җитәләр, шул ук вакытта арганлык та сизелә, бер-берләренә ул кадәр игътибар итмәстән, үзалларына уйланып, ашыгып атлыйлар. Шамил белән Әлфия алдан култыклашып баралар. Әлфия эчкә таба басып килешле атлый икән. Бу кыз буйсынмас Шамилне чын-чынлап сихерләгән, ахрысы. Алар, бер-беренә сыенышып, тын гына үзара гәпләшеп баралар. Габделхакның куллары кесәләрендә. Альбинаның биек үкчәле ак туфлиләре аның ботинкалары белән янәшә «тык-тык» итә.
Виктор Иванович белән ачыктан-ачык сөйләшергәме әллә? Мөгаен, рөхсәт итмәс. «Предприятие сынлы сәнгать мастерское түгел, производство урыны»,— дияр. Ләкин нинди дә булса җай табарга кирәк. Югыйсә, гомер үтеп китәр, берни эшли алмый калырсың. Гел шуның өстендә

генә эшләп, рәсем серләрен көн-төн эзләсәң дә таманга килер. Сиңа үзеңнән башка беркем ярдәм итмәс. Иҗат өчен шартларны үзем булдырырга тиешмен. Нишләргә соң?

Бу үзәк мәйданны безнеке әле. Бәлки, шуннан соң вакыт иркенәер. Кыш көне эш күп булмас. Кыш, озын кыш әле алда.

Каршыга килүче бер төркем яшьләр Альбинаны Габделхак янынарак кысрыкладылар. Аларның иңбашлары кушылып алды. Габделхак уйларыннан арынып Альбинага борылып караган иде, аңа бик күңелсез икәнлеген аңлады. Чибәр үзе.

* * *

Үзәк мәйданны бизәү өчен Габделхакка сварочный агрегат, күтәрү краны һәм ярдәмгә тагын өч кеше беркеттеләр. Алай да эш ике атнага сузылды. Габделхак панноларын зур масштаблы, Октябрьның юбилей бәйрәменә лаек булырлык, мәһабәт итеп ясарга тырышты. Виктор Иванович канәгать иде. Мәйдандагы эшне карарга килгән чакларында ул һич тартынмыйча, Габделхакның җилкәсенә сугып:

— Яхшы, яхшы, молодец,— ди торган иде. Әмма эш төгәлләнгән көнне Дудин Габделхакны бер читкә чакырып алды да:

— Барысы да әйбәт, ләкин беләсеңме, горкомдагы иптәшләр 50 санының язылышын ошатмадылар. Артык кистереп, кроссворд сыман итеп язылган, үзгәртергә кирәк, диләр. Яңадан ясарга туры килер,— диде.

Габделхак үзалдына көлемсерәп куйды һәм:

— Моны рәсемнән зәвыгы булмаган кеше әйткән,— диде.

— Анысы шулайдыр. Минем үземә дә ул шушы килеш ошый. Ләкин эшне кабул итүче комиссия әгъзалары үзгәртергә кирәк диләр иң.

— Комиссия әгъзаларының барысы да түгелдер. Тулы бер коллектив андый сүз әйтмәс,— диде Габделхак, ачуы килеп.— Яңадан ясарга! Кечкенә нәрсәме ул? Ине-буе егермешәр метр бит аның!

— Күз алдына китерергә була,— дип дәвам итте Габделхак, ачы елмаеп. Башкалар «ах-вах» килеп мактап торганда, иң хөрмәтле бер кеше үзенең башкачарак уйлавын күрсәтер өчен үтә акыллы бер кыяфәттә: «Менә шулай, шулай, иптәшләр. Шушы җире шулайрак», дип үз фикерен белдергәндер. Янында, житмәсә, аңа карата җылы хис саклаучы берәр ханым да басып торгандыр.

Габделхак сурәтләгән күренешне күз алдына китерепме, әллә югыйсә чыннан да шулай булгангамы, Виктор Иванович көлеп җибәрде.

— Фантазия эшли синең,— диде ул, көлә-көлә. Аннары житдиләнеп: — Ләкин барыбер яңадан ясарга туры киләчәк. Минем хәлне дә аңла син. Мин аларга: «Ярар, эшләрбез»,— дидем бит.

— Үзем мәгънәсезлек дип исәпләгән эшне мин эшли алмыйм,— диде Габделхак.— Кулым бармый, я бөтенләй бозып ташлармын,— дип өстәде.

— Мин аларга нәрсә дип әйтим алайса. Художник ясарга теләми димме. Ул чагында минем директорлыгымнан ни кала?! Әйе, син рәссам, синең үз зәвыгың, ләкин беренче чиратта син эшче, производство кешесе. Монда икенең берсе: я эшләргә тиешсең, я мин сине эштән азат итәргә мәҗбүр булачакмын.

Габделхак «Ихтыярыгыз» дип башын бер якка кыңгыр айтып, җилкәләрен җыерып алды.

Боларның бөтенесен кич белән Альбинага сөйләгән иде, Альбина үтә салкын бер тонда:

— Подумаешь, кулым бармый, имеш! Буярга да куярга иде. Синә барыбер түгелмени? Бу предприятиедән юкка китәсең. Виктор Иванович белән дуслар идегез бит. Әгәр әйбәтләп сөйләшсәң, ул сиңа квартир да достать итә ала,— диде.

— Хикмәт анда гына түгел,— диде Габделхак.— Бу эш миңа гомумән ошамый. Монда рәсем белән шөгыльләнергә мөмкинлек юк.

— Аһ, боже бой! Рәсем, рәсем! Шул рәсемең аркасында син кешеләрне дә күрмисең. Сизми дип уйлыйсың што ли? Минем янда булганда да гел шул турыда уйлыйсың бит син. Акчаң житмимени? Син болай да Виктор Ивановичтан аз гына ким аласың ич.

Габделхак, баруыннан туктап калып:

— Менә шушы урында безнең юллар аерыла,— диде.

Альбина:

— Подумаешь! — дип аның яныннан үтеп китте.

Габделхак икенче көнне үк гаризасын язып кертте. Дудин сүз озайтып тормады. Моның файдасыз икәнлеген аңлый иде, күрәсең.

— Виктор Иванович, хәтерлисеңме, эшкә алганда: «Ни өчен сезне бер урыннан икенче урынга куып йөртәләр?» — дип сораган идегез.

Виктор Иванович көлемсерәп куйды. Хезмәт кенәгәсе белән гаризаны Габделхакка сузып:

— Ә шулай да мин синнән канәгать. Предприятиене адәм рәтенә кертеп китәсең. Гомумән, әйбәт егет син. Ләкин мондый характерың белән яшәве авыр булыр сиңа,— диде.

Кулларын өстәл өстендә кушырып бер тын уйланып торганнан соң ул:

— Хәзер ни эшләргә исәплисең? — дип сорады.

Габделхак хезмәт кенәгәсенең битләрен актаргалап:

— Менә «география китабын» язып бетерергә кирәк ич,— диде.

Виктор Иванович башын чайкап янә көлемсерәп куйды, урыныннан торып Габделхак янына килде.

— Я, ярый, хәерле юл,— дип кулын сузды.

* * *

Көне буе кызу кояш астында печән чабып арган, имеш. Куыш янына кайтып ял итеп утырган чагы. Көн инде кичкә авышкан. Офык артына яртылаш күмелгән кояш керфек-нурлары белән төнгә куна калган болыт кәрваннарына кадалып аларны кызылга манган. Учак төтене тын һава биеклекләренә сыгылып-сыгылып күтәрелә, имеш.

Шул чак көтмәгәндә җиһанны инләп сүзсез җыр яңгырый башлый. Аның җирдән күтәреләме, яисә күктән инәме икәнлеген аңлап булырлык түгел. Габделхак бу хәлгә аптырап башын күтәрә һәм үзеннән ерак та түгел, ут шикелле янып торучы кызыл болытны күрә. Анда ниндидер сурәтләр төсмерләнә сыман, җыр да шуннан килә кебек. Ул да булмый, күкнең иненнән буена ямьле бер күренеш ачылып китә. Куе яшел тау итәгенә сыенган авылга таба болын юлы буйлап бер кыз килә, имеш. Күренеш тора-бара ачыклана, яшерен дәрт белән башлаган әлеге сүзсез җыр көчәя бара. Ләкин аны икеләнүле, борчулы авазлар эзәрлекли. Көйдәге яшәү көче ул мәкерле авазлардан арынырга теләп, ачыргаланып әле түбән атыла, әле газапланып яңадан югары омтыла.

Габделхак урыныннан торды да, сукмак-юл сайлап тормастан шул якка — Хәят күренгән якка китеп барды.

## Сәҗидә Сөләйманова

### Гомер

Кыш килә,
Көннәрне кыскарта,
Күк йөзенә күк пәрдә тарта.
Ак юрганыңа төрен дә ят!
Мәңге хуҗа булырга уйлап,
Сызгырып, дулап, кыш килә.

Яз килә,
Йөгерә-атлый килә,
Тамчылар аңа сәлам бирә.
Шәрәгә калган дөнья яшәрә, киенә,
Ярларны тарсынып ярсына,
Узмас яшьлек сыман яз килә.

Җәй килә
Җәяүләп, җайлап.
Тетрәтеп уза яшен-җайдак
Сабан туйларына, бәйгегә.
Куенын ачып кояшка, җилгә,
Җәйләүгә чыга дөнья, җәй килә.

Көз килә.
Каеннар күзе күлдә-көзгедә.
Юлларда тау-тау олаулар,
Җырларда көлү дә елаулар...
Бизәнеп, баеп, көз китә,
Ата йортыннан гүя кыз китә.

### И кызлар, и хатыннар

Сагышым үксез —
Далада аунап елардай булам.
Кычкырып, үксеп еласам,
Акылдан язган диярләр.

Шатлыгым чиксез —
Дөньяны кочып җырлардай булам!

Ярларны ярып җырласам,
Бу тәмам азган диярләр.

Без шатлансак,
Керфекләрдән нур тама, нур сирпелә, —
Кем очраса, шул күрә.
Кайгыбызны кем белә?
Керфекләр җиргә иелә,
Күз яше җилгә сибелә.

●

Киткәннәрнең юллары озын,
Көткәннәрнең көннәре озын.
Йөргәннәргә — ачыш-табышлар,
Көткәннәргә — сагыну, сагышлар...

Сагыш коесыннан су эчим,
Сөйгәнемнең юлларын үлчим.
Янадыр ул. Бәлки туңадыр,
Эчеп бетералмыйм, шуңадыр.

Эчкән саен арта сулары,
Чиксездер лә йөрер юллары...
Төпсез коелардан су алам,
Сөйгәнемә кайтыр юл сабам.

●

Аһ, ник түгел җилдәй җиңел чагым?
Кош канаты — кашың-керфегең.
Шул канатка кунып очар идем
Изге хыял итеп җир-күгем.

Бик карамыйм әле күзләреңә,
Юк, бирелмим әле хисемә, —
Иңнәремә авырлыгын салган
Дөньям тарта мине үзенә.

Вәгъдәләрем анда, өметләрем...
Син дә җирсез, илсез ир түгел.
Юк, карамыйм әле күзләреңә,
Җирдә үзем салган эзләрем бар,
Кош канаты — кашың-керфегең.

●

Ымсынган да, очынган да чаклар...
Ташламагыз әле, дусларым!
Сез булсагыз гына бәхетем тулы,
Тулы килеш күрсен дошманым.

Арылган да, кагылган да чаклар...
Борчымагыз мине, дусларым, —
Сезнең алда никтер күңел тула,
Яшь күрмәсен күздә дошманым.

•

Читлəтүең — чиклəвеңме?
Бер кыюга — мең тыю...
Ах, əллə сиңа рəхəтме
Кеше җаннарын кыю?

Сөйсəң сөй, сөймəсəң сөймə,
Урталыгың — үртəвең.
Ах алла, мин үталмыйммы
Җилпеп күлмəк итəген...

Яратуы чыннанмы дип
Əллə инде сынавың?
Ах алла, мин күталмыйммы
Сабырлыгың сынганын?

•

Кем əйтə сөю лəззəт дип?
Дөресе, сөю — газап.
Йөгəнен өзгəн йөрəгең
Əллə кол, əллə азат.

Ут белəн су арасында
Тукталыр нокта эзлəп,
Үрсəлəнə, өзелə үзəк, —
Сөю ул шундый бизгəк...

Үз-үзеңне югалту ул —
Мəхəббəткə таруың.
Йомарлап йөрəккə салган
Оҗмахың ул, тəмугың.

## Кадыйр Сибгатуллин

# Иргә чыкмый калган апалар

Нигә безгә һаман кызлар дисез,
Кызлар яшемени яшебез?
Күңел өчен генә булса да бер
Тол хатыннар диеп дәшегез.

### 1. ӨЧ КУЛЪЯУЛЫК БОЛГАП ӨЧӘҮ КИТТЕ

Печәннәре чәбәләнеп калды,
чабылып бетми калды өч алын.
Чалгыларын онытып калдырдылар
пакусларга кадап очларын.
Китәселәр киткән.
Соңгы озату.
Авылдагы соңгы өч егет.
Бер болында өч кыз басып калды,
күзләрендә калды өч өмет.
Бәлки сугыш бетәр,
менә бетәр,
өчесе дә бергә кайтырлар...
Исән бул, дип кызлар озаталар,
Кайтырбыз, дип китә батырлар.
Урамнардан чыгып китте җырлар,
яшьлек шаулап тынды озакка.
Дугадагы кыңгыраулар чыңы,
гармун тавышы калды колакта.
Өч кулъяулык болгап өчәү китте
кайнар билләренә кул салып...
Калды...
Калды...
Чынлап үбелмәгән
сусыл иреннәре турсаеп.

### 2. ҮКСЕДЕЛӘР КЫЗЛАР КАПЛАНЫП

Хатлар язды өч кыз бер өстәлдә
терсәкләрне терәп терсәккә:
«Ташламагыз безне, ташламабыз,
нәрсә язса,ниләр күрсәк тә!»
Иреннәре белән ябыштырып,
өч кат үбеп бергә салдылар.
Өч тәрәзәдән карап өч кыз көтте,

өч егеттән өч хат алдылар.
Ә бер көнне килде ике җавап.
Ә бер көнне килде соңгы хат.
Хатлар язды өч кыз бер өстәлдә,
бер егеткә өч кыз... соңгы хат.
Яшелләнеп куе булып үсте
былтыр алар чапкан алыннар.
Киң-киң атлап алар үттеме әллә?
Күз алдында таныш адымнар.
Өч кыз йөрде бергә болын ярып,
яшь талларны кочып үттеләр.
Кайтмаска ук киткән егетләрен
болыннарга чыгып көттеләр.
Туры басып кемнәр чалгы янап
сызгырдылар —
бу да истә бит.
Алар тавышы белән дәште болын,
өч кыз йөрде тыңлап, сискәнеп.
Вәгъдәләшкән кебек бер-берсенә
Сыенышып үскән үләннәр.
Аермагыз, без — бер, дигән сыман
кыякларын бергә үргәннәр.
Дер селкетеп үтсә астан елан
аерылып кала пар үлән.
Ташламам, дип вәгъдә биреп кенә
кавышып булмый икән яр белән...
...Яшь малайлар чапты яр буена
алар җиккән атка атланып.
Күз яшьләрен сөртеп үләннәргә
үкседеләр кызлар капланып.

### 3. ЕЛЛАР БЕЛӘН БЕРГӘ ЯШЬЛЕК ҮТТЕ

Үтте...
Үтте...
Еллар елга тоташ...
Җилкенешеп алган чакларда
җыелышып өч кыз хат укыды,
тик үзләре юк шул хатларда.
Алар ташлап киткән аланнарны
өч кыз ел да бергә чаптылар.
Егетләрен кабат күргән кебек
унсигезгә борылып кайттылар.
Кызлар хисен инде яшьлек түгел,
Терлек фермалары исертте.
Кышкы кичтә алар тальян моңын
абзар аша гына ишетте.
Толлар да тол, калган кызлар да тол,
никах күрми китте кияүләр.
Егетләрдән калган бүрекләрне
сеңелләре эшкә кияләр.
Үтте...
Үтте...
Егет кулы түгел,
тормыш тотты нәфис куллардан.
Дүрт баласы бергә елаганда

көнләштеләр кызлар толлардан;
Ач баласын иске шәлгә төреп
толлар мичкә тизәк якканда,
кияүгә дә чыгып калмадык, дип
көрсенделәр ялгыз ятканда.

#### 4. ИЛЛЕ ЯШЬЛЕК КЫЗЛАР ЧИГҮ ЧИГӘ

Аулак өйдә кызлар чигү чигә,
колакларда — сәгать тавышы.
Сәгать кебек келт-келт итеп кенә
гомерләрнең үтеп барышы.
Арттан бәйләп куйган ак яулыктан
күренеп тора бераз ак чәчләр.
...Ут шәүләсен таң дип белә микән,
Сөрән сала чеби әтәчләр?
Яулык чигә өч кыз кич утырып
күзлекләре түбән салынган.
Яулыкларда — болын чәчәкләре,
чәчәк урталары — сарыдан.
Битләрендә бераз кызыл шәүлә,
әллә эссе, әллә кызарган?
Хушбуй микән, иннек, кершән микән,
чәчәк исе килә кызлардан?
Төшеп беткән инде сәгать гере,
күтәрерләр әле күрсәләр.
...Унсигездә шиңгән чәчәкләре
яулык почмагында үсәләр.
Илле яшьлек кызлар чигү чигә,
дулкынлана яулык читләре.
Ишекләр дә ачык, —
егетләре
бүген тагын кайтып җитмәде...

## Мәчет мәйданы

Авыл уртасында басып тора
Моңсу, уйчан, иске манара.
Бу мәйданнан разбой салып үткән
якалашып ике замана.

Бер залптан бишәр пуля алган
Заһид, Салих, Нури, Габдулла...
Стенага терәп аткан аклар,
бисмилла әйтеп торган карт мулла.

Музейдагы кебек тып-тын монда,
Бер мәйданда ике замана:
алтын белән язган мәрмәр һәйкәл,
корт ашаган иске манара.

# Өлкәннәр кул изи

Юлларга чыгыйк әле без,
бер нужа күрик әле.
Рәхәтен, азабын бергә
тигезләп бүлик әле.

Аркадан биштәр төшмәгән,
көн кыска: барыйк, барыйк.
Кемнәрнең хәлләре ничек —
юлларга чыгып карыйк.

Киткәннәр һаман барамы
өметләр өеп алга?
Кешеләр юлда аралар —
җитәрләр микән бар да?

Шырпысы юктыр берәүнең,
беткәндер, дымлангандыр.
Утым юк, учагым юк, дип
ялгызы моңайгандыр.

Ут бирик.
Учак ягарга
бер шырпы җитә бит ул.
Бу дөнья шырпы сызсаң да
ялт итеп китә бит ул.

Юлыннан язганнар булса,
әрнидер, сүгенәдер.
Тауларга менеп кул изик,
биектән күренәдер.

Нурларын күрми таңының
ятадыр берәү оеп.
Сызгырып китик яныннан,
уянсын, торсын тоеп.

Үзебез арсак, өшәнсәк
Күрерләр, булышырлар.
Юлларга чыгыйк, юлларга,
юлда гел узучы бар.

## Идрис Туктар

### Җөмләләр

Янсын күмер — көле калсын, үтсен гомер — гөле калсын!

* * *

Иске хаталарны кабатлау — яңа хаталарга юл ачу.

* * *

Икейөзлегә бер битлек җиткән.

* * *

Берише кешеләр сикереп ябыксалар, беришеләре симереп сикерәләр.

* * *

Чакырылмаган кунак зарыктырмый китсә, син аңа: «Хуш китәсең!» — дип кал.

* * *

Кечкенә булса да кәрәк булсын, зур булса да кашык булсын.

* * *

Үз нәфесенә үзе хуҗа булган — иң көчле кеше.

* * *

Көз булса капчык кирәк, бала туса карчык кирәк.

* * *

Мәктәп имтиханнары кайчан да бер тәмамлана, ә тормыш имтиханнары гомер буе дәвам итә.

* * *

Буш вакытны да бушка үткәрмә!

* * *

Һәрбер тавык үз кетәген белергә тиеш.

* * *

Белмимнең башы авыртмый, әмма башында да артмый.

# ИБРАҺИМ ГАЗИ

(1907—1971)

**РЕДАКЦИЯДӘН.**

*Табигать законнары аяусыз. Үлем безнең арадан язучыларны алып китә тора. Үлү белән аларның эше онытылмаска, халыкка җиткерелеп торырга тиешле. «Казан утлары» шушы елның беренче саныннан «Әдәби мирас» исемле даими бүлек ача. Һәр санда мәрхүм язучыларның мирасы — хикәя, шигырь, мәкалә һәм хатлары, шулай ук язучы турындагы истәлекләр бастырып барылачак. Әнә шул уңай белән редакция әдипләрдән һәм журнал укучыларыннан үзләрендә саклангая хатларны яки язучыларның әсәрләрен, истәлекләрне җибәрүләрен үтенә.*

*Бу санда без күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе, Г. Тукай премиясе лауреаты, зур һәм катлаулы тормыш юлы үзган Ибраһим Гази мирасыннан кайбер әсәрләр бирәбез. И. Газиның «Совет язучысының байрагы», «Язучының гражданлык йөзе» кебек мәкаләләре татар әдәбияты өчен генә түгел, гомумән күп милләтле совет әдәбияты үсеше өчен принципиаль әһәмияте булган зур әдәби документлар, алар әдипнең зур эрудицияле, киң карашлы, нык принциплы коммунист язучы булуын тагын бер мәртәбә раслыйлар. Ә бит вафат булган язучыларның архивында басылмый калган андый мәкаләләр, җыелышларда сөйләнгән чыгышлар аз түгел.*

*Татарстан язучылар союзы идарәсе Ибраһим Газиның әдәби мирасын туплау өчен А. Шамов, Г. Кашшаф, Л. Ихсанова, А. Сердинская (язучының хатыны) составында махсус комиссия төзеде. Әдип турындагы материалларны Татарстан язучылар союзы адресы белән (Казань, ул. Баумана, 19, Союз писателей) яки А. Сердинская адресы белән (Казань, ул. Товарищская, дом 21, кв. 4) шушы иптәшләр исеменә дә җибәрергә мөмкин.*

*Журналыбызның алдагы саннарында Ш. Мөдәррис, Г. Насрый, Г. Хуҗи, Ә. Давыдов, З. Мансурның әдәби мираслары биреләчәк.*

## ГОМЕР БУЕ ҮЗЕ БУЛЫП КАЛГАН КЕШЕ

Мин аны беренче мәртәбә Тукай клубында күрдем.

Ни хикмәттер, авылда туып-үскән кешеләрдә тере язучыны күрү, аның ни сөйләгәннәрен үз авызыннан ишетү — буй житмәс бер хыял булып яши. Әнә шул күптәнге хыял безне язучылар клубына китерде. Казан университетына килеп эләккәннең беренче атналарында ук без, авылдан килгән егетләр, кичектергесез эшебез итеп, Матбугат йортына, язучыларны күрергә йөгердек.

Клубның иң югаргы катта булуы да, анда берничә дистә язучының берьюлы җыела алуы да — барысы искиткеч иде, дулкынландыргыч иде.



— Монысы кем?

— Кит аннан!

— Әнә тегесе, чәчен алга сыпырып сөйләгәне кем?

— Кит аннан! — кебек гаҗәпләнү сүзләре күп булды ул көнне. Әмма барыннан да ныграк гаҗәпләндергәне бер авторның куркусызлыгы иде.

Куркусызлыгы дип шуңа әйтәм. Төп докладчы да, чыгып сөйләүчеләр дә «Онытылмас еллар» романын тетеп салдылар. Монысы житми дә тегесе житми, монысын сурәтләмәгән дә тегесен сурәтләмәгән. Хәзер без андый таләпләр куюга күнеккән инде. Андый жыелышларны да күп күрдек. «Тетеп салынган» китапның яхшы китап булуын, аның хәтта Тукай премиясе ала алырдай китап булуын да аңладык. Әмма ул чакта, авылдан килгән тәҗрибәсез үсмерләргә, безнең үтә дә яратып укыган китабыбызны «яманлаулары» бик кыен булган иде. Бигрәк тә бер язучының — яшькелт ярым хәрби кительле, шадрарак битле, кысык күзле бер кешенең (бәрәкалла, Кави Нәҗми икән!) ярсынып-ярсынып сөйләве истә калган. Сүзләр аның түгәрәкләнеп ачылган авызыннан берәм-берәм түгел, ялкын тасмасы кебек тоташы белән чыгып торалар иде. Хәер, бу «ялкын тасмасын» мин хәзерге язучылык тәҗрибәм ирешкән фантазия белән уйлап чыгарам бугай, ул чакта мин, авыл малайлары кебек, гади генә итеп: «самавыр кебек кайнап сөйли» дип уйлап куйган идем. Чыннан да, Кави агай, кайнап, күбекләнеп сөйли, «Онытылмас еллар» романының авторын әллә ниткән гөнаһларда гаепли иде. Тыңлый торгач, аның нәрсә әйтергә теләве дә аңлашыла башлаган кебек булды. Бактың исә, романның авторы, үзенең китабында, роман хәтле романда, татар милләтчеләрен фаш итмәгән. Хәлбуки, татар милләтчеләренең күңел кайтаргыч, жирәнгеч образын халыкка күрсәтеп бирер өчен авторның көче дә, сәләте дә, мөмкинлеге дә, утлар чәчеп тора торган сатирик куәсе дә бар икән. Ә ул аны эшләмәгән, ул сыйнфый сизгерлеген югалткан.

— Менә сиңа мә! — дип аһ иттек без.— Бетерделәр бит «Онытылмас еллар»ны! Авторы ничек түзә икән?

Күңелдә кыяр-кыймас кына булып язучылык корты кузгалып йөргән заманнар. Төннәр йокламыйча сер бүлешкән Хәлимгә, романның төп героена, арттан килеп, миңгерәүләтердәй итеп, күсәк белән китереп ордылармыни! Шул кадәр әйбәт китап та ярамагач, тагын нинди китап ярар соң? Ай-һай-һай! Язучы булам дип хыялланып, әллә ниткән яшертен уйлар белән саташып йөрү кирәк микән?

Тагын кемнәрдер чыгып сөйләде, кемнәрдер бәхәсләште, кемдер хәтта китапны мактаган да булды, тик аларның берсе дә истә калмаган. «Авторы ни дип әйтер икән? Аңар сүз бирерләрме?» дип көтеп утыруыбыз гына хәтердә саклана.

Ниһаять, без көткән минут житте. Сөйлиселәр сөйләп, ярсынасылар ярсынып беткәч, китапның авторы Ибраһим Газига сүз бирделәр.

Залдан егетләрчә жилләнеп, озын буйлы, күзлекле бер кеше узып китте. Сәхнәгә ул басмачадан түгел, идәннән генә сикереп менде. Три-

буна янына килгәч, трибуна читенә ике куллап чытырдатып ябышты, күзлек пыялаларын ялтыратып, залга үткен итеп бер багып алды, һәм, юка иреннәрен кысып беркавым дәшми торгач, безнең күңелләрне канат кактырырдай, кыска һәм усал итеп, залга берничә сүз ташлады:

— Куркытма сине мине, Кави! Татар милләтчеләрен фаш итү — синең эш, татар крестьянының революциягә килүен сурәтләү — минем эш!

Беренче тәэсир чын була диләр. Ихтимал, бу дөрестер. Ибраһим Газиның холкындагы беренче сыйфат — куркусыз принципиальлеге, әнә шул принципиальлекне өздереп, ярып кына әйтеп бирә белүе гомер буе сакланды. Мин аны егерме ел буена беләм. Егерме ел буена бергә китаплар чыгарырга да, китапларым турындагы киңәшен ишетергә дә, бергәләп «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә, проза секциясе бюросында, ниһаять, Язучылар союзы идарәсендә эшләргә туры килде. Ул һаман да шул принципиаль карашлы, туры сүзле булып калды. Ул минем беренче китабымны чыгарттырмады. Һәм мин моңа рәнжемим, киресенчә, шатланам, ул җыентыкка тупланган беренче хикәяләр бик зәгыйфь булганнар икән, мин аларны хәзерге җыентыкларыма керткәнем юк, «Яшьлек яме» исемле повестьтан беренче китабымны башлап җибәрү миңа отышлырак булды. Тагын шунысын да әйтергә кирәк, ул мине беренче мәкаләмнән үк тәнкыйтьче итеп таныса да, озак вакытлар хикәяче-прозаик итеп танымады; үзем бик якыннан белгән, ярсынып язган «Юллар чатында» хикәямнән соң гына хикәяче итеп тә таныды. Бу — аның шулай ук әдәбиятка булган зур таләбеннән, принципиальлегеннән килә иде. Шул принципиаль җирлектә ул әдәби әсәрләрне энә күзеннән үткәреп барды. Татарстан китап нәшриятында Ибраһим Гази кулы белән язылган берничә йөз эчке рецензия булырга тиеш, заманында кулъязмалар актарганда без аларның беришесен архивка тапшырган да идек, аларны, исән булган сурәттә, халыкка житкерү әдәбият фәненә яңа бер өлеш була алыр иде. Принципиаль, туры сүзен ул телдән әйтергә дә иренми иде. Бер вакыт, Октябрь бәйрәме алдыннан, Әнвәр Давыдовның Октябрь революциясенә багышланган шигыре газетада басылып чыкты. Квартир яклары кысан булу сәбәпле, без, берничә яшь язучы, Язучылар союзы бүлмәсендә һәм редакцияләрдә бикләнеп эшли идек, шушы хәлне белеп торган Ибраһим Гази, якшәмбе булуга карамастан, Әнвәр Давыдовка шалтыратып, аның шигыре турындагы фикерен әйтте. Аның фикере бик югары иде, газетада басылган шигырьләр дежурный-кәжүнни бүлмаска тиешләр, алар поэзиянең барлык таләпләренә җавап бирердәй яхшы сыйфатлы булсыннар иде, диде. Хәтеремдә, Давыдов шигырьне аңлаучы прозаиклар да булуына шатланып, атна буе дулкынланып йөрде. Яшь прозаиклардан ул Шамил Бикчурин иҗатын бик җентекләп карап барды, озак еллар буе аңар иҗатта гына түгел, көнкүреш һәм әхлак мәсьәләләрендә дә киңәшләрен биреп, аның үсүе, язучы буларак формалашуы белән кызыксынып яшәде. Шамилнең күптән түгел тәмамлаган романын укырга Лениногорскига да барып кайтты. Әйбәт роман булачак, тормышчан дип сөйләп торганы хәтеремдә. Бикчурин Әлмәт берләшмәсеннән үсеп чыккан автор булганга, ул миңа күптән таныш иде, күренекле язучы, каләм остасының сүзен ишетү аеруча күңелле булды. Хәзерге яшьләрдән ул Мәдинә Маликова иҗаты белән дә бик кызыксынды, авторны кабинетына чакырып, аның иҗат планнары турында, иҗатындагы уңай һәм кимчелекле яклар турында озаклап сөйләште.

Ибраһим Газиның принципиальлеге Язучылар союзында эшләгәч чакта эш стиленә дә күчте. Аның иң яратмаганы — рәсми кәгазьләр теле иде. Ул миңа, Язучылар союзының секретарена, берәр кәгазь әзерләргә бирә, мин, әлбәттә, хәзерге заман стиленә туры китереп, мөрәҗәгать иткән кешеләргә карата итагатьлек, әдәплелек саклап, кәгазьне язып

бирәм. Аннан ул аны ботарларга тотына. Бер вакыт Әмирхан Еники, үзе яшәгән йортны сүтәр алдыннан, озак кына квартир ала алмый йөрде. Ул хакта без шәһәр Советына да, башка урыннарга да язып карадык. Эш кузгалмады. Ибраһим Гази җиңнәрен сызганып үзе язарга утырды һәм аның каләменнән менә мондыйрак сүзләр чыкты (хәтеремдә калганын язам, алдымда хаты юк). «...Җир йөзендә хәзер фәрештәләр юк. Күктә дә аларны санаулы гына калган диләр. Күренекле татар язучысы Әмирхан Еникигә фатир бирүне озакка сузып йөртүегез аның бәгырен таштай катыландыра...»

Беләсезме, бу сүзләр шундый нык тәэсир иттеләр, алар шундук шәһәргә таралдылар һәм Әмирхан Еники озакламый квартирлы да булып куйды.

Мәскәүгә, СССР язучылар союзына, Язучылар йорты салырга акча сорап хат яздык. Акчаны бирмәделәр. Биш-алты ел көтәргә куштылар. Ә без йортның Татарстанның илле еллыгына кирәк булуын язган идек. «Отказ» хаты алу белән тынычланмады Ибраһим Гази, шундук утырып, яңа хат язды, русча язылган ул хатта (русчаны ул камил белә иде) бер аеруча усал җөмлә истә калган: «Дорогой К. В. Вы нам обещаете построить Дом литераторов через сотни лет, но ведь красное яйцо дорого к Христову дню...»

Яшьли әти-әнисез калып, балалар йортларында тәрбияләнгәнгәме, ул тантананы, шау-шуны, бәйрәмнәрне яратмый, кунак-кунак уйнамый, тәмәкене, эчемлекне җен урынына күрә, бу кадәресендә хәтта кирәгеннән дә арттырып җибәрә иде. Мәскәүдән яки күрше республикадан берәр язучы килеп төшә, син, әлбәттә, аны озатып йөрисең, кунак итәсең, Казанны һәм республиканы күрсәтәсең, Ибраһим абый сиңа чынлап торып үпкәли, синең кунак язучы белән йөрүеңне гаепкә саный, вакытны әрәм үткәрмә, Союзның берәр эшен эшлә, ичмасам, ди. Хәзерге заманда әдәби бәйләнешләрнең көчәюен, ә моның шәхси танышлыктан башка була алмавын ул башына да китерми иде.

Ләкин ничек кенә булмасын, аның үзенә дә хезмәт вазифасы буенча Казаннан читкә чыгарга, зур киңәшмәләрдә катнашырга туры килде. Тик ул анда да, җилкәсен куырып, мескен хәлендә йөрми, әйтәсе сүзен шундый ук усал-үткен итеп, борыч салып әйтә иде. РСФСР язучылар союзының секретаре һәм СССР Верховный Советы депутаты булып сайлангач, ул Архангельскига, РСФСР язучыларының күчмә секретариатына барды. Киңәшмәдә катнашучылар аның әдәбият мәсьәләләре буенча гына түгел, Архангельск шәһәрендәге җәмәгать тәртипләре хакында да образлы итеп, үзәк бәгыреңә үтәрдәй итеп сөйләвен соңыннан бик үз итеп, яратып әйттеләр.

Ибраһим Газиның принципиальлеге, туры сүзлелеге, усал телле булуы гомер буена сакланды. Бу сыйфат аның халык тарафыннан танылган «Онытылмас еллар» трилогиясендә, повестьларында, хикәяләрендә һәм мәкаләләрендә дә бар. Алар аның үзенчәлекле, оригиналь язучы булуының бер сыйфаты иделәр. Ягъни Ибраһим Газиның яшәү стиле белән язу стиле кушыла алды.

Ибраһим Газиның күзгә ташланган икенче житди сыйфаты — шаянлык, юмор.

1960 ел. Лениногорскига нефтьчеләр дуслыгы бәйрәменә бардык. Шамил Бикчурин безне күрергә гостиницага килгән. Аның селкенебрәк сөйләшә торган гадәте бар иде. Шамил киткәч, Ибраһим агай әйтә: теге салам чәчле егетегез өстемә ава дип котым калмады, ди. Лениногорск ул чакта әле төзелеп кенә ята, шәһәр комитетына зур бер алан аша, чокыр-чакырлардан сикереп барабыз, соңга калмыйк дип ашыгабыз.

— Ибраһим абый, сәгатегез дөрес йөриме?

— Бик дөрес йөри, хәтта алга да китә!

Нефтьчеләр бәйрәмендә катнашканнан соң (ул анда барыбыз өчен дә образлы итеп котлау сүзен әйтте), безне табигый урман паркына мәҗлескә алып киттеләр. Һәркем, хәлле хәленчә, котлау сүзе, тост әйтте. Чират Ибраһим абыйга да житте. Кич буена ул, су кушып, бер рюмка кызыл аракы эчте һәм тостын кыска гына итеп, болай диде:

— Монда сезнең эшләрегез чатыр-чатыр килеп тора. Урман паркы да бик шәп. Геройларыгыз да бар. Тик мин сезгә әйтим: без китапханәләрне, уку залларын карап чыктык. Китапханәче штатын кыскарткаинар. Мин әнә шул штат кыскарттырган кешене атарга боерам!

Монда аның баягы принципиальлеге белән борычтай ачы сатирасы бергә кушылды.

Язучылар союзында эшләгән чакта ул директив органнарда эшләүчеләр белән дә төчеләнеп сөйләшүне яратмый иде. Өстәл янынинан торып, аякларны аерып баса, телефон номерын жыя һәм әйтә:

— Бу шул әле: Ибраһим Гази дигәннәре. Йомыш бар. Кайсы көнне һәм ничә сәгатьтә кабул итә аласыз?

Секретарь бүлмәсенә кереп (звонок басып чакыртып түгел!) миннән идарә хәлләрен сораша. Мин сөйлим. Аннары үзе өйдә бик озак уйлап килгән кайбер эшләрен куша. Мин: әһә, әһә, әһә, дип тыңлыйм. Көлеп әйтеп куя: «Әһә, әһә!» дип әйттең дә нәрсә диган сүз соң ул әһә?»

Бездә гомер буе юмор сөйләп, гомер буе эченне катырып көлдергән язучылар бар, әмма, ни хикмәттер, үз әсәрләрендә шул юморны табигый итеп куллана белмиләр. Ибраһим Газиның яшәү стилендәге юмор китапларына да бик табигый булып килеп керде һәм әнә шул юмор аның Ибраһим Газига гына хас язу стилен тудырышудагы бер элемент булып бик һәйбәт кушылды. «Онытылмас еллар»дагы ишектән икегә сынып керә торган Бер ярым Миңнуллалар, ач карынга мәзәк сөйләп йөрүче ярлы-ябагайлар әнә шул тормыштагы табигый юморның якты гәүдәләнеше бит инде. Шулар янына аның чипчык борыны хәтле генә итеп язылган гаять көчле юмористик-сатирик хикәяләрен дә өстәргә кирәк. Чехов мәктәбе үрнәгендә язылган бу хикәя-новеллалар әдәбият хәзинәбезнең югалмас гәүһәрләре булып калачаклар. Гомумән, Ибраһим Газиның үлеменә берничә еллар гына кала язган хикәяләре аеруча оста, аеруча тирән язылган булулары, энже бөртегедәй ялтырап ятулары белән укучыларның да, язучылар җәмәгатьчелегенең дә игътибарын җәлеп иттеләр.

Аның соңгы еллардагы әсәрләрен, бигрәк тә хикәя-новеллаларын игътибар белән күздән кичерсәң, әдипнең, кеше буларак, тагын бер сыйфатын күрми калу мөмкин түгел.

Ул сыйфат — Ибраһим Газиның нечкә күңеллелеге. Принципиальлеге һәм шаянлыгыннан аермалы буларак, аның бу өченче сыйфаты күзгә ташланып тормый иде. Без, аның белән аралашып өйрәнгән кешеләр, аны ничектер, корырак итеп күрергә гадәтләнгәнбез. Әмма тормыштагы аерым очраклар аның күңел нечкәлеген кинәт кабызып җибәрәләр иде.

1951 ел. Мин «Совет әдәбияты»на эшкә кердем, әдәби хезмәткәр булып эшлим. Ул заманда нибарысы өч кенә кеше эшләгәнгә, эш иртәнге алтыдан башланып, кичке тугызларга хәтле сузыла иде. Кичке бишмеалтылармы тирәсендә егетләрчә җилләнеп Ибраһим Гази килеп керә, керә дә, тукталып та тормастан әйтә:

— Әйдә, тәмәке төтененнән туйгансыңдыр, һава сулап керәбез!

Без «һава суларга» чыгабыз. Ул шуннан гыйбарәт: Ибраһим абый мине үргә, Чернышевский (хәзерге Ленин) урамына алып менеп китә, Черек күл аркылы алып чыгып, Казанка елгасы буенда тау башына китереп туктата. Шунда без утырышабыз. Ул кесәсеннән ике телем

кара ипи чыгара, берсен миңа бирә, икенчесен үзе ашый. Ипи ашый-ашый озак кына елга өстенә, ерактагы офык читенә карап утырабыз. Дәшмибез. Аннары сүзгә сүз ялганып, әдәбият мәсьәләләренә керешеп китәбез, ул сугышта йөргән чакларын, татарча газета чыгаруларын, Кутуйның госпитальдәге үлемен, ул хәбәрне хатынына әйтүнең никадәр авыр булуын сөйли. Сузмыйча, азапламыйча сөйли. Аннары без әдәби осталык мәсьәләләренә тукталабыз. Ул миңа әйтә, син, ди, урам тулы халык булуын нинди деталь белән бирер идең? — ди. Мин апырабрак калам, минем ул хакта уйлаганым юк. Шуннан ул әйтә, Горький, ди, халыкның урам тулы булуын кешеләрнең коймаларга бәреләбәрелә баруы белән биргән, ди. Һәм бу сөйләшү минем күңелемә бик озакка сеңеп кала, мин әдәби әсәрнең бик төгәл детальләрдән торуын физик рәвештә тойгандай булам. Ул минем байтак әсәрләремне укыды, тик бер генә мәртәбә каләм тотып, бер сүзне төзәтте. Әлеге дә баягы «Юллар чатында» исемле ул яраткан хикәядә: «Без барлы-юклы әйберләребезне машинага төяп» дигән җөмлә бар иде. «Төяү» сүзе машинаның тулык булуын күрсәтә, диде ул, димәк, барлы-юклы әйберне төяп булмый. Моны «барлы-юклы әйберләрне машина төбенә салып» дип кенә әйтеп була. Хәзер дә мин кайбер детальләрне язган чакта, тукта әле, барлы-юклы әйберне төяү килеп чыкмаганмы, дип тикшереп карыйм.

Сүзем — Ибраһим Газиның нечкә күңелле булуы, табигатьне ярату хакында иде бит. Без әнә шулай табигатьтә утырганыбызны үзебез дә сизмәстән, әдәби осталык һәм дөньяви тормыш турында сөйләшеп, аерылабыз.

Лениногорскига нефтьчеләр бәйрәменә килгән чакта ул минем анда ничегрәк яшәп ятуымны белергә теләп, Әлмәткә дә килеп чыкты, бездә бер көн куныл китте. Аның бездә үзен тотуы бик яхшы истә калган. Ишектән кергәч тә ул семья членнарының барысы белән дә кул биреп, бик җентекләп күрешеп-сорашып чыкты. Аннары битен-кулын юды. Аннары барлык бүлмәләрне карады. Иң азактан кухняга керде, тәрәзә төбендә утырган исле гөлне ике куллап тузгытып, бөтен бите белән күмелеп иснәде һәм бәләкәй генә бер тармагын чеметеп кенә өзеп алды да түш кесәсенә тыгып куйды. Аш-су өлгергәнче без минем эш кабинетына кердек. Ул әйтте:

— Сине нефтьчеләрдән роман яза диделәр. Укып кара әле, мин диванга кырын төшеп тыңлыйм,— диде.

Кулъязманы алып бер бүлек (ун битләр чамасы) укып күрсәттем. «Тагын укы». Тагын бер бүлек укыдым.

— Син беләсең инде, мин бит кеше әйберсен мактарга саран кеше. Моны мактыйм. Чын итеп язасың. Бүленмә, тизрәк бетер,— диде.

Өйләдән соң урманга чыгып кердек. Тын гына сөйләшеп йөргән җирдән зур бер имәннең астагы ботагына сикереп ябышты да турниктагы кебек атына, әллә ниткән әкәмәт бөжралар ясый башлады. Мин алтынчы дистә белән барган кешенең шул хәтле җиңеллегенә шаккатып калдым.

Агачтан төшкәч көлеп әйтте:

— Җыйдыңмы, ничә чиләк ком коелды миннән? — диде.

Иртәгесен мин аны Казанга озатып җибәрдем. Әлмәттә язучы халкын бик ихтирам итәләр, нефтьчеләрдән машина алып, махсус озатып куярга да була иде, тик ул моңа теше-тырнагы белән каршы төште.

Рейстагы автобус киткәнче минем белән тышта сөйләшеп торды, өйдәгеләргә рәхмәт әйтергә кушты, килеп яхшы итүен, күңеле янаруын әйтте, килсәң, миңа керерсең, диде. Мин кышсыз бара алмам шул, дидем. Кышын кил, урманга чыгып учак ягарбыз, көлгә бәрәңге күмеп ашарбыз,— диде.

Автобус китәргә тырылдый башлагач, бик җинел генә, автобус баскычына сикереп миндә дә китеп барды.

Язучылар союзы председателе булып сайланганчы ул байтак еллар профессиональ язучы булып, җәйләрен Аккош күлендәге дачасында алмагачлар, гөлләр үстереп яшәде. Гомуми җыелышларга, киңәшмәләргә бик төгәл йөрүдән башка аны бүтән җирдә күреп тә булмый торган иде. Язучылар союзы җитәкчесе булып сайланганнан соң аңар әдәби хәрәкәтнең барышы өчен дә, аерым әдипләрнең тормыш шартлары өчен дә борчылырга туры килде. Ни сәбәптер, аны соңгы елларда төрле авырулар да бик борчыды. Шулай да ул холкындагы өч төрле сыйфатны: принципиаль-турылыкны, юмор хисен, табигатькә гашыйк-нечкә күңеллелеген ташламады.

Яңа эшендә җаваплылык хисен тою аңар әдәбиятта партиялелек карашларын аеруча басым ясап, кат-кат куярга, тормыштагы бюрократизмга, гамьсезлеккә каршы көрәшүдә табигый юморыннан файдаланырга мөмкинлек бирде. Нечкә күңеллелеге аның әсәрләрендәге лиризмга, образларының пластик булуына алып килде. Мин аның белән егерме ел аралашып яшәвемнән чыгып әйтә алам, ул табигый сыйфатларына гомер буе турылыклы булып яшәгән, димәк, гомер буе үзе булып калган кеше. Әнә шул ныклык аның кабатланмас үз стилен тудырды, әдәби хәзинәбезгә Ибраһим Гази дигән гаять үзенчәлекле, талантлы язучының зур мирасын калдырды. Бу мирас җентекләп тупланырга, барлык зурлыгы, нәфислеге белән халыкка җиткерелергә тиеш.

ГАРИФ АХУНОВ.

*20 сентябрь, 1971*



*Хикәяләр*

# ДҮРТӘҮ



үрт кешелек палатада алар әлегә икәү генә. Уртадагы караватта Вайнберг дигән ак чәчле бер карт инфаркт белән ята. Йоклаганда ялгыш борылып куймагаем да, йөрәгемә авырга килеп, үлеп китмәгәем дип, ул һәр көнне төнгә каршы нянядан кул-аягын караватт тимеренә бәйләтә, иртә белән чиштерә. Икенче ай китте инде, бер генә кичне дә бәйләтми калганы юк. Врач Клавдия Николаевна обходка кергән саен картның караваты янына килеп утыра да, елмаеп:

— Сезгә инде борылырга ярый. Ятыгыз борылып уң ягыгызга,— дип киңәш итә.

Вайнберг чалкан яткан килеш мендәрдәге ап-ак чәчле башын гына чайкый: юк инде, юк, янәсе, куркам...

Аның янына көн саен бер матур карчык килә — хатыны. Палатада икәү генә калган чакларында алар әкрен генә нидер сөйләшәләр. Сүзләре беткәч, карчык дәшми генә идәнгә карап утыра. Карт дәшми генә түшәмгә карап ята. Гомер үткән — сөйләшер сүз сөйләшенеп беткән. Палатада икенче авыру, Николай Евдокимыч, шулай ук инде яшь егет түгел. Аның аяклары сызлый. Врачлар аяк тамырларында кан йөрми дип табалар, күбрәк ятып торырга кушалар. Ә ул озак ятуга чыдый

алмый, сикереп тора да коридорга чыгып китә, врач кергәндә бервакытта да үз урынында булмый. Нянялар аны домино «сугучылар» яныннан табып алып кайталар. Ул, башын бөгеп, караватына килеп утыра да врачның сорауларына әкрен генә җавап бирә башлый. Клавдия Николаевна аның аягындагы кан тамырларына учы белән басып-басып карый:

— Нишләргә инде минә сезнең белән? Сезгә ятып торырга кирәк, ә сез гел йөрүдә. Җитмәсә, тәмәке дә тартасыз.

Николай Евдокимыч врачның шелтәле күз карашы астында, гаепле малай кебек, башын иеп утыра бирә.

— Тартмасам, бик йөткерәм,— ди ул.

Клавдия Николаевна чыгып киткәч, ул бераз ятып торгандай итә дә тагын палатадан чыгып югала. Ул белә, күп йөрергә ярамаганны да — барысын да белә. Тик нишләсен? Бер сүз сөйләшми торган Вайнберг белән ята-ята акылдан шашсынмыни? Ә инде тәмәкегә килгәндә, тәмәкеләрен ул беренче көнне үк пачкасы белән Клавдия Николаевнага тоттырып чыгарды, тартмаска вәгъдә бирде, тәмәкедәге никотин кан юлларын бикли икәнен больницага хәтле үк ишеткән иде. Ләкин сүзендә тора алмады. Төнлә йөткереп, бер тапкыр Вайнбергны уяткач, теге керпе кебек пырш-пырш итте дә: «Коридорга чыгып йөткерсәгез ни була?» — диде. Шуннан бирле Николай Евдокимыч йөткерү өянәге башлануга палатадан чыгып, баскыч авызына барып утыра да туйганчы йөткерә. Берничә төн шулай азапланганнан соң, янадан тәмәкегә тотынырга мәҗбүр булды. Юкса бит, йокламыйча тәмамябыгып бетәчәк.

Врачлар аягыңны кисәргә туры килмәгәе дип куркыталар. Николай Евдокимыч бик борчыла. Күбрәк кешеләр арасында булырга тырыша. Аннары, күрәсең, характеры да шундыйдыр. Кешесез яши алмый. Кешесез һәм эшсез. Больницада каян килгән эш? Николай Евдокимыч тапты: хатыны китергән китапларны, журналларны йөри алмый торган авыруларга өләшеп чыга да, тегеләр укып бетергәч, кире җыеп ала, икенче кешеләргә тарата... Ул хәтта авыруларны туалетка җитәкләп алып барудан, җитәкләп алып кайтудан да тартынмый. Телефон янында да гел ул. Кемне чакыралар, хәзер барып дәшеп килә. Үзе дә еш кына өе белән сөйләшә. Яңа китаплар сорый. Аның хатыны китапханәдә эшли бит. Евдокимычның заказларын үтәп кенә тора.

Аларның палатасына бер көнне Садыйк Гыйльфанов исемле кара күзле, кара чәчле матур гына татарны салдылар. Ул көнне Евдокимыч, яңа авыру белән сөйләшеп, күбрәк палатада утырды. Гыйльфановның ашказаны авырта икән. Язва тапканнар. Ул үзенең авыруы турында бик озаклап, бик тәмләп сөйләде. Евдокимыч аны юатырга тырышты.

— Язваны бетерәләр аны,— диде. Аннары үз авыруына күчеп: — Менә аягым,— дип, аягын күрсәтте. Ярты гына ел элек өч квартал араны ял итми бик ансат кына бара булган, хәзер бер квартал да йөри алмый икән.

Гыйльфанов шундый чир белән авыручыны санаторийда очратканын исенә төшереп:

— Андый аякны кисәләр бугай,— диде.

Евдокимыч «кисәләр» сүзенә игътибар итмәскә тырышып, мондагы больница шартларын сөйләп китте. Клавдия Николаевнаны мактады: янәсе, бик ачык күңелле, елмаеп кына йөри... Врач кеше әнә шундый булырга тиеш. Авырулар аны «безнең Клавдия» дип юкка гына бик яратып сөйләмиләр. Медицина институтына студентлар сайлаганда кешенең белеменә карап кына түгел, характерына да карап сайларга кирәк дип, врач исемен күтәреп йөрүче каткан җаннарны яратмыйча сөйләде.

— Менә иртәгә үзегез дә күрерсез, ошатырсыз,— диде.

Тәнне тагын начар йоклады. «Кисәләр» дигән куркыныч сүз аның өчен яңа сүз булмаса да, Гыйльфанов авызыннан тагын шул сүзне ишеткәч, бик авыр булды аңа. Бик... Немец тылында чолганышта калулар нәтиҗәсе инде бу... Төнлә генә бардылар, көндезләрен сазлыкта бил тиненнән суда качып яттылар. Аяклары гөбе булып шеште... Ике атна буе мүк җиләге һәм гөмбә белән генә тордылар. Үзебезнекеләр ягына килеп чыкканда, кеше тәсе калмаган иде егетләрдә... Аннары алты ай госпиталь... Аннары тагын сугыш... Контузия... Менә нәтиҗәсе...

Евдокимыч йөткеренеп, уйланып, баскыч авызында бик озак утырды. Тәмәке тарткач кына, бераз тынычланып, палатага керде дә иртәнгә таба изелеп йоклап китте.

Обход вакытында Клавдия Николаевна яңа авыру янына туктап сораша һәм карый башлагач, Евдокимыч, тегеләрнең сөйләшүләрен тыңлап, караватында уйланып утырды.

Врачның сораулары беткәч, Гыйльфанов тумбочкада ята торган блокнот сыман дәфтәрен сузылып алды да, шул дәфтәр битенә карый-карый, врач белән сөйләшә башлады. Клавдия Николаевна аны елмая-елмая тыңлый, ә Евдокимыч, тегенең, дәфтәргә карап, «беренчедән», «икенчедән» дип, җөмләләрне пунктларга бүлеп, кәгазьдән укып сөйләвенә сәерсенеп, әкрен генә көлеп җибәрде дә, уңайсызланып, стенага таба борылып ятты.

— Бишенчедән,— диде Гыйльфанов,— мине монда озакмы яткырырсыз?

— Тикшерү бер ун көнгә сузылыр,— диде врач, елмаюын сүндереп.

— Клавдия Николаевна, сез мине гафу итегез,— диде Гыйльфанов һәм блокнотын тумбочкага куйды.— Соңгы сорау: сездә язваны ничек дәвалыйлар? Мин элек яткан больницада...

Клавдия Николаевна аны бүлдерде:

— Беренчедән, сездә язва әллә бар, әллә юк...

— Бар, бар, анысы доказан...

— Әллә бар, әллә юк,— дип дәвам итте врач,— анысын тикшергәч белербез. Икенчедән,— диде ул елмаймаска тырышып,— сездә язва табыла калса, ашказаныгыздагы кислотаны киметү өчен, иртән ач карынга сода яки магнезиум эчәргә туры килер, өченчедән, көндез тагын магнезиум, дүртенчедән, боржоми суы да бик файдалы. Эчеп караганыгыз бармы?

Һәм Клавдия Николаевна, Евдокимыч ягына карап алып, елмаеп куйды. Евдокимыч, борылып яткан килеш, калтыранып көлә иде.

Гыйльфановны ач тотып, ашказаныннан су алдылар, рентгенда карадылар. Шуннан соң Клавдия Николаевна керде дә:

— Беренчедән, сездә язва тапмаганнар, икенчедән...— диде дә көлеп җибәрде. Авыру үзе дә елмайды.

— Юк, доктор, миндә язва бар,— диде ул.— Мине ГИДУВта Эпштейн үзе карады, тапты...

Клавдия Николаевна урындыгыннан торды, фонендоскобын муенына салды.

— Мин сезне әлегә беренче өстәлдә калдырам. Кислотагыз кими төшкәч, бүтән өстәлгә күчәрсез. Магнезиум эчүне дәвам итегез.

Врач чыгып киткәч, Гыйльфанов, «миндә язва барлыгы доказан» дип, Николай Евдокимычка исбат итә башлады. Евдокимыч көлеп:

— Врачлар белән сез тезисларга карап кына сөйләшәсез икән,— диде.

Гыйльфанов кайчандыр инструктор булып хезмәт иткән икән дә шул вакыттагы гадәтеннән котыла алмый икән. Евдокимыч аның сөйләгәннәрен бераз тыңлап ятты, аннары палатадан чыгып китте. Доминочылар янында күңеллерәк иде.

Гыйльфанов үзенең эчен баскалап карады да, торып, Вайнберг янына килде.

— Папаша, сез йоклаганда бик гырылдыйсыз икән,— диде.— Моннан соң мин сезне гырылдый башлагач уятам.

Вайнберг җавап бирмичә чалкан ята бирде. Бүген няня аның аяккулын чишәргә онытткан иде.

Тагын берничә көннән соң дүртенче караватка да бер кеше кертеп салдылар. Бу кырыклар тирәсендәге, бик ябыккан, бик агарган кеше иде. Палатага аны житәкләп үк керттеләр. Ул беләгендәге сәгатен чишеп тумбочкага куйды, кечкенә радиоприемнигын күкрәгенә өстенә бастырып, жырлата башлады. Гыйльфановка палатада приемник кычкырту больница кагыйдәләрен бозу булып тоелды. Ул Вайнберг ягына ишарәләп:

— Папаша бик авыр ята, тавышлануны яратмас,— диде.

Иртәдән бирле сөйләшми яткан Вайнберг кинәт телгә килде:

— Уйнатсын, күңеллерәк...

Евдокимычның яңа авыру белән танышасы килә иде. Ләкин теге дәшми генә музыка уйната, барып сүз кату уңайсыз.

Николай Евдокимыч, сестралардан сорашып, аның нәрсә белән авыруын белеп тә өлгергән иде. Бөерендә ниндидер шеш тапканнар икән. Аңа операция ясарга кирәк, ә ул ризалык бирми икән әле. Евдокимычны аска чакырып төшерделәр. Хатыны килгән. Журналлар китергән. Ул, журналларны күтәреп, палатага кайтты да, бераз икеләнеп торганнан соң, әлеге яңа кергән авыру янына барып:

— «Огонёк» карыйсыгыз килмиме? — дип сорады, журналны тегенең тумбочкасына куйды. Теге, «рәхмәт» дип, ак иреннәрен кыймылдатты да ябыклыктан бик зураеп калган күзләре белән бер читкә карап ята бирде. Приемнигы һаман күкрәгендә, һаман уйный иде. Музыканы тыңлыймы соң ул? Әллә тыңлаган булып, уйга калып ятамы?

Палатада тагын бер сөйләшмәүче артты, икәү булдылар дип торганда гына, Вайнберг ап-ак башын яңа авыру ягына борып (ничек курыкмыйча борды диген):

— Бераз көчәйтә алмыйсызмы? — дип үтенде. Ул да музыка тыңлап ята, имеш. Яңа авыру көчәйтте, приемнигын күкрәгеннән тумбочкага күчерде.

Вайнберг сагышлы итеп пышылдап куйды:

— Штраус... Бөек Штраус...— Үзе дә сизмәстән уң кулын күтәреп, мәгънәле бер хәрәкәт ясады.

— Папаша, сез кулыгызны бәйләтергә онытткансыз ич бүген,— диде Гыйльфанов көлеп.

Вайнберг әллә ишетмәде, әллә җавапсыз калдыруны кирәк тапты. Ишетми калган булуы да бик ихтимал, чөнки ул үзенең яшь чакларын исенә төшергән иде. Хәзерге чал чәчле карчыгы ул вакытта уналты яшьлек чибәр гимназистка иде. Вайнберг аны, гимназия юлында сагалап торып, өйләренә хәтле озатып куя иде. Баскыч алдына кайтып житкәч, алар качып үбешәләр иде. Соңыннан да аңа күп үбешергә туры килде, әмма шул вакыттагы качып үбешүләрдән дә татлырак үбешүләрнең булганын хәтерләми.

Революция еллары... Вайнберг яшь, чибәр... Энергиясе кайнап тора... Чехлар аны, үлем баржасына бикләп, Чистайдан Казанга алып килделәр. Баржада алар егерме бишләп кеше иде. Барысы да коммунистлар. Ни өчен Чистайда гына атмыйча, атарга Казанга алып килгәннәрдер — Вайнберг бүгенге көнгә тикле шуның серенә төшенә алганы юк.

Караңгы төннәрнең берендә, икешәр-икешәр богаулап, аларны Казанка елгасы ярына чыгарып бастырдылар. Яр текә иде. Яр астындагы кап-кара су серле һәм куркыныч булып күренә иде. Менә хәзер чатырдатып атып җибәрерләр дә Вайнберг шул кара суга мәтәлеп барып

төшәр. Үлгән кеше өчен кая егылса да барыбер түгелмени? Вайнберг һич оныта алмый, шул куркыныч шомлы суга кадалып барып төшәм дип уйлаганда аркасы чымыр-чымыр иткән иде.

Винтовкалардан залп биргәнне ул аерым-ачык ишетте, шуннан соң гына яр астына мәтәлде. Үзе белән кулга-кул богауланган Тимофеевның гәүдәсе аны шулай өстерәп төшеп киткәндер, чөнки Вайнберг үзе бөтенләй яраланмаган да иде. Су өстенә калкып чыккач, үзенең исән калуына гаҗәпләнеп, каршы як ярга таба йөзә башлады. Тимофеевның үле гәүдәсе аңа иркенләп йөзәргә бирми иде. Теге якка барып чыкканчы, ул тәмам хәлдән тайды. Аяклары төпкә тигәч, камышлык эченә кереп егылды да хәл җыйды.

— Вайнберг! Вайнберг! — дип кабат-кабат әйтелгән тавыш аны уйларыннан тартып алып, кире больница палатасына кайтарып куйды. Каршысында нидер әйтеп Николай Евдокимыч басып тора иде. Кабатлап әйткәч кенә Вайнберг аңлады: карчыгы шалтыраткан икән, бүген сонрак килермен дигән, өйдә ниндидер мәшәкать килеп чыккан...

— Күңелсезләнмәсен, обязательно киләм дип әйтергә кушты,— диде Николай Евдокимыч, елмаеп.

Хатыны килеп киткәч, кичке ашны ашагач, Вайнберг озакламый гырылдап йоклый да башлады.

— Рәхәтләнә йокыга,— дип, Евдокимыч аның шулай йоклый алуына соклана иде. Үзе ул, кич якынлаша башласа, борчуга төшә, сестрага дару сорарга кереп китә.

Бүген өянәге якынлашканны сизгәч тә, ул тизрәк коридорга чыкты да баскыч авызына барып утырды. Аның буыла-буыла йөткерүен ишетеп, төнге сестра җылытылган датский король тамчылары китереп эчерде. Шуннан соң ютәле басылды, палатага кереп ятты. Вайнберг баягыча чалкан төшеп, рәхәтләнеп гыр-гыр йоклый иде.

— Сәламәтләнә,— дип уйлады Евдокимыч.

Гыйльфанов та, мыш-мыш килеп, балаларча тәмле итеп йоклап ята. Озак та үтмәде, Евдокимычның тагын ютәл өянәге башланды. Аптырагач ул, тәмәке кабызып, юрган астында гына бер-ике тапкыр суырды.

— Сез дә йоклый алмыйсыз икән,— дигән, аргы почмактан ишетелгән тавышка тизрәк тәмәкесен сүндерде: ул инде «тартырга ярамый» дип кисәтүләрдән куркып беткән иде.

— Уяттым, ахры, сезне,— диде ул.

— Мин әле күземне йома алганым юк,— диде Солтанов (яңа авыруның фамилиясе шулай иде).— Музыка борсам, уяныр лар дип куркам.

Николай Евдокимыч аның ник йоклый алмаганын сизенә.

Профессор кичә карагач:— Операция! — дип катгый итеп әйтте.

— Мин берәүне беләм,— дип тотынды Евдокимыч, сүнгән тәмәкесен тумбочка кырыена куеп,— сыңар бөер белән рәхәтләнеп яши...

— Рәхәтләнеп... Әйттегез сүз...— Аның тавышында сагышлы елмаю сизелде.— Минем бит диагноз шәп түгел.

— Яман шеш димәде бит профессор.

— Профессор димәде дә бит...

— Ул дөресен әйтә инде. Миңа миннән яшерми: аягыңны кисәргә туры килмәгәе,— ди.

Аларның сөйләшеп ятуын коридордан сестра ишеткән икән, бүлмәгә башын тыгып: «Ник йокламыйсыз?» — дип сорады. Болар йоклаганга салыштылар, дәшмәделәр. Сестра ишек төбендә бераз басып торды да китте.

Иртә белән Гыйльфанов Евдокимычка бәйләнде: янәсе, сез карт кеше, ә үзегездә тамчы да выдержка юк. Төнлә тагын тәмәке тарттыгыз. Беренчедән, үзегезгә зарар, икенчедән, инде үзегезне уйламасагыз, бүтәннәрне кызгана белергә кирәк. Палатаны төтен белән тутырдыгыз.

Евдокимыч җавап кайтармый гына коридорга чыгып китте.

Сәгать уннарда, матур муенына фонендоскобын аскан килеш, палатага Клавдия Николаевна килеп керде. Евдокимычның буш караватына күз салды да:

— Гадәттәгечә йөгерүдә,— дип узып китте.

Врачны иртәдән бирле көтеп торган Вайнберг кулларын сүзсез генә һавага күтәреп селкеп куйды. Клавдия Николаевна сөенеченнән көлеп үк җибәрде:

— Әллә бәйләтми йокладыгызмы? Молодец! Сезгә торып утырырга вакыт инде. Ятып торулар заманы узды.

Клавдия Николаевна аргы почмакта яткан Солтанов белән кеше ишетмәслек итеп әкрен генә, җитди итеп сөйләшеп утырды. Шул көннән башлап Солтановны сестралар, нянялар операциягә хәзерли башладылар. Аны процедурный бүлмәгә няня чакырып алган арада, бүлмәдәшләре гел аның турында сөйләшәләр иде. Бүген дә Солтанов тапочкаларын шап-шоп өстерәп бүлмәдән әкрен генә чыгып китүгә, Гыйльфанов ишеккә таба ымлады да:

— Чырае бөтенләй юк, бик ябык, яман шештер аңарда,— дип, үзенең шик-шөбһәсен белдерде.— Ярып гомерен генә кыскарталар. Болай әле бераз яшәр иде.

Евдокимыч аның шулай яманга юравын бер дә яратмады.

— Карагыз аны, үзе алдында ычкындыра күрмәгез,— дип кисәтеп куйды.

Вайнберг, күңеленә охшамаган нәрсә булса, ачулы керпе кебек пырш-пырш килә иде. Бу юлы да ул, пырш-пырш итеп, бер сүз дәшми ятты-ятты да кинәт Гыйльфановка:

— Беренчедән, сез магнезиумыгызны эчтегезме әле? — диде.

Иртәгә операция дигән төнне Солтанов бөтенләй йоклый алмады. Юк, операциядән куркып түгел, күңеленнән ул хәтта үлемгә дә әзер, әлбәттә, үләсе бер дә килми. Вайнберг әнә рәхәтләнеп йоклый, Гыйльфанов та күптән эреп китте. Тик Евдокимычның гына коридордан кайтып кергәне юк — йөткереп уятырмын дип куркып йөри булса кирәк.

Менә әкрен генә палата ишеге ачылды. Ярым якты коридордагы пальма гөленең җилпәзәдәй яфраклары күренде. Ишектән Евдокимыч күләгә кебек кенә килеп керде дә караңгыда тизрәк үз караватына сенде. «Ул да бит аягын кистерү алдында тора,— дип уйлап куйды Солтанов.— Аңа да бик авырдыр. Берәр җылы сүз әйтәсе иде үзенә...»

— Евдокимыч,— диде ул әкрен генә,— кайларда йөреп кердегез?

— Әле сез дә уяумыни? Йокы даруы эчтегезме соң?

— Икене берьюлы.

Николай Евдокимыч, аяк очларына гына баса-баса, аның караваты янына килде. Алар шыпырт кына сөйләшеп утыра башладылар. Күпме шулай утырганнардыр, сестра килеп керде дә ятарга кушты. Солтанов йокы алмый дип зарлангач, сестра аңа укол кадарга булды.

Иртәгесен сәгать унберләрдә Солтановны операциягә алып кереп киттеләр. Бүлмәдәшләре озатып: «Хәерле сәгатьтә!» дип, артыннан кычкырып калдылар. Вайнберг, ике кулын бер юлы күтәреп, һавада йодрыкларын йомарлады: янәсе, кулыңны кысам! Евдокимыч Солтановны операционныйга хәтле озата китте. Күпмедер вакыт югалып торгач, ашыгып палатага кайтып керде дә: «Профессор үзе ясый!» дип хәбәр итте. Аннары шундук тагын коридорга чыгып йөгерде. Бу юлы ул бик озак керми торды. Вайнберг беләгендәге сәгатенә һаман саен карап ала иде.

Сөлгесен тотып, Гыйльфанов душтан кайтып керде. Вайнберг аңардан:

— Ничек? Бетмиме әле? — дип сорады.

— Нәрсә бетмиме?

— Операция.

— Ә, анда Николай Евдокимыч сакта тора бит. Беткәч, ул кайтып докладывать итәргә тиеш.— Кулына китап алып, караватына сузылды.

— Озакладыңы,— дип куйды Вайнберг.

Тумбочка өстендә Солтановның приемнигы белән сәгате хуҗасын көтәләр. Вайнбергка алар ничектер ятим кебек, кызганыч кебек тоела иде.

— Озакладыңы,— дип кабатлады ул.

Гыйльфанов та сәгатенә карап алды. «Сестра нишләптер магнезиум кертми». Сестра янына барырга дип, ул палатадан чыгып китте.

— Бетте,— дип, Николай Евдокимыч сулуы кабып кайтып керде.— Операциядән соң бүтән палатага салдылар.— Шулай диде дә, Солтановның сәгатен, приемнигын, китапларын алып, тагын чыгып китте.

Магнезиум тотып, Гыйльфанов кайтып керде.

— Йөгерә дә йөгерә,— диде ул Евдокимыч турында.— Ул саклап торды дип Солтановның хәле яхшырамы?

— Йөреп калсын,— диде Вайнберг.

— Кисәләрмени?

— Рәхәтләнеп йөгереп калсын,— дип кабатлады Вайнберг.

Берничә көннән обход вакытында профессор керде. Аның артыннан язуларын тоткан Клавдия Николаевна күренде. Профессор калын, юан кеше иде. Аяклары белән китереп басканда, идән такталары сыгылып китәр кебек тоела иде.

Профессор башлап Вайнберг янына туктады. Ул караган, тыңлаган арада, Вайнберг күзләрен профессордан бер дә алмады.

— Утыра башладыкмы әле? — дип сорады профессор.

Авыру урынына Клавдия Николаевна елмаеп җавап бирде.

— Юк әле. Кул-аягын бәйләтми инде.

— Йөгереп йөрергә ярый хәзер. Бүген үк утырта башлагыз,— диде ул Клавдия Николаевнага.

Профессорның сөйләшү манерын Клавдия Николаевна яхшы белә. Сукыр эчәген кистергән бер авыру йоклаган чагында ничектер караватыннан егылып төшкән иде. Иртән үзен профессорга күрсәттеләр. Профессор моның ярасын карады, сорашты:

— Кайсы якка егылып төштегез?

Авыру, кайсы якка егылуның әһәмияте бар икән дип уйлап, караватының уң ягын күрсәтте. Профессор һич елмаймыйча:

— Иртәгә сул якка егылыгыз,— диде.

Гыйльфанов янына җиткәч, авыруның хәлен врач кыскача гына сөйләп бирде. Профессор, егетнең күлмәген күтәреп, эченә йодрыгы белән төртеп-төртеп карады. «Авыртамы? — дип сорады. Җавап алгач, врачка нидер әйтеп яздырды.

— Профессор,— диде Гыйльфанов, китә башлаган профессорны туктатып.— Әйтергә мөмкинме? Миндә язва бар. Эпштейн клиникасында ятканда...

Профессор белән Клавдия Николаевна бер-беренә карашып елмаештылар.

— Сезгә нәрсә, язва кирәкмени? Кирәксә, язва бар дип исәпләгез.

Юан аяклары белән чайкала-чайкала атлап, ул Николай Евдокимыч янына барып туктады.

— Сезне бик йөгерә дип әйтәләр? Больница тәртипләренә буйсынмасагыз, без чыгарып җибәрергә дә күп алмабыз.— Аннары кинәт елмайды. Нурлы күзләре җыерчык эченә күмелде.— Ягез әле...

Евдокимыч, пижама балакларын җыерып, күгелҗем аякларын профессор алдына сузды. «Кисәргә!» дип әйтәсен алдан ук белгәнгә, эчтән калтыранып китә башлады.

Профессор Евдокимычның аягын төрле җирдән тотып-тотып карады.

— Да-а...— дип сузды. Клавдия Николаевнага борылып, Евдокимыч аңламый торган телдә нидер әйтте. Евдокимыч, салкын тиргә батып, «кисәргә» сүзен көтә башлады.

— Менә нәрсә,— диде профессор,— сезне кислород белән дәваларга булдык. Минем практикамда шактый кеше кислородтан аякка басты. Менә шулай,— диде ул Клавдия Николаевнага.— Кислород!

Николай Евдокимычның аягына орынып алып, урыныннан торды. Ишеккә барып җиткәч, артына әйләнеп, Вайнбергка:

— Утырырга, утырырга! — дип, учында туп сикерткән шикелле, кулын сикертеп-сикертеп куйды. Аннары яны белән борылып ишектән чыгып китте.

Хатыны белән бүген инде Вайнберг утырып сөйләште.

Евдокимычка беренче тапкыр кислород кададылар. Ул палата ишегеннән, авызын җыя алмыйча, елмая-елмая кайтып керде дә:

— Баскычтан менгәндә аягым тамчы да армады,— дип мактанырга тотынды. Борылды да тагын коридорга чыгып китте. Ул, бүтән палаталарга кереп, андагы танышларына да баскычтан менгәндә аягым армады дип сөйләп чыкты. Хатыны килгәч, аңа да сөйләде. Хатыны газеталар, журналлар китергән иде, аларны өләшергә йөгерде.

*Апрель, 1966.*

# БЕРЕНЧЕ СЫНАЛУ



Комсомолга кергәч, безне бандитлар тотарга алып киттеләр. Ул елларда урманнарда әле бандитлар бетеп җитмәгән иде. Алар крестьяннарның терлекләрен тотып суя, кырдагы бәрәнгеләрен казый, урманга барган хатын-кызларны куркытып кайтара иделәр. Бер тапкыр хәтта өяз каласындагы пекарняның пешкән икмәген талап киттеләр.

Безнең иңбашларыбызда винтовка, кесәләрдә бишәр патрон — шәһәрдән чыктык та урманга таба юл тоттык.

Мин унбиш яшьлек чандыр гына бер малай. Иңбашымны салмак винтовка шактый гына басса да, сер бирмим: ышанып кулыма корал тоттыруларына сөенеп, кыю-кыю атлап барам...

Минем иптәшем (комсомолга икебез бер кичне кердек) унҗиделәрдә... Исеме Салих. Ул эре сөякле, буйга озын, җилкәләре киң, беләкләре нык, мускуллары уйнап тора. Берни булса, беләк мускуллары белән мактанырга ярата. Комклубта спектакль куйган чакта аңа эшчеләр ролен бирәләр. Гадәттә бу роль сүзсез була: Салих, җиңнәрен сызганып, мускулларын уйнатып, сәхнәне арлы-бирле үзгалап йөри.

Безне алып баручыларның берсен мин бөтенләй белмим. Киеменә караганда, ул чекадан булырга тиеш: өстендә күн тужурка, күн чалбар, аягында күн итек, башында күн фуражка — барысы да кап-кара! Тик шактый таушалган. Йөзе кырыс, авыз урынына — бер сызык, иреннәре юк. Икенчесен беләм. Ул комсомолның өяз комитетында кемдер булып эшли. Фамилиясе Тилгәнев. Нигә Тилгәнев? Рус егетләре арасында Коршуновлар булса да, татарда мин Тилгәнев дигән фамилияне беренче ишетәм һәм аңарда тилгәнгә охшашлы сыйфатлар эзлим. Ләкин ул тилгәнгә бер дә охшамаган. Чәчләре житен төсле сап-сары, күзләре зәп-зәңгәр, үзе дә гел елмаеп сөйләшә. Тилгәнев тә заманча киенгән:

өстендә күк пинжәк. Пинжәгенең тункайган кесәсендә наган. Күн итек өстеннән яңа резин калош киеп йөри, мине гаҗәпләндергәне шул. Минем ул вакыттагы карашымча, бу кирәкмәс артык зиннәт, чөнки итек үзе бит пычрак өчен киелә. Мин Тилгәневнең ялт итеп торган матур калошларын кызганам. Бу бит инде берьюлы ике аяк киемен туздыру була, дип уйлыйм. Минә минем бер генә пар ботинкам бар, ул да инде тузып бара, тишекләренә кәгазь тыкмасаң, урамга киеп чыгарлык түгел. Муенында ак ефәк шарф. Каралган якасын шул шарфы белән каплап йөри идеме икән ул, чөнки җәй көне шарфның бүтән кирәге юк.

Кара киемле кеше миңа бик усал кебек тоела: яшел күзләре чанчелеп карый, күзгә-күз очрашсаң, сискәнеп китәрсең... Ул һичбер сүз әйтмичә безнең сул ягыбыздан кырт-кырт атлап бара. Ә без, ике сары авызлы комсомол, Тилгәневкә сыеныбрак атлыйбыз, чөнки ул якты чырайлы. Көлгәндә матур тешләре ялтырап күренеп кала.

Без бары дүрт кеше, бандитлар тота алырбызмы? Алар күбәүдер бит инде. Аннары бандит халкы урманны да яхшы беләдер. Тотыласы урында үзебезне тотып калмаслармы? Алар кулына эләккән комсомолга котылу юк бит инде.

Салихка күз салгалыйм: ул да, ахрысы, мин уйлаганны ук уйлап барадыр. Кашлары җыерылган. Чырае болытлы. Сирәк-мирәк минем якка карап авызын кыйшайта. Бу инде аның елмаерга тырышуы.

Тилгәневкә карыйм, аның йөзе якты, ул, күрәсең, бер дә борчылмый. Яңгырдан соң җыелып калган суларга яңа калошлары белән баса-баса ашыкмый гына атлый.

Шәһәр йортлары өелешеп артта калды. Урман якынайганнан-якыная. Урман якыная барган саен бандитлар тоту сәгате дә якыная...

Тилгәнев безгә аңлата башлады:

— Бандитлар землянкасына барып җиткәч, берегез ишекне дөбердәтер. Менә син дөбердәтерсең,— дип, миңа таба күрсәтте.

«Салихка ник дөбердәтергә ярамый? — дип уйлап куям мин. Ул көчлерәк. Аның беләк мускуллары әнә нинди... Шулай дип уйласам да, «ярар, дөбердәтермен», дип, башымны селкım.

Тилгәнев аңлатуын дәвам итә. Без барасы землянкада дүртмебишме бандит яши икән. Көндез барысының да өйдә утыруы икеле, күп булса берсе өйдә булыр...

— Калганнары кәсептә йөриләрдер. Өйдәгесен тавышсыз-тынсыз гына каптырырга кирәк,— диде Тилгәнев.

Атып тавыш чыгарсаң, бүтәннәренең куркып кайтмый йөрүләре бар, имеш. Бөтенләй икенче җиргә күчеп китүләре дә ихтимал икән.

— Тотылганын бәйләп авызына чүпрәк тутырырбыз да тегеләрнең кайтканын көтәрбез,— диде Тилгәнев. Очлы карашлыга таба әйләнеп:

— Шулай бит? — дип, үз фикерен тегеңәрдән раслатты.

Салих кесәләрен капшый башлады:

— Миндә чүпрәк тә юк әле...

Мин тагын уйлыйм: әгәр дә барысы да өйдә булса? Ләкин үземнең шигемне кычкырып әйтмим, курка дип уйлаулары бар. «Анда баргач күз күрер», дип шигемне басам да Тилгәнев янында салмак кына атлый бирәм.

Урманга килеп кергәннән соң Салих белән без винтовкаларыбызны салып, кулга тотабыз. Тегеләр үзләренең кесәләрендәге наганнарын чыгаралар.

Бу урманда минем күп тапкыр булганым бар иде. Гадәттә берни уйламыйча рәхәт кереп китә торган идем. Бу юлы урман миңа ничектер бик серле, бик куркыныч булып тоелды. Һәр агач артында бандит посып, сагалап торадыр кебек иде.

Мин як-ягыма каранып, агачтан агачка күчә-күчә генә барам. Бүтәннәр дә шулай итә,

Кошларның сайравы бөтенләй күңелгә йокмый: фикер башкада булганга, колак урман моңын бөтенләй ишетми. Ә менә аяк астында кипкән агач шартлавын, бәрелгәндә куакларның кыштырдавын аерым-ачык ишетәм.

Эчкәрәк кергән саен урман караңгылана, дымлана барды. Ерак түгел бу тирәдә чишмә барлыгы искә төште. Җиләккә йөргәндә без, ятып, ул чишмәнең салкын суын эчә идек. Уйлап карасаң, әле кайчан гына бу урманда мин җиләк җыеп йөргән, ә бүген бандит тотарга барам. Бер бик юан, бик карт имәнгә җитәрәк Тилгәнев безне ым белән туктатты. Ни әйтә икән дип, күзләренә карап тора башладык. Салих белән миңа алгарак чыгып барырга кирәк икән. Алар үзләре икәү берничә адым арттарак барачаклар. Нигә без алданрак, нигә сез арттарак дип сорап тормадык. Винтовкаларыбызны атарга хәзер килеш тотып, Салих белән алгарак чыктык та, арттан баручыларга борылып карамаска тырышып, сагаеп кына атлап киттек.

Агач араларында шикле нәрсә күрдек исә, туктап, тыңлап торабыз. Шикле нәрсә дигәнебез яшен суккан, кара көйгән, яисә тау хәтле өелгән кырмыска оясы булып чыга да, без, иркен сулап җибәреп, тагын әкрен генә кузгалабыз.

Землянкага ерак калмады дип, Тилгәнев безгә ым какты. Тагын да сагаебрак бара башладык. Менә бервакыт шарт-шорт аткан тавышка сискәнеп китеп, артка әйләнеп карасак (тавыш арттан килә иде), аптырап калдык: юл буе бер сүз дәшми килгән теге борау күзле егет Тилгәневкә наганнан ата. Тилгәнев, агачларга ышыклана-ышыклана, кара киенгәненә тезеп-тезеп җибәрә, ә үзе кача, йөгерә иде.

Без, берни аңламыйча, атаргамы-юкмы, атарга булса кемгә атарга икәнен һич белмичә, таңга калып, тик басып торабыз.

Тилгәнев, ата-ата, каеннар арасына кереп күздән югалды. Кара кигән егет: «Гад!» «Трус!» дип сүгенә-сүгенә, наган барабанына кесәсеннән яңа патроннар тутыра башлады. Аның куллары калтырый, күзе-башы акайган иде.

Аннары ул безнең янга йөгереп килде. Егетнең сулышы тыгылган, тавышы өзелә иде. Йөгереп килеп җитте дә безгә ташланды:

— Ник атмадыгыз? Ник авызыгызны ачып карап тордыгыз?

Без нәрсә дип җавап бирергә дә белмибез, чөнки ни булганны аңлап житкермибез, югалып калганбыз...

Бу килде дә:

— Бирегез миңа винтовкаларыгызны! — дип акырды.

Мин дә, Салих та ЧОН отрядларында йөргән кешеләр. Винтовканы бирергә ярамаганны беләбез. Бирми торабыз. Ул өремәләнеп, кулларыбыздан винтовкаларны тартып-тартып алды, чигенеп агачка сөяп куйды. Без каршылык күрсәтә алмый калдык. Шуннан соң безнең куркынган күзләребезгә бер акаеп карады да кесәсеннән наганын тартып чыгарды.

— Гадлар! Комсомоллар! Хәзер җаннарыгызны алам! Басыгыз агач янына, ну! — дип кычкырды. Безнең аптырап, нишләргә белми торганыбызны күреп, тагы:

— Кемгә әйтәләр, ну! — диде.

Без аңлый башладык шикелле. Башлап Салих аңына килеп өлгерде.

— Син үзең гад! — дип акырды һәм, сөялгән винтовкасын алмакчы булып, агачка таба ыргылды. Теге шундук наганын күтәреп:

— Кузгаласы булма, атам! — дип җикерде, Салихны ташланган җиреннән туктатырга мәҗбүр итте.

Мин, агачка аркам белән сөялеп, дөресрәге, юан юкә агачына бөтен тәнем белән сыланып, катып калдым. Башымнан әллә нинди уйлар үтеп китте. Бу үзе бандитлар белән бер шайкадан икән! Шулай да атар дип, үтерер дип уйлыйсы килми, әле кайчан гына безнең яныбыздан тыныч кына атлап барган кеше бит. Тик җанны өшеткеч кеше... Тилгә-

нез бер дә башымнан чыкмый. Ни өчен ул безне ташлап качты? Ә бу кеше үзе кем?

— Гадлар! — дип, (бу аның яраткан сүзе иде бугай) безнең алдыбызда наганын селкеп басып тора.— Гадлар! Комсомоллар! Мин менә сезгә күрсәтим әле социализмны! Ягез, әниләрегезне исегезгә төшерегез, елашыгыз!

Мин үзем нинди кыяфәттә булганмын, белмим. Салихның чырае коточкыч иде. Күзләре иләс-миләс. Үзе һаман винтовкасына ташланмакчы була. Минем колагым чыңлый, башымда әллә ничә төрле уй...

Бу кеше очлы күзләре белән безне бораулый, үзе:

— Чыгарыгыз комсомол билетларыгызны! — дип кычкырды.

Без хәрәкәтсез басып торабыз. Мин сөялгән юка агачы кинәт калтырый башлады. Аңлыйм, агач түгел, мин калтырыйм!

— Ну, биш минут сезгә!

Ничә көн генә элек без Салих белән комсомолга кергәндә тап төшермәскә тантаналы сүз биргән идек, ә бүген билетларыбызны чыгарып бирсәк? Юк, үлсәк үләбез, бирмибез,— минем ул вакыттагы уйларым шушындыйрак иде. Икебез дә билетны бирүдән баш тарттык.

— Үтер, гад, бирмибез! — күкрәкләребезне киереп бастык (укыганым бар иде, комсомоллар дошман каршында шулай басып торалар), ә минем тез буыннары дер-дер итә иде...

Салих акрын гына тегенең янына китте, куллары кесәсендә. Барып житте. Мангае белән сөзеп карап тора. Кара киргән буш кулын билетка дип сузды. Һәм кинәт Салих сулагайлап тегене бәтереп салды, өстенә ауды. Мин дә йөгереп килеп життем.

Шул вакыт сул яктан, яшел каен агачлары арасыннан:

— Борис, Борис, житте, житте егетләр! — дигән тыныч кына тавыш ишетелде. Ул да булмады, елмая-елмая, агачлар артыннан Тилгәнев килеп чыкты.

— Егетләр, туктагыз. Торгызыгыз,— диде. Мин, аңыма килә алмыйча, басып карап торам. Салих кара киемле өстендә, ул да башын калкытты, әмма тегенең ике кулын беләктән жиргә кыскан иде. «Борис, житте!» дигән сүздән соң кара киргән дә елмаеп жибәрде.

Шул вакыт Салих сикереп торды да атылып барып, винтовкасына ябышты! Чатыр-чотыр китереп, затворын ачып япты һәм атарга дип иңбашыма терәде.

— Сез безне мыскыл итмәкче...

Борис тә, сикереп торып, наганын кесәсенә тыга-тыга, Салихны килеп тотты һәм Тилгәнев белән бергә кулыннан винтовкасын тартып алдылар.

Мин дә, йөгереп барып, винтовкамны алган идем инде, чалт-чолт китереп, корып өлгергән идем.

— Егетләр, егетләр,— диде Тилгәнев.— Бетте! Сынау бетте. Сез молодцы! Өркеп калмадыгыз. Сынауны яхшы үттегез. Молодцы! Настоящий комсомоллар!

Без дә акрынлап суындык. Елмаеша башладык. Салихның битенә төс керде. Минем дә йөрәк тынычрак тибә башлады, тез буыннары ныгыды. Өркеп калмадыгыз, имеш. Кая инде өрекмәгән. Әле дә авыз кибүләрем бетми, телемдә ниндидер тимер тәме...

— Кайтабыз,— диде Тилгәнев.

Кайтыр юлга чыктык. Чишмә буена төштек.

— Утырып бераз хәл алыйк,— диде кара киргән.

Менә без урмандагы чишмә буенда кырын ятып торабыз. Агач башлары арасында зәңгәр күк йөзе эскәтер хәтле генә... Мүкләнеп, яшелләнеп беткән тар улактан баш бармак юанлыгы су ага. Без аны учыбызга жыеп эчтек, битләребезне дә чылаттык, хәзер кырын ятабыз.

Бака яфракларын кыймылдатып, су әкрен генә челтери... Кыргый умарта кортлары су өстендә кайнашалар...

Мин дә, иптәшем дә үпкәбезне әйтәбез. Шушы да булдымы инде сынау? Бу бит уен, аннары күңелсез уен... Сезнең кебек олы, җитди кешеләргә бөтенләй килешми, дибез. Үзегезне шундый хурлыклы хәлгә куйсалар, нишләр идегез?

Тилгәнев елмая-елмая үлән сабагы чәйни... Кара кигәннең күзләрендә чәнечкеләр беткән, карашы ягымлы... Авыз читләрендә хәтта елмаю талпынып-талпынып куя.

— Хурлыклы? — дип элеп ала ул безнең сүзебезне.— Нишләр идекме? Мин үзем шундый хәлдә булмаган дип беләсезме?

Һәм ул, аягын чишмәгә таба сузып, сөйләргә кереште... Күз карашларында тагын баягы чәнечкеле энәләр ялтырап-ялтырап киткәли башлады...

— Чехлар явына каршы сугышканда...— дип тотынды ул.

Малай гына әле ул. Нибары уналты яшендә... Бер көнне разведка начальнигы, яман да усал, яман да тәвәккәл кеше, моны үз янына чакырта...

— Син бу якларны беләсең икән?

— Беләм,— ди бу.

— Ә син безне сатмассыңмы?

Бу гарьлегеннән начальник өстенә җикерә:

— Кара аны, син үзең сатма! — чөнки ул яхшы белә, разведка начальнигы башкисәрләрчә усал, кыю сөйләшкәнне ярата...

— Ә менә миңа мәгълүм, син инде безне саткан, син хыянәтче, мин сине чокырга алып төшәм дә атам!

Бу ни дә булса әйтеп өлгергәнче, начальник наганын кабурасыннан тартып чыгара да:

— Марш! — дип наган көпшәсе белән моның җилкәсенә төртә.— Тизрәк кыймылда! Күп сөйләшеп торырга минем вакытым юк...

Егетнең аяклары камырга әйләнә... Урыныннан куба алмыйча тора.

— Кемгә әйтәләр?

Чокыр буенда, ниһаять, аңлашалар.

— Молодец! — ди начальник,— өркеп калмадың. Сине разведкага җибәрергә була...

Аны чехлар тылына җибәрәләр. Караңгы төндә, юлга чыгып китәр алдыннан, начальник егетнең кулын кыса да әкрен генә әйтә:

— Булдырып кайтсаң, рәхмәт алырсың. Буяп кайтсаң, я анда калсаң, бел аны: авылдагы әти-әниләреңне тотып үз кулым белән атармын! Бар, хәерле юл! — Егетне кысып кочаклый да, кочагыннан чыгарып, аркасына төртеп җибәрә...

Шушыны ишеткәннән соң, без инде сүзне артык озайта алмадык. Шулай да минем иптәшем:

— Ул бит сугыш вакытында булган, ә хәзер...— дип каршы килергә маташып караган иде дә, кара кигән тагын күзләре белән бораулый башлады:

— Хәзер дә сугыш бара...— диде ул һәм сикереп торып басты... Басуы булды, гөрселдәтеп атып җибәргән тавыш урман эчен айкап узды. Ул җиргә сыгылып килде дә төште.

Барыбыз да сикерешеп тордык.

— Окружить! — дип, Тилгәнев безгә команда бирде. Без икәү, Тилгәнев үзе дә яшел куаклар арасына ташландык...

Чыбыклардан носилка ясап, кара кигәнне шул носилкаларга салдык та шәһәргә алып кайтып киттек.

Өч көннән соң без тагын бардык, ике бандитны эләктердек, землянка нигезендә кояшта кызынып утырган чакларына туры килдек. Өченчесе ычкынды, җитмәсә, Салихны яралап китте.

Ул заманнан бирле инде кырык елдан артык вакыт узган, ә мин үземнең бандит ауларга йөрүемне һаман оныта алмыйм. Сүздән сүз чыгып, комсомолга кергән чакларымны сөйли башласам, иптәшләрем миңа әйтәләр, син моны хикәя итеп яз, диләр. Аларның киңәшен тотып, мин менә язып карадым. Хикәяме бу, истәлекме, әйтә алмыйм. Хәер, анысының әллә ни әһәмияте дә юк.

* * *

Тилгәнев Ватан сугышыннан исән кайтты. (Тилгәнев аның үз фамилиясе түгел, комсомолда ул вакыт исем алмашу чире бар иде.) Ул «Катюша»да сугышкан икән. Аягына хәзер картларча җылыката гына өстери. Урамнан барганда яшьләр аны кагып-кагып узалар — нинди-дер җылы каталы ямьсез картка берәү дә игътибар итми. Трамвайда да, яшьләр утырып барганда, ул басып бара. Ә Борис күптән инде кара җир куенында — Сталинград янындагы каты сугышларда полковник Борис Петрович Беляков туган ил өчен башын салды.

Менә шундый хәлләр.

*Апрель, 1966, Казан.*



## *Публицистика*

# СОВЕТ ЯЗУЧЫСЫНЫҢ БАЙРАГЫ[1]

Иптәшләр! Без иптәш Табеев докладыннан республикабызның культура өлкәсендә дә яңа җиңүләре барлыгын зур канәгатьләнү белән белдек. Олы юбилей көннәрендә, культура работниклары үз эшләренә йомгак ясаган чакта, без театрларыбызның, композиторларыбызның, рәссамнарыбызның һәм әдәбиятчыларыбызның зур уңышларга ирешүен билгеләп узган идек инде, шуңлыктан аларны яңабаштан кабатлап торуның кирәге булмас дип уйлыйм.

Тик бер нәрсәне әйтеп китим, композитор Җиһановка 1970 елны СССР Дәүләт премиясе бирелүне, шагыйрь Сибгать Хәкимгә Максим Горький исемендәге РСФСР дәүләт премиясе бирелүне без партиябез һәм хөкүмәтебезнең милли культураларны үстерүдәге яңа бер кайгыртуы, безнең әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләребезнең хезмәтенә югары бәя бирүе дип карыйбыз.

Мин язучы, шуңа күрә республикабыздагы әдәби хәрәкәткә киңрәк тукталырга уйлыйм.

Язучы эшендә һава шартлары роль уйнамый. Яңгыр да, кар да, бозлавыклар да безгә комачау була алмый. Ләкин безнең дә үз кыенлыкларыбыз бар.

Без еллар буе авыл турында язып килдек. Язучыларыбыз авыл кешесенең хезмәтен, ял итүен, моң-зарын, җырын, көндәлек мәшәкатьләрен яхшы беләләр иде, кайчандыр индустриаль хезмәт татар халкы

---

[1] Партия өлкә комитетының XXXIV конференциясендә сөйләргә әзерләнгән речь. Русча язылган. Г. Ахунов тәрҗемәсендә бирелә. *Ред.*

тормышында әйдәп баручы булмаган кебек, эшче образы да безнең әдәбиятта зур урын алып тормый иде.

Заманалар үзгәрде. Эшче сыйныфының материаль байлык тудырудагы өлеше көннән-көн арта. Хәзер безнең язучыларга индустриаль хезмәт кешеләрен язарга, хезмәтнең поэтик ягын ачып бирергә кирәк.

Узган елның февралендә Кама автозаводын төзүгә багышланган республика активы җыелышында иптәш Табеев партия активы исеменнән язучыларны, художникларны, композиторларны «җитмешенче елларның индустриализация дәвере кешеләрен җырларга» чакырды.

Без бу чакыруны истә тотабыз һәм язучыларны төп геройлары эшчеләр, инженерлар, төзүчеләр һ. б. булган китаплар язарга юнәлтәбез. Эшчеләр сыйныфы турында элеккерәк елларда язылган роман һәм повестьларга Эдуард Касыймовның химиклар турындагы романы (хәзер ул аның икенче китабын яза), Гариф Ахуновның нефтьчеләр турындагы «Хуҗалар» романы өстәлде. Сөббух Рафиков Зәй ГРЭСын салучылар хакында роман язды, әсәр «Казан утлары» журналында басыла башлады. Әхсән Баян Кама ГЭСын төзүчеләр турында повесть тәмамлады, ул хәзер әсәрен камилләштерә. Геннадий Паушкин Чаллы шәһәрен салучылар хакында «Кама өстендә йолдызлар» исемле документаль повесть төгәлләп, нәшриятка тапшырды. Аяз Гыйләҗев нефтьчеләр хакында яңа роман язу өчен материал туплый.

Эшчеләр турында югары идеяле, чын мәгънәсендә сәнгатьчә язылган китап тудыру өчен эшчеләр тормышын яхшы белергә, соңгы елларда эшчеләр сыйныфында нинди психологик, әхлакый үзгәрешләр барганны җентекләп өйрәнергә кирәк. Эшчеләр белән янәшә яшәмәсәң, бергә эшләмәсәң — моны белүе кыен. Язучылар кыюсыз гына булса да эшчеләр коллективларына юл алдылар. Кама автозаводына, Түбән Камага килделәр, әнә шул процесс гел кубәячәк. Язучылар анда эшчеләр сыйныфының алдынгы вәкилләрен күрәчәкләр, яшьләр белән танышачаклар, хезмәт романтикасын тоеп, характерлар чыныкканны, яңа кеше туганны үз күзләре белән күреп кайтачаклар.

Без хезмәт турында, дөресрәге, хезмәт кешесе турында сөйлибез икән, бу әле кешене гел эш эшләп кенә тора торган итеп бирү дигән сүз түгел. Әлбәттә, геройны материаль байлыклар тудыручы итеп бирү зарури, ләкин шуның белән бергә аны яңа революцион әхлак, яңа психология иясе итеп тә бирергә кирәк. Бүгенге заманның эшче образын тудыру — совет кешесенең иң яхшы әхлакый сыйфатларын раслаучы характер тудыру дигән сүз. Бу образ — актив, ул бөек коммунистик төзелештә аңлы рәвештә катнашучы, социалистик ватанның патриоты. Андый характерны тудыру өчен язучының иҗади кыюлыгы, яңаны тоюы, талантын тулысынча эшкә җигүе таләп ителә.

Тормышта мавыктыргыч сюжет, кызыклы вакыйга, катлаулы язмышлар гел очрап тора, боларны язып чыгып, укучыны мавыктырырга була, билгеле. Шул схема белән язылган китаплар бездә бар, аларны укыйлар да. Ләкин таләпчән язучы алар белән генә туктап калмый, үзенә ул зуррак бурыч куя, ул кешене аның иң яхшы кешелек сыйфатлары — интеллектуаль, әхлакый, эмоциональ сыйфатлары ачылган чакта сурәтләп бирергә тырыша. Кеше үзендә булган кимчелекләрне, йомшак якларны җиңеп, үзеннән-үзе булдыра алганнан югарырак күтәрелә, шуның белән ул геройга, әгәр беләсегез килсә, «илаһи бер затка» әйләнә, ягъни аңарда гади кешеләр ирешә алмастай сыйфатлар барлыкка килә. Безнең өчен җирдән аерылган герой кызык түгел, әдәбият абстракцияләр белән эш итми, безнең героебыз кайгыра да, шатлана да белә, җиңә дә, җиңелү ачысын да татый, әмма теләсә нинди шартларда да ул кеше булып кала, кирәк икән, ул үзеннән югары, илаһи булырдай зарурилыкны саклый.

Әдәби геройның иң югары әхлакый-интеллектуаль киеренкелектә сурәтләү Ленин эстетикасыннан килеп чыга, ягъни художник тормышның күчерми, аны үзгәртә, икенче төрле әйткәндә, художество принципларыннан чыгып тормышны яңабаштан кора, объектив дөньяны субъектив оешкан дөньяга әйләндерә.

Язучының сәнгатьчә такты һәм тормышны тирәнтен белүе, аңар безнең тормышны бозмыйча, гомумиләштерелгән өр-яңа дөнья корырга мөмкинлек бирә, вакыйгалар ул дөньяда шундый итеп тыгызланалар, бу хәл безгә тормышны калку итеп, кешеләрне хәзергә булган хәлендә генә түгел, булырга тиешле хәлендә күрергә ярдәм итә. Кеше үзенең рухи ныклыгын бер төбәккә туплый, көндәлек тормышында ул үзендә андый ныклык булуын башына да китермәгән була. Әгәр шул позициядән килеп карасак, безнең кайбер әсәрләребез җирдән үрмәләп баручы, көнкүрешкә «баткан» булып тоелалар. Җирдән үрмәләп баручы китаптан нинди тәрбия күтәргә була? Дөньяга чыккан һәрбер китап безне шатландыра, ләкин һәр китап та канәгатьләндерми. Кайбер китапларда образлар сай, зур әһәмияткә дә ия түгел, андый китаптан нәрсәгә генә өйрәнәсең?

Ул яктан караганда өлкән буын каләм осталары тормышка житди карау, образны тирән һәм кызыклы итеп язу, кемне ярату, кемне ярата алмауларын ачык итеп әйтә белүләре белән аерылып торалар. Фатих Хөсни, Афзал Шамов, Гомәр Бәширов, Габдрахман Әпсәләмов, Әмирхан Еники, Мирсәй Әмир, Сибгат Хәким, Гариф Гобәй әсәрләрендәге образлар шундый, яшьрәк әдипләрдән образны тирән итеп язу ягыннан Илдар Юзеев поэмалары аерылып тора. Соңгы вакытта Барлас Камалов «Күршеләр» исемле әйбәт повесть бастырып чыгарды, бу әсәрдә образларның оста тасвирлануы күзгә ташланып тора.

Илебезнең тулы канлы, бай тормыш белән яшәүче совет кешеләренә тормышка битараф һәм салкын карау, көнкүреш вак-төякләренә күмелү, җирдән үрмәләп бару чит бер нәрсә. Совет кешеләре, киресенчә, дөньяга карашларның киңлеге, яңаны тою һәм тормышка актив мөнәсәбәттә булулары белән аерылып тордылар һәм торалар. Язучылар аларны нәкъ әнә шундый киң карашлы итеп, ярлыландырмыйча, рухи зәгыйфьләндермичә гәүдәләндерергә тиешләр.

Безнең китапларыбыз яшьләрне чит идеология белән килешмәүчән рухта, революцион традицияләребезне саклау рухында тәрбияләргә, шуңа күрә югары художестволы булырга тиешләр. Заманыбызның уңай героен тудыру бик мөһим, чөнки безгә коммунистик җәмгыять төзүдә үрнәк алырдай, өйрәнердәй геройлар кирәк.

Кеше җанын аулау, кем-кемне җиңә мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән куелган дәвердә язучылар әдәбият һәм сәнгатьнең роле чиксез артканын, безгә гаять зур җаваплылык йөкләнгәнен аңлыйлар. Кем сәнгате көчлерәк, кем сәнгате миллионнар акылына һәм күңеленә күбрәк йогынты ясый ала, шул җиңеп чыга. Без үзебезнең көчебезгә һәм җиңеп чыгачагыбызга ышанабыз. Чөнки безнең идеология революционлыгы, иреклe булуы, интернациональлыгы, гуманлыгы белән көчле, безнең сәнгать нәкъ әнә шул сыйфатлары белән аерылып тора.

Бүген язучылардан беркайчан да булмаганча хәрби-патриотик китап таләп ителә, яшьләрдә ватанга мәхәббәт, дошманга нәфрәт уята торган китап таләп ителә. Җитәрлек күләмдә булмаса да, бездә андый әдәбият туып килә. Комсомолец Барый Шәвәлиев Александр Матросов батырлыгын кабатлады. Шамил Рәкыйповның «Чәчәкләр сөйли белә» исемле китабы Барый Шәвәлиевнең тормышы һәм батырлыгы турында сөйли. Шул ук автор тарафыннан «Таңнар һаман матурмы?» дигән икенче бер китап язылды. Анысы япон самурайларына каршы Хәсән күле буенда Кызыл Армия сугышкан чакта батырлык үрнәге күрсәтеп,

Советлар Союзы Герое дигән исемнәргә лаек булган Гыйльфан Батыршин һәм аның дусты Иван Чернопятко турында.

Бөек Ватан сугышында һәлак булган геройларны эзләүче Самат Шакирны искә алу да урынлы булыр. Ул фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелгән сугышчы шагыйрь полковник Хәйретдин Мөҗәйнең фронт көндәлеген эзләп тапты, безнең нәшрият аны бастырып чыгарды. Бу — туган иленә соңгы сулышына хәтле турылыклы булып калган совет офицерының кайнар тойгылары, бу — бик мөһим кешелек документы. Мондый китаплар яшьләребезне тәрбияләүдә зур роль уйныйлар. Шәйхи Маннурның «Муса» романы, Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» повесте, Габдрахман Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше» романы, Юрий Белостоцкийның «Кыска шырпы» повесте, Тихон Журавлевның «Юлдагы очрашулар» исемле новеллалары һәм шуңар охшаш башка китаплар безнең язучыларыбызның әйбәт китаплары саналалар.

Татар әдәбиятының төп герое һәрвакыт хезмәт кешесе булды. Язучылар кешенең гүзәллеге һәм олылыгы хезмәттә ачылганын, кешегә нәкъ менә хезмәтнең хөрмәт һәм чын ләззәт китергәнен, хезмәтнең кешене намуслы һәм гадел иткәнен яхшы беләләр.

Эшчеләр хезмәте белән бергә авыл кешеләренең хезмәте безнең язучыларыбызның өйрәнәсе төп объектлары булып кала. Авылның яңаруы, яңа мөнәсәбәтләр туу, яңа кешеләр үсеп, яңа проблемаларның калкып чыгуы — болар барысы язучыга уй-фикер йөртү, анализ ясау өчен бай материал бирәләр.

Язучылар союзы үзенең членнарын еш кына колхозларга җибәрә: алар анда командировкага да баралар, чираттагы ялларын да шунда үткәрәләр, матур әдәбиятны пропагандалау бюросы путевкалары белән әдәби очрашуларга да чыгалар.

Бездә талантлы, белемле әдәби алмаш үсә. Соңгы өч елда гына да СССР язучылар союзына член итеп 26 кеше алынды. 26 — бу бит гади бер сан гына түгел, бу безнең киләчәгебез. Яшьләргә хас булганча, аларның тормыш тәҗрибәсе аз әле, аларны яңа кешеләр, талантлы оештыручылар яшәгән җирләргә — зур төзелешләргә, нефть промыселларына, колхозларга җибәрергә кирәк, алар анда тормыш һәм гражданлык тәҗрибәсе туплап, үзләренә яңа темалар, яңа конфликтлар табарлар...

Әдәбиятның киләчәге алмаш әзерләүгә бәйле. Язучыларыбызның күпчелеге нык һәм җитлеккән карашлы, аларның гражданлык йөзе, әхлакый йөзе бернинди шикләнүгә дә урын калдырмый, моңар аларның китаплары, партиягә һәм совет халкына тугрылыклы булулары дәлил. Бу тугрылык бигрәк тә авыр сынау елларында, мәкерле фашизм белән күзгә-күз очрашкан чакта, аеруча ачык күренде. Безнең язучыларыбыз ныклык, батырлык, корыч ихтыяр үрнәге күрсәттеләр, баш өсләрендә палач балтасы торган чакта да совет кешесенең әхлакый йөзен чиста итеп сакладылар, илебезнең тугры уллары булып калдылар.

Безнең әдәби алмашыбыз, бүген генә әдәбият мәйданына аяк баскан яшь язучыларыбыз совет язучысы байрагын кер кундырмыйча алып баручы өлкән буын язучыларның сугышчан традицияләрендә тәрбияләнә.

## ЯЗУЧЫНЫҢ ГРАЖДАНЛЫК ЙӨЗЕ[1]

Партия Үзәк Комитеты һәм Өлкә Комитеты карарларын укып, уйланып, тагын шуңа үземнең әдәби һәм тормыш тәҗрибәмне кушып, мин үзебезнең әдәби хезмәтебез турында кәгазь битләренә кайбер фикерләр сызгаладым, шул фикерләрне сезнең белән уртаклашмакчы булам.

[1] 1968 елны яшь язучылар семинарында русча сөйләгән речь. А. Сердинская тәрҗемәсендә бирелә.

Соңгы вакытта «Литературная газета» битләрендә: «Әдәбиятта гражданлык һәм әдипнең гражданлык йөзе» дигән темага дискуссия бара. Биредә утыручыларның һәркайсы тегеләйме, болаймы бу сорауга җавап бирә алыр иде, әлбәттә.

Мәсьәләнең фәнни билгеләмәсенә кереп чумарга теләмәгән хәлдә, мин бүген гражданлыкның бик әһәмиятле бер ягына гына кагылырга телим.

Бу — әдипнең җаваплылыгы. Үз халкы, үзе хезмәт итә торган сәнгате каршында җаваплылыгы. Беренче чиратта, үз оешмаң, каләмдәш иптәшең өчен җаваплы булу. Синең җәмгыятең ни белән яши, ул нинди мөһим һәм кичектергесез проблемалар куя һәм хәл итә, ниләргә омтыла — шулар өчен үзеңне җаваплы сизү.

Әдип — үзен һәрвакыт җаваплы һәм үз вазифасына турылыклы итеп сизә торган кеше.

Әдип — үзен үстергән, аңа иҗади көч биргән һәм аңардан таләп итәргә хакы булган туган җире каршында җаваплы.

Әдип — баррикадаларда, ачык сугышларда аңа власть алып биргән һәм аңа өметләр баглап, көтеп тора торган өлкән буын каршында җаваплы.

Әдип — аның китаплары буенча яшәргә, аның үрнәге буенча халыкка хезмәт итәргә өйрәнүче совет яшьләре каршында җаваплы.

Шулай итеп, күрәсез, әдипкә зур җаваплылык, бик зур бурычлар йөкләнә.

Безне, әдипләрне, интеллигенция дип атыйлар. Интеллигент кеше кем ул? Укымышлы булу гынамы? Укымышлы, культуралы, тәрбияле булу өстенә, интеллигентлыкка кешенең гражданлык активлыгы да кирә.

Битарафлык, пассивлык, «минем читән читтә» дип, «карап карыйк, болар нәрсә тожырыр» дип читтән карап тору интеллигент кешегә чит бер нәрсә, бу интеллигент намусына сыймый.

Үз җәмгыяте эчендә яшәп тә, анда булган хәлләргә катнашмый торган кешене (аның катнашуы пассив күзәтү белән, тагын да начаррагы — мыскыллап сүз кату: минем бурыч җитешсезлекне әйтү, бармак төртеп күрсәтү, ә сезнең бурыч төзәтү, җайлау, эшләү дип обывательләрчә тәнкыйть итү белән чикләнә икән) интеллигент дип атап буламы?

Интеллигентлык гражданлыктан тыш әле ул кыюлык та!

Безнең кайбер иптәшләр аңлавынча кыюлык нәрсә? Кыюлык, алар карашынча, язучыга ошамаган, я ул килешмәгән нәрсәне кыю итеп тәнкыйтьләү. Ул кыю язган, курыкмаган, ул кыю язучы, диләр. Тик һәр кыюлыкны, чиге булмаган һәр сүзне кыюлык дип әйтеп буламы? Ә нигә хулиганлык димәскә? Хулиган да бит кыю була.

Шушы һәм шуңа охшашлы мәсьәләләр газета-журнал битләрендә, бигрәк тә яшьләр матбугатында хәзер бик киң тикшерелә.

Кыюлык бик яраттыра торган сыйфат, кыюлык каршында һәрвакыт тез чүккәннәр, бигрәк тә яшьләр кыюлык алдында мөкиббән китә. Шуның өчен дә кыюлык белән артык уйнарга ярамый.

Тагын шуны онытмаска кирәк, дөньяда **сүз кыюлыгы** һәм гамәл кыюлыгы бар. Безнең кайбер иптәшләр нәкъ менә сүз кыюлыгына атланырга яраталар: төрле тәкъдимнәр кертәләр, проблемалар тартып чыгаралар, тик шул тәкъдимнәрне гамәлгә ашырырга тотынгач, үзләре читтә калып, сугыш кырын башкалар кулына тапшыралар. Ә бит шулар ук, җәмгать эшенә керешеп, бай һәм мәгънәле тормыш белән яши башласалар иде. Җәмгать эше аларны тар шәхси тойгылар сукмагыннан социаль кичерешләр дөньясына алып керер иде, аларда көч арттырыр, яңа сәләт ачар һәм талантларын чарларга ярдәм итәр иде.

Шулай да, кыюлык нәрсә соң ул? Әйтик, язучы кыюлыгы?

Кыюлык — кешедә тәрбияләнгән җаваплылык һәм бурычны тану тойгыларына нигезләнгән мораль сыйфат ул. Чиге булмаган кыюлыкның идея дошманнарыбызга хезмәт итүе мөмкин. Кыю язучы әсәрен бастырыр алдыннан яки халык каршында чыгыш ясаганчы, үзе теләп хезмәт итәргә алынган җәмгыятенә файдалымы, әллә зарарлымы эш эшләячәген кат-кат уйларга тиеш. Кыюлык — безнең идея дошманнарыбызны чыбыркылап, безнең җәмгыятькә хезмәт итсә генә, безгә файда китерсә генә кыюлык, алай булмаса кыюлык түгел, бары тик чыныкмаган яшь-җилбәзәкне алдау өчен кыю, батыр булып кылану гына.

Кыюлык турында сүз кузгалгач, мин ихтыярсыз үзебезнең тирә-юньгә, үз-үзебезгә күз ташлыйм. Без үзебез һәрвакытта да шушы сүзнең яхшы мәгънәсендә кыюмы? Әйтик, журналыбызның редколлегия утырышында берәүнең әсәре тикшерелә ди. Без барыбыз да ачыктан-ачык кыю итеп үз фикерләребезне әйтәбезме? Кайберебез тикшерелә торган китапның авторы белән бозылышмас өчен бүтән кеше артына качмыймы? Кайвакыт тикшерелә торган әсәрне бераз гына тәнкыйтьлибез дә, төзәткәннән соң басарга ярый, дигән нәтиҗә чыгарабыз түгелме? Ә бит кайвакыт әсәрдәге мәсьәләләр нигезендә үк ялгыш яктыртыла. Андый әсәрне яңабаштан, бөтенләй яңа принципларда торып язмаган хәлдә төзәтеп буламы? Андый чакта кайбер иптәшләр болай уйлыйлар: китапны зур язучы язган икән, ни генә язса да басарга кирәк, чөнки ул үзе өчен үзе җавап бирә алырлык кеше. Мондый позицияне кыю һәм җаваплылык позициясе дип әйтеп буламы? Бу үз өстеңә төшкән җаваплылыкны башка берәү өстенә салу түгелме? Әйтик, Главлит җилкәсенә? Соңыннан шул ук иптәшнең Главлит үткәрми, анда консерваторлар утыра, дип әйтүе мөмкин. Шулай итеп, әлеге иптәшебез яхшы атлы була, ул бик «тәти» егет, ә минә китапны уздырмаган Главлит янсә башка берәү, әлбәттә, бик начар кеше булып чыга! Әгәр сәяси категорияләрне әхлакый телгә күчерсәк, мондый сәяси оппортунизмны әхлаклы һәм намуслы эш дип атап буламы? Сүз әхлак турында барганда бөтенесе дә — күңел кылларының һәр хәрәкәте, һәрбер уең, һәр эшең — мөһимгә әйләнә. Бу бигрәк тә язучы өчен шулай, чөнки язучы башкаларны өйрәтә, ул миллионнарның иң элек язучыга ышана торган, аның идеаллары белән рухланган, ул тудырган әдәби геройларга охшарга тырышкан, яшь, тәҗрибәсез буынның рухи җитәкчесе булырга тиеш кеше. Димәк, без яшь буынның җаны өчен җаваплы, шуңа күрә дә иң элек үзебез гадел булырга, икейөзлеләнмәскә, башкалар артына качмаска тиешбез.

Бүгенге идеологик көрәшнең катлаулылыгы һәм үткенлеге журналларның, атап әйткәндә «Казан утлары»ның, редакторлары һәм барлык редколлегия членнарының җаваплылыгын күтәрүне сорый, басыла торган материалларның идея-политик юнәлешенең җаваплылыгын күтәрүне сорый.

Редколлегияләрнең ролен күтәрергә кирәк, һәр редколлегия члены журнал эше өчен, анда басылган материаллар өчен зур җаваплылык сизсен, кеше артына ышыкланмасын.

Бер үк язучыны берничә журнал редколлегиясендә эшләргә мәҗбүр итү, минемчә, дөрес түгел. Бу хәл житди, сәяси эшкә җиңел, кайвакыт җавапсыз караш тудыра, язучының булсын, тулаем редколлегиянең булсын эш нәтиҗәсе кими, битарафлыкка китерә. Берьюлы ике редколлегиядә: «Казан утлары», «Чаян», «Азат хатын» һәм «Ялкын» журналларында эшләп килүче Мирсәй Әмир, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәүкәт Галиев иптәшләрне кайсы редколлегиядә калдыру мәсьәләсен безгә тиз арада хәл итәргә кирәк булыр.

Идея ягыннан житлекмәгән, художество ягы йомшак әсәрләр журнал битләренә кермәсен өчен редколлегияләр эшендә югары таләпчән-

лек, принципиальлелек, үзара тәнкыйть һәм иҗади эзләнүләр шарты тудырырга кирәк.

Искәндәр Рушанның юмористик шигырьләрен «Казан утлары» битендә чыкканчы редколлегия члennарының барысы да укыганмы, юкмы, мин анысын белмим. Тик ул шигырьләр моннан ун еллар элек язылганнар һәм заманында, дөрестән дә, кайбер кирәкле мәсьәләләрне күтәргән булганнар, әмма хәзер алар көннең кадагы булудан төшкәннәр инде. Ун еллап, хәтта аннан да артык вакытка соңарып басылган бу шигырьләргә карата редколлегия членнары үзләренең мөнәсәбәтләрен әйтергә тиешләр иде...

Гомумән, теге яки бу проблеманы кую кыен эш түгел, әмма аларны хәл итү читен. Күптән түгел Нәби Дәүли шәһәребезнең йөзен тәнкыйтьләп газетага язып чыкты. Мәкаләсе яхшы, әйбәт язылган. Язучыларның хәл итүне сорап торган мәсьәләләр күеп, көн кадагына язылган мәкаләләр белән матбугатта чыгуларын хупларга кирәк.

Бу очракта Дәүли Кабан күлен чистарту һәм шундый башка кызыклы мәсьәләләр куя. Кабанны чистарту яңа мәсьәлә түгел. Әмма бүген шәһәр өчен нәрсә әһәмиятлерәк: яңа торак йортлар салумы, әллә Кабан күлен чистартумы? Хәзер торак йортлар салырга, кешеләргә адәм рәтле яшәрлек мөмкинлекләр бирергә кирәк.

Бер өч ел узгач, Нәби Дәүлинең, Кабан күлен чистарту кебек мөһим мәсьәлә күтәргән идем, шәһәр башлыклары Кабан күлен һаман пычрак тоталар дип тагын язып чыгуы мөмкин. Шәһәр башлыклары — бюрократлар, консерваторлар, ә менә безнең Дәүли бик яхшы кеше булып чыга! Ул мәсьәләне куйган, укучы алдында ул бик әйбәт булып күренә, ә менә башкалар бик начар, бик булдыксыз булалар. Укучы алдында шул рәвешчә үзенә авторитет казану ансат эш, тик менә башкаларны уңайсыз хәлдә калдырасың. Чөнки куелган мәсьәләне бүген үк тормышка ашыру һич мөмкин түгел. Хәл ителмәгән башка мәсьәләләр, әһәмиятлерәкләре чиратта торучан була.

Моның белән мин нәрсә әйтергә телим? Төрле мәсьәлә куярга ярамый дип һич әйтәсем килми, киресенчә, язучыларның гражданлык активлыгын үстерергә кирәк. Тик сүзеңне әйтер алдыннан күтәрергә теләгән мәсьәләнең вакыты җиткәнме, шул көннәрдә аны тормышка ашырып булырмы дип ныклап уйлап карарга кирәк. Әллә син тавышыңны ишетсеннәр дип, менә ул нинди акыллы, шундый зур мәсьәләләр күтәрә дип әйтсеннәр өчен генә чыгасыңмы?

Шулай итеп, язучының таланты дошманнарга каршы сугышсын, аның таланты безнең файдага эшләсен. Талантыңны дөрес файдалану язучы өстенә төшкән зур җаваплылык ул. Язучы сүзе көчле корал, аны зур саклык белән кулланырга кирәк, юкса бу коралның үзеңнекеләргә атуы бар. Язучы сүзенә меңнәр һәм меңнәр колак сала, бигрәк тә радио һәм газета-журналларның зур тиражлары заманында... Үзеңнекеләр дә, дошман яклар да тыңлый.

Без, язучылар, уйланмаган чыгышларыбыз белән дошманнарны шатландырмаска тиешбез. Нәрсә, тәнкыйтьләргә ярамыймы, дип сораулары мөмкин. Бу сорауга болай дип җавап бирергә була: безнең тәнкыйть җимергеч түгел, ә төзергә булышучы тәнкыйть булырга тиеш. Биредә күп нәрсә язучының карашларына бәйләнгән. Сүз җаенда шуны да әйтим, бездә язучының дөньяга карашы дип аның фәлсәфи һәм теоретик белемен уйлыйлар. Янәсе, ул мәктәптә марксистик фәлсәфәне өйрәнгән икән, аның дөньяга карашы да марксистик булырга тиеш. Кызганычка каршы, бу гел алай булмый. Әлбәттә, язучы марксизмны яхшылап өйрәнсә, аның асылын төшенсә, ә ятлап кына калмаса, бу аңа тормышта акны карадан аерырга ярдәм итәчәк. Ләкин шуны да онытмаска кирәк, художник дөньяга гади күз белән генә карамый, ул дөньяны үзенчә.

әдәбият кешесенә хас булганча күрә. «Дөнья күрә белү — ул язучының дөньяга карашының бер ягы, җитмәсә, иң әһәмиятле ягы», — диде Александр Фадеев.

«Мин үзем күрдем, үзем күзәттем, — ди кайбер язучы, — мин моны тормыштан алдым», — дип дәгъвали ул. Әйе, ул чыннан да тормыштан алган, бусын язучы дөрес әйтә. Биредә без әдәбият теориясендә әйтелгәнчә, «факт дөреслеге һәм сәнгать дөреслеге» дигән төшенчә белән очрашабыз. Без дөреслекнең, эстетик категория буларак, бервакытта да факт дөреслегенә, язучының күргәннәрен гади сурәтләвенә кайтып калмавын беләбез.

Бу темага күп язылды, «Әдәбият мәсьәләләре» журналы битләрендә бәхәс уздырылды, А. М. Горькийның әйткән сүзләрен беләбез, шуңа күрә бу турыда җентекләп тукталуның кирәге юк, тик басым ясап, тагын бер мәртәбә шуны әйтәсе килә, язучының дөньяны күрә белүе күп очракта аның тормыш тәҗрибәсеннән килә. Тормыш тәҗрибәсе зуррак булган саен, язучы үткенрәк күрә һәм тормыш каршылыкларын дөресрәк чишә ала.

Тормыш тәҗрибәсе — ул язучының материал чумыра торган тирән коесы. Шуның өчен дә мәктәп эскәмиясеннән туп-туры профессиональ язучыга әверелгән яшь язучы белән яшь шагыйрьгә кисәтеп әйтәсе килә. Аларның материал ала торган әлеге сай коеларының бик тиз кибүе мөмкин, шул чакны аларның язар нәрсәләре бетәчәк, үз-үзләрен кабатларга керешәчәкләр, кайбер яшь язучылар белән андый хәлләр булгалады да инде. Әле яшь чакларында, республика газета-журнал редакцияләрендә утырып җылыткан урыннарын вакытлыча ташлап, бу иптәшләргә төзелеш мәйданнарына, әйтик, шул ук Түбән Кама ягына, я бүтән җиргә китеп бару яхшырак булмасмы?

Язучының дөнья күрә белүе аның талантына да һәм, югарыда әйтелгәнчә, тормышта биләгән позициясенә дә бәйләнгән. Бер вакыт Леонид Леонов болай дигән иде: «Тирә-юньдә барган вакыйгаларга кайсы ноктадан торып каравың әһәмиятле. Берәүләр башы болытка тиеп, як-якка чайкалып торган манара очыннан карый, берәүләр кыя башыннан, ә тагын берәүләр — подвалдан. Боларның кайсы күбрәк күрер дә, тирә-яктагы чынбарлыкны кайсы яхшырак аңларын төшенү кыен түгел».

Язучының яши һәм эшли торган кече мохите турында да әйтик. Кеше бер үк вакытны нефтьчеләр арасында да, колхозчылар яки фән работниклары белән дә яши алмый. Аның көн саен очраша, сөйләшә, аралаша торган дуслары, танышлары була. Шушы кечкенә мохит язучының кәефенә, аның фикерләренә, омтылышларына тәэсир итә торган, эшләгән эшләренә юнәлеш биргән төп чыганак ул. Көн саен кем белән очраша ул, кем белән сөйләшә, әхлакый таза кешеләр арасында яшиме, әллә обывательләр беләнме, язучының карашлары менә шуларның барысына да бәйләнгән була. Язучының эчке тормышы нихәтле катлаулырак һәм баерак булса, үзенең әсәрләрендә ул җәмгыятебезнең асылын, халкыбызның җанын тулырак ачып бирә ала.

Шушы көннәрдә «Правда»: «Һәр буын художнигы үз дәвере каршында җаваплы, — дип язды. — Алар халыктан өйрәнергә һәм алган белемнәрен бик күпкә тапкырлап, халыкка кайтарырга тиешләр. Ә кулны заман пульсында тоту өчен күп вакыт безгә иҗади һәм гражданлык кыюлыгы җитми. Кайвакыт без әһәмиятсез, вак фактларга бирелəбез».

Үземнән өстәп шуны әйтәсе килә — заманны тою художник өчен бик кирәкле сыйфат. Үз заманының идеяларын чагылдырган художник кына озак яшәячәк. Безнең язучылар бүгенге көн турында язмыйлар дип зарлана алмыйбыз, бигрәк тә шагыйрьләр актив эшлиләр. Әмма кайвакыт шул кадәр абстракт, заманның төсе чагылмаган шигырьләр языла, шагыйрьнең кайнап торган чорда яши торып та, тормышыбызда

булган вакыйгаларны күрмәвенә, хәзерге заман хәлләренә, катлаулы политик һәм мораль категорияләргә битараф булуына, поэзия чаралары белән вакытны һәм шунда яшәгән кешеләрне аңлатып бирергә тырышмавына хәйран каласың.

Укучыны дулкынландырмаган шигырьләр күп языла бездә. Ул шигырьләр йөрәк белән түгел, кул белән генә языла. Андыйлар «Казан утлары» битләренә дә үтеп кергәли.

Хәзерге вакытта шигырь яза белү белән ерәүне дә шаккатырып булмый. Шигырьне балалар да, гашыйклар да, пенсионерлар да яза. Әмма чын шигырьне бары тик чын шагыйрь генә яза ала. Хәзерге укучыны мәгънәсе белән тирән, язылышы белән оста булган әсәрләр генә канәгатьләндерә. Темасы һәм материалы бик әһәмиятле булса да, югары дәрәҗәдәге поэтик формага салынмаса, шигырь шагыйрьгә уңыш китермәячәк. Яңа гына Союзга алынган яшь шагыйрь Гәрәй Рәхимнең уңышлы шигырьләре турында әйтеп узасы килә. Автор юри оригиналлык эзләп маташмаса да, алар бик үзенчәлекле, эчтәлеге белән дә кызыклы. Әгәр бу яшь иптәш сәләтен үстерү өстендә тырышып эшләсә, киләчәктә аннан зур шагыйрь чыгарга тиеш.

Җитлеккән гражданлык сыйфатлары әһәмиятле булган кебек, әдип өчен профессиональ осталык та бик кирәк. Дөньяга карашы бик дөрес булган кеше дә, әгәр ул шагыйрь яисә язучы буларак көчсез икән, рәтле әсәр бирә алмаячак. Язучыны актуаль тема күтәргән өчен генә мактый торган заманнар узды хәзер. Актуаль тема әдәби кануннарга буйсынмаса, укучының йөрәгеп яулап алган, аны дулкынландыра, хәсрәткә сала, елата, көлдерә торган кызыклы, җанлы характерлар анда булмаса, яхшы тема бары яхшы ният булып кына кала.

Сез әйтерсез, бу инде бик күптәннән билгеле, монда Америка ачып торасы юк, диярсез. Шунысы бар, Американы да ике тапкыр ачканнар: беренче тапкыр Колумб ачкан, икенчесендә — Америго Веспуччи, шуның өчен Америка дип атаганнар да аны. Инде кабатлауга килсәк, кабатлауны руслар өйрәнүнең анасы диләр. Проблема хәл кылынмый торып кабатлаудан туктап булмый.

Яшьләр тиз кабынучан була. Алар тормышның фәлсәфи асылына төшенүдән бигрәк, хиска бирелеп яшиләр. Һәм шул сәбәптәндер, тормыш күренешләренә бәя биргәндә еш кына ялгышалар.

Белгәнебезчә, сәнгать — тормышны чагылдыручы гына түгел, сәнгать — үз чаралары белән тормышны яңадан иҗат итү. Сәнгатьтә язучының йөзе чагыла, таланты көчлерәк булган саен аның үзенчәлеге ныграк сизелә. Шуңа күрә дә иҗат эшендә әдипнең йөзе, позициясе, аның нәрсәнедер яратуы-яратмавы бик зур урын тота. Язучының таланты, тормышка карашы, тоткан позициясе — әдипнең өч киты менә шулар. Талант ул табигать биргән байлык һәм, кызганычка каршы, Язучылар союзы аны Литфонд аша өләшеп утыра алмый, әмма язучыны дөньяга дөрес карарга өйрәтү, дөрес позициядә торырга булышу һәм, әлбәттә, табигатьтән мирас итеп алган талант чаткысын көчәйтергә ярдәм итүне Союз булдыра ала, ул аны эшләргә тиеш.

Тормышка карашы буталчык, тормыш позициясе таркау булган язучы еш кына хисләргә бирелеп, эмоциональ фактның көчле йогынтысы белән яши һәм тормышны бер яклатып күрә, бәяли башлый.

Балалыклары сугыш елларына туры килгән язучылар авылларыбызның сугыш вакыты һәм сугыштан соңгы хәлләрен язганда эмоциональ фактлардан чыгып эш иттеләр. Бу чорны кешеләр ачыккан, колхоз председательләреннән, бригадирлардан кыерсытылган иң авыр эшләр итеп, нәкъ шуларга басым ясап сурәтләделәр, тылдагы совет кешеләренең колхоз кырларында, урман хәзерләү пунктларында һ. б., фронттагы дошманны җиңү өчен зур тырышлык күрсәтеп, геройларча хезмәт итүен

бик еш кына әһәмиятсез калдырдылар. Мондый берьяклылык Аяз Гыйләжевнең «Берәү» повестена, Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» повестена (бигрәк тә беренче редакциясенә) беркадәр хас. Н. Фәттахның «Артта калган юллар» хикәясе турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Кайбер язучыларга дәүләтебез тарихының мөһим чорларын субъектив карашта торып, берьяклы бәяләү хас, алар җитешсезлекләрне тәнкыйтьләгәндә партиячел һәм гражданлык позициясендә торып эш итмиләр, гаепләүче роленә яки социалистик реализм принципларына ят булган абстракт гуманизм юлына басалар. Сугыш елларындагы авыл тормышын сурәтләгәндә безнең хатын-кызларыбыз, бала-чага, карткорыларыбыз эшләгән батырлыкны күрмичә, ул елларның тормышын гел кимсетелү, гел газап чигү итеп бирү, бу — дәүләтебез тарихының мөһим чорын ялгыш, берьяклы бәяләү дигән сүз. Кайвакыт, үзара сүз чыкканда, авылны коллективлаштыру барганда кулакларны сөрү — артык каты, гуманлыкка сыймый торган чара булды дигән сүзләрне ишетергә туры килә.

Нәкъ менә буржуаз идеологлар лагерендагы дошманнарыбыз яшьләребезне бутау өчен безгә гуманизм дигән нәрсәне төртәләр, «гомумхалык интересын» пропагандалыйлар, һәртөрле абстракт «сыйныфсыз идеаллар»ны үткәрергә телиләр, кешелек бөтен бер нәрсә ул, безнең заманда сыйнфый интереслар турында сүз йөртү искергән нәрсә һ. б. һ. б.ларны исбат итәргә маташалар. Тарихыбызны сыйныфсыз гуманизм карашыннан торып аңлатырга тырышучы иптәшләр кайчандыр сыйнфый дошманнарыбызга, әйтик, шул ук кулакларга карата кулланылган көчләү чараларын гуманссызлык акты дип карыйлар икән, алар нык ялгышалар.

Югарыда мин талант турында әйткәндә, тормышны дөрес аңлау язучының талант дәрәҗәсенә дә бәйле дигән идем. Әйе, талант үткен күзле, тирәнтен күрә, ләкин талантның табигый көченә генә ышанырга ярамый, аны тәрбияләргә, туктаусыз чарлап торырга кирәк. Язучының зур тормыш тәҗрибәсе — талантны үстерә һәм чарлый торган материал шул үзе инде. Тигез талантлы ике язучының берсе — тормышны читтән күзәтеп тормыйча, актив катнашып, эчендә кайнаганы чын китап язачак. Талантка — социаль юнәлеш кирәк. Талант **социаль яктан** үткен булырга тиеш. Менә шунда инде язучының тормышка карашы бөтен көче белән алга килеп баса. Тормышка карашы дөрес булмаган талант — сукыр, компассыз талант, аңа тормыш океанында дөрес юл табу бик кыен булачак.

Кайвакыт шундый язучы да очрап куя: табигый сәләтен үстерү өстендә эшләү урынына, ул таланты белән масая, каләмдәшләренә өстән торып карый, талантсызлар дип мыскыллый, тәнкыйтьне күтәрми, үзен тәнкыйтьләүчене дошман итеп күрә, редколлегияләргә бойкот белдерә. Кәҗә сөзде дип тау ишелми ишелүен, шулай да үз-үзен тотышы белән андый язучы күңелсезлекләр тудыра.

Ә бит талант язучының шәхси милке түгел, талант ул халыкныкы, халык байлыгы, язучы таланты белән масаерга тиеш түгел, бигрәк тә талантын, безнең кайбер язучыларыбыз кебек, аракыга батырырга хакы юк. Талант язучыга табигать тарафыннан бирелгән булса да, ул аның үзенеке генә түгел, талант халыкка хезмәт итәргә тиеш, яхшы, талантлы хезмәт итәргә тиеш!

Әдәби хәрәкәтебезнең теоретик һәм практик мәсьәләләре буенча безнең әдәби тәнкыйть кызыксынып эшләргә тиеш иде. Әдәбиятта тәнкыйтьнең роле — укытучы һәм пропагандист роле ул. Кызганычка каршы, өлкән буын тәнкыйтьчеләр тарихка кереп чумдылар, хәтта урта буын тәнкыйтьчеләре дә күбрәк әдәбият белеме һәм укыту эше белән шөгыльләнәләр, тәнкыйтьчеләр сафы яшьләр хисабына бөтенләй дияр-

лек үсми. Әдәби журнал битендә тәнкыйть — сирәк кунак. Өлкә газеталары да яңа басылган китапларга рецензияләрне бик сирәк урнаштыралар, һәр футбол матчына газеталар битендә даими рәвештә бәя бирелеп килә, әмма сирәк китаплар гына җитди рецензия алу бәхетенә ирешә. Дөрес, «Казан утлары» тәнкыйть жанрын активлатырга тырыша. Рафаэль Мостафинның яшь һәм урта буын язучылары әсәрләрен тулы анализлаган мәкаләләрен мин җитди һәм файдалы эшкә саныйм, бигрәк тә, әгәр Мостафин, әдәби әсәрләргә бәя биргәндә, кайбер субъективлыктан арынса, алар безнең әдәби хәрәкәттә үз рольләрен уйнарлар. Күптән түгел үткәрелгән әдәби ел йомгакларында сөйләнгән Фатих Хөсни, Ибраһим Нуруллин, Азат Әхмәдуллин, Роберт Батуллин докладлары һәм чыгышлары да әдәби хәрәкәткә уңай йогынты ясарлар дип уйлыйм.

Хәзергә әле тәнкыйть көчләребез ел саен чыгып килә торган чагыштырмача күп булмаган әсәрләребезне дә күзәтеп барырга өлгермиләр. «Казан утлары» тәнкыйтьчеләрне тарту эшен бик каты җанландырырга, бигрәк тә университетта һәм пединститутта укучы талантлы студентлар хисабына тәнкыйтьче яшьләрне үстерергә тиеш. Зур тәнкыйтьсез әдәби журнал — яртылаш кына журнал.

* * *

Югарыда әйтелгәннәрнең барысыннан шундый нәтиҗә ясарга була: язучыларның гражданлык активлыгын үстерү өчен көрәшергә кирәк. Язучы партия һәм халык алдында үзенең эшчәнлеге өчен җаваплылык сизәргә, әдәбиятның җәмгыять тормышындагы урынын һәм әһәмиятен яхшы аңларга һәм аның идея сафлыгы өчен көрәшергә тиеш.

«Казан утлары» журналы әдәбиятта партиялелек һәм халыкчанлык, традиция һәм новаторлык, бүгенге көннең уңай герое шикелле, әлегә кадәр журнал эшенең арткы планына күчерелгән, бик әһәмиятле темаларны яктыртуда актив эшләргә тиеш. Хәзергә әле журнал әдәби хәрәкәтнең актуаль мәсьәләләре турында язу урынына, игътибарын күбрәк әдәбият тарихына бирә. Журнал битләрендә буржуаз теоретикларның әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә карашлары тәнкыйтьләнми. Мондый хәл бигрәк тә хәзер — идеологик дошманнарыбыз әдәбият теориясе мәсьәләсендә булсын, әдәби практикада булсын, позицияләребезгә һөҗүм итеп торганда, еш кына яшьләребезне буталдырып, башларына чуп-чар тутырырга тырышканда кирәк.

«Казан утлары» эшендә редколлегиянең ролен күтәрергә кирәк. Аның һәр әгъзасы журнал эше өчен үзендә зур җаваплылык сизәрлек булсын.

Журнал әдәбиятның идея сафлыгы өчен көрәшкәндә тәнкыйтьнең ролен истә тотып, язучыларыбызның әсәрләренә җитди тәнкыйть мәкаләләре басарга, бу эшкә өлкән буын тәнкыйтьчеләре белән бергә аспирантлар, фән кандидатлары һәм студентлар арасыннан килгән яшь тәнкыйтьчеләрне дә тартырга тиеш.

Буржуаз идеологияләргә тиешле отпор бирү, үз позицияңне яклап кына калмыйча, дошман пропагандасына каршы аяусыз һөҗүмгә күчү — ул һәр язучының бурычы. Без, язучылар, чит йогынтыларның һәр төрле формасына — тарихыбызны берьяклы, субъектив аңлату булсын, сәнгатьнең сыйнфый асылын оныттыруга һәм идея көрәшендә килешүчәнлек позицияләренә алып бара торган абстракт-гуманизм теорияләреннән чыгып, теге я бу тарихи фактка бәя бирү булсын, барысына да нык каршылык һәм килешмәүчәнлек күрсәтергә тиешбез.

Марксистик-ленинчыл тәгълимат нигезендә барлыкка килгән һәм сәнгать тәҗрибәсендә күп еллар буена сыналган идеологик-эстетик принципларга турылыклы булу, әдәбиятта партияле һәм халыкчанлык принципларында торып эш итү — безнең уңышларның нигезе әнә шунда!

## *Хатлар*

### *Афзал Шамовка*

*4 август, 1943 ел*

**Эх, малай, Әбҗәлттин, Әбҗәлттин!** [1]

**Сагынуның әче шәрабын мин дә касә тутырып эчәм аның, малай, шуңа күрә мин сине больше чем аңлыйм. Кайвакытта, малай, әйтергә оят, тамак төпләре кытыкланып китә. Беразга гына булса да кайтып килергә мөмкин булса, Казан каласына дүрт аякланып керер идем, яңа солдатский чалбарым буяла дип тормас идем. Менә ничек, малай!**

**Ләкин сезнең хәл — җәннәт, минеке белән чагыштырганда... Җәннәт кенә дә түгел — рай. «Ник!» дисең инде син. Кайтам дисәң, кайтаручысы бар, ара якын, аннан, ни әйтсәң дә, үз кешеләр. Это много значит. Мин бит җиде ят арасында. Җитмәсә, үзем — певец, үзем — жнец, үзем — в дудку игрец. Безнең икенче литературный сотрудник каләме әлифне таяктан гына аера. Бөтен авырлык миндә — терпи минем бөкре. Ә Клиблинең [2] телен беләсең... Аннан ул гаҗәп кызык политика тота: бернәрсә дә эшләми, буквально бернәрсә дә; бер җөмлә әйбер язмый, бер кәлимә тәрҗемә итми. Аның б ө т е н эше — макет оештыру, ул да чиле-пешле. Калган вакытын я йоклап, я авырып, врачларга йөреп үткәрә. Мин макандировкага [3] киткәч, алар бер газета чыгарганнар. Укып карау өчен җибәрәм. Аяк мәкалә [4] — аның тәрҗемәсе. Клибли, малай, туйда [...] [5]. Ләкин аның да бер яхшы ягы бар: ул бер эшкә дә тыгылмый, ягъни мешать итми — шул ягы җәдә (үзбәкләрнең «бик» дигән сүзе) яхшы. Алты ай дигәндә звание кундырдылар — младший лейтенант. Аңа да бик канәгать — акчасы бар. Аннан минем хәлне беләсең бит син. Синеке белән чагыштырып булмый — җәяүле [6] идем бит мин. Менә шулай. Пауза.**

**Болай, барысын бергә җыеп алганда, ничего торабыз. Берничә (!) хикәя яздым. Берничә ай эчендә бит, ә элек ничәме елга берәү дә язылмый иде. Материал бар да, тынычлык җитеп бетми. Ни әйтсәң дә, сугыш бит инде.**

**Мин сезгә бернәрсә дә җибәрә алмыйм [7], чөнки язганнарым санаулы. Миңа гел тәрҗемә белән (русчадан татарчага һәм киресенчә) шөгыльләнергә туры килә. Әгәр син җибәрә алсаң, бик яхшы булыр иде.**

**Ласипед [8] дигәнең кайтты шикелле инде. Ул аны илтеп бирә алмагандыр, бездә тора торгандыр. Ләкин аның тәгәрмәче өчен [9] синнән (синнән бигрәк, Гадиләдән [10]) уңайсызланып торам. Сугыш бетеп, исән-сау калсак, җайларбыз.**

**Үзең син берәр хикәя яздыңмы, ә!**

**[...]**

**Менә шулай, малай, ят-чит җирләрдә, тәмсез су эчеп, бомбалар сызгыруы астында, кайчан муены сына инде бу Гитлерның дип, өмет белән яшибез.**

**Тагын берәр елга түзсәк, шаять, очы-кырые күренә башлар иде инде.**

**Гыймадига [11], А. Әхмәткә [12] сәлам!**

**Дусларча сәлам белән**

ИБРАҺИМ.

---

[1] Ә б җәлттин — Әфзалетдин, Афзал Шамов; гади халыкча әйтелеш. Ибраһим Гази мине шулай атап йөртә иде. Моның кыска гына тарихы да бар. Утызынчы елларның башында ул, минем квартирага килгәч, әнинең миңа Әбзәлеттин дип эндәшүен ишетте дә, моны бик ошатып, мине шулай атап йөртә башлады, тик «з» хәрефен «җ» белән генә алыштырды. (Афзал Шамовка адресланган хатлардагы искәрмәләр Афзал ага тарафыннан эшләнде. Ж у р н а л р е д а к ц и я с е.)

[2] Клибли — Г. Х. Клеблеев; Бөек Ватан сугышы елларында башта Көньяк фронтта, аннары 4 нче Украина фронтында чыккан «Сталин байрагы» исемле татар газетасы редакторы.
[3] Макандировкага — командировкага. Ибраһимның якын иптәшләре белән сөйләшкәндә, шаяртып, кайбер сүзләрне бозып, үзгәртеп әйтә торган гадәте бар иде. Хатларында да ул кайбер сүзләрне үзгәртеп яза.
[4] Аяк мәкалә — баш мәкалә. Шаяртып әйтүе.
[5] Хатларны матбугатка әзерләгәндә төшерелгән сүзләр, җөмләләр квадрат җәяләр эчендәге нокталар белән күрсәтелде.
[6] Җәяүле — бу урында рядовой мәгънәсендә.
[7] Җибәрә алмыйм — Калинин фронтында чыга торган «Алга, дошман өстенә» исемле татар газетасында аның хикәяләр, мәкаләләр белән катнашуын үтенгән идем. Сүз шул хакта бара.
[8] Ласипед — велосипед.
[9] Тәгәрмәче өчен — 1942 елны Ибраһим, минем велосипедны алып торып, Лаеш районындагы Мирәтәк авылына барган иде, юлда велосипедым ватылган һәм, ул аны авылда калдырып кайткан иде. Сүз шул турыда бара.
[10] Гадилә — тормыш иптәшем.
[11] Гыймади — Минһаҗ Гыймадиев (1903—1970), журналист, «Алга, дошман өстенә» газетасы редакторы.
[12] А. Әхмәт — Абдулла Әхмәт, язучы, шул ук газетаның штаттагы хәрби хәбәрчесе.

*5 май, 1944 ел*

**Әбҗәл!**

**Ярты елга бер хатың килде. Ул да булса 23 мартта, ягъни моннан ай ярым элек язылган хат. Минем хатлар үгез белән барсалар (синең сүзләр), синекеләр кыслага (рак) атланып киләләр. Ничек булса, шулай булды, ләкин хатың килде — рәхмәт!**

**Кырым шәһәрләренең берсеннән агачтагы чәчәкләр санынча, безнең яндагы тау биеклегенчә, безнең яннан гөрләп ага торган тау елгачыгының төбендәге чуер ташлар санынча сәлам үзеңә (беркадәресен А. Әхмәткә, Минһаҗга, Әхмеровка[1] дә бүлеп бир, ярыймы!). Мин инде ни уйларга да белми идем: ни булды бу Әбҗәлттингә! Үпкәләде дисәң, сәбәп юк шикелле — язмый да язмый. Җавап алмагач, минем дә күңел сүрелә... Ә үзе дөньяда бар: «Өзелгән кыллар»ны язды. Тәүгилденең[2] бөтен нәрсәләрен дә укыштырдым, ә үзе, уч иткән кебек, тавыш бирми. Аннары болай уйладым: бөтен уйлаганны, әйтергә теләгәнне язып булмый, хатлар үгездә йөри, аннары — барып җитүенә дә ышаныч юк,— шуңа күрә язмый инде бу дип уйлыйм. Күп вакытны минем үземнең дә хат язарга кул күтәрелми.**

**Язу-язмау турында. Хәлемне ничек аңлатыйм икән! Әйтик, менә син редакциядә тәрҗемәче дә — үзең (русчадан татарчага һәм киресенчә), литредактор да — үзең, корректор да — үзең, язучы да — үзең, ди. Ә редактор, тегене тәрҗемә ит, моны яз, дип әйтә дә ятып йоклый, ди, ә литсотрудникның бөтен язганын сиңа яңадан эшләргә туры килә, ди; корректордан соң гранканы да, полосаны да үзең укыйсың, ди; шуннан соң гына үзең бирер нәрсә язасың, ди. Менә минем хәл шул. Шул ук вакытта алар «тәти абыйлар» каршында 100 процентлы булып күренеп, редакция, гомумән алганда, яхшы работниклар белән тәэмин ителгән санала («тәти абыйлар» шулай саный). Безнең хәл үз редакциябез эчендәге сер булып кына кала. Тыштан бөтенесе «аллага шөкер», асылда «ходаем, үзең коткар». Мин моңа инде күнеккән. Күнегүен күнеккән, ә газетага бу начар тәэсир итә.**

**Ярый, бетсен.**

**Тылдагы иптәшләр миңа бик сирәк язалар. Күбесеннән хат алмаганга ярты елдан артык. Шунысы кызык — язган хатка җавап бирмиләр. Нишләмәк кирәк: шуның өчен алар иптәш, ә иптәшлек бездә үзең беләсең... Я, җитәр, әллә нәрсә әйтеп куюым мөмкин.**

**Я, хуш әлегә!**

**Яз дип әйтмим, язгала дип кенә әйтәм. Иптәшләрдән хат алсаң, күңел рәхәтләнеп китә.**

**Сәлам белән**

**ИБРАҺИМ.**

---

[1] Әхмеров — Котдус Әхмеров, журналист, «Алга, дошман өстенә» газетасының тәрҗемәчесе.
[2] Тәүгилде — А. Тәүгилде, әдәби псевдонимым.

*9 сентябрь, 1944 ел*

**Әбҗәлттин!**

Исәнме-саумы, малай! Синең 8 нче июльдә язган хатыңны 8 нче сентябрьдә алу бәхетенә ирештем. Менә шуннан соң хат язарга ничек итеп каләм күтәрелсен инде! Ике ай бит! Ул ике ай эчендә мин Кырымнан Карпат тауларына кадәр килеп җиттем. Бер атна Казанда булып, хикәяләремә договор төзеп, хатынны-баланы кочаклап, Казанка буйларын әйләнеп килдем. Ә синең хатың килгән дә килгән.

Карпат таулары арасында йөри хәзер синең абыең. Кичә генә Фәйзи[1] белән алгы сызыктан кайттык: тузан тулмаган тишек калмады, тирләп, сасып беттек.

Мин хуҗа[2], ләкин хуҗаның хуҗалыгы гына юк. Без өйләнгәч, төн кыскарды — бетерделәр, яптылар[3]. Алдагы көндә кайда эшләрмен — билгесез. Имеш, монда татарлар аз...

Инде, малай, хикәяләр язуга кучәргә дә вакыт иде. Сугышның очы күренә шикелле. Материал — муеннан! Вакыт бирелсә, әллә ниләр язарга мөмкин.

[...]

Баян[4] Бухарестта хәзәр. Аның адресы: 08739-Ч.

Сәлам белән **д у с т ы ң.**

P. S.

Фәйзидән сәлам. Эх, күрешәсе иде бер! Менә сөйләшер идек.

---

[1] Ф ә й з и — Әхмәт Фәйзи (1903—1958), шагыйрь, «Сталин байрагы» газетасының хәрби хәбәрчесе.

[2] М и н  х у җ а — Г. Клеблеев хезмәтеннән алынгач, И. Гази газетаның вакытлы редакторы итеп билгеләнгән иде. Сүз шул турыда бара.

[3] Я п т ы л а р — газетаны чыгарудан туктаттылар.

[4] Б а я н — Нур Баян (1905—1945), шагыйрь; Бөек Ватан сугышында һәлак булды.

*21 ноябрь, 1944 ел*

**Әбҗәлттин!**

Калын (!) җилкәңә атланып, муеныңнан кочып үбәм үзеңне! Элекке кебек, урамдагы исерек түбәләшүчеләрне аерып, милициягә илтергә яратучы батыр, таза, гайрәтле, куәтле, дәһшәтле (беттеме, әллә тагын бармы!) һәм добродушный Әбҗәл булсаң, бу наянлыгымны, шуклыгымны, шаянлыгымны (үзең сайлап куй!) гафу итәрсең. Иптәшләрне сагынып искә алганда, сине **а е р у ч а** (48 ж. баш)[1] юксынып, искә алам. Әллә бик озак заманнар тәрҗемә өстендә бергәләп «бөкре чыгарганганмы» (минеке һаман чыга да чыга!) һәм бергәләп «тирес башын» актарганганмы[2], әллә үзең шундый добродушный әдәм булганганмы, син минем күңелдә **а е р ы м** (курсив) урын тотасың. «Менә кызык!» — диярсең инде син. «Торып-торып торҗагун, исән торасыңмы! 40 яшькә җиткәч (40 бик тиздән! Ә синекен әйтергә дә куркам инде мин — цензура кызлары, куркып, хатны ташлаулары мөмкин!), кырыкка җиткәч, безнең Ибраһим гакыйга җиңеләйгән, ахры, үзенең иске дусларына мәхәббәт изһар итә башлады»,— диярсең. Теләсәң нәрсә әйт. Күңелдә барны яздым.

Мин, Карпат тирәсендә тау төшә, тау менә бераз йөргәч, пайтәхеткә чакырылып, 1 нче ак руска[3] бәрәңге ашарга озатылдым. Резерв дигән җан биздергеч җирдә бераз кыйналгач, 1 нче ак рустагы тастымалның[4] бер почмагыннан барып тоттым. Тиздән, бәлки, сез безнең тастымалга кул (кул гынамы!) сөртә башларсыз.

Теге немецлар өчен алган(мы!) орденың белән котларга рөхсәт ит. Инде сиңа орден тегеләй дә, болай да бирелергә тиеш, чөнки син — Шиһабетдин үгезе[5] — газетагызда вол урынына эшләп килдең һәм кучеп-нитеп йөрмәдең. Ә 7 мимечны да плен алгач, берәр йолдыз (күктән алып булса да) бирәсе иде. Мин булсам, йолдызын да, аен да бирер идем сиңа. Анысы инде, малай, берәүгә йолдызы, ә синең белән миңа: «Йом күзең» — маңгаеңа сукканда чәчрәп чыкмасын. «Яшәсен аркадагы бөкре!» Тагын бераз үссә, айга да, йолдызга да барып тияр!

Нәрсә булса да язасыңмы! Синең дәшми ятуыңнан курка башладым инде мин; дәшми-дәшми торып, өстәлгә, шалт иттереп, берәр роман чыгарып саласыңмы инде син! Алдан ук әйтеп куям: көнләячәкмен! Көнләячәкмен, ләкин сөенәчәкмен. Әгәр инде тагы очерклар тупламасы гына булса, шулай ук алдан әйтеп куям, минем кашлар җыерылган булыр. Ә күзләр күзлек өстеннән ачулы карарлар.

Кутуй[6], язарга комачаулап, уң ягымда сөйләнеп утыра. Сәлам язарга кыстый. Сәлам аңардан. Ярмәки[7] сөйләнмичә генә сул ягымда утыра. Күзлеген әле сала, әле кия — кигәчме яхшырак күрә, салгачмы — әйтми.

Я, бир кулыңны. Сау бул!

Гыймадига сәлам әйт. Абдуллага да сәлам күндер.

Хат көтеп дустың

ИБРАҺИМ.

Адресым болай: 48251-А.

---

[1] (48 ж. баш) — 48 пунктлы кара баш хәрефләр; типография билгесе, эре хәрефләр белән җыярга кушу.

[2] «Тирес башын» актаргангамы — Татарстан китап нәшриятында безнең кулга эшләнеп бетмәгән әдәби әсәрләр, начар тәрҗемәләр еш кына килеп кергәли иде. Шундый кулъязмалар өстендә эшләүне без «тирес башын актару» яисә «тирестән энҗе-мәрҗән эзләү» дип атый идек. Бу очракта Ибраһим шуны искә ала.

[3] 1 нче ак руска — Беренче Белоруссия фронтына.

[4] Тастымалның — газетаның. Татар телендә чыккан «Кызыл Армия» газетасы күздә тотыла.

[5] Шиһабетдин үгезе — бу исемнең дә үзенә күрә тарихы бар. Сабый чагымда мине абыйларым үз яшемдәге күрше малайлары белән кәрәштерергә яраталар иде, хәтта сөзештерәләр дә иде. Олылар кушкач, җитмәсә, мактау сүзләре әйтеп, дәртләндереп, котыртып та торгач, без чын күңелдән бирелеп, күзләребездән утлар чәчрәгәнче тырышып сөзешә идек. Сөзештергәндә мине Шиһабетдин үгезе дип атыйлар иде (әтием Шиһабетдин). Бервакыт мин, бала чагымны искә төшергәндә, моны Ибраһимга сөйләгән идем. Аңа, һәртөрле шаянлыкны, уйнап-көлеп сөйләшүне яратучы дустыма, бу җитә калды, шуннан соң ул мине кайвакытларда, бигрәк тә авыр эш эшләгәндә, мәзәкләп, Шиһабетдин үгезе дип атый башлады.

[6] Кутуй — Гадел Кутуй (1903—1945), язучы, югарыда телгә алынган газетаның хәрби хәбәрчесе. Бөек Ватан сугышыннан соң хәрби госпитальдә вафат булды.

[7] Ярмәки — Ярулла Ярмәкиев (1905—1968), журналист, шул ук газетаның редакторы.

*14 январь, 1945 ел*

Әбҗәлттин!

Үзең язмагансың да, озын колаклардан ишетеп кенә белдем. Не хруша[1], егет! Орден алуың түгел, әйтмәвең не хруша! [...]

Әллә минем хатлар барып җитми, әллә син хат яза белми башладың, һич кенә минем хаттагы мәсьәләләргә җавап язмыйсың.

Нәрсә дә булса берәр нәрсә (мәсәлән, повесть, руман![2] Тыңдагылар руман язалар!) язасыңмы, әллә вак-төяккә чәчелеп бетәсеңме! Минем «Апар өчәү иде»не укыдыңмы! Ник берәр сүз әйтмисең! Язучының күңеле мактау көтә бит, каһәрең...

Минем планнарым зур, ләкин үзең беләсең: план — это люди, это мы с вами, ә мин хәзергә «люди» түгел, «люд» та түгел, ә люди кушканны эшләп кенә йөри торган бәндә... Бу сугышта йөрү бик күп нәрсә бирде, малай: вакыт булса, хәзер хикәяне коймак урынына (коймакның хәзер еш пешмәгәнен дә искә алганда) пешерер идем. Повестьлык та материал бар. Синең дә күптер инде хәзер, ә!

Синең күкрәккә бераү (котлы булсын!), күршесендә тагын ике урын әзер — көтеп торалар. Яшәсен киң күкрәк!

Гыймадига, Абдуллага сәлам сөйлә.

Минем моннан элек сиңа мәхәббәт изһар итеп язган хатымны алдыңмы! Ник җавап язмыйсың!

Кара әле, Әбҗәл, ходай язып, Казан каласында, синең, я минем бүлмәдә (шкафтан китаплар карап тора!) очраша калсак, московский-особыйны өстәлгә утыртып

**(кызыл-мызыл бер якка китсен, интеллигентлар һәм кызлар эчемлеге!), бер рәхәтләнеп сыйланыр идек, ә! [3]**

**Я, хуш! Мә минем ябык кулны!**

Дустың ИБРАҺИМ.

---

[1] Не хруша — не хорошо.

[2] Руман — роман. Соңгы ике сүзне, гадәтенчә, шаяртып әйтүе.

[3] ... сыйланыр идек — Ибраһим градуслы эчемлекләрне бервакытта да эчмәде. Бу аның: «Эчмәүчеләрдән булсак та, явыз дошманны тәмам җиңгәннән соң, шатлыгыбыздан шулай да синең белән бер эчәр идек»,— дип язуы. Гаеплебез: Бөек Җиңү көнен, бик олылап, күп мәртәбәләр искә алсак та, аны беркайчан да аракылы касәләр белән үткәрмәдек.

## *Кыям Хисмәтуллинга*

*5 февраль, 1966 ел*

**Кыям туган, мин сиңа инде әллә кайчан җавап язарга тиеш идем. Катокта шуып йөреп салкын тидердем дә авырып яттым. Сәламәтләнгәч тә кулга каләм аласы килмәде. Бик арылган.**

**Син онытты дигән шикеллерәк үпкә белдергәнсең. Хат язышмауны онытты дип санаганда, син мине дә оныттың. Казанга килгәч, Ярмәки янына керәсең икән, минем янга — юк! Ләкин мин үпкәләмим. Ә сине онытканым юк, гел искә алам. Тәмәке төтененә төренеп, тезеңне чәнчеп утырып торганың бер дә күз алдымнан китми. Ростовтан алып, Шахталар аша, Мелитопольләр, Карпатта, редакция әйберләрен саклап, нинди-дер сарай чормасында кунуларыбыз, аннары соңгы Берлин, Потсдамдагы тормышлар һич күз алдымнан китми. Мине бик гаҗәпләндергәне — синең сөйләшмәвең. Синнән бит сүз алып булмый торган иде. Гел бер үзең утырасың: баш турында болыттай тәмәке төтене, тезне кочаклагансың, бармак арасында папирос. Ни уйлый бу кеше, ничек япа-ялгыз утырып тора ала — һич төшенә алмыйм.**

**Инде Чирмешәнгә килгәндә, Чирмешән юлында мин бит үз иркемдә кеше түгел. Бригада. Кая алып барсалар, шунда барам. Сине мин уйладым. Шушы тирәдә Кыям тора бит, дим, сине яшел шинелең белән күз алдына китерәм, фуражка бераз кырын салынган, иреннәр җәелгән — елмаясың... Шул килеш син мәңгегә минем күңелдә калган. Ләкин хат алмаганга ничә еллар. Шушындамы ул хәзер! Кил дип чакырганы да юк. Барам дисәң, машина да юк. Шулар барысы бергә мине синең янга алып бармады. Аннары минем бер гадәтем бар — кешегә комачау итүдән мин, уттан курыккан кебек, куркам. Картая барган саен шушы тойгы миндә көчәя бара.**

**Үз тормышыма килгәндә, «Онытылмас еллар» романының II китабын язып бастырдым. Озакламый русчасы басылачак. Аннары «Канатланыр чак» дигән бер повесть язып ташладым. Анысы быел март-апрель саннарында «Казан утлары» журналында чыгачак.**

**Картая баруымны сизәм. Хәзер инде теге еллардагы кебек эшләп булмый. Җәйләрен дачада ятам. Бакча карыйм, чәчәк үстерәм. Җәйли Казанга килсәң, Язучылар союзына кереп, Лебяжье дигән җиргә ничек барасы дип сорашып, минем янга сугыл. Сөйләшеп утырырбыз. Автобус гел йөреп тора. Местный вокзал янынннан китә. «Казань — Зеленый дол» дигәнгә утырырга кирәк. Лебяжье дигән тукталышта төшеп каласың. Аннары уңга борылып, урман эчләп, балалар лагерьлары янынннан безгә. Сорасаң күрсәтерләр. Дача писателей дип сора. Билет бәясе (Казаннан безгә хәтле) 20 тиен.**

**Фатих Хөсни исән-сау йөри. Ул да картая инде, чәчләре агарды, тамак аслары салынды. Ярмәкине гел күрәм. Пенсиядә булса да, эшләп йөри. Картайса да әллә ни бирешми әле.**

**Миңа хат язарга уйлаганда болай язарсың: Казань, центр, а/я, 12.**

**Карчыгыңа сәлам диген. Мин аны рәтләп белмим бит. Казанга килгәндә бер күргән идем.**

**Я, сау-сәламәт булып торыйк. Ибраһим.**

---

Кыям — язучының фронтовик дусты Кыям Хисмәтуллин.

# *Гариф Ахуновка*

*4 декабрь, 1968 ел*

Гариф, китеп эзең дә суынып җитмәде (тышта — 30° суык булса да), артыннан хат чыгып чапты.

Тегe Зарипов [1] белән эшлисе китабыгызның кульязмасы,— дип кайтып әйтте Мурзаһит Фатхеевич [2],— март аенда Мәскәү нәшриятында булырга тиеш. 10 табаклык китап [3], ике ай калып бара, аена 5 табак язарга син әзерме! Мәскәүдә чакта, нәшриятка кереп, белешеп чык.

Бу булды бер. Икенчесе. Тәрҗемәләр өчен түләргә 300 сум акча табылды — каяндыр килеп чыкты. Нинди тәрҗемәләр өчен, кемгә түлисебез бар,— шуны әйтеп телеграмма сук.

Киткәч тә тынычлык юк!

Равил [4] килде, эшли башлады. Казандагы 30° ка син эләкмәдең, борының исән калды.

Декабрь ахырында Мәскәүдә пленум [5] була дип ишеттек, син шунда килерсең бит.

Хуш!

ИБРАҺИМ ГАЗИ.

---

[1] Зарипов — Марсель Зарипов, язучы һәм журналист.

[2] Мурзаһит Фатхеевич — КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев.

[3] 10 табаклык китап — «Без Казаннан, Иделдән» исемле китап. 1971 елны «Советская Россия» нәшрияты бастырып чыгарды. Татарстан турындагы очерклар тупланган.

[4] Равил — Равил Фәйзуллин, шагыйрь, Язучылар союзының Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре. Г. Ахунов ялда чакта Казанда, Язучылар союзында эшләп торды. Хат язучыларның Мәскәү янындагы иҗат йортына — Малеевкага җибәрелгән иде.

[5] Мәскәүдә пленум — РСФСР язучылар союзы пленумы. Ред.

*13 декабрь, 1968 ел*

Гариф, пленум хакында безгә хәбәр җибәргәннәре юк. Син пленумда бул. Ленин темасына язылачак китаплар турында чыгып сөйлә. Син аларны күңелдән дә беләсең. Аяз Гыйләҗев Ленинга бәйләнгән пьеса яза — Парадский затонны меньшевиклар демонтировать итәргә җыеналар, эшчеләр, күтәрелеп, Ленинга телеграмма сугалар һ. б. һ. б.

Мин әллә барам, әллә юк. Син, бер кич утырып, хәзерлән. Син — каласы кеше, мин — китәсе. Күрен шунда, аралаш.

ИБРАҺИМ АБЫЕҢ.

---

Бу хат та Язучыларның Мәскәү янындагы иҗат йортына — Малеевкага җибәрелгән.

*Агреппина Сердинскаяга*

III корпус, 1 этаж, 7 комната

*26 октябрь, 1970 ел*

**Әнисе, китәм, ә күңелдә тынычлык юк. Син өйне тутырып, матурлап тора идең, син булмагач, өй буш, җансыз, шыр... Температураң гына төшсә дә яшәү күңеллерәк булыр иде, синең җанып ятуыңны белеп торгач, бик кыен... Ашыйсы килми, тынычлап йокыга ятасы килми.**

**Үзем авырсам, миңа ансат булыр иде, менә хәзер генә мин синең җәйли бик каты борчылуыңны аңладым, синең авыруың минем үзем авырудан кыенрак.**

**Тик шуның белән юанам, син хәзер врачлар кулында, алар кирәк чакта ярдәм итәрләр, өйдә ятуга караганда врачлар янында тизрәк сәламәтләнүеңә өмет бар, шул уй мине юата, тик барыбер бушлыкны тутыра алмый.**

**Я, әлегә хуш. Берничә көннән кайтырмын.**

**Балаларга әйтеп калдырам, сине карарлар. Тик ул су ташуның кирәге булырмы, шул ук чәй суыдыр бит ул! Кирәк тапсаң сорарсың, мин Ритага әйттем.**

**Оля укып утыра, бу хатны кичтән язам, чөнки самолет иртән сәгать 10 с. 25 м. китәргә тиеш, һава ирек бирсә.**

**Әлеге шул картың.**

---

1970 елның көзендә — 27/X дә Казан язучылары Әлмәткә «Әдәбиятта хезмәт кешесе образы» дигән темага киңәшмә уздырырга бардылар. И. Гази бу хатны шунда китәр алдыннан больницага хатыны А. Сердинскаяга язган. Ред.

# ТӨРКМӘН ШАГЫЙРЕ КӘМИНӘ



Узган елда шагыйрь Мәмәдвәли Кәминәнең[1] тууына ике гасыр тулды. Кәминә исеме Төркмәнстанда олыга да, кечегә дә таныш, аның шигырьләрен, аның турындагы мәзәкләрне республикадан читтә дә бик күпләр белә.

Ул бала чактан ук белемгә омтыла, башта мулладан сабак ала, аннан Бохара мәдрәсәсендә укый. Тормыш алып бару, хәлфәләргә түләү өчен берниндн эштән дә баш тартмый. Ниһаять, аңа мулла булып мул тормышта яшәү мөмкинлеге туа. Әмма Кәминә — хөр фикерле һәм бунтарь йөрәкле егет — башка юл сайлый: ул халык күңелендәге хисләрне җырга сала.

Феодаллар изүеннән, ачлыктан һәм хокуксызлыктан интеккән халык Кәминә тавышын бик тиз ишетә. Шулай булмый хәле юк. Кәминә шигырьләрендә киез тирмә, балчык алачык эчендә сөйләнгән аһ-зарлар, изүчеләргә карата протест бар. Аның шигырьләре ачы язмышка баш имәскә, гаделсезлеккә каршы көрәшергә өнди. Бөек төркмән шагыйре Мәхтүмкули иҗатындагы демократик мотивлар Кәминә шигырьләрендә тагы да куәтлерәк яңгыраш ала.

Шагыйрь тормышта бик күп кыенлыклар кичерә. Әмма ул беркайчан да рухи төшенкелеккә бирелми, реакцион көчләргә каршы үткен каләме, көйдергеч мәзәкләре белән армый-талмый көрәшә, изүчеләрне фаш итә, җәмгыять алдында аларны көлкегә калдыра.

Төркмәнстан тарихында Кәминә гаять катлаулы чорда — XVIII гасырның ахыры һәм XIX гасырның башында иҗат итә. Ул чорда төркмән кабиләләре феодаллар, байлар, руханилар изүеннән җәфа чигәләр. Алар арасында политик бердәмлек булмый. Шуның өстенә, төркмән кабиләләре, Россиягә кушылганга кадәр, басып алучылар белән өзлексез көрәш алып барырга да мәҗбүр булалар. Ә хезмәт ияләре тормыш өчен иң кирәкле нәрсәдән — җир-судан мәхрүм ителә. Кәминә руханиларга каршы сүз әйтүдән дә курыкмый. Алар каршында ул дәһри исемен ала.

Кәминәнең мәхәббәт лирикасы да заманы өчен үзенчәлекле. Ул, борынгы көнчыгыш шагыйрьләренең күпчелеге кебек, хатын-кызны җәннәттәге хур кызлары итеп түгел, тормыш юлдашы итеп, шатлык-кайгыны уртаклашучы хезмәт кешесе итеп сурәтли.

Төркмәнстанда ул заманда язу таный белүчене эзләп авылдан авылга ат куарга кирәк була. Кәминә замандашларының күпчелеге китапны төшләрендә дә күрмәгән. Шуңа күрә Кәминә шигырьләре, Сәйди, Җәлили, Молланепес әсәрләре кебек үк, халык арасында телдән-телгә күчеп таралган.

---

[1] Кәминә — шагыйрьнең кушаматы, хадимегез — хезмәтчегез мәгънәсендә.

Аның әсәрләре үзе үлгәннән соң ике ел үткәч, 1842 елда гына беренче тапкыр дөнья күрә. Поляк шагыйре һәм галиме Александр Леонардович Ходзько-Борейко аның бер шигырен инглиз теленә тәрҗемә итеп бастырып чыгара. Революциягә кадәр рус галимнәреннән А. Самойлович һәм А. Крымский төркмән әдәбияты турындагы хезмәтләрендә Кәминә иҗатына да тукталалар.

Бары тик Бөек Октябрь революциясеннән соң гына тикшеренүчеләр чичәннәрдән шагыйрьнең күп кенә әсәрләрен язып алалар. Бөек Ватан сугышы алдыннан төркмән һәм рус телләрендә аның сайланма әсәрләре басылып чыга. Кәминәнең күп кенә әсәрләре СССР халыклары телләренә тәрҗемә ителә. Хәзер аның шигырьләрен рус, казакъ, таҗик, татар, үзбәк, украин, чуваш, кыргыз, әзәрбайҗан телләрендә укыйлар.

Кәминәнең үзе турында да әдәби әсәрләр язылды. П. Скосыревның «Хадимегез», К. Корбансахатовның «Кырык тәңкә» повестьларын халык яратып укый. Б. Алсапановның «Кәминә» комедиясе, Д. Овязов белән А. Шапошниковның «Кәминә белән казый» операсы да уңыш казанды.

Халык Кәминәне онытмый, чөнки аның шигырьләре халык күңелендәге хисләрне чагылдыра. Аның иҗаты — халык тормышының бер сәхифәсе.

Түбәндә без төркмән шагыйре Кәминә шигырьләрен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.

## Ярлылык

Көнгә йөз чирем бар, меңләгән бәлам,
Барча чир-хастадан начар ярлылык.
Әзеңә төшеп, гел кайгы-гамь белән,
Яныңа килер дә басар ярлылык.

И фани дөньяның зиннәт, ямьнәре!
Ачлыктан бәгырем ташка әйләнде,
Түләнмәс бурычтан куллар бәйләнде,
Елдан-ел катырак буар ярлылык...

Ашамый-эчмичә тәнгә көч үтмәс,
Бөрешеп ятарга карарым җитмәс,
Көнгә мең кусам да, байларга китмәс,
Янымда сулкылдап елар ярлылык.

Табар ул һәр төштә сине гел генә,
Бәйләр ул каешен кысып биленә,
Алыр ул таш башлы чукмарын менә,
Китереп башыңа сугар ярлылык.

Бу хәлдән — бәладән кем алып чыгар,
Ярлының йөзенә кем көлеп багар?
Ярышсам — йөгерек ул, көрәшсәм — егар,
Отышлы уйнасам — отар ярлылык.

Сәйранда йөрмәдем гизеп чүлләрдә,
Сәфәрләр кылмадым ерак илләргә,
Былбыл идем бер — кунмадым гөлләргә,
Янымда булганга каһәр ярлылык.

Кәминә: һәр нигә бар, диер, үлем,
Берәүгә — туй-бәйрәм, берәүгә — золым:
Кыйналма, сыкранма-сызланма, күңелем,
Килгәндәй — бер заман китәр ярлылык.

## Фәкыйрь

Ялварамын «бай ага!» дип, ябышам сагыз кебе,
Баскычында бай аганың мин фәкыйрь ком бөртеге,
«Бир әҗәтеңне кире!» дип, юк кабармаган көне,
Угрыдан, фахишәдән дә чирканыч бай, үлгере,
Бер ходайның органы, һәр җирдә сансыз бит фәкыйрь.

Ел башында нан сорап эше ишек какмак булыр,
Челеме юлдаш, янында гел аның чакма булыр,
Тез чүгәр, үз корсагын утларда ул якмак булыр,
Гәпләшә китсә сүзе булмас — гүя ахмак булыр.
Ил кучәр, ялгыз калыр тереләй черергә тик фәкыйрь.

Байгурага — мал-туар, ә ярлыга кыйммәт ватан,
Бер юлы ике көймәгә атланып кем батмаган?
Ярлының кызын җәберләп кем генә елатмаган?
Ярлылык-юклык Кәминә җанына ут каплаган,
Аны онытырлар, калыр тереләй черергә тик фәкыйрь...

## Казый

Котлы булсын сәфәрегез!
Догадан ташламаң, казый:
Йөк авыр — сынар билегез,
Мин әйтә башласам, казый.

Көн эсседә йөреп булмас,
Җанга ямау тегеп булмас,
Йорт кәҗәсе киек булмас,
Аңа нигә далаң, казый?

Ялган шаһит икән бит сез,
Таралган илдә шундый сүз:
«Ул вөҗданын кич вә көндез
Сата», — диләр, — яман, казый!

Кәминәгез үтерер мактап,
Барча әйтер сүзләрем хак,
Килер бер көн — үч алыр чак,
Явыз дип дан алган казый?!

## Сәлбиназ

Гамь кәрваны йөрәгемә юл үтте,
Көндәшләрем уң әшемне сул итте,
Тинтерәтеп күз яшемне күл итте,
Яшел язым, киек казым, Сәлбиназ!

Буй-сыныңны уйнаклатып барасың,
Кырыс караш белән җаным аласың,
Җырчың көтә кочагыңа барасың,
Мәхәббәтең белән янып, Сәлбиназ!

Мин Кәминә, гизеп чыктым илләрне,
Очратмадым синең кебек чибәрне.
Җаным тели, кочак ачып кил әле,
Киек казым, яшел язым, Сәлбиназ!

## Яшь киленнәр

Килгәнсез хуш, хушлык белән китәрсез,
Җиргә бәхет өчен туган киленнәр!
Хәрабә шәһәрем төзек итәсез,
Мине йолып кайгылардан, киленнәр.

Ак тирмәләр иясе, хан кызлары,
Атыйлар сезне — күңелләр солтаны.
Хезмәтчегә лаек күрче без ярны,
Җанга сөю нуры салган киленнәр.

Ир — чичәнлек, кыз — чибәрлек белән шәп.
Бәһасы андыйларның бездә кыйммәт.
Буйга зифа, йөзгә көләч бер сурәт,
Сый-хөрмттә дан казанган киленнәр.

Ай йөзенә кара пәрдә ябылган,
Гүя гүзәл айга болыт сарылган,
Сырхавыма минем имче табылган,—
Сез ул чирдән алып калган, киленнәр.

Җиләк-җимеш кебек сез татлы телгә,
Сүзегез бал шикелле хуш күңелгә,
Кәминәгә кызыл гөлләр бирергә
Ашыгыгыз, сабрын алган киленнәр.

●

Бернинди хәбәрсез көн арты көн үткән,
Сизмәдем бәлане, гамьсез җан булганга,
Кайгылар керделәр биксез ишектән,
Сулышым тар минем далада тусам да.

Йөземне чөердем дуслардан-ишләрдән,
Чәчәкләр өзмәдем салкынча кичләрдә,
Бер кабым капмадым, кайгыга төшкәндә,
Ашамлык-эчемлек алдымда торса да.

Кайда син, дускаем, хәятым, чырагым?
Тауларга мендем мин — ай-дала һәр ягым.
Җәядәй бөгелеп, ялгызым калганым,
Бу җирдә яшәүче үз халкым булса да.

Үрелдем күкләргә — кулларым җитмәде,
Карадым җиремә — җаннарым тетрәде:
Аягым астында еланнар тезмәсе
Шикелле үзәннәр күңелгә шом сала.

Кырмыска-бөҗәккә дә оя бирелгән,
Черки дә аерылмый канатлы иленнән.
Ханчалар кызганмый хезмәтен иренә,
Ханчам юк йортымда, ялгыз мин тол бала.

Кәминә, иректә үзеңне юаттың,
Утызны үткәрдең — яшьлегең югалттың.
Ахырдан тик чытык елларны очраттың,
Шатлыклар үттеләр югала-югала.

Төркмәнчәдән Нури Арсланов тәрҗемәсе

## Былбылга кил

Әй, сөеклем, җилфердәп, йөз мең балку белә кил,
Керфек кагып, елмаеп, уйнап көлә-көлә кил,
Табып татлы сүзләрне, тутый коштай телгә кил,
Кызыл кигән җан дустым, таң атканда гөлгә кил,
Гөлнең зарын теләсәң, мин мескен былбылга кил.

Алтын, көмеш, зөбәрҗәт ак муенга тагасың,
Миннән йөзең яшереп, качып кына багасың,
Кергән чакта баш иеп, җаным утка ягасың,
Тотып булмас киектәй, кулым сузсам, чабасың,
Төш, шонкарым, ялварам, төшеп, минем кулга кил.

Син гүзәлгә баш иеп, дусларымнан бизәм мин,
Йөз мең газап күрсәтеп, җаным алсаң риза мин,
Көндез күрсәм сыныңны, кичен чигәм иза мин,
Гашыйк булдым, аһ, сиңа, кызыл кигән кызга мин,
Ал кулыңа хәнҗәрең, бгырем теләтелә кил.

Күңлем таба юаныч, ярга күзем төшкәндә,
Йөзен күреп ярымның, күзләрем камашканда,
Кунып кипарисларга, былбыллар сайрашканда,
Бакчаларда шаулашып, гүзәлләр уйнашканда,
Мин булсам Гашыйк-гарип, син Шаһсәнәм була кил [1].

Кәминә, ярың исме — «кяф» артыннан «лям» булды,
«Җим» белән «мим» артыннан шул «лям» янадан булды [2],
Кипарислар елмайды, бакчага гөлләр тулды,
Бу — сүземнең ахыры, ул шунда тәмам булды,
Язам ярның сыйфатын, каләм-кара ала кил!

---

[1] Гашыйк-гарип һәм Шаһсәнәм — көнчыгыш легендасы геройлары.
[2] Кяф, лям, җим, мим, лям — гарәп хәрефләренең исемнәре. Шуларны бергә кушканда «клҗмл» булып чыга һәм ул «гөлҗамал» дип укыла. Димәк, шагыйрьнең мөрәҗәгать иткән сөеклесе Гөлҗамал исемле булган.

## Сүзем бар сиңа


Кара күзле, каләм кашлы гүзәл яр,
Әйтә генә белмим, сүзем бар сиңа.
Көям гыйшкың утында, орып аһлар,
Бер күрергә ике күзем зар сиңа.

Диванамын, чәчләреңә баглама,
Хәнҗәр алып, йөрәгемә кадама,
Кунагың мин, ишегеңнән каулама,
Әллә ятмы намус белән гарь сиңа?

Муеныңа алтын, энҗе такмыйсың,
Һомай күзең сөзеп, керфек какмыйсың,
Минем йөз мең сүземә бер бакмыйсың,
Ничек ярыйм, нишләсәм ошар сиңа?

Мин — Кәминә көттем син ярдан вафа,
Вафа көттем, ә син күрсәттең җәфа,
Гыйшкың белән чирлим, бир, зинһар. шифа,
Шифа сорап килде хәстә яр сиңа!

Әхмәт Исхак тәрҗемәсе



**Диас Вәлиев**

# ХӘРӘКӘТТӘ БӘРӘКӘТ

*КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Рәис Беляев, Кама автозаводы төзелеше начальнигының беренче урынбасары Евгений Никонорович Батенчук һәм «Гидропроект» институтының техник бүлеге баш белгече Иосиф Сергеевич Завалишин белән әңгәмә.*

Бер караганда гаҗәп тә кебек: бары тик ике генә ел элек булып узган вакыйгалар хәзерге көн өчен инде тарих булып калды. Ул вакытта бу урыннарда буш дала иде. Тын дала уртасына тимер-бетоннан коелган ике багана утыртылган һәм шуларның берсенә буяу белән: «Биредә Кама автомобиль заводы төзеләчәк» дип язылган иде. Бу якларга килгән журналистлар өчаяклы теодолитлар тирәсендә кайнашкан берничә геодизист белән сөйләшү, аларны рәсемгә төшереп алу белән генә чикләнәләр иде. Бүтәнчә мөмкин дә түгел, чөнки бульдозерлар актарып ташлаган туфрак өемнәре, тирән чокырлардан үсеп чыккан нигез чөлтәрләре, тимер-бетон каркаслары юк иде әле. Озак та үтмәде, «Правда», «Труд», «Известия» һәм башка газеталарда бу төзелеш турында берничә юллык информация басылып чыккач, илебезнең төрле почмакларындагы меңнәрчә, ун меңнәрчә кеше хәрәкәткә килде, бу якларга әллә ничә төрле машина агыла башлады.

Менә шуннан соң ике ел вакыт узды...

Мин шул вакыттагы язмаларымны актарып утырам. Барысы да хәтердә. Әмма Чаллының бүгенгесе мәһабәт. Электәге язмаларымны бер читкәрәк этәрәм дә КамАЗга соңгы баруымда язган блокнотларымны укырга керешәм... Төрле кешеләр белән әңгәмәләр, төзелеш күренешләре... Тормыш детальләре...

«Быел безгә меңгә якын нигез салып, монтажчыларга тапшырырга кирәк. Монтажчылар 33 мең кубометр тимер-бетон каркас, 10,5 мең тонна металл конструкция корырга, 234 мең квадрат метр плита коярга тиеш. Болар — производство бианалары һәм корылмалары гына. Төзелеш индустриясе, ТЭЦ, шәһәр йортларын салу буенча да шул кадәр үк эшләр алда тора...»

«Без бит, ачуым да килмәгәе, тавык кетәклеге салмыйбыз! Без Европадагы иң зур төзелешкә килдек!..»

«Планёркаларда гы сүз боткасы туйдырды инде. Безгә эш эшләнгән булсын. Әшкә сәләтең юк икән, гаризаңны яз! Биш йөз урынлык ашханәне дә срогына төзеп бетерә алмыйбыз икән, безгә бирәдә маташасы да юк. Бүтәннәр килер, бүтәннәр төзер. Алар безнең кебек булдыксыз булмаслар...»

«Башкалар кешечә яши, ә без... тормышмыни бу?.. Өйгә төнге унберДә кайтам, ашыйм-эчәм дә мендәргә авам. Эш процессы тиешенчә оештырылмаган, хезмәтеңнең файдалы эш коэффициенты аз. Шимбә көннәрендә ял итәргә тиешлегемне дә әллә кайчан оныттым инде. Хәтта якшәмбедә дә ял итәргә ирек бирмиләр. Гаиләнә дә тәүлеккә берничә минутка гына күрәсең. Шайтан белсен, балалар кай арада тугандыр да нидән булгандыр... Братскида эшләдем, Красноярск ГЭСын төзедем... Сине тиргиләр, начар эшләгән өчен син бүтәннәрне тиргисең. Тормыш шулай инде ул. Төзисең, кибет, мәктәп, балалар комбинаты, ашханә, кафэ, ит комбинаты, культура сарае саласың. Һаман җитми. Азык-төлек, дефицит товарлар төялгән эшелоннар атна буе бушатуны көтеп торалар. Складлар, базалар юк. Сиксән километр тимер юл, җитмеш километр автомобиль юлы салырга кирәк. Аларсыз һич мөмкин түгел: Бөгелмә — Круглое Поле арасындагы станцияләр, разъездлар поезд составлары белән тулган. Шәһәрдә быелдан ук трамвай йөри башларга тиеш. Мең кешеле йортларга эссе пар җибәрәчәк ТЭЦ казаннарын торгызу да никадәр көч куюны сорый...»

Блокнотларда әнә шундый өзек-өзек язмалар күп. Әлбәттә, аларны теркәп бару өчен уннарча километрларга сузылган төзелеш мәйданында күп йөрергә, куәтле «КрАЗ»лар, «БелАЗ»лар, «МАЗ»лар үтеп киткәндә болытларга кадәр күтәрелә торган Чаллы тузанын йотарга, дистәләгән кеше белән сөйләшергә, аларның тормышларын өйрәнергә туры килде.

— Безнең төзелештә барлык эшне берьюлы башкарырга кирәк,— дип сөйләп китте партиянең Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре **Рәис Беляев**.— Төзелештәге объект исемнәрен теркәп бару өчен генә дә әллә нихәтле кәгазь кирәк булыр иде. Яңа шәһәрдә бары тик бер квартираны өлгертү өчен төзүчеләргә өч йөз илле мең кеше яшәячәк бөтен шәһәрнең барлык инженерлык коммуникацияләрен күз алдында тотарга кирәк булды. Бер проблеманы хәл итә башласаң, йөзләрчә башка проблема туа...

Төзелеш начальнигының беренче урынбасары **Е. Н. Батенчук** болай диде:

— Чаллы автозаводы төзелешенең төп үзенчәлеге шунда: проект эшләре төзелеш белән бер үк вакытта алып барыла. Әлбәттә, башта төзелгән проект буенча эшләү ансатрак, уңайрак. Әмма, болай булганда, Кама автозаводы кебек гигант төзелеш бик озакка сузылыр иде...

**— Сезнеңчә, хәзер эшнең иң мөһиме кайда! Нинди кыенлыклар алда тора! Иң төп проблемалар нәрсәдән гыйбарәт!**

**Р. Беляев.** Әлегә берничә мәсьәлә бер төенгә бәйләнгән. Мәсәлән, төзүчеләр коллективын туплап бетерү. Гаять катлаулы проблема бу. Икенчедән, торак йортлар салу, культура, көнкүреш объектларын өлгертү. Өченчедән, төзелеш индустриясе базасын — йорт төзү комбинатын салып бетерү, күзәнәкле бетон заводын киңәйтү һ. б. лар. Дүртенчедән, автозавод төзелешенең барлык объектларындагы төзү-монтаж эшләре. Кыскасы, җитмеш беренче елда төп бурыч — төзелешнең дәвамы өчен ныклы тыл булдыру иде. Темпны тагын да үстерү, алга зур сикереш — плацдарм булдырмыйча мөмкин түгел. Боларның барысын да чынга ашыргач кына — хәзер инде без моңа ирештек — төзелешнең икенче, өченче этабына юл ачыла...

**Е. Н. Батенчук.** Узган ел төзелештә эшләр катлаулы булды. Төзелеш мәйданы тиешенчә әзер булмау, төзелешнең үз базасы җитәрлек тәэмин ителмәү, торак урыннары һәм кадрлар җитешмәү темпны шактый киметте. Әмма темп мәсьәләсенә гадәттәгечә карарга ярамый, чөнки шундый зур завод салуны шулкадәр кыска вакыт эчендә башкарып чыгу әле моңарчы дөньяда булганы юк иде. Ә ничек соң тиешле графикка керергә? Иң элек, төзелештә эшләүче һәр кеше үз бурычын тирәнтен аңларга, перспективаны күрергә, әйләнә-тирә һәм вакыт категориясен тормыш кушканча итеп күңеленә беркетергә тиеш. Без моңа быел ирешәчәкбез. Моңа ирешкәннән соң инде төзелеш ритмы куәтле инерция алачак. Менә шуңа күрә дә хәзерге

вакытта төзелештә кешеләр генә түгел, фикерләр дә сынала. Проблемалар шул кадәр күп, алар кеше аңына кереп бетәрлек тә түгел. Аларны хәл итү өчен максатның бөтен зурлыгын тоярга кирәк. Безгә хәзер төзүчеләр коллективын туплау, аны төп максатка юнәлдерүне тизләтергә кирәк. Чыннан да, без төзү эшләренең тылын ныклы итеп тәэмин итәргә тиешбез. Барлык омтылышларны да төп максатка ирешүгә юнәлдерергә кирәк!

**— Коллективны оештыру турында тулырак итеп ни әйтергә мөмкин! Мәсәлән, кеше һәм төзелеш проблемасы.**

**Р. Беляев.** Төзелеш мәйданында шундый бер сөйләшү булды. Мин бер сварщик белән очраштым. «Син секретарьмы?» — дип сорый бу. «Әйе, секретарь,— дим,— ни йомыш?» Ул төзелештә эшләргә дип Чаллыга килгән. Кадрлар бүлегендә аны дүрт куллап каршы алганнар. Табигый: сварщиклар бик кирәк. «Рәхим итегез, «Металлургстройның «СУ-1» идарәсенә барыгыз». Сварщикның машинасы юк. һәм ул көне буе «СУ-1»не эзләп йөри. Ниһаять, таба. Әмма, начальнигы каядыр киткән. Ашханәнең кайда икәнен дә белми, кунарга да урыны юк. Икенче көнне начальникны эзләп таба. Ә начальник аның хезмәт кенәгәсен карый да: «Син миңа кирәк түгел, «Автозаводстрой» идарәсенә бар. Анда сварщиклар кирәк, дип ишеткән идем. Ә миңа хәзер бетончылар гына кирәк»,— ди. Егет «Автозаводстрой»га юнәлә. Көне буе аны эзли. Ниһаять, таба. Анда да шундый ук хәл.

Моның белән мин шуны әйтергә телим: кешеләр килеп кадрлар бүлеген эзләргә тиеш түгел, кадрлар бүлекләре үзләре кешеләрне эзләргә тиеш. Дөрес, мондый хәлләр Чаллыда сирәк. Нәкъ менә шундый хәлләр булмасын өчен, хәзер партиянең Татарстан өлкә комитеты, Чаллы шәһәр комитеты, төзелештәге партия комитетлары, комсомол һәм профсоюз оешмалары, төзелештәге җитәкчеләрнең эше бирегә килүчеләрне кирәк урынга кабул итүгә һәм аларга нормаль яшәү шартлары тудырырга юнәлдерелгән.

**— Бу проблеманы хәл итү дә җиңел түгелдер!**

**Н. С. Завалишин.** Әйе, торак урыннары җитми. Торак биналары салырга эшче кирәк. Ә эшче ник җитми? Торак урыннары җитәрлек түгел. Зур төзелешләрнең һәрберсендә шундый хәл туа.

**Е. Н. Батенчук.** Әлбәттә, торак йортлар салу темпы Чаллыда бик зур. Әмма һаман торак урыннары җитми. Салынган йортларның күбесе вакытлыча тулай торак итеп файдаланыла. Әмма барыбер тулай тораклар җитми. Бу проблеманы ничек хәл итәргә? Минем, күчмә йортлардан вакытлы рәвештә поселоклар оештырырга кирәктер. Аннан тыш КамАЗ төзелешендә эшләүче һәр кешедә, һичшиксез, квартира алачагына ышаныч тудырырга тиешбез.

**— һәр төзүчегә квартира булыр дип ышандыра аласызмы соң!**

**Е. Н. Батенчук.** Ышандыра алам. Шул ук вакытта каршылыкларга күз йому да кирәкмәс. Автозавод төзелешендә бары тик чыныккан кешеләр генә эшләргә тиеш. Монда килгән кеше элек үк башын-ахырын уйлаган булсын. Эленке-салынкы йөрүчеләр безгә килмәсен дә. Бу турыда ачыктан-ачык әйтергә кирәк. Әлбәттә, төзүчеләргә башта якын-тирәдәге авылларда, вагоннарда яшәргә дә туры килә. Мондый вагоннарда торучылар өчен бездә хәзер поселоклар төзелә. Әмма мин ышандыра алам: КамАЗ төзергә дип, монда яшәргә һәм эшләргә дип килгәннәр, вакытлыча кайда гына яшәмәсеннәр, алар тормыш өчен кирәкле һәр нәрсә белән тәэмин ителәләр.

**Р. Беляев.** Шуны да истән чыгармаска кирәк: төзелешкә эшчеләр даими килеп тора. Ә торак йортларның өлгерүе ритмлы түгел. Җитмеш беренче елда эксплуатациягә тапшырыласы ике йөз мең квадрат метрдан артык торак мәйданының яртысы бары тик елның дүртенче кварталында гына өлгерде. Шуңа күрә, бик табигый, барлык эшчеләрне квартиралар белән тәэмин итеп бетерү берьюлы мөмкин булмады.

Сәүдә, туклану, транспорт мәсьәләләре буенча канәгатьсезлек күрсәтүчеләр дә шактый. Әйе, боларның һәрберсе игътибар үзәгендә тора. Партия, хуҗалык, профсоюз оешмалары бу проблемаларны тиз арада хәл итү өчен барлык чараларны күрәләр. Әлбәттә, КамАЗ төзү бик күпләр өчен зур имтихан. Турыдан-туры әйтергә кирәк: теләсә кем бу имтиханны тота да алмый.

**— Соңгы айларда төзелешкә тагы ун меңнәрчә кеше килде. Алар, минем, тагын күп кенә проблема тудырганнардыр!**

**Р. Беляев.** Эш килүчеләрнең санында гына түгел. Эш шунда: безгә кемнәр килә, алар төзелешкә барлык көчләрен бирергә әзерме?.. Ә проблемаларга килгәндә, алар күп. Мәсәлән, эшчеләр һәм инженер-техник кадрлар туплау. Комсомол оешмаларына, комсомол путевкалары белән яшьләрне эшкә җибәргәндә, төзелеш таләпләренә яраклы рәвештә аерым һөнәр иярен җыярга вакыт. Конкрет социаль тикшеренүләр шуны күрсәтте: безгә килгән эшчеләрнең 71,3 проценты сигез класс һәм аннан югарырак белемле. Партия, комсомол, хуҗалык органнары алдына бу факт шактый зур проблема куя. Иң элек эшчеләрнең квалификация һәм белем дәрәҗәләрен берләштерергә кирәк. Саннарга күчик. Сигез-унбер класс белеме булган эшчеләрнең 43 проценты түбән квалификацияле эшләрдә эшли. Бу нәрсә яшьләрнең күңелен биздерә. Димәк, квалификация күтәрүнең төрле формаларын булдырырга, профессиональ-техник белем бирүне көчәйтергә кирәк. Яшьләргә һөнәр сайлауда мөмкинлек зур булырга тиеш. Әмма әлегә кайбер хуҗалык җитәкчеләре теге яки бу эшчене күңеленә ятышлы эш белән тәэмин итүгә караганда, аны бөтенләй эштән чыгаруны артыграк күрәләр. Һәрнәрсәне тирәнтен уйлап эшләү яхшы. Төзелеш хезмәт күтәренкелегеннән һәм темптан гына гыйбарәт түгел. Төзелеш — тормыш ул. Һәрберсенең үз язмышы булган ун меңнәрчә кеше тормышы. Аларны игътибар үзәгеннән төшереп калдырабыз икән, димәк, Кама автозаводын тиешле срокка өлгертә алмыйбыз...

Чыннан да, Р. Беляев дөрес әйтә, Кама автозаводы белән ун меңнәрчә кешенең язмышы бәйләнгән.

Кама автомобиль заводы...

Андагы кебек зур төзелешләрнең моңа кадәр әле булганы юк дисәк тә ялгыш булмас. Аны төзү, сугышка кадәрге һәм сугыштан соңгы бишьеллыклар чорындагы иң зур төзелеш объектлары кебек үк, илебез өчен бик мөһим. Шуңа күрә дә ул моңа кадәр күрелмәгән темплар белән төзелә. Мондагы төзелеш мәйданы фронт шартларын хәтерләтә. «КрАЗ»лар колоннасы үтеп киткәндә, тузан болытларга тоташа. Бирегә мең төрле машина тупланган. Әйтерсең гаскәрләр бик тә мөһим стратегик ударга әзерләнә. Һәм бу чыннан да шулай. Стратегик, экономик һәм политик әһәмияте бар аның. Бирелә батырлык та, кыюлык та, талант та кирәк. Штурмовщинага, халык байлыгын әрәм-шәрәм итүгә юл куелмаска тиеш. Алдагы елларда миллиард ярым дәүләт акчасын автозаводның гигант корпусларына әверелдерергә кирәк. Шул еллар эчендә миллиард кубометр чамасы җир эше башкарылырга, биш ярым миллион кубометр тимер-бетон, дүрт йөз илле мең тонна чамасы металл конструкцияләрне монтажларга, йөзләрчә километр бетон юл, ике миллион квадрат метрлык торак йорт (аларда тугызынчы бишьеллык ахырында 300 меңнән артык кеше яшәячәк) төзелергә тиеш. Төзүчеләргә шул ук срокта Түбән Камада ГЭСны һәм ТЭЦны төзеп бетерергә, Зәй ГРЭСын дәүләт комиссиясенә тапшырырга, төзелеш мәйданындагы авылларны күчерергә, Чаллы шәһәре тирәсендә агрошәһәрләр салырга кирәк. Боларны башкарып чыгу бик катлаулы эш...

...Кичә мине төзелеш объектлары буйлап бишенче АТХ шоферы Әсәд Әмирасланов озатып йөрде. Ул бирегә Бакудан килгән. Сөйләүләрендә Кавказ юморы. Тирә-юньгә карашы төпле.

— Юк ла, акча эшләргә дип килмәдем мин монда,— ди ул.— 180—220 сум төшә. Квартира да юк. Тулай торакның кухнясында торам. Романтика. Тормыш кайнап торса, тирә-юньдә шау-шу гүләсә — шул миңа тормыш рәхәте. Без кечкенә кеше, җырдагыча әйтсәк: «Рульне туры тот!». Җир тетрәүдән соң Ташкентта эшләдем, Кавказда, Мәскәүдә эшләдем. Нишләп КамАЗда да эшләмәскә?!. Барыбер шул ук йөк ташыйсың. Әмма, йөкне кая ташырга? Кичә миңа кая ташыйсын да белмәдем. Эзлим, эзлим, һич таба алмыйм. Клиент юкка чыккан, печән кибәненә төшкән инәмени. Ә бетон суына. Ни эшләргә? Суынган бетонны бушатып китү дәүләт өчен дә, КамАЗ өчен дә, машина өчен дә, минем өчен дә әйбәт түгел. Күрәм: кызлар, егетләр юл салып ята. «Бетон кирәкме?» — дим. «Бушат әйдә!» — диләр. Көне буе аларга бетон ташыдым. Төзелеш бер үк бит. Бәлки, мин ташыйсы урынга бүтән берәрсе адашып барып чыккандыр. Миңа бүген гравий ташырга куштылар. Бүген дә миңа клиентны таба алмыйм...

Шул вакыйгага хәтергә төшкәч, тагын бер мөһим сорау туды:

**— Төзү сроклары кыска. Заводны элекке ысуллар белән генә салып чыгу мөмкин түгел. Биредә инндидер бүтән ысуллар кирәктер!**

**И. С. Завалишин.** Һәрбер зур төзелешнең, шул исәптән КамАЗ төзүнең дә, үзенчәлекле яклары бар. Бу төзелешләрдә кешеләрнең яңа сыйфатлары һәм бөтен илебездәге үзенчәлекләр чагыла. Хәзер Советлар Союзында төзелешнең яңа стиле формалаша. КамАЗ төзелеше дә хәзер яңа чор, шундый стиль формалашу чорын кичерә. Бу стиль, кыскача әйткәндә, шуннан гыйбарәт: теге яки бу проблеманы экономик күзлектән карап хәл иткәндә, мөмкинлектән чыгып кына түгел, мөмкин булмаганнарны да гамәлгә ашырырга тырышырга кирәк.

**— Бу яңа стильнең үзенчәлекләрен кайда һәм ничек күрергә була!**

**Е. Н. Батенчук.** Без, мәсәлән, нигез корганда гадәттә сугыла торган тимер-бетон багана свайлар урынына бораулап бетон салу ысулын киң куллана башладык. Бу ысулны кулланганда төзелеш өчен нигез астында зур чокырлар казу, миллионнарча тонна туфракны читкә ташу, аннары ул чокырларны тәеп кабат тутыру кирәк булмаячак. Яңа ысул белән эшләүгә күчкәч, 600 һәм 1200 миллиметрлы скважиналар бораулап, аңа арматура каркаслары куела һәм бетон коела. Болай эшләгәндә, төзү материалларына да, вакытка да зур экономия ясала, эшнең күләме дә азрак була. Алтмышар тонналы эре блоклы монтажлар куллану да — төзелеш эшендәге яңа стильнең бер формасы.

Төзелеш — технологик производство гына түгел, ул җанлы организм да. Эшнең барышын күзәтеп торырга, иң мөһим мәсьәләләрне генә алга куеп, икенче чираттагысын, вак-төяген калдырып торырга кирәк. Әгәр дә теге яки бу җитәкче, белмичәме яки каушап калыпмы, үз эшен онытып, бүтәннәр эшенә тыгыла икән, шуның белән ул барлык производствога буталчыклык кертә. Тиздән производствоны идарә итү эшенә автомат система ярдәм итәчәк. Промышленность предприятиеләрендә автоматлаштырылган идарә итү системаларын куллану буенча инде шактый тәҗрибә тупланган булса да, төзелештә исә әле аның кайбер элементлары гына сыналды. Алар да Мәскәү, Ленинград, Ташкент һәм Киев кебек зур шәһәрләрнең корылмаларында гына. КамАЗ төзелешендә бу система Союзда беренче мәртәбә теоретик планда түгел, ә киң планда эштә сынала. Кыскасы, без киләчәктә дә вакытны һәм эш күләмен кимету ысулларын эзләячәкбез. Шуның белән бергә аларны гамәлгә ашыру ягын да уйларга кирәк.

**И. С. Завалишин.** Әгәр кешеләр төп көчкә — техник прогресска таянмыйча, эшкә тотыналар икән, артиллерия әзерлегеннән башка гына чәнечкеле тимер чыбыклы киртәгә ташланган солдатка охшап калалар. Мең тапкыр приказ чыгарырга, мең тапкыр боерырга мөмкин, һәр очракта судан коры чыгарга җайлашкан җансыз, ваемсыз кешеләр барыбер табыла. Ә кешеләрдә чикләнмәгән ресурслар бар. Ул ресурсларны эшкә җигү өчен приказ гына җитми, киеренке шартлар тудыру кирәк. Шул вакытта гына тигез ритмлы темп барлыкка килә.

Мәсәлән, ярдәмчел предприятиеләр төзү проблемасын алыйк. Бу гаять зур күләмле эш. Братск төзелешенә, әйтик, барлыгы 127 мең кеше-ел кирәк булган, ә ГЭСның үзен төзүгә бары тик 20 мең генә кеше-ел хезмәте тотылган. Биредә, КамАЗда да, автозаводның үзен төзү барлык төзелешнең ун гына процентын тәшкил итә. Яңача чишелергә тиешле бик күп проблемалар алда тора. Мәсәлән, зур күләмле блоклардан йортлар салу. Бу Советлар Союзында уйлап чыгарылды. Лейпциг ярминкәсендә бу ысул белән җыелган йортларны күргәч, барлык белгечләр үзләрен киләчәктә итеп хис иттеләр. Шуннан соң Европа һәм Америка илләреннән, бу ысул белән танышу өчен, Советлар Союзына бик күп белгечләр агыла башлады. Менә шундый проблемаларны хәл иткәндә инде төзелешнең яңа стиле формалаша. Әлбәттә, бу процесс күзгә күренми, әмма ул сизелерлек. Бу табигый процесс, ул бөтен ил буенча — промышленностьта да, кешеләр аңында да бара, ул — яңа сыйфат сикерешә. Шуңа бу процессны күзәтү өчен КамАЗ зур бер полигон булып хезмәт итә...

**— Әгәр Советлар Союзындагы төзү тарихын алсак, яки чит илләргә күз салсак! КамАЗдагы бу яңа төзелеш стилен чагыштыру өчен объектлар бармы!**

**И. С. Завалишин.** Мәсәлән, Скандинавия стилен алыйк. Аның асылы нәрсәдә соң? Бу стильнең принцибы — эшченең югары квалификациясендә. Шведлар һәм норвегия-

ләр безнең өчен кечкенә генә Борисоглебск ГЭСын төзеделәр. Алардагы эшчеләрнең уртача хезмәт хакы 400 сумга җитә. Төзүче монда семьясыз һәм кайда туры килсә шунда яшәргә риза. Төзүчеләр өчен анда төзелеш мәйданы Антрактида белән бер. Безнең өчен мондый ысул яраксыз.

Ә Россиядә төзелеш ысулы ничек булган? Беренчедән, революциягә кадәр сезон ысулы кулланылган. Бу ысул белән, мәсәлән, транссебер тимер юлын ун ел эчендә салып бетергәннәр. Заманы өчен гаять зур техник нәтиҗә бу! Әмма ничек итеп аңа ирешкәннәр? Җәй көннәрендә куак төбендә дә төн кунарга мөмкин һәм йөз меңнәрчә сезонлы эшчеләр яздан көзгә кадәр меңнәрчә километр юл салганнар. Хәзер бездә, әлбәттә, сезонлы эшчеләр юк. Сугышка кадәрге бишьеллыклар чорында төзүчеләр палаткаларда торып эшләделәр. Әмма исәпләп карасалар — ике мичле, егерме дүрт урынлы палатка дәүләткә капиталь йорт салуга караганда кыйммәткәрәк төшә икән. Хәзерге шартлар өчен, әлбәттә, палатка ысулы гомумән яраклы түгел. Менә шулардан чыгып бездә, Евгений Никонорович Батенчук әйткәнчә, күчмә йортлар булдыру идеясе туды. Йортлар бездәге климат шартларына яраклы булырга тиеш. Мондый күчмә, җылелма йортларда барлык уңайлыклар да бар. Мондый йортлардан төзелгән поселоклар Чаллы тирәсендә инде бар һәм аларда КамАЗ төзүчеләре яши. СССР Энергетика министрлыгы системасында гына да хәзер алты завод шушындый йортлар хәзерләү белән шөгыльләнә. Бу йортлар беренче этапта илебездәге барлык төзелешләр өчен дә яраклы.

**— Әлбәттә, төзелештәге техник проблемаларны хәл итү җитмеш дүртенче елда сигез тонналы беренче «КамАЗ» машинасының Татарстан җиренә көпчәк тидерүе өчен зур әһәмияткә ия. Әмма аларның барысын да кешеләр, төрле характерлы, әйләнәтирәгә — хезмәткә төрлечә мөнәсәбәте, төрле омтылышлы, төрле язмышлы кешеләр хәл итә бит.**

**Е. Н. Батенчук.** Шуңа күрә дә төзелеш эшләре белән бергә коллектив тәрбияләүгә дә зур игътибар юнәлтелә. Әлбәттә, бу эшне администрация генә башкарып чыга алмый. Партия, комсомол оешмалары бу юнәлештә зур эш алып бара, алар кешеләрне иң катлаулы проблемаларны гамәлгә ашыруга илһамландыралар. Партия һәм хөкүмәт максатка ирешү өчен техниканы да, материаль-техник ресурсларны да җитәрлек бирде. Безнең аларны тиешенчә файдаланмаска хакыбыз юк. Барыбызның да омтылышы бердәм булырга тиеш. Бердәм омтылыш барысын да хәл итәргә сәләтле. Шундый бер вакыйга хәтердә. Вилюй елгасын буып алган чакта булды бу. Өч ай эчендә плотинага бер миллион ике йөз мең тонна кыя ташы салырга, ташлар арасына ике йөз мең кубометр балчык төеп тутырырга кирәк иде. Аннан тыш бетон кою һәм башка бик күп эшләр... Бу эшләрне вакытында башкарып чыкмасак, бөтен тырышлыкны язгы ташу агызып китәчәк иде. Яз кételгәннән уналты көнгә иртәрәк башланды. Хәлиткеч чаралар күрергә кирәк булды. Чөнки өч ай буена көн дими, төн дими башкарган хезмәтебез нәтиҗәсе җилгә очачак иде. Ике атна дәвамында котырып аккан су ташкыны белән киеренке көрәш барды. Һәм без җиңеп чыктык. КамАЗ төзүчеләренең дә рухи омтылышы, биредәге коллектив көченә партиянең дәртләндергеч йогынтысы да андагыдан ким түгел.

**— Ә яңа төзү стиленең кешеләргә тәэсире нинди рәк!**

**И. С. Завалишин.** Реаль техник казанышларга нигезләнгән яңа стиль белән эшләгәндә хезмәт тә гадиләшә, җиңеләя, аның мәгънәсе, нәтиҗәсе ачыграк булып күзгә күренә. Себер төзелешләрендә эшләгәндә, бер таныш эшче миңа: «Иң элек эш үзе күңелдә канәгатьлек тудырамы-юкмы — башта шуны уйлыйсың. Хезмәт хакы турында шуннан соң гына сорашасың»,— дигән иде. Әгәр кеше эшен булсын дип, белеп эшли икән — бу зур казаныш.

**— Хәзер төзүчеләр коллективларында искелек калдыклары һәм киләчәкнең яралгылары нәрсәдә күренә!**

**Р. Беляев.** Әйе, хәзер төзелештә үз алдында торган бурычларны хәл итәргә сәләтле, төгәлрәк әйтсәк, тулысы белән хәл итәргә сәләтле коллективлар барлыкка килде. Виктор Шатунов җитәкчелегендәге бетончыларның комсомол-яшьләр бригадасы, монтажчыларның Филимонов җитәкчелегендәге бригадасы һәм башка бригадалар бөтен республикага билгеле. Бу бригадаларда ирешелгән казанышлар бик мөһим. Мәсәлән, Бөтенсоюз өмәсе көнне шатуновчылар 500 квадрат метр бетон коеп,

рекорд куйдылар. Бу — дүрт сменалык эш нәтиҗәсе. Уйланырлык урын бар. Кеше нәрсәгә генә сәләтле түгел! Әмма яхшы эшләсен өчен төзүчене даими рәвештә бетон белән, эш фронты белән тәэмин итеп торырга, хезмәтне тиешле дәрәҗәдә оештыра белергә кирәк. Болары инде җитәкчеләргә бәйле. Төзелешнең туып килә торган яңа стиле белән бер сафка басарга сәләтебез бармы безнең?.. Кешеләрдә, безнең кебек гади кешеләрдә, чикләнмәгән мөмкинлекләр бар. Кайчагында нәрсәгә сәләтле икәнебезне без үзебез дә белмибез. Кешеләрнең сәләтенә юл ачарга, кеше рухының эчке резервларын да күрә белергә кирәк. Төзелештә туып килә торган яңа стиль партия, профсоюз, комсомол оешмалары алдына яңа бурычлар куя...

Без КамАЗ булыр дип ышанабыз. Һәм ул җитмеш дүртенче елда булыр. Аны Кама буенда яшәүчеләр һәм көн саен бирегә килеп торган кешеләр булдырыр...

...Бер әңгәмәдә генә барысын да сөйләшеп бетереп булмый. Биредәге һәр көн — дистәләгән яңа проблема. Хәрәкәт. Хәрәкәт. Хәрәкәт. Темп. Мин язмаларымны актарам. Аларда тормышның вак кына кисәкчәләре теркәлгән. Төзелеш мәйданнары, партиянең шәһәр комитетындагы, булачак заводның генераль директоры бүлмәсендәге киңәшмәләр күз алдыма килә...

«Бетон! Бетон бир син миңа!»

«Безгә төзелештә көн саен бер миллион сум акча үзләштерергә кирәк. Көн саен, һәр көнне!..»

Тормыш детальләре. Төзелеш көндәлеге.

Хәрәкәт. Хәрәкәт. Хәрәкәт.

«Хәрәкәттә бәрәкәт»,— ди халык.

**Зәйни Шаһиморатов**

# ЕРАКТАГЫ ЯКТЫ ЙОЛДЫЗ



Гадәттә, зур шәһәрләрдә, олы театрларда, җәмәгатьчелек фикере тудыручы дәүрәк шәхесләр күз алдында иҗат иткән артистларның гомер юллары шау-шулырак, кыңгыраулырак була. Алар турында күбрәк сөйләнә, күбрәк чаң сугыла. Бу һич тә начар нәрсә түгел, әлбәттә. Яхшы ат кыңгыраусыз йөрми дигән кебек, яхшы артист та шау-шусыз яшәргә тиеш түгел. Шуңа да артист ул! Ләкин артистларның шау-шулы үзәкләрдән еракта, район театрларында, тәнкыйтьчеләр чаңыннан читтә гомер үткәргәннәре дә байтак. Мондый артистлар ун роль уйнап бер җылы сүз, утыз-кырык ел эшләп бер юньле тәнкыйть фикере ишетә алмыйлар. Аларның бердәнбер бәяләүчеләре дә, иҗат шатлыкларын, иҗат кайгыларын уртаклашучылары да, ниһаять, начардан арынып, яхшыга юнәлеш бирүчеләре дә тамашачылар була. Татарстанның халык артисты Мөхит Кичүбаев та менә шундый язмышлы, үзенең бөтен иҗат гомерен Минзәлә театрында шау-шуларсыз, кыңгырауларсыз гына үткәргән артистларның берсе. Ул режиссер Сабир Өметбаев белән бергә Минзәлә театрының үзенә генә хас реалистик мәктәбен тудырышуда һәм бүген Мулланур Мостафин белән шул мәктәпне тагын да үстерешүдә катнашкан актив иҗатчы. Бу мәкаләнең максаты бөтен иҗат гомерен тәгәрмәч өстендә үткәргән, сәхнәдә йөздән артык рольләр уйнап, тоташ бер образлар галереясе барлыкка китергән кешенең иҗат юлын азрак яктыртып үтүдән, укучыларда, галәм киң икән, кояштан еракта да йолдызлар яна икән дигән фикер тудырудан гына гыйбарәт.

Шулай, хөкем эскәмиясендә Мөхит Кичүбаев. Кем ул? Нинди уртаклыктан чыккан һәм театр дөньясына каян килеп эләккән?

## Биографиянең башы

Мөхит 1910 елның 16 августында хәзерге Свердловск өлкәсенең Красноуфимский районы, Сызгы авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне шул ук авылдагы мәктәптә ала. Укытучы Харис Хәйдәровтан математика, агасы Габделәүвәлдән татар теле һәм әдәбияты, Наталья Прокофьевна Луконинадан рус теле һәм әдәбияты укый.

Гражданнар сугышыннан соң, Габделәүвәл Красноуфимскига мәгариф бүлегенә эшкә чакырыла, һәм кечкенә Мөхитны да үзе белән шунда алып китә. Габделәүвәлләр, Красноуфимскида драма түгәрәге оештырып, Галиәсгар Камалның «Уйнаш» драмасын сәхнәгә куялар. Спектакль карарга Мөхит та бара. Ул шунда беренче мәртәбә гаҗәеп

яңа, сихри дөнья күрә һәм ул спектакль аның күңеленә иң яхшы уен, иң яхшы могҗиза булып сеңеп кала. Аңарда театр сәнгатенә мәхәббәт, сәхнәдә уйныйсы килү тойгысы уяна. Бу тойгы Мөхитны шуннан соң беркайчан да ташламый, аның иң кадерле хыялына әверелә һәм, ниһаять, театр дөньясына тартып кертә.



1927—28 елларда Сызгыга укытучылар булып Самига һәм Габдрахман Гатауллиннар килә. Габдрахман авылда яшьләр арасында культура-агарту эшләре җәеп җибәрә, драма түгәрәге оештыра. Алар Кәрим Тинчуринның «Казан сөлгесе»н, Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ын, Кәрим Әмиринең «Казан кызы»н сәхнәләштерәләр. Мөхиткә да сәләтен сынап карарга юл ачыла. Ул «Казан сөлгесе»ндә мәзинне, «Галиябану»да Бәдрине, «Казан кызы»нда кызның атасын уйный.

Габделәүвәл белән Габдрахман Мөхиттә театрга мәхәббәт тәрбияләгән булсалар, Мостафа абзый дигән Сызгы зимагоры аңарда музыкага мәхәббәт уята. Мөхит аның кул астында скрипкада уйнарга өйрәнә. Ә армиядән кайткач, Башкорстанның Мәчетле авылындагы колхоз театрында эшләгән чагында театрның җитәкчесе шахтер Гафиятовтан нота белән эш итәргә өйрәнә.

## Тернәкләнү еллары

1935 елда, Татарстан Халык Комиссарлары советы карары нигезендә, Минзәләдә Сабир Өметбаев җитәкчелегендә Татар дәүләт колхоз-совхоз театры оештырыла. 1936 елда Мөхит Кичүбаевны да Минзәлә театрына чакырып алалар.

Мөхит Минзәләгә театрда Н. Шаповаленконың «Альбина Мегурская» дигән драмасын сәхнәләштерү буенча кызу эш барган вакытта килеп төшә. Декабристларның Себер каторгаларындагы тормышларын, көрәшләрен күрсәтүгә багышланган бу драма Мөхиттә көчле тәэсир калдыра. Аңа бу спектакльдә почтальон ролен бирәләр. Ул роле өстендә башта Сызгыдагыча гына эшләргә керешә. Ләкин әсәрне сәхнәгә куючы Сабир Өметбаев (хәзер Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты) аны беренче адымыннан ук туктата да, йөгертә-йөгертә, «дрессировать» итәргә керешә. Түземлелек белән игътибар, күрү, ишетү, тою, партнерны сизү, вакыйгаларның барышын, рольнең бурычларын аңлау, сүзләрнең мәгънәләрен ачу кебек сәхнә кагыйдәләре өйрәтә башлый. Өметбаев «дрессировкасыннан» соң эшләр алга киткән кебек була. Ләкин беренче спектакльдә үк, сәхнәгә чыгуга, бөтенләй югалып кала. Аңа сәхнәдә бөтен нәрсә комачаулаган төсле, залдагы тамашачылар да аңардан мыскыллап көләләр кебек тоела. Кулларын кая куярга, аякларын ничек басарга белми аптырап бетә. «Ник килдем мин бу театрга? Миннән барыбер бернәрсә дә чыкмаячак» дигән уй аның миенә утлы без булып кадала. Спектакльдән соң Мөхит чын мәгънәсе белән суд, җәза көтә. Ләкин Сабир Өметбаев аңа елмаеп бага да: «Тышкы күренешең әйбәт кенә синең, егет! Гримга да кулың килешә икән, молодец! Каккаласак, суккаласак берәр нәрсә чыгар синнән!» — ди. Һәм яшь артистның беренче адымын котлап кулын кыса. Шушы чын күңелдән әйтелгән кечкенә генә мактау да Мөхитның күңелен күтәреп, үстереп җибәрә. Икенче спектакльдә инде ул кыюрак, ышанычлырак уйный башлый. Өметбаев аны ул чакта театрның төп героинясы булып саналган талантлы артистка Гөлсем Йосыпова белән Мәсрур Арслановларга беркетә. Алар Мөхиткә чын күңелдән ярдәм кулы сузалар. Җитешсез якларын күрсәтәләр, ничек

эшләргә киңәшләр бирәләр, өйрәтәләр. Шулай итеп, өметсезләнеп Сызгыга кайтып китәргә җыенып беткән Мөхит театрда төпләнеп кала.

1937 ел башында театр драматург Таҗи Гыйззәтнең «Мактаулы заман» драмасын сәхнәгә куя. Бусында Мөхиткә Ярулла карт ролен тапшыралар. Шушы спектакльдә уйнаганда Мөхит артист өчен бик мөһим булган тагын бер хакыйкатькә төшенә. Бер вакыт алар Калинин районы культура йортында «Мактаулы заман»ны уйныйлар. Шунда Хөбәйдә ролен уйнаучы Хәдичә ханым Сәлимова репликаны бутый. Мөхит тәмам югалып ни эшләргә белми кала. Хәдичә ханым аңа ярдәмгә килеп, сүзләрне искә төшерә торган репликалар биреп карый. Ә Мөхит аның саен каушый бара, бутала, чын-чынлап ояла. Ә залда халык, аларны чынлап та шулай уйныйлар икән дип, рәхәтләнеп шаркылдарга, аяклары белән дөбердәтә-дөбердәтә кул чабарга керешә. Шунда Мөхит: «Менә чынын уйнасаң ничек була икән? Сәхнәдә кыланырга түгел, яшәргә кирәк икән ләбаса?» дигән фикергә килә һәм соңыннан бу фикер аның иҗатында юл күрсәтүче якты маякка әверелә.

1937 ел Минзәлә театрының яшь профессиональ көчләр белән ныгытылган, театр буларак профессиональ якка чын-чыннан борылыш ясаган чоры була. Театрга Гыйззәтуллина-Волжская, Габдулла Кариевлар белән бергә «Сәйяр», «Нур» труппаларында уйнаган атаклы артист Гыйлаҗ Казанский эшкә килә, артистлар составы театр техникумы тәмамлаган яшьләр белән тулылана. Театр ике бригадага бүленеп эшли башлый. Гыйлаҗ Казанскийның театрга килүе Мөхит тормышында да зур вакыйгага әверелә. Мөхит Гыйлаҗ белән бер бүлмәдә яши һәм бер бригадада эшли. Бригада Задонскийның «Илья Лебедев» дигән драмасын сәхнәләштерә. Мөхит Тимер юл политбүлек начальнигын, Гыйлаҗ Казанский үзе бер кара шәхесне уйный һәм Мөхитны сүзне әйтә белергә өйрәтә.

— Сәхнәдә коры сүз генә сөйләп йөрмә син, энем! Әйтәчәк сүзләреңнең төп фикерен билгелә дә шуларга басым ясап әйт. Кулларыңны, әгъзаларыңны шулардан чыгып эшкә җик. Тышкы хәрәкәтләрең эчке кичерешләреңә бәйләнсен һәм шуларның нәтиҗәсе булып чыксын,— ди ул Мөхиткә. Мөхитнең Гыйлаҗ Казанский белән иҗади дуслыгы 1938 елга, Казанскийның вафатына чаклы дәвам итә. Шул ук елда Сабир Өметбаев «Козгыннар оясында» драмасының Шәриф Камал тарафыннан Минзәлә театры өчен атап эшләнгән махсус вариантын кайтадан сәхнәгә чыгара. Бу — Минзәлә театрының иҗат тарихында этап спектакле булган, аның репертуарының алтын фондына кереп калган һәм дистәләрчә артистлар тәрбияләгән әсәр. Мөхит Кичүбаевка «Козгыннар оясында»гы Усман карт ролен уйнарга туры килә. Сатлык җан Садри Усман карт шахтада эштә чакта аның өенә кереп кача да, ул кайткач: «Мәрьям янына куна кергән идем» дигән пычрак гайбәт тарата. Мәрьям, хурлыгына чыдый алмый, суга батып үлә. Садри коткысына ияргән кайбер аңсызрак шахтерлар Усман картны үртиләр, мыскыллап көләләр. Мөхит шунда үртәлүнең, гарьләнеп әрнүнең нәрсә икәнен чын мәгънәсендә тоя һәм күзеннән яшьләр акканчы үртәлә. Усман карт образы Мөхиткә образларның эчке дөньяларына үтеп керергә ачкыч тоттыра. Бу әсәр театр өчен генә түгел, Мөхит иҗаты өчен дә этап спектакле, борылыш ноктасы була. Соңыннан 1950 елда инде Мөхит бу спектакльдә Таҗи мулланы уйный.

1939 елда Минзәлә театры Таҗи Гыйззәтнең «Чаткылар» драмасын сәхнәгә чыгара. «Чаткылар» да Мөхиткә әсәрнең баш герое тимерче Гаяз ролен ышанып тапшыралар. Бу ансамбльлелек ягыннан Минзәлә театрының ул елларда иң яхшы эшләнгән спектакле була һәм театр «Чаткылар» белән Мәскәүгә колхоз-совхоз театрларының беренче Бөтенсоюз фестивалена барып яхшы бәя ала. Мәскәү тәнкыйтьчеләре Мөхитнең уенына да әйбәт бәя бирәләр һәм хаклы рәвештә мактыйлар. Ләкин бу мактаудан Мөхит үзе генә канәгать булмый. Мөхит үзен Гаяз ролен тиешенчә башкара алмадым дип саный. Чөнки моңа кадәр гел картларны, өлкән яштәге кешеләрне уйнап килгән артистка кинәт кенә яшьләрне уйнарга күчүе авыр була. «Миңа ул чакта Тимай бабайны бирсәләр, яхшырак уйнаган булыр идем, мөгаен»,— ди Мөхит. 1940 ел башында театр В. Масс һәм Н. Куличенколарның «Бакчалар чәчәк ата» дигән комедиясен сәхнәгә чыгара. Бу комедиядә Мөхит 24 яшьлек Владимир Карпович ролен уйный һәм беренче мәртәбә комедия материалы белән очраша. Моңарчы драмаларда гына уйнарга, җитди хәлләр эчендә җитди хәрәкәтләр ясап, җитди идеяләр үткәрергә күнеккән Мөхит үз гомерендә беренче мәртәбә комик хәлләр эчендә комик хәрәкәтләр аша җитди һәм

зур идеяләр үткәрү бурычы алдына килеп баса. Ул башта Карповичны клоунланып, комикланып уйнап карый. Ләкин тамашачыда хуплау табә алмый. Режиссер Өметбаев та аңардан җитди хәрәкәт таләп итә. Шуннан Мөхит аны драмаларда уйнаган төсле җитди итеп уйный башлый. Тамашачылар да аның бу уенын хуплап каршы алалар. Мөхитка җиңел дә, рәхәт тә булып китә. Владимир аның «үзенекенә» әверелә. Шул ук елда театр Риза ага Ишморатның «Гөлзада» драмасын да сәхнәләштерә. (Артист Фәридун Юнысов постановкасы.) Мөхит Риза Ишморат иҗаты белән беренче мәртәбә шунда очраша. Аңа Рәшит ролен тапшыралар. Рәшит, әсәрнең баш герое хисчән Хафизга капма-каршы буларак, акыл белән, сабырлык белән эш итеп, Гөлзаданың күңелен яулап ала. Аларның караш, омтылыш бердәмлекләре әкренләп хис, мәхәббәт бердәмлегенә әверелә. Мөхит бу тирән кичерешләргә бай фәлсәфи драманың геройларына сокланып кына калмый, Рәшит образын сокланырлык итеп уйнап та чыга. Спектакль өчен «Гөлзада җыры», «Хафиз җыры», «Яшьлек җыры» дигән көйләр яза. Көйләрне башкару өчен махсус оркестр да оештыра. Күрәсез, Сызгы зимагоры Мостафа абзыйның аны скрипкада уйнарга өйрәтүе дә, Мәчетле режиссеры шахтер Гафиятовның нота таныуы да бушка китми. Алар Мөхитның икенче бер матур ягын, композиторлык сәләтен ачарга да ярдәм итәләр.



*«Әй, кызлар» спектакленнән бер күренеш. Әбделкадыйр ролендә И. Кичубаев.*



## Ватан сугышы сабаклары

1941 елның 22 июнендә безнең илгә игълансыз-нисез гитлерчылар басып керә. Бөтен ил Гитлер илбасарларына каршы көрәшкә күтәрелә. Артистларның шактый өлеше сугыш башлануның икенче көнендә үк фронтка китәләр. Сабир Өметбаев та, Мөхит та кулларына корал алып Ватанны яклаучылар сафына басалар. Мөхит, бишенче Кызыл Байраклы укчы мотополк составында Смоленск юнәлешендә Савино авылы өчен барган каты сугышларда кыюлык, батырлык күрсәткән өчен, III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә. Озак та үтми, яраланып, госпитальгә озатыла. 1943 елның башында аны, армиягә яраксыз табып, Минзәләгә кайтаралар. Мөхит өчен солдат буларак сугыш бетә. Ләкин театрның хәле тагын да аянычрак булып чыга. Анда ирләрдән берәү дә калмаган диярлек. Бөтен эш, бөтен авырлык хатын-кызлар җилкәсенә өелгән. Труппа Хәдичә Сәлимова, Рәбига Шакирова, Җиһан Сәетова, Нурия Гыйззәтуллина, Галия Юнысова, Нәзифә Гайнетдинова кебек фидакарь артисткалардан гына тора. Репертуарның рәтебашы калмаган. Берәр пәрдәле пьесалардан, концерт номерларыннан башка халыкка күрсәтер әйберләре дә булмый. Алар да искереп, таушалып беткәннәр. Мөхит алдына театрны аякка бастыру өчен яңа программа әзерләү бурычы килеп баса. Күп пәрдәле зур спектакльләр кую турында ул чакта уйларга да мөмкин булмый. Мөхит үзе «Таныштылар, кавыштылар» дигән музыкаль куплетлар яза. «Кайгырма, чибәрем», «Гау беркетем» дигән көйләр иҗат итә. Артист Юныс Фарсинның «Погоди, постой, тукта» дигән такмакларын музыкалаштыра һәм шуңа бер пәрдәле пьеса өсти дә труппаны гастрольгә алып чыгып китә. Аңа бу чорда артист, композитор, музыкант һәм администратор да булып эшләргә туры килә.

1943 елның язында театр Риза ага Ишморатның «Кайту» дигән драмасын сәхнәләштерә. Көзен Мөхит Вл. Суходольскийның бер пәрдәле «Җуләр»ен, Н. Шаповаленконың «Очрашу» дигән әгәрен тәрҗемә итеп сәхнәгә куя. 1944 елда Хан Җәмилнең «Кура җиләге», 1945 елның язында Эмма Шамилнең «Кунак егете» комедияләре сәхнәгә менәләр. Мөхит бу спектакльләрнең барысында да катнаша. Ләкин алар Мөхит иҗатында сизелерлек эз калдырмыйлар. Чөнки аларның берсе дә театрның иҗади йөзен билгели алырлык спектакльләр булмый. Театр үзенең чын җитәкчесен, оештыручысын көтә.

## Яңа урләргә менгәндә

1946 ел башында сугыштан Сабир Өметбаев кайтып төшә. Шинелен дә салып тормый, җитәкчелекне яңадан үз кулына ала һәм театрны сугышка кадәрге профессиональ дәрәҗәсенә күтәрү өчен көрәш җәеп җибәрә. Ул эшне театрга кадрлар туплаудан башлый. Сугыштан Габдулла Шәрифҗанов белән Мөхәррәм Зәйнуллиннар кайта. Артистлар составы яңа яшь көчләр белән тулылана. һәм театр берьюлы өч зур спектакль әзерли. Максим Горькийның «Васса Железнова» драмасы, Мольерның «Ирексездән табип» комедиясе һәм Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасы сәхнәләштерелә. Театрга җан кереп китә. Бигрәк тә Максим Горькийның «Васса Железнова»сы артистларның иҗат рухын күтәрә. Хәдичә ханым Сәлимова Вассаның үзен, Рәбига ханым Шакирова революционерка Рашельне, Мөхит Кичүбаев Вассаның бертуган агасы Прохорны уйный. Прохор — Железновлар өендә берни дә эшләмичә, бөтен вакытын эчеп-исереп, гитара чиертеп, хатын-кызлар белән чуалып, азгынлык, бозыклык юлында үткәрүче түбән җанлы, тасма телле шәхес. Мөлаем йөзенә, йомшак, ягымлы мөгамәләләренә карап, бу кеше куркыныч, кансыз бер ерткычтыр дип уйлавы да читен. Кешеләрнең яхшы якларын гына эзләп, яман якларын тешен кысыбрак чыгарырга күнеккән Мөхит алдына мөлаемлык битлеге астына яшеренгән бу ерткычның чын йөзен ачу бурычы килеп баса. Прохор образын тудырганда ул сәхнә обр[illegible]ларын күп кырлы, күп бизәкле итеп уйнарга өйрәнә һәм, иң мөһиме, үзен моңа чаклы интектергән «мускуллар киеңрәкелеге» дигән актерлар чиреннән бөтенләйгә котыла.

Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасында Мөхиткә Бәдри ролен тапшыралар. Бәдри абзый Мөхитны җылытып кына калмый, үзенең каршылыклы хәрәкәтләре, кичерешләре белән тетрәтә дә. Кыскасы, Мөхит Прохорда явызлыгын яхшылык битлеге астына яшерүче икейөзле шәхес белән очрашса, Бәдридә бөтен эшен, хәрәкәтен ихластан, шулай кирәгенә ышанып эшләүче беркатлы кешегә юлыга.

Минзәлә театры, 1947 елның июлендә колхоз-совхоз театрларының башкалабыз Казанда үткәрелгән республика фестивалендә «Васса Железнова», «Ирексездән табип», «Галиябану», «Килен төшкәч» (Гариф Галиев әсәре) спектакльләре белән катнашып, икенче урынны яулап ала. Башкалар белән бергәттән, Мөхитнең хезмәтләре дә уңай бәяләнә.

1949 елда театр Хәбибулла Ибраһимовның «Башмагым» комедиясен яңадан сәхнәгә күтәрә. Моңа чаклы әсәрнең баш герое Галимҗан һәм Вәли кучер рольләрен уйнап килгән Мөхиткә бу юлы Кәрим байның үзен тапшыралар. Мөхит, уйлана торгач, аның да кул-аяк тимәгән ягын таба. Кәрим бай үзен генә акыллы, эшлекле кеше дип уйлый, башкаларны аңгыра, ахмак, вак кешеләргә, эшлексезләргә саный. Мөхит Кәрим байның менә шушы якларына басым ясый. Аларны зурайтып, купайтып, дөньяга сыймаслык нәрсәләр игеп кабартып уйный. «Башмагым»нан соң театр Шәриф Камалның атаклы «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясен сәхнәгә куя. Бу җаваплы спектакльдә Мөхиткә Хаҗи әфәнденең үзен тапшыралар. Мөхит Хаҗи образын мавыгып, канатланып иҗат итә. Хаҗи әфәнде дә, Прохор төсле үк, катлаулы, үзенчәлекле образ. Ул үзенең азгынлыгын, физиологик комсызлыгын изгелек, хаҗилык битлеге астына яшерә. Кешеләрне сәүдәгәрләргә хас елгырлык белән үзенә җәлеп итә белә. Шул ук вакытта арадагы чикне дә югалтмый. Кирәк урында аркадан кага, мактый, кирәк җирендә тавышын да күтәрә. Мөхит Хаҗи әфәндене әнә шулай сурәтли һәм зур уңышка ирешә. Хаҗи әфәнде Мөхиткә «Зәңгәр шәл»дәге ишан ролен уйнарга трамплин булып хезмәт итә.

Илленче еллар Минзәлә театры өчен музыкаль комедияләр сәхнәләштерү белән дә характерлы. 1950 елда сәхнәгә күтәрелгән «Аршин мал алан» комедиясендә Мөхит Сөләйман ролен башкара һәм режиссер-постановщик вазифасын да үти. Аңа, постановщик буларак, тормыш хакыйкатен сәхнә хакыйкате белән бәйләү юлларын эзләргә, әсәрнең «сверхзадачасын» билгеләргә, барлык актерларның бурычларын ачарга, үтәтергә, иҗат процессын оештырырга, спектакльне яңабаштан иҗат итәргә туры килә. Бу эштә аңа сугыш елларында берәр пәрдәле әсәрләрне сәхнәгә кую тәҗрибәсе, «Гөлзада» драмасын музыкаль яктан формалаштыру практикасы һәм баянчы Шамил Сабировның музыкаль башкару, оештыру таланты ярдәмгә килә. «Аршин мал алан» уңышка ирешә. Әзәрбәйҗан халкының мактанычы булган бу атаклы әсәр Минзәлә сәхнәсендә дә йөзгә кызыллык китермәслек дәрәҗәдә яңгырый.



*М. Кичүбаев «Һиҗрәт» спектаклендә.*

Театр «Аршин мал алан»нан соң Җәүдәт Фәйзинең Гамир Насрый либреттосы буенча язылган «Идел буенда» музыкаль комедиясен сәхнәләштерә. Мөхит бу спектакльдә авылга кимсетеп караучы, культураны шәһәр кешеләренә генә хас нәрсә дип ышанучы шаккатар мещан Закир Саттаровны уйный. Ләкин аңа, барыннан да бигрәк, әсәрнең музыкаль ягын эшләү бурычы йөкләнә. Ул башта баянчы Шамил Сабировны нота белән уйнарга өйрәтә. Аннан алар икәүләп комедиянең опера театры өчен язылган тулы партитурасын карап чыгалар. Көйләрне баянга, скрипкага яраклаштырып уйнарга өйрәнәләр. Аннан җырчыларны, хор партияләрен өйрәтәләр. Нәтиҗәдә спектакль баян, скрипка озатуында бара торган чын музыкаль комедиягә әйләнә. Спектакльне Казан тамашачылары да хуплап каршы ала. Аны Салих Сәйдәшев тә карый һәм ул:

— Музыкаль әсәрләрне академия театрында да болай уйный алмыйлар иде. Сездә музыка көчләре әйбәт икән. Мин дә сезнең театрга «Наемщик»ны әзерләп бирәм әле,— ди.

Ләкин йөрәге вакытсыз тибүдән туктау гына мәшһүр композиторга вәгъдәсен үтәргә комачаулый.

Композитор Җәүдәт Фәйзи исә:

— Мин сезне «Идел буенда»ны бу хәлгә китереп җиткерә алырсыз дип һич тә уйламаган идем. Болай булгач, мин сезгә «Акчарлаклар»ны да әзерләп бирермен, дип вәгъдә итә. Композитор театрга биргән сүзендә тора. 1954 елның язында Минзәлә шәһәре яңадан Җәүдәт Фәйзинең искиткеч матур музыкалары белән шаулый башлый. «Акчарлаклар» Минзәлә сәхнәсендә дә очып йөри. Мөхит, Шамил Сабиров белән бергә, бу спектакльне дә музыка ягыннан формалаштыра. Фатхи образын эштә дә, хисте дә уңган җор егет итеп уйный.

Бу чорларда Мөхит, болардан тыш та, күп кенә рольләрдә уйный. Атаклы Украина драматургы Александр Корнейчукның «Балан куаклыгы» комедиясендә язучы Батура; драматург Шәриф Хөсәеновның «Профессор киявe» комедиясендә мещан семьясыннан чыккан, мещанларча тәрбияләнгән, исеме дә нинди дер модага иярел кенә кушылган татар Эдуарды образларын сәхнәдә иҗат итә.

1954 елның көзендә Сабир Өметбаев драматург Юныс Әминовның «Язылмаган законнар» драмасын сәхнәгә куя. Мөхит бу спектакль өчен «Сайрат, дустым, гарму-

ныңны», «Бәхетем син», «Мәк чәчәге» дигән көйләр яза. Тракторчы Шәйхинур ролен башкара.

Шәйхинурның хезмәттәге уңышлардан башы әйләнә, ул бозыла, кирәгеннән артык масая башлый. Иптәшләреннән, кешеләрдән аерыла. Үзен югары культуралы кешегә санап, башкаларга түбәнсетеп карый башлый һәм хәйләкәр Назлыбикә тырнагына килеп эләгә, сөйгән хатыны Фәридәне, баласын ташлый... Ләкин җәмәгатьчелек ярдәмендә үзендә хатасын аңларлык, төзәтә алырлык көч таба. Мөхит Шәйхинур образын үз итеп, күп кырлы, саф йөрәкле, ләкин ялгышып күзләре ачылгач, яңадан яктылыкка омтылучы шәхес итеп гәүдәләндерә. Шул елда Мөхитның иҗади хезмәтләре Татарстанның партия һәм хөкүмәт органнары тарафыннан югары бәя ала. Аңа Татарстанның атказанган артисты дигән мактаулы исем бирелә.

Сәхнәдә заман сулышын чагылдырган, тормышчан конфликтлар эчендә кайнаучы партия җитәкчеләренең образларын иҗат итү теләге Мөхит Кичүбаевка күптәннән тынгылык бирми килә. Шул елларда драматург Гамир Насрый «Кадерле минутлар» драмасын яза. Әсәрдә куелган проблема да, кешеләрне көрәшкә күтәргән, бәрелешкә китергән конфликт та һәм шул конфликтта хәлиткеч рольне уйнаучы геройлар да яңача, тормышчан булып чыга. Кайчандыр җитен комбинатында көндәлек эш нормасын ике йөз-өч йөз процентка үтәп, үз ачышы, үз новаторлыгы белән ил шаулаткан тукучы Суфия, заман, таләп үзгәрү, комбинат җитәкчеләренең аның новаторлыгыннан дөрес файдаланмаулары, рекорд шаукымы белән мавыгулар аркасында, мин мин икән, мин кем икәнгә әйләнеп, масая. Үз тәҗрибәсен бирәү белән дә уртаклашмыйча һәм уртаклаштырга да теләмичә ялгыз новаторга әйләнеп кала. Озак та үтми, Суфияның кызы инженер Әлфиягә өйләнәчәк Ильяс Заманов дигән егет партком секретаре булып килә. Суфиядагы бу торгынлыкны, бу аяныч хәлләрне күрә, аларга каршы кискен көрәш җәеп җибәрә, конфликтның, көрәшнең үзәк фигурасына, юнәлдерүче компасына, илһамчысына әверелә. Суфияның йөрәгенә дә ачкыч ярата ул. Нәтиҗәдә курслар оештырыла, тоташ бер новаторлар армиясе, Суфия тәҗрибәсен масса төсендә гамәлгә ашыручылар армиясе барлыкка килә. Гамир Насрый, совет язучысы буларак, үз өстенә алган җаваплы бурычны җиренә җиткереп, коммунистларча үти. Татар драматургиясе җәмгыятебезнең үсү законын диалектик дөрес сурәтләгән олы бер әсәр, чын партком секретаре образы белән бизәлә. Һәм бу әсәр мәрхүм Гамир Насрый иҗатының югары ноктасы булып кала.

Мөхитка «Кадерле минутлар»да Ильяс Заманов ролен бирәләр. Мөхит бу рольдә шатланып уйный, күптәнге кадерле теләгенә, зарыгып көткән морадына ирешә. Заманов Мөхит Кичүбаев башкаруында ярата, сөя, кайгырта һәм көя дә, оештыра, көрәшә, көрәштерә дә белә торган чын коммунист, сизгер җитәкче булып гәүдәләнә. Мөхит «Кадерле минутлар» спектаклен, уйнаган роле белән генә түгел, «Бар Казанда бер комбинат», «Тиз кил, иркәм», «Дәү әни» кебек көйләре белән дә бизи.

1955 елның көзендә, театр, артистларның профессиональ осталыкларын тагын да күтәрү максаты белән, рус драматургиясенең атасы Александр Островскийның «Бирнәсез кыз» драмасын сәхнәләштерә. Бу спектакльдә бирнәсез кыз Ларисаны Нәсимә ханым Җиһаншина, пароход хуҗасы Паратовны Мөхит Кичүбаев уйный. Бу — Минзәлә артистларының бөек рус драматургы иҗаты белән беренче очрашуы була. Һәм алар рольләрен зур канәгатьлек белән, бирелеп уйныйлар. Мөхит кына үзендә Паратов белән килешә алмаслык капма-каршылык сизә. Паратов Ларисаны кызганмый, Мөхит кызгана. Паратов Ларисадан көлүне егетлеккә, Мөхит этлеккә саный. Һәм шуңа Мөхит Паратовны башка эксплуататорлардан аермасы булмаган, икенче берәүләрнең бәхетләрен җимерү хисабына үзенә бәхет төзүче түбән җанлы, көләч йөзле кыргый франт, мәдәниятле палач итеп тамашачы алдына бастыра.

## Ил алдында имтихан тотканда

1956 ел җитә. Шул елны Мөхит та үз тормышын онытылмаслык истәлекләр белән бизәгән өч зур вакыйгага аша үтә. Театр атаклы татар драматургы Кәрим Тинчуринның мәшһүр «Зәңгәр шәл» драмасын сәхнәләштерә. Мөхитның күптән көткән һәм гомер буе әзерләнгән хыялы гамәлгә аша. Ниһаять, аңа ишан ролен уйнарга мөмкинлек бирә-

ләр. Ишан «Козгыннар оясында»гы ташландык сөяк артыннан чабучы Таҗи мулла дә, Хаҗи әфәнде кебек, авторитет алу өчен генә хаҗга барып хаҗи булып маташучы надан, диндар сәүдәгәр дә түгел. Ул диннең дә, көннең дә ни бәя торганын бик яхшы белүче, ярлысын гына түгел, байларын да үз алдында биетеп, кулында тотып тора алучы аңлы реакционер. Ул үз тирәсен, малын гына түгел, кирәк булса хәләл хатынын да талак итеп һиба кыла ала торган фидаи мөридләр белән чолгый. Аңа Таҗи муллага әйткән кебек: «Алланың үзен, забойга төшереп, күмер чаптырсаң нишләр иде икән?»— дия алмыйлар. Аны, башың белән бәхилләшмичә, Хаҗи әфәндене япкан кебек, үз хатыны янына ябарга да мөмкин түгел. Ул ишан, ул хаким. Ләкин ул бүре кебек ялангач ерткыч кына да түгел, төлке кебек хәйләкәр җанвар. Корбанын һәйһулап куып тотмый, посып, майлап, җайлап, балга ябыштырып кына тота. Мөхит ишан хәзрәт образын менә шулай трактовать итә һәм сәхнәдә дә шулай уйный. Уфада гастрольдә вакытта аңа:— «Нигә син ишанны болай культурный итеп уйныйсың? Бездә аны дуңгыз итеп уйныйлар иде бит!» — диләр. Мөхит аларга: «— Дуңгызлар да бер генә төрле булмыйлар бит. Дорфа, дуамал кешедән кеше кача. Ә бу песәем, песәем, перс!» — дип җавап бирә.

Шул ук 1956 елда Мөхитны коммунистлар партиясе сафына кабул итәләр. Ул «Кадерле минутлар» драмасында үзе иҗат иткән Ильяс Заманов кебек көрәшчеләр арасына аяк баса.

Шул ук елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәреләчәге игълан ителә. Минзәлә театры да катнашучылар исемлегенә кертелә һәм декадага алып бару өчен «Язылмаган законнар» белән «Галиябану» драмаларын әзерләргә керешә. «Язылмаган законнар»ны театрның баш режиссеры Сабир Өметбаев үзе, «Галиябану»ны әле бер генә ел элек театр институты тәмамлап кайткан яшь режиссер Мулланур Мостафин әзерли башлый. Мөхит Кичүбаевка «Язылмаган законнар»да Шәйхинурны, «Галиябану»да Исмәгыйл ролен тапшыралар. Мөхит Исмәгыйльне штампка кергән «лобовой»лыклардан качып, яңачарак уйнарга карар бирә. Ул аны хәйләкәррәк, тотнаклырак кеше, усаллыкларын, мактанчыклыкларын ялгыз калган чакларында гына чыгара, кискен бәрелеш моментларында гына кансыз юлбарысларча хәрәкәт итеп уйнарга уйлый. Нәтиҗәдә Мөхит Исмәгыйле «лобовой» Исмәгыйлләрнең барысыннан да катлаулырак, көчлерәк, куркынычрак булып чыга. Авыл тамашачылары гына түгел, Казан, Мәскәү кебек мәдәният үзәкләренең таләпчән тамашачылары да яңа Исмәгыйльне хуплап каршылыйлар. Аңардан буып үтерерлек дәрәҗәдә нәфрәтләнәләр һәм Мөхитның уенына сокланып кул чабалар.

Декадада Минзәлә театрының егерме ике еллык эшенә йомгак ясала. Аның үз иҗат йөзе, үз мәктәбе булган профессиональ театр булуы таныла. Башкаланың сәнгать белгечләре, реалистик театр буларак, сезнең театрның үз мәктәбе барлыкка килгән, дип бәялиләр. Бу мәктәп сәхнәдәге уенның тормышчан булуында, тормыш чынлыгының сәнгать хакыйкатенә әверелеп үсүендә, артистларның сәхнәдә барган хәлләргә чын-чыннан ышанып уйнауларында ярылып ята диләр. Мөхит Кичүбаевка Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исем бирелә.

## Яңадан тәгәрмәч өстендә

Театр декададан кайту белән Югославия драматургы Бронеслав Нушичның «Иң гади кеше» дигән комедиясен сәхнәгә күтәрә. Бу искиткеч бер осталык белән язылган табышмак комедиядә Мөхит Кичүбаев Арса дигән кеше ролен уйный. Арса, кызын кияүгә бирү өчен, хәйләле юллар белән агасының милкетен кулга төшерергә йөри. Ә кызы шул арада, малсыз да үзе яраткан шагыйре белән кавыша. Кызына хәрам мал белән хәләл бәхет табып бирергә теләгән ата көлкегә кала. Мөхит бу шаккатыргыч комедиядәге шаккатыргыч вакыйгаларга да ышанып уйный.

1958 ел башында театр тамашачыларны бурят халкы тормышы белән таныштырырга теләп, бурят драматургы Цырен Шагжинның «Хәйләкәр Будамша» дигән комедиясен сәхнәләштерә. (Мулланур Мостафин постановкасы.) Бурятларның борынгы тормышкөнкүрешләрен чагылдырган бу комедиядә Мөхит Елбай ролен уйный. Елбай үз улусында сәйранда йөргәндә кетмәгәндә бер көтүче кызы белән очраша һәм кыз-

ны үз сараена илтергә әмер бирә. Ләкин кызның гашыйгы юлаучы Будамша Елбай сараена кыз урнына кызның анасын капчыкка салып илтеп, Елбайны көлкегә калдыра. Мөхит Елбайны көнчыгыш феодалларына хас тәкәббер, боерырга, хакимләнергә яратучы, үзен генә сөяр, башкаларны кеше дип тә белмәс хөкемдар итеп уйный.

1959 елның язында Мулланур Мостафин Галимҗан Сәгыйдуллинның «Сибелә чәчәк» драмасын сәхнәләштерә. Мөхиткә Әмирхан ролен тапшыралар. Бу аның сәнгать кешеләре образы белән сәхнәдә беренче мәртәбә очрашуы була. Караңгы юллар белән сәнгатьтә якты дан казану юлына баскан дустының «изгелеге» белән тормыштагы урынын югалта язган һәм яхшы кешеләр ярдәмендә үзендә яңа опера язып сәхнәгә куйдырырлык көч тапкан романтик Әмирхан образын Мөхит гашыйк булып уйный. Үзендә тагын да зуррак, авыррак, катлаулырак образлар тудырырга теләк, омтылыш, ашкыну тууын сизә.

Алтмышынчы ел башында театр Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт» драмасын сәхнәгә чыгара. Бу драмада Мөхиткә укытучы Сәлим ролен бирәләр. Мөхит Сәлимне яратып уйный. Аның балалар кайгысын кайгыртып йөрүләре Мөхитны җылыта. Ләкин Мөхит Тәлгатьнең анасының гамәлләрен генә аңлап җиткерә алмый. Ана башта баласын атасына дошманлык рухында тәрбияли, соңыннан аны шул ук ата янына озата. Ана бу эшне атадан үч алу өчен эшлиме, әллә күз яше аша шулай эшләргә мәҗбүрме? Бу нәрсәнең ачык түгеллеге Сәлим образына күләгә ташлый һәм Мөхитның аңа биргән бәясен ике яклырак итә. Ул аны яратып уйнавына карамастан, гаепли дә, аклый да алмый.

1961 елның язында театр шушы юлларны язучының «Дәһшәтле минутлар» комедиясен сәхнәгә чыгара. Бу нефть, газ разведка системасында эшләүче вышка монтажлаучылар тормышыннан язылган әсәрдә Мөхит контора директоры инженер-геолог Рәшит ролен башкара. Һәм беренче мәртәбә сәхнәдә Татарстанны индустриаль Татарстан иткән нефтьчеләр белән очраша. Бу яңа төр профессия кешеләренә йөрәгендә тирән хөрмәт һәм мәхәббәт сизә. Рәшит образы Мөхит уенында бөтен каршылыкларны таптап сындырып үтеп, яңалыкны, алдынгылыкны кыю рәвештә тормышка ашыручы ачык күзле белгеч, какшамас оештыручы, тимер куллы производство командиры, иҗатчы новатор һәм тирән хис иясе булып сурәтләнә.

1963 елның язы Мөхит иҗадын яңа бер баскычка күтәрүче истәлекле яз булып килә. Режиссер Мулланур Мостафин гарәп язучысы Сәхиб Җамалның әфган халкы тормышын чагылдырган «Кара чәчәкләр» романы буенча Вәли Галимов тарафыннан эшләнгән инсценировкасын сәхнәгә куя. Мөхиткә бу спектакльдә Сәид баба роле тапшырыла. Мөхит аны трагик язмышлы аталарның фаҗигале кичерешләрен бөтен тирәнлеге белән тоеп, трагедияләргә хас югарылыкка күтәреп башкара. «Кара чәчәкләр» спектакле Мөхит иҗаты өчен генә түгел, режиссер Мулланур Мостафин иҗаты өчен дә зур борылыш, этап спектакле була. Актер белән режиссер бу спектакльдә бербернсен табалар.

Бөек Ленинның йөз еллыгына, Татарстанның илле еллыгына өзерлек белән үткән тарихи елларда театр башкорт халык шагыйре Мостай Кәримнең «Айгөл иле» дигән романтик драмасын һәм Нәкый Исәнбәтнең



*М. Кичубаев Сәид баба ролендә.*

«Һиҗрәт» сатирасын (Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Марсель Сәлимҗанов постановкасы) тамашачылар алдына чыгара. Мөхит «Айгөл иле» драмасында гаепсезгә җәберләнеп, сөргеннән акланып, сугышта аягын калдырып кайткан элекке зоотехник, хәзерге умартачы Җәгъфәр ролен уйный. «Һиҗрәт»тә аферист Баһави ролен башкара. Мөхит уенында «Айгөл иле» Җәгъфәре болганчык күл төсле тымызык кеше булып сурәтләнсә, «Һиҗрәт» Баһавие, эчкәндә дә билгеләнгән сәгатьләр беләч генә эчеп, баш төзәткәндә дә сәгатенә карап кына төзәтә торган мут кеше булып гәүдәләнә.

1970 елның язында Мулланур Мостафин шагыйрь Әхсән Баянның «Һәйкәл» дигән гражданнар сугышы елларында авылда Совет властен ныгыту өчен көрәш вакыйгаларын сурәтләгән шигъри-драматик репортажын сәхнәләштерә. Бу романтик стильдә язылган һәм романтик алымнар белән сәхнәгә куелган героик спектакльдә Татарстанның халык артисты Әнвәр Фәсхетдинов коммунист Арслан ролен, Мөхит Кичүбаев авыл кулагы Гобәй ролен башкара. Мөхит бу образны җаны-тәне белән яратмый һәм үзенең зәһәр чәчрәтеп тора торган кансыз хәрәкәтләре белән әсәрдәге сыйнфый дошманнарга каршы юнәлдерелгән нәфрәтне көчәйтүгә хезмәт итә.

Сызгы һәвәскәреннән Татарстанның халык артисты дәрәҗәсенә күтәрелгән, дистәләрчә яшь артистлар үстерүдә армый-талмый эшләгән, утыз елдан артык театрның төп герое булып килгән, драмаларда да, комедияләрдә дә, трагедияләрдә дә бертигез уйнау остасына әверелгән һәм үз көйләре белән театрның уннарча спектаклен бизәгән Мөхит Кичүбаевның кырык еллык сәхнә гомере эчендә иҗат иткән образлары шул кадәр күп, аларның барысы турында язып та, сөйләп тә бетерергә мөмкин түгел. Сүз ахырында шуны гына әйтәм, Мөхит үзенең алтмыш еллык юбилеена минем Якутиядә алмаз эзләүчеләр турында, татар-рус-якут халыклары дуслыгы турында язылган «Раушан» дигән драмамда экспедиция җитәкчесе рус галиме Аркадий Захарич ролен уйнап килде. (Татарстанның халык артисты Хәким Сәлимҗанов белән Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Марсель Сәлимҗанов постановкалары.) Мин Мөхит кебек олы җанлы, зур талант иясенең үз әсәрем буенча эшләнгән спектакльдә катнашуы һәм үз уены белән спектакльне бизәве белән горурланам.

Мөхит Кичүбаев иҗат иткән образлар арасында татарлардан тыш, рус, башкорт, украин, казакъ, әзәрбәйҗан, грузин, бурят, югослав, әфган һәм башка халыкларның вәкилләре дә, ялкынланып янып торучы фидакарь революционерлар да, партия җитәкчеләре дә, колхоз председательләре дә, промышленность командирлары да, нефтьчеләр, партизаннар, укытучылар да, композиторлар, язучылар, гади колхозчылар, эшчеләр дә, яшьләр һәм картлар да, муллалар, ишан вә мөдәррисләр дә, байлар, кулаклар да, бизнесменнар, аферистлар да, бюрократлар һәм ялагайлар да бар. Никадәр көч, никадәр энергия кирәк шул кадәр күп образны иҗат итәргә! Мөхитның иҗат юлына өстән-өстән генә күз йөртеп чыксаң да, аның гомерен эзяга уздырмаганлыгын, кеше буларак, Советлар Союзы гражданы буларак, коммунист буларак ил тарафыннан үз өстенә йөкләнгән бурычларны намус белән үтәп чыкканлыгын ачык күрәсең. Бу мактанырлык та, горурланырлык та олы, якты гомер юлы.

≈≈≈≈≈

# МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫНДА БЕР КИЧӘ

Егерменче еллар ахырында Казанда әдәбият кичәләре шактый еш үткәрелә иде. Мәдәният йортында (хәзер ул йортта Яшь тамашачылар театры) уздырыла торган ул кичәләр кызыклы була, шуңа күрә халык бик күп җыела иде. Безнең өй шул Мәдәният йорты каршында гына булганлыктан, мин ул кичәләрнең барысына да йөрим һәм, яшь җырчы буларак, үзем дә чыгышлар ясыйм. Шуның өстенә ул елларда мин үзем дә язгалыйм һәм язучыларның барысы белән дә яхшы ук таныш идем.

Бу истәлегемдә мин 1929 елда үткәрелгән һәм күңелемдә аеруча нык сакланып калган бер кичә турында сүз алып бармакчы булам.

Мин тамаша залына килеп кергәндә анда байтак кына язучы җыелган иде инде. Беренче рәттә Гадел Кутуй утыра һәм, гадәтенчә, бик ягымлы елмаеп, янәшәсендә утырган Һади Такташка нидер сөйли. Һади Такташ, иелә төшеп, аны зур игътибар белән тыңлый. Тамаша залы шактый суык булуга да карамастан, Кутуй сары эт тиресеннән тегелгән тунын салып, үз янындагы буш урындыкка куйган. Тун өстендә соры кепкасы ята. Такташ та өске киемен салган. Ул соры костюм, ак күлмәк кигән һәм галстук таккан. Әнә ул, озын саргылт чәчләрен сыпыргалап, зур зәңгәр күзләрен Гаделгә текәп утыра. Ә Гадел аңа кызып-кызып футуризм турында нидер сөйли. Мин аның футуризм белән мавыкканын беләм, әмма футуризмның асылын тиешенчә аңлап бетерми идем әле. Шунлыктан, кызыксынып китеп, аларга якынрак килдем. Мине күргәч, алар мине үзләре янына ук чакырып утырттылар. Шуннан соң моңарчы тыныч кына тыңлап утырган Такташ, Гадел сөйләгәннәргә җавап итеп:

— Юк, йөрәк маем, алай түгел,— диде.— Татарлар футуризмга соңга калдылар инде, канатым.

Шул чак шагыйрьләр янына урта буйлы, базык гәүдәле шагыйрь Фатих Кәрим килеп исәнләште һәм тегеләрнең сүзе бүленеп калды. Ул чорда Фатих Кәрим «Азат хатын» редакциясендә эшли иде. Беренче карашка кырыс холыклы булып күренсә дә, асылда Фатих йомшак табигатьле кеше иде. Аскы ирене өскесеннән калынрак булганга, сөйләшкәндә ул авызын бөребрәк сөйләшкән сыман күренә иде. Кара чәчләрен сыпырып-рәтләп алгач, Фатих минем янга килеп утырды. Шул чак Һади аңа, мине күрсәтеп:

— Фатих, бу кызны һәр яктан үстерергә кирәк. Аңлыйсыңмы, йөрәк маем? — диде.— Син риза булсаң, без аны Кутуй белән икебез шефка алыр идек.

Фатих эчкерсез итеп елмайды да:

— Бик әйбәт булыр! — диде.— Без дә тырышырбыз аны үстерергә. Безнең журналда аның шигырьләре генә түгел, русчадан тәрҗемә иткән мәкаләләре дә басылгалап тора, шеф иптәшләр!

Аннары Такташ минем кайсы мәктәптә укуым, кайда тууым, ана теле укытучыбыз кем булуын сораша башлады. Мин татар телен Уфада язучы Нәкый Исәнбәт укытканлыгын әйткәч:— Ә шигырь кайчан яза башладың? — диде.

— Аның өчен үзем җавап бирим әле,— диде Фатих, мин авыз ачарга өлгергәнче.— Мин үзем дә Уфадан бит. Мөбичәне бала чактан ук беләм.

Такташ кычкырып көлеп җибәрде дә, Гаделгә борылып:

— Гадел, бак канатым, без инде шефлык мәсьәләсендә соңга калганбыз икән ләбаса! — диде һәм, миңа мөрәҗәгать итеп:— Ә син, сеңел, кызарма. Без бит якын итеп, дус итеп кенә көлешәбез.

Аннары кулымнан тотты да:

— Әгәр, сеңел, киңәш, ярдәм кирәк булса, безгә кил! Всегда поможем. Шулаймы, Кутуй? — диде.

— Әлбәттә, әлбәттә! — диде Кутуй, һәрвакыттагыча ягымлы елмаеп.

Мин ул кичне Муса Җәлилгә урын алып калырга вәгъдә иткән идем, шунлыктан, әлеге шагыйрьләргә рәхмәт әйтеп, арткы рәтләрнең берсенә утырдым. Аннары минем янга таныш кызларым Хаҗәр белән Зәйнәп һәм «Кызыл кошлар» исемле әсәре һәм рус классикларының шигырьләрен татарчага тәрҗемә итүе белән танылып киткән яшь шагыйрь — урта буйлы, чандыр гәүдәле Әхмәт Исхак та килеп урнаштылар. Без үзара исәнләшә торган арада залга юнгштурм костюмы — өстенә күн тужурка, аягына гетрлар кигән Фатих Хөсни килеп керде дә ишек төбендә тукталып калды. Ул кепкасын салып кулына тоткан, кара һәм озын «тыңлаусыз» чәчләре бүрек сыман булып күперәп тора. Ул инде шактый танылып килүче әдип. Аның шигырьләре һәм хикәяләре саф татарча, халыкчан итеп язылулары белән аерылып тора. Кичәләрдә ясаган чыгышларында да һәм, гомумән, кешеләр белән сөйләшкәндә дә мәкальләрне, әйтемнәрне бик еш һәм урынлы куллана. Аның җылы лиризм белән сугарылган хикәяләрен мин аеруча яратып укый идем.

Үзе шундый җор кеше булса да, Фатих күп вакыт кичәләрдә ялгыз утыра, кызлар белән бер дә аралашмый иде. Менә бүген дә шулайрак булды. Аның ишек төбендә тукталып, як-якка карангалап торуын күреп, шагыйрь Сирин минем яндагы буш урындыкка ымлаган иде, ләкин Фатих утырмады. Сирингә карап:

— Сыерлар су эчкәндә бозаулар боз ялый! — диде дә алгарак үтеп китте.

Кичә башланачагын белдереп, кыңгырау шалтырагач, залга халык күпләп керә башлады. Әнә өстенә шинель кигән зифа буйлы язучы Габдрахман Минский да, йолдызлы шлемын кулына тотып, килеп керде. Аның Кызыл Армия тормышын чагылдырган хикәяләре басыла, Татар дәүләт театрында «Керәш бара», «Шлем» исемле пьесалары зур уңыш белән куелып килә. Әмма ул үзен тыйнак тота, чыгышлар ясарга ашыкмый, юри күләгәдә калырга теләгәндәй, җыелышларда арткы рәтләрдә утыра. Залны бер кат күздән кичергәч, Габдрахман Әмирхан Еники янына барып утырды.

Әмирхан Еники — урта буйлы, бик сәламәт кешеләрдә генә була торган алсу йөзле егет. Ул һәрчак бик пөхтә киенеп йөри. Бүген дә ул бик әйбәт соры костюм киеп килгән. Аның хикәяләрен тәнкыйтьчеләр югары бәяли: кечкенә әсәрләрендә дә зур фикер бирә, безнең әдәбиятта Әмирхан Еники зур художник булып үсәчәк, дип язалар. Мин үзләренә карап торганны күргәч, Әмирхан белән Габдрахман баш иеп минем белән исәнләштеләр дә үзара сөйләшә башладылар.

Өченче кат кыңгырау чылтырагач, ашыгып, Муса Җәлил килеп керде. Үткен күзләре белән залны тиз генә тикшереп чыкты да, минем яндагы буш урынны күреп, шунда килеп утырды. Гел җыелыш башланыр алдыннан гына килеп керә ул.

Президиумга башта Кави Нәҗми белән Шамил Усманов чыктылар. Алар икесе дә хәрби кием кигән, икесе дә базык буйлы. Кави Нәҗми инде танылган язучы, ТАППның җитәкчеләреннән берсе. Шигырьләрдән прозага күчеп, зур әсәрләр, хикәяләр язган кеше. Үткән 1928 елда Казанга Максим Горький килгәч, аның белән якыннан дуслашучы да ул булды. Ә Шамил Усманов атаклы хәрби язучы, ул Татарстанның тамаша идарәсе җитәкчесе. Аның пьесалары да Татар дәүләт театрында зур уңыш белән бара. Үзе инде танылган әдип булса да, аның дулкынлы кара чәчләрендә, түгәрәк ачык чыраенда балалык кыяфәте, йомшак күңеллелек чагылып тора.

Кави Нәҗми басып, халык тынганны көтте дә, җыелышны ачып, президиум исемлеген укыды. Залдан берничә кеше сәхнәгә менде. Алар арасында интеллигент кыяфәтле Гомәр Толымбай белән күбәләк-галстук кигән базык гәүдәле, түгәрәк йөзле Мирсәй Әмир дә бар иде. Ул галстук Мирсәй Әмиргә артистлар кыяфәте бирә. Аның кара күперенке чәчләре маңгаена төшеп тора. Искиткеч тыныч, тыйнак, аз сүзле булуы белән ул бар нәрсәгә битараф кеше кебек күренә. Чыгышларында да бәшкалар кебек ямьмый, чәпчеми, ләкин тиешлесен, кызган тимерне вакытында суккан

кебек, җайлап кына әйтеп, өздереп бла. Тавышына караганда аны мактамаса да яманламый дип уйларга мөмкин, ә нәтиҗәдә әсәрне дә, авторны да туздырып ташлый иде.

Кави Нәҗми көн тәртибен укыды да трибуна артына басты. Ул Татарстан комсомолының XIII конференциясенә әзерлек барышы турында сөйләде, язучылар алдында торган бурычларга тукталды. Соңыннан иртәгә ТАПП әгъзалары махсус җыелышка килергә тиешлеген белдерде.

К. Нәҗми докладыннан соң, үз әсәрләрен уку өчен, язучыларга сүз бирелә башлады.

Беренче булып, чәчләрен артка сыпыра-сыпыра, сәхнәгә Фатих Кәрим менде. Гадәттәгечә сөйләшкән кебек, шигырьләрен дә сәлмәк кына, сабыр гына итеп укыды. «Безнең һәйкәл», «Мин дә бүген орденлы» исемле шигырьләр иде алар. Соңгысы тыңлаучыларга аеруча ошады, икенче кат укырга мәҗбүр иттеләр. Ул шигырь мондый сүзләр белән бетә иде:

**Комсомолия!**
**Синең әгъзаң бит мин,**
**Сиңа гына**
**Беркеткәнмен бөтен күңелне;**
**Шулай булгач,**
**Һәммәгезгә игълан итәм:**
**Мин дә бүген**
**Кызыл орденлы!**

Фатих трибунадан төшкәч, Гадел Кутуй сүз алды. Ул үзенең «Илләр кызы» белән «Карт пычкычы» исемле шигырьләрен укыды. Кутуй әсәрләрен шагыйрьләрчә сузып түгел, ә артистларча, хисле итеп укый иде. Язучылар да, студентлар да аны бик яраталар, ул трибунага чыкканнан соң зал гөж килә иде. Бүген дә каты алкышладылар.

Җиңел сөякле, тиз хәрәкәтле Кутуйдан соң, сабыр атлап, трибунага Һади Такташ күтәрелде. Озын чәчләрен артка чайкап алгач, укый башлады. Башта «Алсу», аннары «Мокамай» исемле әсәрләрен укыды. Такташ укыганда Муса Җәлил блокнотына нидер язып утырды. «Мокамай»ны залдагы халык бик хуплап кабул итте, аны ике кат укыттылар. Гадәттә тыныч, тыйнак Такташ, шигырьләрен укыганда янып, дәртләнеп, киң күкрәген тагы да киерә төшеп укый, бөтенләй башка кешегә әйләнә иде. Бүген дә шулай укыды ул.

Такташ артыннан Габдрахман Минский үзенең яңа хикәясен укыды. Аны да яратып тыңладылар.

— Тагы кем әсәрен укырга тели? — дип, Кави Нәҗми аягүрә басты. Җавап булмагач тагы сорады:

— Кем тәнкыйть белән чыга?

Мин бер читтәрәк утырган Гази Кашшафка карадым. Башка вакытта ул залны гөрләткән әсәрләрдән соң тәнкыйть белән чыга иде. Бүген кузгалмады, тыңлап кына утыра.

— Мин бер-ике сүз әйтим әле,— дип, президиумда утыручы Гомәр Толымбай трибуна янына килде. Ул инде әдәбият өлкәсендә танылган, яшьлегенә карамастан, татар язучылары арасында иң күп китаплар, мәкаләләр язган кеше. Аның теле үткен, тәнкыйть итсә төпле итеп, әсәрдән мисаллар китереп сөйли торган иде. Бүген укылган әсәрләрдән Такташның «Мокамай»ына аеруча югары бәя бирде.

— Бу шигырендә «үлеп» яңадан туган Такташны тагы да ачык күрәбез,— диде ул.— Татар язучыларыннан беренче буларак автор бу шигырьләренә социаль эчтәлек керткән...

Толымбай президиумга утыргач, Муса кулын күтәрде дә, сәхнәгә менеп, трибуна артына басты.

— Мин дә Такташның «Мокамай» шигыренә тукталасым килә,— диде ул.— Бу шигыре белән безнең атаклы, талантлы трибун шагыйрь тагын да үскәнен раслый. Бу әсәрдәге юллар совет шагыйренең девизы дип әйтергә була...

Муса төшеп утыргач, башка чыгышлар булмады — тәнәфес игълан ителде.

**МӨБИНӘ ТАҺИРОВА.**

Рафаэль Мостафин

# ҖАВАПЛЫЛЫК ХИСЕ

*Яшь шагыйрьләр иҗаты турында уйланулар*

## Кереш урынына

Казанның актерлар йортында яшь шагыйрьләр иҗатына багышланган әдәби кичә бара. Зал шыгрым тулы, зал тып-тын. Эшче яшьләр, студентлар, иҗат интеллигенциясе вәкилләре йотлыгып шигырь тыңлый. Сизеп, тоеп-күреп утырам: зал белән шагыйрьләр арасында тулы аңлашу, якынлык һәм теләктәшлек хөкем сөрә. Заманында кайбер тәнкыйтьчеләргә артык катлаулы һәм авыр тоелган шигырьләр дә халыкка барып җитә, рәхәтләнеп аңлашыла икән ич. Тәнәфес җитүгә, әле анда, әле монда бәхәсләр кабынып китте. Тамашачылар яңа гына тыңлаган шигырьләр турында фикер алышалар. Коридорларда, кием-чишенү урыннарында теге яки бу шагыйрьнең иҗади йөзе, әдәби хәрәкәттәге роле хакында әңгәмәләр куерып китә, ак һәм иркле шигырь, традиция һәм новаторлык мәсьәләләре кузгатыла.

Бер төркемнән икенчесенә күчә-күчә, бәхәсләргә колак салып йөрим. Бүгенге поэзиябез турында уйланам, аның иҗтимагый һәм социаль йөзе, авторитеты күтәрелүгә куанам. Без: «Укучыларны сәнгать әсәрләре, язучылар тәрбияли», дип сөйләргә яратабыз. Дөрес сүз, билгеле. Әмма әдәбият белән укучылар арасында башка төрлерәк бәйләнешләр дә яши, укучының аң-белем һәм культура дәрәҗәсе, ахыр килеп, үзе дә әдәбият үсешенә билгеле бер йогынты ясый икән. Һәм безнең бүгенге поэзиянең казанышларын әдәби кадрлар саны артуы белән генә түгел, ә укучыларыбызның белем, культура дәрәҗәсе, эстетик сизгерлеге күтәрелү белән дә аңлатырга кирәктер.

...Моннан унбиш еллар элек танылган язучыларыбызның берсе татар поэзиясенең картаеп баруы турында борчылып сөйләгән иде. Ул, мисаллар китереп, исәпләп тә күрсәтте. Әгәр ялгышмасам, безнең шагыйрьләрнең уртача яше илләләр чамасында, дигән иде бугай. Яшьләр рәтендә йөргәннәрнең дә күбесе кырыкны тутырып килә, диде ул. Аннан бирле хәл нык үзгәрде. Хәзер без, газета-журналлар аша, ел саен диярлек дистәләгән яңа авторлар белән очрашып торабыз. Ихтимал, аларның һәммәсе дә поэзиядә генә калмас, үз йөзләрен таба алмыйча, иҗат эшеннән бөтенләй китүчеләр дә булыр. Әмма шул кадәресе бәхәссез: әдәбиятка килүче яшь көчләр ташкыны никадәр көчлерәк булса, әдәбиятның базасы, аны туендырып торган туфрак шул кадәр баерак, яшь авторлар арасыннан яңа Тукайлар, Такташ һәм Җәлилләр чыгачагына өмет һәм ышаныч шул кадәр зуррак булачак.

# Дөньяны шигъри танып-белү

Без барабыз
Яшьлек юлларыннан,
Корчагиннар үткән юллардан.
Без яшьлекне мирас итеп алдык
Көрәшләрдә егылганнардан —
Мусалардан, Мулланурылардан.

И. ЮЗЕЕВ.

Кеше организмында өзлексез яңару процессы бара, картайган күзәнәкләр үлә, алар урынына яңалары туа, диләр. Шигърият организмы да шундый. Анда да мәңгелек хәрәкәт, өзлексез үзгәреш бара. Бу бик табигый һәм закончалыклы күренеш. Шуның белән бергә, әдәби буыннар алмашынуы гел бер төсле генә дә бармый. Әдәбият тарихында шундый дәверләр очрый, талантлы яшьләр иҗат мәйданына төркемнәре белән, дулкын-дулкын булып киләләр дә беренче адымнарыннан ук укучыларның ихтирамын һәм мәхәббәтен казанып өлгерәләр. 50 елларның беренче яртысында бездә дә шундыйрак хәл булды: поэзия күгендә бер ук вакытта диярлек биш яңа исем күренде. Сүз Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Рәшит Гәрәй, Хисам Камалов һәм Илдар Юзеевлар хакында бара.

Дөрес, бу шагыйрьләр тәүге адымнарыннан ук үз мәктәпләрен тудырдылар, шигъриятkә яңа тон бирделәр, дип булмый. Аларның беренче әсәрләре камиллектән шактый ерак һәм ярыйсы ук бертөсле иде. Әмма, шуңа да карамастан, алар иҗатында киң катлау укучыларның игътибарын җәлеп итәрлек ниндидер уңай сыйфатлар да булган, билгеле. Нинди сыйфатлар соң алар!

Барыннан да элек, алар иҗатында гадилек, эчкерсезлек, дөньяны аңларга, аны танып-белергә теләк, омтылыш көчле иде. Үз иҗатларының шул сыйфатлары белән алар укучыны тарттылар, аның игътибарын җәлеп иттеләр. Ул чактагы өлкән поэзиябез исә, ничектер, әле һаман парадный киемнәрен салырга куркыбрак йөри, шагыйрьләребезнең кайберләре, үз исемнәреннән сөйләүдән бигрәк, кирәксә-кирәкмәсә дә бөтен халык исеменнән, үз хыялларындагы миллионнар исеменнән сөйләргә ярата иде. Шуңа күрә дә, телиләрме-юкмы, аларга тавышларын күтәрә төшеп, күкрәкләрен киеребрәк сөйләшергә, зуррак, биегрәк күренү өчен, аяк очларына басып йөрергә туры килде. Ахыр чиктә, бу аларны ясалмалыкка этәрде, укучыларның ышанычын югалтуга китерде. Болардан аермалы буларак, 50 еллар башындагы яшь шагыйрьләр (соңыннан алар «беренче дулкын шагыйрьләр» дигән исем алдылар) укучы белән гади һәм табигый тонда, күптәнге дуслар кебек сөйләшергә тырыштылар. Алар үзләре белгән чын тормыш турында, сугыш елларына туры килгән авыр бала чаклары, сугыш кырларыннан кайтмый калган әтиләре, абыйлары турында яздылар. Һәм укучы да дуслыкка дуслык белән җавап бирде, әлеге төркемгә кергән шагыйрьләрнең әсәрләрен үз итте, яратты.

Дөрес, яшьләре, тормыш тәҗрибәләре һәм талант дәрәҗәләре ягыннан ул шагыйрьләр бер төсле түгел иде. Алар арасында иң яше саналган Илдар Юзеев, мәсәлән, әдәбият мәйданына мәктәп эскәмиясеннән килде дияргә була. 1955 елда, аның хакында укучылар сөйли, тәнкыйтьчеләр яза башлаганда, ул нибары 22 яшьтә иде. Арада иң өлкәне саналган Гамил Афзал беренче шигырьләрен 34 яшь тулганда дөньяга чыгарды. Шул ук 1955 елда Хисам Камаловка — 29, Шәүкәт Галиевкә — 27, Рәшит Гәрәйгә 24 яшь иде. Шулай да иҗат һәм эстетик платформалары ягыннан алар бер-берсенә шактый якын торалар иде.

Беренчедән, аларның әдәби остазлары уртак була. Ул — Сибгат Хәким. Нәкъ менә ул, беренче булып, аларга игътибар итә, аларны әдәби осталыкка, үз иҗатларына таләпчән булырга өйрәтә, беренче җыентыкларына шигырьләрен сайларга булыша. Шуңа да әлеге төркемгә кергән шагыйрьләрнең тормыш күренешләренә якын килү алымнарында, алар иҗатында лиризмның өстенлек итүендә, шигырьләренең басынкы һәм эчкерсез характерда булуында Сибгат Хәким шигъриятенең йогынтысы сизелә.

Бу шагыйрьләрне үз вакытында юкка гына «Хәким мәктәбе шәкертләре» дип йөртмәгәннәр, билгеле.

Икенчедән, алар һәммәсе дә диярлек уртак әдәби традицияләр тәэсирендә тәрбияләнеп үсәләр. Алар иҗатында, барыннан да ныграк булып, һади Такташ интонацияләре (бигрәк тә И. Юзеев шигырьләрендә) сизелә, аңа караганда бераз кимрәк, шулай да ярыйсы ук сизелерлек дәрәҗәдә Әхмәт Фәйзи поэзиясе йогынты ясый. Миңа калса, Ш. Галиев һәм Г. Афзал шигырьләрендәге юмористик агым Әхмәт Фәйзи иҗатыннан башланып китә шикелле.

Һәм, ниһаять, өченчедән, бу шагыйрьләр иҗатына үз эзен салган чор, заман уртак була. 50 еллар уртасында безнең тормышта булып узган үзгәрешләр поэзия әсәрләренә дә тәэсир итми калмый. Иҗтимагый тормыштагы яңа җилләрне, башлап, тагын да әлеге яшь шагыйрьләр сизеп ала, алар тасвирлый башлый. Әйе, беренче дулкын шагыйрьләрен үзара берләштерә, якынайта торган сыйфатлар шактый. Әмма алга таба аларның һәркайсы үз юлы белән китә, үзенә генә хас стиль тудырырга, үзенә генә хас тавыш белән җырларга тырыша.

Шәүкәт Галиев, мәсәлән, баштарак бүтәннәрдән бер ягы белән дә аерылып тормый иде. Башка каләмдәш дуслары кебек үк, ул да иҗат эшчәнлеген традицион калыптагы лирик шагыйрь буларак башлады. Әгәр Ш. Галиевнең бүгенге лирик шигырьләрен аның беренче иҗат тәҗрибәләре белән чагыштырып карасак, шагыйрьнең осталык ягыннан нык үскәнен күрербез. Аның беренче шигырьләре гади һәм табигыйлар, вакыты-вакыты белән хәтта беркатлырак иделәр. Ш. Галиевнең бүгенге лирикасы тепенең байлыгы һәм сыгылмалыгы, композицион төзелешенең төгәллеге, үткен һәм нечкә юморы, кыскалыгы һәм җыйнаклыгы, әдәби образлардан гаять оста файдалана белүе белән аерылып тора. Әмма югалтулар да юк түгел. Никадәр генә гади һәм беркатлы күренмәсеннәр, авторның беренче шигырьләрендә ихлас күңеллелек, эчкерсезлек көчле иде. Хәзер исә еш кына аның әсәрләренә шигъри кайнарлык җитми. Ул әйтерсең лә үзенең осталыгы белән масая, гади генә әйбердән, очраклы рәвештә килеп туган теге яки бу фикердән менә дигән шигырь «эшли» алуы белән горурлана. Бу яктан караганда, аның «Казан утлары» журналының 1971 елгы 6 санында басылган «Тормыш тозы» исемле шигыре аеруча характерлы. Сугыш елларында кешеләргә ашамлык тоз җитешмәвен искә төшереп, шагыйрь тоз төшенчәсен һәм туры, һәм күчермә мәгънәсендә уйната:

...Аңла син ул заманны да,
Тозсыз сүздән арала,
Кайчагында тозсыз сүз дә
Тоз сала бит ярага...

Һәр кешенең тозы була,
Була, ягъни, мәгънәсе,
Сер түгел, тозсыз да була
Кайбер хода бәндәсе...

Ә тормыш — тозлы тир түккән
Җир уллары кулында.
Җирдә иң кирәк тә шулар —
Сүземнең тозы шунда.

Сүз дә юк, әдәби яктан шигырь менә дигән итеп эшләнгән. Башка бер шагыйрь өчен ул зур уңыш булып санала алыр иде. Әмма хәзерге көндә Татарстанның күренекле шагыйрьләренең берсе булып җиткән Шәүкәт Галиевтән фәлсәфи тирәнлек, чын дулкынлану һәм кайнарлык белән сугарылган тагын да көчлерәк әсәрләр көтәсе килә.

Ш. Галиев юмористик жанрлар өлкәсендә аеруча зур уңышка иреште, шул өлкәдә һәм бигрәк тә балаларга багышланган шигырьләрендә ул үзен тыңдаучысез шагыйрь итеп танытты. Һич шикләнми әйтергә була, бүгенге көндә ул Бари Рәхмәт традицияләрен уңышлы дәвам иттерүче иң яхшы балалар язучысы. Ш. Галиев — иң актив һәм

эшчән шагыйрьләребезнең дә берсе. Әдәбиятта ул өч кеше өчен — лирик шагыйрь, юмористик шагыйрь һәм балалар язучысы буларак — эшли. Киләчәктә, бәлки, аның иҗаты бераз үзгәрәк юлдан, юмор һәм лириканың якынаюы, синтезы юлыннан үсәр. Ш. Галиевнең иң яхшы шигырьләре шулай уйларга нигез бирә.

Гамил Афзал укучылар алдында шулай ук ике планда: лирик һәм юмористик шагыйрь буларак ачылды. Тик шунысы бар, әгәр Ш. Галиевнең юморы йомшак, ягымлы, лирик характерда булса, Г. Афзал үзен үткен фельетон, усал һәм рәхимсез сатира остасы итеп танытты. Үкенечкә каршы, соңгы елларда Г. Афзал иҗатының сатирик куәте шактый йомшарды. Авторның узган ел «Казан утлары» журналында басылган «Түн астында кыюлык» һәм «Иялэнгән бөркет» исемле сатирик шигырьләре аның бу өлкәдәге үз казанышларыннан шактый кайтышлар.

Гамил Афзалның лирикасы да үзенчәлекле. Дөрес, Ш. Галиевнекеләр белән чагыштырганда, аның лирик шигырьләре композицион яктан таркаурак, әдәби эшләнеше ягыннан йомшаграк сыман тоела, аларда буш токымнар да ешрак очрый. Шулай да иң яхшы шигырьләрендә Г. Афзал кайнар һәм эчкерсез хисләре белән яндыра, тормышның катлаулы һәм җитди күренешләренә карата игътибарлы булуы белән үзенә җәлеп итә. Тау сыртларының биеклеген иң югары ноктлары буенча билгелиләр. Ә Г. Афзал иҗатында исә биек ноктлар аз түгел.

Бу дулкынның иң яшь вәкиле саналган Илдар Юзеев иҗаты да үзенчәлекле юл белән үсеп китте. Укучылар, илленче еллардагы яшь буынның уй-теләкләрен чагылдыручы романтик шагыйрь буларак, аны баштан ук яратып каршы алдылар, үз иттеләр. Үзе хакында зур шау-шу кузгаткан шагыйрь соңыннан үз лирикасының кайнар дәртен бераз киметә төште. Ул әле драматургиягә, әле эпик һәм фәлсәфи поэма жанрына мөрәҗәгать итеп карады. Һәм бу эзләнүләр аның иҗаты өчен эзсез калмады. Шагыйрьнең соңгы еллар лирикасына көчле драматизм да, эпик киңлек һәм фәлсәфи тирәнлек тә өстәлде. И. Юзеевның «Казан утлары» журналының 1971 елгы 2 һәм 10 саннарында басылган шигырьләрен аның үз иҗатында бер адым алга китеш дип кенә түгел, соңгы еллардагы татар поэзиясе өчен дә матур бер вакыйга дип бәяләргә кирәк. Хәзер аның иҗатының тематик колачы гына киңәеп калмый, ә яңгырашы, тональносте үк үзгәреш кичерә. Яшьлек пафосы төпле, тирән уйланулар белән алмашына. Тыштан аның поэзиясе салмакланды кебек, аның каравы, тагын да тирәнәя, олыгая төште. Хәзер ул ташларга бәрелеп аккан тау чишмәсе кебек шауламый, ә чәчәкле ярлар эченнән җай гына агып яткан елганы хәтерләтә:

Һәр нәрсәгә карыйм исем китеп:
Алтын көзгә,
Ачык йөзгә,
Бөдрә тупылга.

Уйчан Айга,
Шаян тайга,
Йөгерек дулкынга,—

Һәр нәрсәгә карыйм исем китеп,
Тәүге тапкыр күргәндәй итеп.

Бу төркемгә кергән ике шагыйрьнең — Рәшит Гәрәй белән Хисам Камаловның — иҗат язмышы катлаулырак булып чыкты.

Хисам Камалов поэмаларында сугыш утында янып көйгән, яраланган һәм сугыштан соңгы тормышта үз урынын эзләп җәфаланган буынның авыр уйлары, үкенечле кичерешләре тасвирланды. Салмак тавышлы, тормыш турында җитди итеп, тирәнтен уйлана белүче шагыйрьне укучы тиз таныды һәм яратып өлгерде. Ләкин аның соңгы елларда язган әсәрләрендә ясалмалык, бертөрлелек сизелә башлады. Үзен борчыган һәм дулкынландырган мәсьәләләр, үзе кичергән һәм күргән вакыйгалар турында язганда, шагыйрь буларак, ул кызыклы һәм үзенчәлекле. Инде үзе белмәгән, үз башыннан узмаган тормыш күренешләре турында язарга тотындымы, аның шигырьләре сыегая һәм төссезләнә башлый, шагыйрь белән укучы арасына салкынлык үтеп керә. Юк, гомумән алганда, Х. Камалов элеккедән начаррак язмый, тик тормыш үзе, бүгенге чынбарлык нык алга китте.

Рәшит Гәрәй белән дә шуңа охшашрак хәл булды. Аның беренче шигырьләре дөньяны шигъри итеп сурәтли, артык гадәти күренешләрнең яңа, гадәти булмаган якларын ача алулары белән аерылып торалар иде. Ләкин, Ш. Галиев, И. Юзеевлардан аермалы буларак, ул ирешелгәннәр белән канәгатьләнеп калды, эзләнүләрен йомшарта төште, башка жанрларга игътибар итми башлады һәм моның нәтиҗәләре дә үзен озак көттермәде. Мин Нәби Дәүлинең «Бизәк өчен түгел, кирәк өчен» [«Казан утлары» журналы, 1971 ел, 7 сан.] исемле мәкаләсендә Р. Гәрәй иҗатына бирелгән гомуми бәя белән килешәм. Ләкин шуны гына искәртәсе килә, соңгы елларда иҗат ителгән шигырьләрендә ул, шагыйрь буларак, шактый үсте, тирәнәйде. Бу киләчәктә аның иҗатында яңа бер күтәрелеш булачагына ышаныч уята.

Төрле характердагы кимчелекләре булуга да карамастан, беренче дулкын шагыйрьләре асылда үзләренә булган ышанычны аркладылар һәм бүген, урта буын шагыйрьләр рәтенә күчеп, шигъри йөкне төпкә җигелеп тарталар. Һәр кайсының индивидуаль йөзе никадәр генә ачык беленеп тормасын, әле хәзер дә аларның ниндидер уртак, гомуми сыйфатлары сакланып калган. Дөньяны лирика алымнары белән танып-белергә омтылу, һәртөрле формаль алымнарны кире кагу, шигъри яңгыраштагы басынкылык һәм эчкерсезлек, поэзияләренең югары идеялелеге — ул сыйфатларның иң мөһимнәре әнә шулар.

## Көч туплау дәвере

Алмаш булып килер яңа буын,
Көнләшербез карап аңар без,
Бездән көчле,
Таза шул буынга
Аренаны биргән чагында,
Горур караш ташлый алырбызмы
Үткән көннәребез ягына.

М. ШАБАЕВ.

Яшьләре һәм иҗади өлгерүләре ягыннан күптән өлкәннәр ягына чыксалар да, Галиевләр, Юзеевлар буынына бик озак яшьләр рәтендә йөрергә туры килде. Чөнки алардан әдәби эстафетаны кабул итеп алырга тиешле алмаш артык акрын үсте.

50 елларның икенче һәм 60 елларның беренче яртысы — поэзия белән кызыксыну аеруча көчәйгән һәм барыннан да бигрәк яшь рус шагыйрьләре иҗаты иниәт күтәрелеп, үсеп киткән заман. Е. Евтушенко, В. Вознесенский, Б. Әхмәдуллина, Б. Окуджава, Р. Рождественский кебек шагыйрьләр нәкъ менә шул чорда шау-шулы дан, популярлык казаналар. Бу елларда татар поэзиясендә шактый кызыклы процесслар бара. Классик мираска, аерым алганда, Дәрдмәнд, С. Рәмиевләр иҗатына, Такташның беренче чор шигырьләренә булган мөнәсәбәт яңадан карала. Поэзиягә Хәсән Туфан кебек үзенчәлекле зур талант кайта, әдәбиятыбыз Муса Җәлилнең Моабит шигырьләре белән баый. Бу елларда Сибгат Хәким поэзиясендә яңа сыйфат үзгәрешләре барлыкка килә, күп кенә башка өлкән шагыйрьләрнең иҗади тавышы яңара. Ә менә поэзиягә яңа көчләр килү ягыннан эшләр мактанырлык булмый. Рус поэзиясендә шул чорда ук хасыйл булган көчле поэтик дулкын безнең әдәбиятка бары җиде-сигез елдан соң гына килеп җитә.

Дөрес, үз Вознесенскийларыбызны эзләү, хәтта аларны ясалма юл белән булса да тудырырга тырышып караулар булмады түгел. Мәсәлән, заманында бу шагыйрьнең алымнарына Роберт Әхмәтҗанов нярөп карады. Ләкин бер милли җирлектәге күренешне икенче милли җирлеккә күчереп утырту сирәк очракта уңышлы чыга. Һәм ул эшне Р. Әхмәтҗанов та уңышлы итеп башкарып чыга алмады. Татар Вознесенские булу түгел, ул хәтта үз иҗатындагы казанышларны да (әйтик, лирик җыр, романс өлкәсендәге) югалтып бетерә язды. Аның «Казан утлары» журналының 1971 елгы 11 санында басылган «Мин — Сонгми» исемле шигыре шул хакта сөйли торган бер мисал була ала. Шигырь зур һәм актуаль темага язылган, ләкин эчтәлеге ягыннан га-

зета, радио, телевидение аша белгән нәрсәләргә әллә ни яңалык өстәми. Формасы ягыннан исә ул яшь рус поэзиясенең үткәннәрен генә кабатлый.

Әмма акрынлык белән, аз-азлап булса да, безнең поэзиягә яшь көчләр килә торды. Әхсән Баянов шигырьләрендә, әйтик, 50 еллар уртасында безнең тормышта булып узган үзгәрешләрне аңларга тырышучы яшь кешенең каршылыклы уйлары чагылды. Аның герое өзгәләнә-бәргәләнә, еш ялгыша, әмма һаман дөреслекне, хакыйкатьне эзли. Соңгы елларда Ә. Баянов күбрәк проза әсәрләре яза башлады. Аның лирикасы проза әсәрләренә дә билгеле бер эз салды, аларны лирик тон, психологик нечкәлек белән баетты, прозасы исә, үз чиратында, поэзиясен тирәнәйтте. Бу тагын бер тапкыр чиктәш жанрларга мөрәҗәгать итү язучы өчен никадәр файдалы булуы турында сөйли.

Әмма шулай да, Ә. Баянов иҗатында күпмедер күләмдә социаль зәгыйфьлек, өлгермәгәнлек үзен сиздерә әле. Аның лирик герое тормышта барган процессләр өчен үзен җаваплы тоеп бетерми, ул еш кына тормыштагы кыенлыклардан зарлана, әмма шуларны бетерү өчен ныклап торып көрәшми. Шунысын әйтергә кирәк, Ә. Баянов әсәрләренә хас әхлакый, социаль өлгермәгәнлек «икенче дулкынга» кергән башка яшь шагыйрьләр иҗатында да сизелә. Аларның иҗади яктан акрынрак өлгерүләренең сәбәбе дә, бәлки, нәкъ менә шундадыр әле.

Марс Шабаев поэзиядә үз урынын тиз тапты һәм әдәбиятта ныклы урын алды. Ул әдәби телне әйбәт белә, шигырь һәм поэмаларын композицион яктан оста төзи, беркайчан да халтура юлына басмый, тема актуальлеге белән спекуляция ясамый. Ул күп эзләнә торган җитди шагыйрь, өстәвенә, искиткеч хезмәт сөючән булуы белән верылып тора. Ләкин, миңа калса, аның да ахырга кадәр ачылып җитә һәм үз мөмкинлекләрен тулысынча файдалана алганы юк әле. Вакыт-вакыт аның шигырьләренә чын кайнарлык, ихлас күңелдән дулкынлану җитми. Хисләрен укучыга ул еш кына тышкы чаралар — инверсияләр, юлларны бүлеп язу, күп нокталар кую аша җиткермәкче була:

Йөгереп-уйнап йөгерек дулкын килә,
Йөгерек дулкын ярга тартыла.
Килә...
бәрелә...
үлә...
Күбекләре сүнә...

Менә тагын бер мисал:

Шаулап торган яшел җикәннәр
Корый...
көя...
яна...
Тик көл кала...
Күтәрелә янә...

Ләкин бу юлларда чын дулкынлану сизмим мин. Шундый тәэсир кала, гүя ки бу — хиснең үзе түгел, бары аның шәүләсе, имитациясе генә.

Әлеге төркемгә кергән шагыйрьләр арасында, аерым алганда, Нәҗип Мәдьяров, Егор Уткиннар иҗатында, пейзаж лирикасына тартылу да сизелә. Ләкин кояш баеган яки кояш чыккан вакытларның гүзәллеген, чык бөртекләрендә көмеш нурлар җемелдәвен, яңа чапкан печәннәрнең хуш исен бирәбез дип, алар еш кына тышкы матурлыкка, сентименталь төчелеккә бирелеп китәләр. Ә бит поэзия тормышның сурәтен ясау белән генә чикләнә алмый, ул аны тирәнтен аңлатып та бирергә тиеш.

Икенче дулкын шагыйрьләрнең күбесенә иҗади активлык җитми. Поэзиядә мәгълүм бер югарылыкка ирешкәннән соң, алар тынычланып калдылар, яңа формалар һәм алымнар эзләмәделәр, әдәбиятның башка жанрларына җитәрлек мөрәҗәгать итмәделәр шикелле. Дөрес, әгәр талантың булмаса, иҗади активлык үзе генә әллә ни файда китерә алмый, хәтта зарарлы булырга мөмкин. Касыйм Фәсәхов белән Абдулла Сәләхетдиновның чын шигърияттән шактый ерак торган китаплары нәкъ шул турыда сөйли.

Икенче буын шагыйрьләренең ни өчен иҗади яктан акрын үсүләрен, чагыштырмача йомшак булуларын ачыклап бетерү кыен эш, билгеле. Бәлки, аларга артык баласытып карау, мәрхәмәтле мөнәсәбәт кирәгеннән артыграк булгандыр! Бәлки, аларның үз сәләтләренә, үз көчләренә ышанычлары җитеп бетмәгәндер! Әмма төп сәбәпне аларның гражданин буларак акрын өлгерүләреннән, заман каршында, укучылар каршында, күп гасырлык татар поэзиясе каршында җаваплылык хисе тоеп җиткермәүләреннән эзләргә кирәктер. Менә шуңа да 50 елларның азагын һәм 60 елларның башын безнең яшь поэзиядә үзенә күрә көч туплау чоры булды, дип бәяләргә туры килә.

Шушы ук чорда бездә Әнвәр Давыдов башлап җибәргән сызык — интеллектуаль поэзия, зур социаль гомумиләштерүләргә омтылган, татар шигыренең сурәтләү чараларын яңартырга, баетырга омтылган поэзия сызыгы да — дәвам иттерелә. Бу агым, мәсәлән, Ш. Мәхмүдов, К. Мостафиннар иҗатында шактый нык сизелә. Безнең матбугатта аларның икесе дә чагыштырмача аз басыла, алар шулай ук әдәби тәнкыйть игътибарын да аз күргән кешеләр. Шулай да Ә. Давыдов поэзиясенең иң көчле, иң үзенчәлекле якларын 60 еллар уртасында иҗат мәйданына килгән «Өченче дулкын шагыйрьләренә» китереп бәйләүчеләр нәкъ шулар булды.

Яшьләре ягыннан икенче дулкын шагыйрьләре дә яшьләр рәтеннән чыктылар инде, ләкин аларның байтагы өлгергән шагыйрьләр сафына күчеп китә алмый тора әле. Алар поэзиядә үз урыннарын таба алырлармы — ул кадәресен вакыт күрсәтер.

## Күтәрелеш еллары

Кичә табылган алланы
Онытып, бүген
Яңасына ант бирәбез,
Күңел диварларына һаман
Яңа рәсемнәр эләбез,
Яңа җырлар өйрәнәбез,
Кырын көйгә көйләнәбез,
Кумирларны искерәләр,
Үзебезме
Акыллыга әйләнәбез?! —
Үзгәрәбез...

Р. ГАТАУЛЛИН.

Рус һәм күп милләтле бөтен совет әдәбиятында 50 елларның икенче яртысында һәм 60 еллар башында барган процесслар безнең яшь поэзиябезгә дә йогынты ясамый калмады. Барыннан да бигрәк, аны туендырып торган туфрак баеды, традицияләр киңәйде. Яшь шагыйрьләр үз классикларыбыз тәҗрибәсен генә үзләштереп калмадылар, Э. Межелайтис, П. Элюар, П. Неруда, Г. Лорка, Н. Хикмәт кебек шагыйрьләр иҗатына да торган саен күбрәк игътибар бирә башладылар. Аларның белеме һәм культура дәрәҗәләре күтәрелде, гражданин буларак җаваплылык хисләре үсте. Өстәвенә, алда бер тапкыр әйтелгәнчә, безнең укучыларның да, аеруча яшьләрнең, белем һәм эстетик дәрәҗәләре сизелерлек үсте. Шуларның һәммәсе яшь поэзиянең яңа күтәрелешен тәэмин итте. 60 елларның урталарында башланган шул күтәрелеш бүген дә дәвам итә. Мин Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Ренат Харисов, Гәрәй Рәхим, Рәшит Әхмәтҗанов, Рөстәм Мингалимов кебек шагыйрьләр иҗатын күздә тотам.

Бу шагыйрьләр игътибарны, барыннан да бигрәк, форма өлкәсендәге эзләнүләре белән җәлеп иттеләр. Кайберәүләргә бу эзләнүләр озак еллар буе туплана килгән традицияләрне җимерү, юкка чыгару булып тоелды, икенче берәүләр исә яңа ритмиканы, образлы фикерләүнең ассоциатив формаларын танырга һәм кабул итәргә ук теләмәделәр. Әмма аннан бирле узган вакыт эчендә шул нәрсә ачыкланды: әлеге шагыйрьләргә яңа формалар яңа эчтәлекне гәүдәләндерү өчен кирәк булган, хикмәт форма яңалыгында гына түгел, ә тормышны яңача танып-белергә һәм аңларга омты-

луда икән. Бүген ул шагыйрьләрнең кайберләре әледән-әле традицион шигырь калыпларына мөрәҗәгать итә, ләкин бу әле алар иҗатының яңалыгын, оригинальлеген юкка чыгара алмый. Боларның беренче дулкын шагыйрьләре белән уртак ягы шунда, Ш. Галиевләр буыны кебек үк, алар да поэзиягә оешкан төстә, бердәм эстетик платформалары булган хәлдә килделәр. Хәлбуки, әсәрләренең сыйфатлары ягыннан алар беренче төркем шагыйрьләреннән шактый аерылалар. Өченче дулкын шагыйрьләре иҗат мәйданына әдәби яктан ныграк әзерлекле, поэтик яктан өлгергәнрәк хәлдә аяк бастылар. Алар, барысы да диярлек, беренче адымнарыннан ук үзләрен башкалардан аерылып торган кызыклы авторлар итеп таныттылар. Бу төркем шагыйрьләр әдәби иҗат юлларын биегрәк ноктадан башладылар һәм алар үзләренең элгәреләреннән ераккарак китәрләр дип ышанырга кирәк.

Әлеге шагыйрьләрнең иҗат алымнары, ак һәм ирекле шигырь тирәсендә кирәгеннән артык тавыш, шау-шу куптару шуңа китерде, бер-берсеннән нык аерылып торуларына, һәркайсының үз йөзе, үз стиле булуга да карамастан, аларның һәммәсен бер кучкә өеп йөртә башладылар. Н. Дәүли, мәсәлән, 1970 елгы поэзия турындагы докладында Р. Фәйзуллин белән Р. Гатауллинны игезәк шагыйрьләр дип атады. Чынында исә бу шагыйрьләр бер-берсеннән җир белән күк шикелле аерылалар.

Рәдиф Гатауллин «Чәчәкләр су сорый» (1966 ел) исемле беренче җыентыгында ук үзен давыллы хисләр, асылда, мәхәббәт хисләре җырчысы итеп танытты. Аның шигырьләрендә эчкерсез хисләр ташкыны, кайнар дәрт ташып тора. Рәдифнең яшьләр арасында зур популярлык казануы да шуның белән аңлатыла булса кирәк. Ул яшьләргә, барыннан да элек, аларның эчке, эмоциональ дөньяларын чагылдыра алуы белән якын.

Равил Фәйзуллин шигырьләрендә исә тынгысыз, эзләнүчән фикер алгы планда тора. Ул — югары гражданлык хисләрен, үз буынының уй-теләкләрен, киләчәккә булган социаль омтылышларын җырлаучы шагыйрь (моңа ышану өчен аның «Көрәшчеләр» исемле циклын искә төшерү дә җитә).

Рәдиф Гатауллин, кагыйдә буларак, шигырь төзүнең традицион алымнарыннан файдалана (дөрес, шигырьләрен ул бары үзенә генә хас сыйфатларга һәм буяуларга төреп бирә). Р. Фәйзуллин шигырьнең яңа алымнарын, яңа мөмкинлекләрен эзли. Әгәр фикер, эчтәлек таләп итсә, ул шигырь төзүнең иске нормаларын кыю төстә җимерә, бер дә курыкмый ак һәм ирекле шигырьгә мөрәҗәгать итә. Шунысы да бар, соңгы вакытларда Р. Гатауллин үз шигырьләренең ритмик сурәтен төрләндерергә омтыла, Р. Фәйзуллин исә торган саен традицион формаларга якыная бара. Ләкин бу әле аларның һәркайсына үзенчәлекле, башкалардан аерылып торган шагыйрьләр булып калырга комачауламый.

Р. Гатауллин беренче җыентыгында аеруча тулы ачылды, аның шуннан соңгы җыентыкларында беркадәр сүлпәнлек сизелә. Кайбер шигырьләрендә тормышның мәгънәсен, бәхет төшенчәсен артык тар, шәхси планда гына аңлатуын автор үзе дә сизә булса кирәк, хәзер ул яңа темалар эзли, фикер тирәнлегенә омтыла, әсәрләренең идея тирәнлеген көчәйтергә тырыша.

Р. Фәйзуллин, киресенчә, беренче шигырьләрендә корырак, салкынрак иде. Хәзер ул хис һәм фикер бердәмлегенә омтыла һәм шул юнәлештә бәхәссез уңышларга да ирешә. Аның, мәсәлән, халык җырларындагы мотивларны файдаланып язылган шигырьләре популярлык казанды («Башны салларга салып, китәсе иде агып»...). Р. Фәйзуллин стиле — җыйнак, кырыс, урыны-урыны белән хәтта өзек-өзек яңгырый торган стиль. Аның шигырьләрендә метафора, эпитетлар аз очрый, фигыльләр исә тагын да азрак. Әйбер һәм предметларның бары исемнәре генә атала, шулар ярдәмендә автор фикерләрен күпертеп, көчәйтеп бирүгә ирешә. Автор кабатланып килгән образларны яратып куллана, бу аңа төп идеяне алгы планга чыгарып кую өчен кирәк:

Җирдә — аклык, җанда — шатлык!
Беренче кар, беренче кар!
Баш — бүректә, бүрек — күктә!
Беренче кар, беренче кар!
Чана-чана бала чага —
Беренче кар, беренче кар!

Яки:

Кук тулы — сер, җир тулы — сер,
Һәр үлән — сер, һәр таш — сер,
Чылтырап аккан чишмәләр — сер,
Йөзеңә баккан туташ — сер.

Җир-кояш — сер, гыйшкый яз — сер —
Дөнья — тылсым, тоташ сер.

Мин юри Р. Фәйзуллинның артык уңышлы булмаган шигырьләрен китердем. Аның иң яхшы шигырьләрендә дә шул ук хәл — бер-берсен кинәт алмаштырып килгән һәм шагыйрьнең эчке дулкынлануын чагылдыра торган атау җөмләләр:

Җирдә күпме
күрелмәгән
яңа төс, ямь!

Тәндә күпме
татылмаган
ләззәт, көч, тәм!

Ренат Харисовның иҗат алымы тыштан Равилнекенә якын кебек. Баштарак кайберәүләр аны Фәйзуллинга нәреп йөрүче гадәти бер шагыйрь дип кенә уйлаганнар иде. Ләкин бик тиз ачыкланды: ул беркемне дә кабатламый, берәүгә дә нәрми торган үзенчәлекле һәм кызыклы, мөстәкыйль шагыйрь икән. «Яралар» («Казан утлары» журналы. 1971 ел. 11 сан) исемле яңа шигырьләр циклыннан соң, Р. Фәйзуллин иҗаты кебек үк, Р. Харисов иҗаты да яшь поэзия рамкалары белән генә чикләнеп кала алмый инде.

Р. Харисов иҗаты өчен нинди сыйфатлар характерлы соң! Аны Н. Хикмәт һәм Дәрдмәнд традицияләрен дәвам иттерүче дип атыйлар. Бу аның шигырьләренең ритмик һәм интонацион охшашлыгында гына чагылып калмый. Укытучылары кебек үк, Р. Харисов шигырьнең төп идеясен, асыл мәгънәсен шигъри образ аша бирергә тырыша. Ул укучыга әйтер яңа сүзе булмаганга күрә алай эшләми, киресенчә, аның әйтер сүзе артык күп, ләкин ул укучыларның үз фантазиясенә дә урын калдырырга омтыла. Нәкъ менә шуңа күрә дә кайбер кешеләргә аның шигырьләре артык катлаулы булып күренә. Хәлбуки, игътибар беләнрәк укырга тотынсаң, аның шигырьләренең һәр юлы бик гади һәм аңлаешлы, тышкы бизәкләрдән һәм һәртөрле шалтыравыклардан азат булуын күрәсең.

ӨЯНКЕ

Өскә үсмәсен әле дип,
Баш ботагымны киссәң —
Мин бит як-якка үсәм!..

Киңлеккә китмәсен диеп,
Ян-якларымны киссәң —
Мин куелыкка үсәм!..

Куелыкка үсмәсен дип,
Ябалдашымны киссәң —
Мин тамыр якка үсәм!..

Бәгыренә чабыймчы диеп,
Казып тамырыма төшсәң —
Кабереӊ өстендә үсәм!

Монда нәрсә аңлашылмый, нәрсә томанлы һәм уйлап чыгарылган!!. Һәммәсе дә аңлашыла, гади һәм ачык. Әммә шигырьнең эчтәлеген бөтен тирәнлегендә аңлар өчен, аны туктый-туктый укырга, бер генә кат түгел, күп мәртәбәләр укырга кирәк. Ул гади бер өянке агачының ботаклары турында гына язылган шигырь түгел, билгеле. Шигырьнең идея яңгырашы күп тапкыр зуррак. Әсәрдә сүз яшәү көченең, тормышның мәңгелек процесс булуы, кешенең ныклыгы һәм чыдамлыгы турында бара.

Шагыйрь Шәйхи Маннур, «Казан утлары» журналын тикшерүгә багышланган җыелышта чыгыш ясап, «Өянке»не салкын акыл белән уйлап чыгарылып язылган әсәрләр рәтенә кертте. Мин мондый бәя белән килешмәс идем. Әйе, Р. Харисов яңгыравыклы буш сүзләргә кызыкмый, тирәнтен уйлап, барысын да үлчәп яза. Ләкин аның иң яхшы шигырьләрендә бик эчкә яшерелгән, шуңа күрә дә аеруча нык тәэсир ясаучан тыенкы дәрт кайный. Тагын шунысы бар, бу дәрт Р. Гатауллин шигырьләрендәге ялкыннан нык аерыла, бу өлгергән ир кеше, кеше һәм гражданин кайнарлыгы. Мин Р. Харисов иҗатына Ш. Әхмәдуллинның «Уйланырга кирәк...» исемле рецензиясендә [«Казан утлары» журналы. 1971 ел. 8 сан] бирелгән бәя белән дә килешеп бетә алмыйм. Р. Харисовны үзенчәлекле һәм эзләнүчән шагыйрь дип бәяләвендә рецензент хаклы. Ул шагыйрьнең үзенчәлеген ачу юнәлешендә кызыклы гына адымнар ясый. Инде рецензент шагыйрьдән һәммә кеше өчен аңлаешлы булуны таләп итәргә тотынгач, мин аның белән килешмим. Р. Харисовның «Чигешем, тегешем» исемле шигырендәге «Вакыт — җеп, мин — энә» дигән юлларны ала да, рецензент мондый фараз кылуларга керешеп китә:

«Кайсы категория укучы бу әверелүне кабул итәргә мөмкин! Терлекче, савымчы! Юк. Игенче, тегүче, механизатормы! Юк. Китапханә эшчесе, татар теле укытучысымы! Юк...»

Сүз дә юк, Р. Харисовның да кимчелекләре, йомшак һәм җитешсез яклары бар. Ләкин мине рецензент тарафыннан мәсьәләнең бу рәвешле куелуы канәгатьләндерми. В. Маяковский: «Төрле һәм яхшы шагыйрьләр күбрәк булсын!» — дигән. Чөнки укучы үзе дә бер генә төрле булмый. Һәрхәлдә, рецензент үз исеменнән генә сөйләсә, күп тапкыр урынлырак булыр иде кебек.

Рәшит Әхмәтҗановны дөньяны шигъри сурәтләүдә Р. Харисовның антиподы диярга була. Ул сүзнең тәмен белә торган ифрат халыкчан шагыйрь. Р. Харисовтан аермалы буларак, ул образның стихия көченә ышана, шул көч аны үз артыннан ияртеп алып китә. Ләкин кая! Моны еш кына шагыйрь үзе дә белми. Моннан берничә еллар элек «Казан утлары» журналы битләрендә яшь авторның бер төркем шигырьләре чыккан иде. Шуларның кайберләре беренче укудан ук хәтергә сеңеп калды:

Без мәңгегә, без мәңгегә монда,
Их, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәренең
Кыңгыраулар таккан атлары!

Хәзер бу юллар шигырь яратучы һәркем телендә. Шигырьнең соңгы ике юлына игътибар итегез. Образ төзелеше ягыннан никадәр катлаулы алар. Берсе өстенә икенчесе өелгән метафоралар арасыннан иң үзәктәгесен, иң әһәмиятлесен табып алу шактый кыен эш. Ләкин шигырьнең төп пафосы шул кадәр эчкерсез, авторның хисләр агышы шул кадәр көчле ки, үзебез дә сизмәстән без шигырь стихиясенә ияреп китәбез һәм әлеге юллардагы мәгънә тирәнлеген, акыл белән аңлаудан да бигрәк, күңел, йөрәк белән тоябыз.

Рәшит Әхмәтҗанов — зур мөмкинлекләре булган, шуларга да карамастан, бик аз яза торган шагыйрь. «Казан утлары» журналының 1971 елда чыккан саннарының берсендә аның дүрт кенә шигыре бар иде. Әмма аларның һәрберсендә Рәшитнең үз йөзе үз стиле ярылып ята. Әгәр Р. Фәйзуллин белән Р. Харисов моңарчы беркайда да очрамаган яңа образ уйлап табарга, яки электән яшәп килгән образның яңа якларын ачарга тырышсалар, Р. Әхмәтҗанов, кагыйдә буларак, традицион образ-метафораларның халыкта киң таралган мәгънәләренә таяна. «Сугыштан кайтапмаган егет сүзләре» исемле шигырендә ул, мәсәлән, халык иҗатында сафлык, пакьлек символы булып йөргән образны менә ничек файдалана:

Иелеп-иелеп ак каеннар сорый,
Ак розалар сорый шул хакта —
Нигә соң мин яшь шаһзадә булып
Киләлмадым сиңа ак атта!

Ләкин шагыйрь халык иҗатындагы традицияләрне кабатлау белән генә чикләнми. Ул аларны үстерә, баета, аларга яңа ямь бирә.

Шагыйрь Гәрәй Рәхимнең дә кабатланмас үз йөзе бар. Үзен борчый торган мәсьәләләргә җавап эзләп, аның лирик герое тирә-як тормышны, чынбарлыкны игътибар белән күзәтә. Г. Рәхим әсәрләре кыска һәм җыйнак булулары белән аерылып тора, ул гади, халыкчан тел белән яза. Аның пародияләре һәм көлке әйберләре, кыска проза әсәрләреннән нәсерләре аеруча уңышлы чыга. Шуларга таянып, Г. Рәхимдә прозаикка хас сыйфатлар бар, дип нәтиҗә ясарга була. Аңа проза өлкәсендә дә көчен сынап карарга кирәк.

Рөстәм Мингалимов әдәби иҗат өлкәсендәге беренче адымнарын Р. Фәйзуллин шәкерте, аның юлын дәвам иттерүче буларак башлаган иде шикелле. Әмма еллар узган саен, бу ике шагыйрь бер-берсеннән ераклаша барды. Әгәр Р. Фәйзуллинның стиле азмы-күпме формалашып, калыплашып килсә, Р. Мингалимов әле һаман үз тавышын, үз җырын эзли. Заманында аның ак һәм иркен шигырь өлкәсендәге тәҗрибәләре Нурихан Фәттахның кискен тәнкыйтенә очраган иде. Яшь шагыйрьнең яңа форма өлкәсендәге кыю эзләнүләрен хуплап һәм яклап чыккан кеше Ә. Давыдов булды. Әмма хикмәт форма эзләүдә генә түгел иде. Рөстәмнең традицион калыпта язылган, Г. Тукай, С. Хәким шигырьләрен хәтерләткән әсәрләре дә аз түгел:

Рәхәтләнеп көлеп яшәгәндә  
Күкрәгемә авыр уй баса:  
Бу дөньяда әле бер көлүең  
Җинаятьтер, бәлки, уйласаң,  
Җинаятьтер, бәлки, уйласаң?!.

Әмма шундый шигырьләрендә дә Рөстәм үзе булып, фикерләрен кыю рәвештә яклый белүче, кырыс, принципиаль шагыйрь булып кала. Аның шагыйрь булып формалашуында Ленин темасына мөрәҗәгать итүе уңай роль уйнады. «Минем дәүләтем» исемле поэмасында шагыйрь әлеге зур темага үзенчә, яңача якын килә алды. Әсәрдә шагыйрь күңелендә яшәгән Ленин образын бирү юлында кызыклы омтылыш ясала. Поэма, иң элек, әнә шул ягы белән игътибарны җәлеп итә. Миңа калса, Р. Мингалимовның, шагыйрь буларак, әле бөтен көченә ачылып җиткәне юк. Аннан, моңарчы язганнарына караганда, зурракны, күбрәкне көтәргә мөмкин.

Сибгат Хәким Р. Мингалимовны Язучылар союзына тәкъдим иткәндә болай дигән иде: «Кешене онытып, гомуми шау-шулар белән мавыгу заманы үтте поэзиядә. Бик нык уйлану, фикерләү чоры килде, үз авылына гына бикләнеп, шуннан гына торып бәяләүче түгел, зур дөньяны үзенеке итеп санаучы, аңа үзен хуҗа итеп санаучы, шул позициядән дөнья белән сөйләшүче яшь поэзия барлыкка килде. Мингалимовның «Эзләр»ендә әнә шул масштабны күрәм мин». Бу сүзләр бер Р. Мингалимовка гына түгел, өченче дулкын шагыйрьләренең барысына карата да туры килә.

Өченче буын шагыйрьләр турында күп сөйләргә мөмкин. Мин исә аеруча талантлыларына гына тукталдым. Аларның матур яшьлеге зирәк картлыкларына ныклы нигез булыр, дип ышанасы килә. Өченче дулкын шагыйрьләр арасында традицион калыпта иҗат итә торган авторлар да байтак: К. Булатова, Т. Камалиев, Р. Закиров, Ш. Маннапов һәм башкалар. Аларның талантлары тыштан әллә ни ялтырап тормый. Шулай да һәркайсы, көченнән килгән кадәр, бүгенге замандашларыбызның шигъри образын иҗат итү эшенә катнашып килә.

## Поэзиябезнең яңа көчләре

Исәнмесез, өлкәннәр! — дим,  
Йөрәк шашып каккaнда.  
Алар таннан кыңгыраулар  
Чыңлый безнең атларда.

М. ӘГЪЛӘМОВ

Өченче дулкын артыннан кемнәр килә! Бүген укучылар игътибарын Э. Мостафин, Ф. Шәфигуллин, Х. Әюпов, Ә. Рәшитов кебек дүртенче дулкын шагыйрьләре җәлеп итеп өлгерде. Шулай да бу дулкынның иң талантлы вәкилләре Зөлфәт белән

Мөдәррис Әгъләмов булса кирәк. Аларның икесе дә хәзергә берәр генә җыентык чыгарган кеше, әмма иҗатларының сыйфаты ягыннан алар өйрәнчеклек чорын күптән уздылар. Алар турында иң зур таләпләр югарылыгыннан торып сөйләргә була.

Бу группа шагыйрьләре безнең поэзиягә нинди яңалык алып килә соң! С. Хәким бик дөрес күрсәткәнчә, поэзиядә формаль эзләнүләр, коры шау-шулар заманы үтте. Форма яңалыгы үзе генә уңыш та, дан да китерми хәзер. Бүгенге яшьләр иҗатында классик шагыйрьләр традициясенә тартылу нык сизелә, шигырьнең музыкальлегенә, эчке гармониясенә омтылу көчле:

Назларымны кичер — соңардылар,
Язларымны кичер — соңардылар,
Күзләремне кичер — соң бактылар,
Сүзләремне кичер — елаттылар...

Зөлфәтнең шушы кыска гына шигырендә искиткеч камиллек, әгәр шулай әйтергә яраса, классик төгәллек бар. Шигъри юлның һәр сүзе алдагы юлның берәр сүзе белән рифмалаша. Һәм бу формаль алым гына түгел, андый алым ярдәмендә автор үзенә бер төрле, артык кычкырып тормаган, күңелдә моң һәм сагыш хисләре уята торган мелодия тудыруга ирешә. Шушы бер строфасы гына түгел, шигырь баштан ахырга кадәр нык уйланып, җентекләп эшләнгән. Шигырьдә Лермонтов әсәрләренә хас аһәңнәр ишетелә кебек. Бу очраклы күренеш түгел. Зөлфәт иҗатында да, бүгенге башка яшь шагыйрьләр иҗатында да татар һәм рус классикларының традицияләре нык сизелә.

Мөдәррис Әгъләмов шигырьләре тагын да дәртлеләр, пешерер-көйдерер дәрәҗәдә кайнарлар. Шагыйрь беренче юллардан ук югары авазларга күчә. Менә сулышы кысар, тыны җитми, туктап калыр дип куркып торасың. Юк, туктамый, алай гына да түгел, үз артыннан сине дә ияртеп алып китә.

Безнең халык биредә дә шулай,
Табигатең нинди булмасын —
Тукайларга, Такташларга тотынып
Гомер итә, саклый йоласын...

...Алгы көнгә атлаганда халык
Үткәненә карый текәлеп...
Үткәннәрнең яхшыларын ала,
Яхшыларын бара күтәреп.

Бу юллар М. Әгъләмовның «Туй» исемле («Казан утлары» журналы. 1971 ел. 1 сан) шигыреннән алынды. Яшь шагыйрьләр үзләренә кадәр яшәгән буыннарның әхлакый тәҗрибәсенә торган саен ешрак мөрәҗәгать итәләр, үз халкының тарихи барыштагы урынын һәм ролен аңларга тырышалар. Торган саен ныгый барган тарихилык хисе — бер яшьләр иҗатына гына түгел, ә соңгы еллардагы бөтен татар поэзиясенә хас күренеш. Ләкин шунысын истән чыгарырга ярамый, бу заманнан качу түгел, киресенчә, халыкның, мәдәниятебез һәм телебезнең киләчәгенә күз ташларга омтылуның бер формасы.

Зөлфәтнең дә, М. Әгъләмовның да шигырьләренә хас үзгә бер сыйфат бар, мин аны лиризмның эчтәлеклелеге дип атар идем. Бу — вакытлы бер омтылыш, йөрәкнең яшьлек кайнарлыгы гына түгел. Бу — заман белән бер адымнан баруыңны тою, замандашларың һәм киләчәк алдында үзеңне җаваплы итеп сизү хисе. Менә шуңа да, яшь булуларына, башкарган эшләренең аз булуына да карамастан, мин аларны өлгергән шагыйрьләр дип саныйм. Кайвакыт бер чын шигырь дә урта кул шигырьләрдән төзелгән калын-калын җыентыклардан кыйммәтрәк йөрергә мөмкин. Зөлфәтнең һәм М. Әгъләмовның «Казан утлары» журналының 1971 елгы саннарында басылган шигырьләрен, Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арсланов, Ш. Галиев, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Р. Харисов кебек шагыйрьләрнең шул ук елда дөньяга чыккан әсәрләре белән бергә, әдәби елның иң мөһим казанышлары дип бәяләргә була.

Дүртенче дулкын артыннан офыкта талантлы яшь шагыйрьләрнең бишенче дулкыны да күренеп килә. Р. Миңнуллин, Ф. Сафин, К. Сибгатуллин, З. Насыйбуллин, Л. Шакирҗановаларны шулар рәтенә кертергә мөмкин. Бу яшь шагыйрьләрнең һәркайсының, профессиональ әзерлек һәм әдәби сәләттән тыш, тормыштагы күренешләргә карата үз карашлары, тема-проблеманы чишүгә үзләренчә якын килә белүләре, кыскасы, поэтик индивидуальлекнең нигезендә яткан сыйфатлар бар. Әйе, поэзиягә яшь көчләр шул кадәр күп килә, аларның һәркайсына тулы характеристика бирү түгел, исемнәрен санап чыгу өчен генә дә күп вакыт, күп урын кирәк булыр иде.

Беренче карашка бик уңай күренгән, безне горурланырга, шатланырга мәҗбүр итәргә тиешле бу күренешнең күләгәле яклары да бар. Беренче булып, бу хакта нәшрият эшчеләре пошына башлады. Китап нәшрияты портфелендә инде бүген үк әллә ничә елга җитәрлек шигырь тупланган икән. Ә менә әйбәт проза әсәрләре, сәхнә әсәрләре җитенкерәми, алары бик аз. Язучылар союзында уздырылган җыелышларның берсендә Р. Фәйзуллин да шул хакта сөйләде. Ул яшь шагыйрьләрне үз көчләрен әдәбиятның башка жанрларында да сынап карарга чакырды. Чыннан да, кайсы гына драматургны яки прозаикны алып карама, аларның күбесе беренче иҗат адымнарын шигырь язудан башлаган. Тора-бара, бүгенге шагыйрьләрнең дә кайберләре, бәлки, башка жанрларга күчәр. Шуңа күрә бүгенге яшь шагыйрьләрне мин әдәбиятыбызның ышанычлы резервы дип саныйм.

Күргәнегезчә, соңгы еллар татар поэзиясендә яшь көчләр нык активлашты, шигъриятта яңару, яшәрү процессы бара. Бу эш өлкән буын шагыйрьләр сәхнәдән төшеп калды дигән сүз түгел, билгеле. Һич юк. Алда без Х. Туфан, С. Хәкимнәр иҗатындагы күтәрелеш турында язган идек. Соңгы елларда Н. Арсланов, Ә. Исхак, Ш. Маннур, С. Баттал кебек өлкән буын шагыйрьләребез дә үз иҗатларының яңа яклары белән ачылдылар, безнең поэзияне гаять үзенчәлекле һәм кызыклы әсәрләр белән баеттылар. Бер сүз белән әйткәндә, поэзия төрле буын вәкилләренең уртак тырышлыгы, уртак омтылышы белән үстерелә.

Безнең поэзиянең темалар даирәсе киңәя, шигырьнең идея һәм мәгънә йөге тирәнәя. Шунысы аеруча куандыра, яшьләр әдәбият мәйданына зур җаваплылык хисе тоеп киләләр. Шигъри сүзнең кадере, тәме артты. Хәтта поэзия хәзер, күпмедер күләмдә башка жанрларны кысрыклап, әдәби хәрәкәтнең алгы сафына чыкты дияргә була. Поэзия, үтә сизгер сейсмограф кебек, иҗтимагый тормыштагы барлык үзгәрешләрне теркәп, чагылдырып бара. Шигърият яшь буынны коммунизм рухында тәрбияләү эшенә якыннан торып катнаша. Һәм безнең шигъриятнең бу рәвешле җанланып, күтәрелеп китүендә яшь шагыйрьләрнең өлеше дә аз булмады, билгеле.

# БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**Н. НУРУЛЛИН. Тукай турында хикәяләр. Казан. 1971 ел**

Татарстан китап нәшрияты, «Мәктәп китапханәсе» сериясендә, филология фәннәре докторы, профессор Ибраһим Нуруллинның Габдулла Тукай турындагы хикәяләренең яңа, тулыландырылган басмасын чыгарды. Әгәр галим Нуруллин халык шагыйрен укучыга якынайту, аның иҗатының идея байлыгын һәм эстетик матурлыгын аңлауны җиңеләйтү өчен тырышса, хикәяче Нуруллин да, бераз башкарак алым һәм үзгәрәк чаралар ярдәмендә, шул ук максатка омтыла. Тик шунысы бар, тормышта теләсә кайсы, хәтта иң тулы һәм иң җентекләп эшләнгән гыйльми хезмәтнең дә көче җитмәслек нәрсәләр очрый. Бөек шагыйрьнең тере, җанлы образын тудыру, аның тирәсендәге кешеләрнең портретларын, ул еллар тормышының рухи атмосферасын, чорның колоритын бирү, мәсәлән, шундый кыен бурычлар рәтенә керә. Боларын чын сәнгать әсәрләре ярдәмендә генә хәл итәргә, тормышка ашырырга мөмкин. Һәм, дөресен әйтергә кирәк, хикәяче үз алдында торган бурычны уңышлы башкарып чыккан.

Хикәяләрендә автор халык шагыйренең биографиясен сөйләп чыгу белән генә чикләнми. Ул, XX йөз башындагы иҗтимагый тормыш вакыйгалары белән бәйләнештә, Габдулла Тукайның социаль һәм әхлакый йөзен ачарга, әдәби образын тудырырга омтылыш ясаган. Ә. Фәйзинең «Тукай» романыннан һәм С. Хәкимнең мәгълүм поэмаларыннан соң, бездә бу юнәлештә ныклап эшләгән кеше юк иде.

Җыентык кыска-кыска хикәяләрдән, шагыйрь тормышындагы төрле вакыйгаларны тасвирлаган аерым эскизлардан тора һәм вакыт ягыннан Тукайның Казанга килгәннән соңгы 6—7 еллык гомерен үз эченә ала. Автор шагыйрьнең тышкы вакыйгаларга әллә ни бай булмаган, әмма гаять мәгънәле һәм киеренке тормышының борылыш моментларына ныграк игътибар иткән. Ул аның шатлык һәм кайгыларын, бәхетле һәм бәхетсез минутларын, тар дөнья читлеге эчендә газапланып талпынуларын сурәтли. Автор шагыйрьнең кешеләргә мөләемлеген, үз замандашларының акыл һәм йөрәкләренә йогынты ясавын күрсәтә алган.

Болай һәр хикәядә шагыйрь тормышыннан алынган теге яки бу реаль эпизод сурәтләнсә дә, автор төп игътибарын ул эпизодларның тышкы ягына түгел, ә Тукай образының эволюциясен, эчке психологик хәрәкәтен бирүгә юнәлткән. И. Нуруллин шагыйрьнең фикер агышын, йокысыз төннәрдәге газаплы уйларын тасвирлый. Бу яктан «Карахмәт» исемле хикәя аеруча кызыклы. Хикәядә автор Тукайның иҗат лабораториясенә үтеп керергә, аның иҗатындагы иң күренекле әсәрләрдән саналган «Печән базары яхут яңа Кисекбаш» поэмасының язылу тарихын ачыкларга уңышлы омтылыш ясый. И. Нуруллин хикәяләре буенча Габдулла Тукай безнең алга катлаулы, каршылыклы, тынгысыз шәхес булып килеп баса. Ул горур табигатьле, шул ук вакытта көче күңелле, нечкә күңелле, тиз яраланучан кеше. Ул ялгышырга, көтелмәгән эшләр эшләп ташларга мөмкин, әмма, И. Нуруллин бик дөрес күрсәткәнчә, аның һәр адымы шагыйрьнең рухи эзләнүләренә, эчке кичерешләренә барып тоташа, шулар белән аңлатыла.

И. Нуруллин хикәяләре җыйнаклыклары, тарихи обстановканы дөрес һәм тулы чагылдыра алулары, детальләр төгәллеге белән аерылып торалар.

Билгеле, җыентыктагы хикәяләрнең барысы да бер тигезлектә эшләнмәгән. Арада таркаурак, сүлпәнрәк язылганнары да бар. Аннан соң авторны, бәлки, шагыйрь тормышындагы аерым эпизодларны өстән-өстән генә тасвирлаган өчен дә гаепләргә кирәктер. Хикәяләрдә XX йөз башында төрле әдәби агым һәм төркемнәр арасында барган катлаулы көрәшкә бары ишарә генә ясала. Безнеңчә, боларны киңрәк яктыртырга кирәк иде, шунсыз Тукайның әдәби хәрәкәттәге ролен һәм бөеклеген күз алдына китерү кыен булачак. Тукайга якын,

аның тирәсендәрәк йөргән язучылар да тулы ачылмый, кайберләре исә ышандырмый. Җыентыкка тупланган хикәяләрне тоташ укып чыкканда, шундый тәэсир кала, алар, мөстәкыйль әсәрләр булудан бигрәк, зур эпик әсәрнең аерым кисәкләрен хәтерләтәләр. Әгәр шулай икән, әгәр автор Габдулла Тукайга багышланган зур әсәр язарга уйлый икән, аңа ул эшне, һичшиксез, дәвам иттерергә кирәк. Чөнки «Тукай турында хикәяләр» Ибраһим Нуруллинның проза өлкәсендә дә мөмкинлекләре булуы турында сөйли.

Р. ӘХМӘТОВ.

**Г. БИКУШЕВ. Иң бәхетле чүмеч. Повесть. Рус телендә. Казан. 1971 ел**

«Иң бәхетле чүмеч» — Гани Бикушевның аерым китап булып чыккан өченче повесте. Аның «Бүген дә, иртәгә дә» (1967) һәм «Өйгә кайтыйк» (1969) исемле беренче повестьлары мораль сафлык һәм турылык, кеше күңеленең матурлыгы кебек әхлак мәсьәләләренә багышланган иде. Яңа әсәрендә дә шул ук тема дәвам иттерелә.

Хикәяләү повестьның төп герое Сәлим исеменнән алып барыла, әсәр аның үз алдына уйлануы рәвешендә язылган. Повестьта сурәтләнгән вакыйгалар агышы дәвамында Сәлим үз тормышындагы иң истәлекле, иң гыйбрәтле минутларны искә төшерә. Истәлекләр бүгенге тормыш күренешләренә килеп бәйләнә, геройларның хәзерге хәленә һәм язмышына ачтылык сирпи. Әсәрдәге аерым эпизодлар һәм тормыш күренешләре лирик чигенешләр, Сәлимнең уйланулары белән аралашып бара. Безнең күз алдына аның ерак бала чагы, сугышчан юлы, Фатыйма белән алар арасындагы соклангыч мәхәббәт тарихы килеп баса. Кыска гына бер әсәрдә без төп геройларның шактый гыйбрәтле һәм кызыклы тормыш юлы белән танышабыз.

Авыр елларга туры килә Фатыйма белән Сәлимнең яшьлеге. Бер-берсен яратышып өйләнешәләр, матур гына гаилә тормышы корып җибәрәләр. Инде рәхәтләнеп яши башлыйбыз гына дигәндә, фин сугышы башланып китә: Сәлимне фронтка алалар. Ак финнарны тар-мар итеп, туып-үскән илләргә кайтырга җыенган көннәрдә, илгә җиребезгә немец фашистлары басып керә. Сәлим башыннан ахырына кадәр Бөек Ватан сугышына катнаша. Күп мәртәбәләр каты яралана, госпитальләрдә ятып чыга. Әмма ни генә булмасын, нинди генә газаплар күрмәсен, ул шул ук Сәлим булып, тирән хисле, нечкә күңелле авыл кешесе булып кала. Ашкынып, дәртләнеп туган авылына — Фатыймасы янына кайта. Ләкин монда аны күңелсез хәбәр каршылый. Колхозның чәчүлек ашлыгын бозауларга ашаткан өчен, Фатыйманы судка бирергә йөриләр икән. Сугыштан кайтуга, Сәлим хатынын коткару артыннан йөри башлый. Районына бара, тиешле кешеләрне күрә, сөйли, аңлата. Юк, Фатыйма моны һич тә начар ният белән эшләмәгән. Андый кеше түгел ул. Колхоз бозауларын ач үлемнән саклап калырлык бернинди чара калмагач, аптыраганнан шул эшкә барырга мәҗбүр булган ул. Сәлим белә инде хатынының нинди кеше икәнен.

Әмма, нинди генә кыенлыклар күрсәләр дә, повестьның төп геройлары иелмиләр, бөгелмиләр. Тормышта очраган кыенлыкларны җиңеп чыгалар, шул процесста үзләре дә олыгая, сафлана төшәләр, тагын да матуррак, тагын да күркәмрәк кешеләргә әйләнәләр. Автор төп игътибарын кеше күңеленең матурлыгын ачуга юнәлткән. Әсәр безгә әнә шул матурлыкны тоярга булыша. Г. Бикушевның җыйнак һәм оста язылган повестеның төп кыйммәте шунда. Чөнки рухи сәламәт кешеләр генә чын мәгънәсендә бәхетле була алалар. Фатыйма белән Сәлимнең яшьлек елларында, бәхет сынар өчен, суга ташлаган чүмечләре аларны алдамый. Алар, чыннан да, бәхетле кешеләр булып чыгалар.

И. САТТАРОВ.

**Б. КАМАЛОВ. Күңел кыңгыраулары. Повестьлар һәм хикәяләр. Казан. 1971 ел**

Бүгенге урта буын прозаиклар арасында Барлас Камалов хәзерге тормыш мәсьәләләренә аеруча сизгер булуы белән аерылып тора. Ул үзен заманның актуаль мәсьәләләрен вакытында күзгатә, күтәрә барырга сәләтле өлгер һәм оператив язучы итеп танытты. Аның иң яхшы әсәрләренә әйбәт мәгънәсендәге актуальлек, заманчалык хисе хас. Авторның «Күңел кыңгыраулары» исемле яңа җыентыгына кергән әсәрләре дә, барыннан да элек, әнә шул яклары белән игътибарны җәлеп итәләр.

«Күңел кыңгыраулары» җыентыгына язучының өч яңа повесте һәм дүрт хикәясе кертелгән. Үзәк урынны «Күңел кыңгыраулары» исемле повесть алып тора. Әсәр комсомол җитәкчеләренең эшен һәм тормышын тасвирлауга багышланган.

Беренче секретарь авырып больницага кергәнлектән, райондагы комсомол эшенең бөтен мәшәкате икенче секретарь Инсаф җилкәсенә өелеп кала. Аңа тәрбияче һәм оештыручы булырга, колхозларга барып отчет-сайлау җыелышларын уздырырга, үзешчән сәнгатьтә йөрүчеләр белән җитәкчелек итәргә дә туры килә. Кешеләр күңеленә ачкыч табу җиңел эш түгел, билгеле. Көтелмәгән хәлләр, уйламаган каршылыклар чыгып кына тора. Үзешчән түгәрәк әгъзаләре «Зәңгәр шәл»не куярга йөриләр. Ә утыз елга якын спектакльләрдә катнашып йөргән Мәрзия апа, «иремнең рөхсәте юк» дип, уеннан баш тарта. Бер караганда, вак нәрсә кебек. Ләкин әнә шундый «вак-төяк» эшләрне дә Инсаф эшләргә тиеш. Һәм ул Мәрзия апаның ире Хәмидулла абзый янына китә. Әйбәтләп сөйләшкәч, һәммәсе ачыклана. Баксаң-күрсәң, Хәмидулла абзыйның үзенең дә театрда уйныйсы килә икән. Шуның өчен генә карчыгын тыеп маташкан...

Вакыйгаларны, әсәрдәге персонажларны бер төбәккә туплау эше повестьның төп героена — Инсафка йөкләнгән. Әсәр аның исеменнән язылган. Бу алым, беренчедән, композиция бөтенлегенә ирешергә ярдәм итсә, икенчедән, Инсафның эчке дөньясын укучыга якынайтырга булыша. Ләкин кеше, бигрәк тә ул тыйнак булганда, үзе турында бөтенесен әйтеп бетерә алмаска мөмкин. Шуны күз алдында тотып булса кирәк, автор әсәренә Розаның көндәлеген керткән. Роза — Инсаф белән бергә райкомолда эшләүче кыз. Ул Инсафны һәр көн күрә, кешеләр белән ничек мөгамәлә итүен белә. Секретарьның ашкынуын, һәр эшкә йөрәксенеп тотынуын күңеленнән хуплап йөри. Роза Инсафны, үзенә сиздермичә, тыйнак кына рәвештә яратып та йөргән икән. Моны да без аның көндәлеге аша беләбез.

Әсәрдә өч образ — Инсаф, Гөлнар һәм Роза образлары шактый тулы канлы итеп эшләнгән. Ә гомумән алганда, повестьта персонажлар шактый. Райком секретаре Илдар Мәхмүтович, кошчы Зөлхәбирә, бухгалтер Гөлназ, инструктор Шәяхмәт, комсомол секретаре Фидаил, Хәмдия апа, аның улы Хәйдәр Исламшин, учетчик кыз Нурия һәм тагын бик күпләр. Бер яктан, персонажларның күп булуы секретарь эшенең күпьяклы булуын ачарга ярдәм итсә, икенче яктан, авторга һәр образга озаграк тукталырга комачаулаган.

Әсәрдәге вакыйгаларның ничәнче еллар-да баруы әйтелмәсә дә, заман сулышы һәр биттән сизелеп тора. Повестьның төп герое Инсаф күп укыган, киң эрудицияле кеше булып күңелдә кала. Ләкин кайвакыт ул шул эрудициясен күбрәк күрсәтергә тырыша кебек. Үзе укыган китапларны еш искә төшерүе, алардан цитаталар куллануы геройның тыйнаклыгына зыян итмиме икән?..

Тормышта һәр язучыны аеруча нык борчыган һәм дулкынландырган мәсьәләләр була. Җирдә тынычлык өчен көрәш, сугыш уты кабызучыларга каршы нәфрәт тәрбияләү — бүгенге язучылар алдында торган иң зур һәм иң төп мәсьәләләр әнә шулар. Барлас Камаловның «Җан кардәшләр» повестенда сугыш елларындагы авыл тасвирлана.

Илебезгә искәрмәстән фашистлар басып кергәч, безнең якларга эвакуацияләнгән семьялар килә башлый. Бу хәл Яртуган авылын да читләтеп үтми. Фин сугышында ук ирен югалткан укытучы Фәгыйләләргә Эстониядән килгән Кристина Хярмсонны урнаштыралар. Фәгыйләнең дә, Кристинаның да уллары бар. Татар малае Гашыйк белән эстон малае Вольдемар арасында якын дуслык башлана. Алар бер-берсенә һәркайда ярдәм итәләр. Эстон малае Вольдемар немец телен әйбәт белә икән, ә Гашыйк русчага шомарак. Бер дә ялындырып тормыйча, үсмер малайларда гына була торган хирәслек һәм кызулык белән, җае чыккан саен алар сүзләр өйрәтешәләр. Ләкин аларның якынаеп китүләренә тормыштагы уртак кайгы да ярдәм итә. Гашыйкның әтисе сугышта үлгән, ә Вольдемарныкы авыр яраланып госпитальдә ята. Озакламый Вольдемар әнисез дә кала. Малайны язмыш төрле яклап яңаклап кына тора. Балалар йортында да шактый гына кыерсытылу күрә ул. Чит җирдә япа-ялгыз калган малай дуслык җылысы һәм яклау кирәк булганда Гашыйкларга йөгереп килә.

Әсәрдәге геройларны бер уй, бер теләк — сугыш алып килгән авырлыкларны җиңәргә омтылу берләштерә.

«Күңел кыңгыраулары» җыентыгына болардан тыш «Зөбәйдә» исемле повесть, «Елла үткәч», «Савыгу», «Кыл өстендә» һәм «Юлда» исемле хикәяләр кергән. Б. Камаловның бу җыентыгына кергән барлык әсәрләрендә дә диярлек тәрбия мәсьәләләре күтәрелә. Китапта гыйбрәт алырлык, күңелгә салып куярлык хәлләр бар. «Күңел кыңгыраулары» җыентыгы күп эшләүче авторның уңышлы адымы диясе килә.

Ф. ЯРУЛЛИН.

# «КАЗАН УТЛАРЫ»НЫҢ КЫСКАЧА БИОГРАФИЯСЕ

## Журналның иҗтимагый йөзе

Шушы елның май аенда «Казан утлары» журналының чыга башлавына 50 ел тула.

Билгеле булганча, «Казан утлары» — татар телендә чыга торган бердәнбер калын әдәби журнал. Аны киң илебезнең бөтен почмакларында беләләр, яратып укыйлар.

Менә ярты гасыр инде татар язучыларының иң яхшы романнары, повесть һәм хикәяләре, шигырь, поэмалары һәм сәхнә әсәрләре башлап шушы журнал битләрендә дөнья күреп килә. Болардан тыш, анда совет кешеләренең эшен, тормышын, уй-хисләрен чагылдырган әдәби очерклар, әдәби хәрәкәтнең актуаль мәсьәләләренә багышланган тәнкыйть мәкаләләре, халкыбызның тарихына, театр, музыка, рәсем сәнгате үсешенә караган фәнни материаллар, яңа чыккан китапларга рецензияләр, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары турында хәбәрләр басылып бара. Журнал укучыларны тугандаш халыклар әдәбиятының һәм чит ил язучыларының иң яхшы үрнәкләре белән таныштырып бару эшенә дә җитди игътибар бирә. Бер сүз белән әйткәндә, «Казан утлары» — киң профильле, бай эчтәлекле журнал. Журналның илле еллык тарихы татар совет әдәбиятының һәм гомуми культурабызның формалашу, үсү-чәчәк ату тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Аны татар совет мәдәниятенең үсеш юлын чагылдырган җанлы елъязма дип атарга мөмкин.

Журнал язучыларны һәм сәнгать көчләрен оештыруда, әдәби процесска юнәлеш бирүдә, язучыларның игътибарын чорның актуаль мәсьәләләренә юнәлтүдә, киң катлау укучыларны идея-эстетик яктан чыныктыруда, аларны халыклар дуслыгы рухында тәрбияләүдә зур һәм файдалы эш башкара.

## Журналның нәсел-ыруы

«Казан утлары»ның шәҗәрәсе татар халкының атаклы әдибе Галимҗан Ибраһимов инициативасы белән оештырылган «Б е з н е ң  ю л» журналыннан башланып китә. Татарстан республикасы Үзәк Башкарма комитеты һәм Халык Мәгариф Комиссариаты карамагындагы бу журналның беренче саны 1922 елның май аенда чыга.

Журнал яңа чорның үз әдәбиятын тудыру, сүз сәнгатен аңлый һәм тоя белүче укучылар тәрбияләү эшенә зур өлеш кертә. «Безнең юл» журналына актив язышучы авторлар арасында Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Шамил Усманов, Фатхи Бурнаш, Шәһит Әхмәдиев, Фатих Сәйфи-Казанлы, Габдрахман Сәгъди, Гомәр Гали кебек күренекле әдип һәм галимнәрне очратырга мөмкин.




Бүгенге «Казан утлары» белән чагыштырганда «Безнең юл» шактый үзгәрәк һәм киңрәк программалы журнал була. Әдәби әсәрләр белән бергә, аның битләрендә революция һәм партия тарихына караган материалларга, совет төзелеше, хуҗалык һәм экономика мәсьәләләренә багышланган мәкаләләргә киң урын бирелә.

1930 елның апреленә кадәр журнал «Безнең юл» дигән исем белән чыгып килә. Ә май аеннан исә аның урынына берьюлы ике әдәби журнал чыга башлый. Берсе — «Я ң а л и ф», икенчесе «А т а к а» исемле. Дөрес, «Яңалиф» журналы 1927 елда ук оештырыла. Тик баштагы дүрт елда ул нигездә татар халкы арасында яңалиф шрифтын пропагандалау эше белән мәшгуль була. Үзенең бу юнәлештәге төп бурычын үтәгәннән соң, 1930 елның маеннан «Яңалиф» әдәбият, тәнкыйть, сәнгать мәсьәләләрен яктырта торган зур күләмле айлык журналга әйләнә. «Атака» Татарстан пролетариат язучылары ассоциациясе (ТАПП) органы буларак оеша. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, журнал эшчеләр арасыннан әдәби кадрлар тәрбияләп үстерү эше белән шөгыльләнә, аның битләрендә эшче һәм изелгән сыйныф арасыннан чыккан әдипләр иҗатына, пролетариат идеологиясен чагылдырган әсәрләрне пропагандалауга киң урын бирелә.

Бер үк елда, бер үк айда чыга башлаган бу ике журнал бер үк вакытта диярлек тукталалар да. Ике ел ярымлап вакыт эчендә «Яңалиф» журналының 28 саны, ә «Атака»ның 31 саны (1932 елда журнал айга икешәр мәртәбә чыккалый) дөньяга чыгып кала. Партия Үзәк Комитетының әдәби оешмаларны үзгәртеп кору турындагы 1932 елгы мәгълүм карарыннан соң, «Атака» һәм «Яңалиф» журналлары урынына «Совет әдәбияты» исемле яңа журнал чыга башлый. 1965 елга кадәр ул шул исем белән басылып килә.

Утыз өч елдан артык вакыт эчендә «Совет әдәбияты» журналы татар совет әдәбиятын үстерү һәм пропагандалау эшенә зур өлеш кертә. Журнал үз тирәсенә республиканың иң яхшы әдәби көчләрен туплый. Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте, Кави Нәҗминең «Язгы җилләр», Гомәр Бәшировның «Намус», Фатих Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», Мирсәй Әмирнең «Саф күңел», Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» романы кебек күп милләтле совет әдәбиятының алтын фондына кергән әсәрләр беренче мәртәбә шушы журнал битләрендә басылып чыга.

1965 елның июнь аеннан журналга «Казан утлары» исеме бирелә, һәм ул бүгенге көнгә кадәр шушы исем белән чыгып килә.

## Җаваплы редакторлары

Ярты гасыр вакыт эчендә егермеләп кеше журналның җаваплы редакторы булып торган. Алар арасында Фатих Сәйфи-Казанлы, Галимҗан Нигъмәти, Кави Нәҗми, Гомәр Гали, Газиз Иделле, Гомәр Бәширов, Гази Кашшаф кебек танылган әдипләр һәм тәнкыйтьчеләр бар. Бу эшне озак еллар буе башкаручылар: Г. Кашшаф (10 елдан артык), К. Нәҗми (6 еллап), А. Гумеров (6 еллап), Р. Мостафин (3 ел) һәм З. Нури (3 ел). Бүгенге көндә журналның җаваплы редакторы — Гариф Ахунов.

Җаваплы редактор вазифасын вакытлыча башкарып торучылар да булган. Бу эш төрле елларда, төрле вакытта Р. Ильяс, Х. Хәйри, А. Шамов, Г. Әпсәләмов, С. Хәким һәм Л. Ихсановаларга йөкләнгән.

## Редколлегия членнары

Редакциядәге төп эшләрне журнал аппаратындагы хезмәткәрләр (җаваплы редактор һәм секретарь, бүлек мөдирләре һәм әдәби сотрудниклар, техник хезмәткәрләр) башкара. Аппараттагы кешеләрнең эшен тикшереп-күзәтеп тору, кирәк булганда аларга эшлекле ярдәм күрсәтү өчен, редколлегия сайлана. Журналның редколлегия составына элек-электән иң күренекле язучылар сайлана килгән. Әгәр журналның ярты гасырлык тарихын күздән кичерсәк, редколлегия членнары арасында без Ш. Камал, Г. Толымбайский, Г. Сәгъди, К. Тинчурин, һ. Такташ, Т. Гыйззәт, Х. Туфан, И. Гази, М. Садри, Г. Бәширов, Х. Хәйри, Ә. Еникәй, А. Шамов, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни кебек танылган әдипләрне очратабыз.

Редколлегия членнарының составы да, саны да үзгәреп торган. 1930 елда, мәсәлән, «Атака» журналының, ә 1931 елда «Яңалиф» журналының редколлегия составында нибары 3 кеше булган. Әдәбият үскән саен, журналның күләме калыная барган һәм редколлегия членнарының да саны арткан. Бүген «Казан утлары» журналының редколлегия составына, баш редактордан тыш, 13 кеше керә: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Лабибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев һәм Мирсәй Әмир. Алар журнал редакциясенә килгән әдәби әсәрләрне һәм фәнни хезмәтләрне сайларга булышалар, яшь һәм башлап язучы авторларга консультацияләр бирәләр, журналның эш планнарын төзүдә катнашалар.

## Журналның күләме һәм тиражы

«Казан утлары» баштан ук айлык, ягъни айга бер мәртәбә чыга торган журнал булып оеша. Әмма, төрле сәбәпләр аркасында, бигрәк тә баштагы елларда, бу тәртиптән читкә китүләр дә булгалаган. 1924 елда, мәсәлән, журналның 3 кенә, ә 1923 елда 9 гына саны чыгып кала. 1933 елдан алып бүгенге көнгә кадәр журнал даими төстә айга бер тапкыр чыгып килә.

Ярты гасыр вакыт эчендә журналның күләме өзлексез арта бара. «Безнең юл» журналының беренче саны урта кул форматта, 84 бит күләмендә басыла, 5 саны исә 64 кенә бит булып чыга. «Яңалиф» журналының күләме беркайчан да 5,5 басма табактан артмый, «Атака» исә тагын да юкарак була. «Совет әдәбияты» 5 басма табак чамасында чыга башлый. Шулай да беренче елларда аның күләме еш кына үзгәргәләп тора. 4 табакка кадәр кимегән чаклары да, 6 басма табакка җиткән саннары да була. 1950 елда журнал 8 басма табак күләмендә чыга башлый. 1962 елда аның күләме 13 басма табакка җитә. Бүгенге «Казан утлары» — 16 басма табак күләмендәге, 192 битлек калын журнал. Күләме ягыннан ул илебездәге иң калын әдәби журналлар белән тигезләшеп килә.

Журналның тиражы турында да шул ук сүзләрне сөйләргә туры килә. Баштагы елларда тираж гел тирбәлеп, үзгәреп тора. Ике, өч меңгә күтәрелгән еллар очрый, мең-мең ярымнан артмаган вакытлар күп була. Журналның тиражы Бөек Ватан сугышы елларында аеруча нык арта. 1941 елда ук тираж биш меңнән узып китә, 1944 елда 10 000 гә җитә. Шулай да үсешнең иң зур өлеше 60 елларга туры килә. Әле 1965 елда гына «Казан утлары» нибары 20 000 данә тираж белән чыгып килә иде. 1967 елда бу сан — 57 000 гә, 1968 елда — 65 000 гә, 1969 елда — 84 000 гә, ә 1970 елда 88 000 гә җитте. Хәзер ул тираж ягыннан «Дружба народов», «Волга», «Сибирские огни», «Урал» кебек журналларны артта калдырды. «Казан утлары» журналының тиражы якын елларда 100 000 гә җитәр дип өметләнергә тулы нигез бар.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ДРАМАТУРГИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Узган елның 28—29 октябренда Әлмәт шәһәрендә бүгенге көн татар совет драматургиясенә һәм республикабыз театрларының репертуар проблемасына багышланган киңәшмә булды. Аны Татарстан язучылар союзы, ТАССР Культура министрлыгы, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге оештырды.

Драматурглар һәм язучылар, театр эшлеклеләре һәм сәнгать белгечләре, партия һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре, халык театрлары, үзешчән драма коллективлары членнары катнашкан бу киңәшмәне Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Гази Кашшаф ачты. Бүгенге драматургиябез, театр һәм драматургларның иҗади бәйләнеше турында доклад белән Татарстан язучылар союзының драма секциясе җитәкчесе А. Гыйләҗев чыкты. Театр белгече И. Илялова, драматурглар Р. Ишморат, Т. Миңнуллин республикабызның күчмә театрлары эшенә анализ ясадылар. Фикер алышуларда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры М. Сәлимҗанов, Р. Тумашев, Минзәлә драма театрының баш режиссеры М. Мостафин, Әлмәт драма театрының баш режиссеры Г. Хөсәенов, әдәбият белгече А. Әхмәдуллин, язучылар М. Әмир, Г. Минский, драматург Ю. Әминов һәм башкалар катнаштылар.

Киңәшмә барган көннәрдә Казаннан килгән язучылар Әлмәтнең беренче мәктәбендә, Бигәш һәм Кәләй мәктәпләрендә укучылар белән очраштылар.

Киңәшмәдә катнашучылар Әлмәт драма театрының «Сөенеч һәм көенеч» (С. Кальметов), «Минем җинаятем» (Ю. Әминов), Минзәлә драма театрының «Һәйкәл» (Ә. Баянов) спектакльләрен карадылар.

Киңәшмәдә Татарстан культура министры Б. М. Гыйззәтуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

## ТАТАРСТАН ЖУРНАЛИСТЛАРЫНЫҢ V СЪЕЗДЫ

Узган елның октябрь аенда Татарстан журналистларының чираттагы V съезды булды. КПСС өлкә комитетының Мәгариф йортында үткәрелгән ул съездда журналистлар союзы идарәсенең эше һәм республикабыз журналистлары алдында торган бурычлар турындагы докладны Татарстан журналистлар союзы идарәсе председателе Ш. Х. Хамматов ясады.

Докладтан соң булган фикер алышуларда Буа районында чыга торган «Байрак» газетасының редакторы Н. И. Гобәйдуллин, Татарстан АССР Министрлар Советының телевидение һәм радиотапшырулар комитеты председателе Ф. Г. Надыйров, «Заветы Ильича» газетасы (Лениногорск) редакторы С. Г. Андреева, язучы Мирсәй Әмир, Чистайдагы башлангыч журналистлар оешмасы секретаре К. С. Хәйруллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. К. Камалиев, «Советская Россия» газетасының баш редакторы П. Ф. Алексеев, «Ульяновская правда» газетасының (Ульяновск өлкәсе) редакторы М. А. Колодин, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының журналистика кафедрасы мөдире Л. Г. Юдкевич, «Волжская коммуна» газетасының (Куйбышев өлкәсе) редакторы К. И. Шестаков иптәшләр катнашты.

КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев чыгышын съездда катнашучылар зур кызыксыну белән тыңладылар.

Фикер алышулардан соң съезд КПССның XXIV съезды карарларын уңышлы рәвештә тормышка ашыру өчен журналистлар алдында торган бурычларны билгеләгән карар кабул итте.

Съезд Татарстан журналистлар союзының яңа идарә составын, ревизия комиссиясен һәм СССР журналистларының III съездына делегатлар сайлады. Татарстан журналистлар союзы идарәсе председателе итеп «Социалистик Татарстан» газетасының баш редакторы Ш. Х. Хамматов, аның урынбасарлары итеп Татарстан китап нәшрияты директоры Г. К. Камалиев һәм Татарстан АССР Министрлар Советының телевидение һәм радиотапшырулар комитеты председателе Ф. Г. Надыйров, идарәнең җаваплы секретаре итеп В. Н. Михайлов иптәшләр сайланды. Татарстан журналистлар союзы идарәсенең президиум членнары итеп «Татарстан коммунисты» журналының баш редакторы Ш. М. Вәлиев, «Советская Татария» газетасының баш редакторы А. И. Клименков, Татарстан АССР Министрлар Советы каршындагы матбугат идарәсе начальнигы В. П. Федоров, «Азат хатын» журналының баш редакторы А. Ф. Хәсәнова һәм В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының журналистика кафедрасы мөдире Л. Г. Юдкевич иптәшләр сайланды.

## И. САЛАХОВКА 60 ЯШЬ

Үткән елның сентябрь аенда Казагыстанда яшәүче татар язучысы, «Казан утлары» журналының актив авторларыннан берсе Ибраһим Салаховның тууына алтмыш яшь тулды. Шул уңай белән һәм нәтиҗәле

әдәби эшчәнлеге өчен, Казагыстан ССР Верховный Советы Президиумы Ибраһим Салаховны Казагыстан ССР Верховный Советының Почет Грамотасы белән бүләкләде.

Әдипнең юбилей тантанасына Татарстан язучылар оешмасыннан Нури Арсланов барды. Ул юбилярга Татарстан язучылары исеменнән котлау адресы һәм бүләкләр тапшырды.

## ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

29 октябрьда Казанның Актерлар йортында татар театрына нигез салучы артистлардан Габдулла Кариев, РСФСРның халык артисткасы Гөлсем Болгарская һәм Башкортстанның халык артисты Вәлиулла Мортазин-Иманскийларны искә алу кичәсе үткәрелде. Башта атаклы артистларның тормыш һәм иҗат юллары турындагы докладлар тыңланды, аннары аларның замандашлары истәлек сөйләделәр.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Әлмәттә яшәүче язучыларыбыздан Сәет Кальметов, Равил Фәйзуллин, Лениногорскидан Шамил Бикчурин, яшь шагыйрь Разим Вәлиуллин һәм Казаннан килгән шагыйрь Гәрәй Рәхим республикабызның Лениногорск районы колхозларында китап сөючеләр белән очрашу кичәләре үткәрделәр. Алар кичәләргә җыелган халыкка үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнарын сөйләделәр. Колхоз җитәкчеләре белән әңгәмәләр алып бардылар. Кичәләрдә китап сату оештырылды.

* * *

«Казан утлары» журналының бүлек мөдире, язучы Вакыйф Нуруллин газета-журналларга язылу кампаниясе көннәрендә Пермь шәһәрендә булып кайтты. Ул Пермь телевидениесе һәм радиосы аша чыгышлар ясап, Пермь шәһәрендәге һәм өлкәсендәге күп санлы журнал укучыларына 1972 елда «Казан утлары»нда басылачак әсәрләр турында сөйләде, Пермь өлкәсе укучыларыннан килгән хатларга җаваплар бирде.

* * *

Зеленодольск шәһәрендә яшәүче өлкән язучыбыз Идрис Туктар еш кына яшь дуслары — мәктәп балалары белән очрашып тора. Соңгы айларда гына да ул Зеленодольскиның 12, 1, 3, 5, 8, 10, 11, 13 һәм 14 мәктәпләрендә укучылар алдында чыгышлар ясап, балалар өчен язылган әсәрләрен укыды.

* * *

Зәки Нури, Нәби Дәүли, Рафаэль Мостафин, Геннадий Паушкин һәм Юрий Белостоцкий Казандагы Югары командир-инженерлар училищесы курсантлары белән очрашып, булачак командирларны татар әдәбияты белән таныштырдылар, хәрби патриотик темага язылган яңа әсәрләрен укыдылар.

## ПОЛЯК ЖУРНАЛИСТЛАРЫ ТАТАРСТАНДА

Варшавада поляк-совет дуслыгы җәмгыяте тарафыннан «Пшиязнь» («Дуслык») исемле журнал чыгарылып килә. Үткән елның октябрь аенда әнә шул журналның культура бүлеге мөдире Марек Сечковский һәм фотокорреспонденты Станислав Черногурский безнең Татарстанга килеп, дүрт көн торып киттеләр. Алар Казанның Ленин булган урыннарын карадылар, Казан елга порты хезмәткәрләре, республикабыз журналистлары һәм укытучылар белән очраштылар. Кунаклар Әлмәт шәһәренә барып, «Дуслык» нефть үткәргече башланган урынны карадылар, нефть промыселларында булдылар, «Әлмәтнефть» идарәсе хезмәткәрләре белән сөйләштеләр.

* * *

Шул ук октябрь аенда Польшаның «Культура» газетасына безнең илебез турында материал туплап кайту максаты белән СССРга килгән поляк язучысы Анджей Гарлицкий да Казанда һәм Әлмәттә булып китте. Ул Казан дәүләт университеты профессорлары, татар әдәбияты кафедрасы мөдире Хатип Госман белән, Казан елга порты җитәкчеләре һәм «Дуслык» нефть үткәргече башланган урында эшләүчеләр белән сөйләште. Анджей Гарлицкий, илебез тормышы белән танышуын дәвам итеп, Татарстаннан Ташкентка китте.

## АВЫЛДА ГОРЬКИЙ МУЗЕЕ

Республикабызның Кама Тамагы районына караган Красновидово авылында А. М. Горький музее ачылды. Казандагы М. Горький музей-йортының директоры М. И. Елизарова яңа музейга һәр җәһәттән уңыш теләде һәм яңа музейны шефка алачакларын белдерде.

## КЫРГЫЗ КИТАПЛАРЫ КҮРГӘЗМӘСЕ

Октябрь аенда Казанның политик китаплар кибетендә (Бауман урамы, 19 йорт) кыргыз китаплары күргәзмәсе үткәрелде. СССРның төзелүенә 50 ел тулуга багышланган әлеге күргәзмәне ачкан чакта Кыргызстан ССРның культура министры урынбасары Ж. Сатыбалдыев революциягә кадәр кыргызларның үз полиграфиясе бөтенләй булмавын, ә хәзер исә Кыргызстан хезмәт ияләренә алты нәшрият хезмәт күрсәтүен, шуларның өчесе махсус китап нәшриятлары икәнлеген әйтте.

Күргәзмәгә Кыргызстан китап нәшриятларында басылган 250 китап куелган, алар арасында татар язучыларының кыргызча басылган китаплары да бар иде.

Күргәзмәне оештыручылар Татарстан язучыларына кыргыз халкының культурасын, тарихын һәм экономик үсешен чагылдырган китаплар бүләк иттеләр.

# 1971 ЕЛДА БҮЛӘК АЛГАН АВТОРЛАР



Н. АРСЛАНОВ



ЗӨЛФӘТ



М. ЗАРИПОВ



Г. МӨХӘММӘТШИН



Т. СӘГЫЙТОВ



Н. ЮЗИЕВ

«Казан утлары» редакциясе журналыбызда басылып чыккан кече жанрдагы иң яхшы әсәрләргә ел саен бүләк бирү тәртибен кертте.

Редколлегия тарафыннан 1971 ел бүләгенә түбәндәге авторлар лаек дип табылды:

Нури Арсланов. 9 санда басылган шигырьләр циклы өчен — 100 сум.

Зөлфәт. 4 санда басылган «Керә вакыт байракларын җәеп» исемле шигыре һәм 8 санда басылган шигырьләр циклы өчен — 100 сум.

Марсель Зарипов. 5 санда басылган «Җәйге командировкада» хикәясе өчен — 100 сум.


Газиз Мөхәммәтшин. 8 санда басылган «Ике әби бәрәңге ала» исемле юмористик хикәясе өчен — 100 сум.

Тәүфыйк Сәгыйтов. 7 санда басылган Кама автомобиль заводы төзүчесе турындагы «Галимулла аганың истәлекле көне» дигән очеркы өчен — 100 сум.

Нил Юзиев. 1 санда басылган «Яңа матурлык җырчысы» исемле мәкаләсе өчен — 100 сум.

Редакция бүләк алучы авторларны чын күңелдән тәбрик итә һәм иҗатларында яңа уңышлар тели.

# КамАЗ-дан фото-репортаж



Күз ачып йомган арада
тигез җирдә тау булды.

Бөтен юллар
Чаллыга илтә.





Беренче адымнар.



Кама таныштырды.



Озакламый моннан троллейбуслар йөрер...
Ә хәзергә әти җилкәсе бик ышанычлы.



Өлгер.



Канатлы яшьлек.



Кызлар хыялыдай
яктырды тәрәзәләр.

Э. ХӘКИМОВ фотолары

**«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНЫҢ 3 НЧЕ САНЫНДА**

Фәнис Яруллинның «Җилкәнне җилләр еккач» повесте басыла.

Фәнис Яруллин — татар әдәбиятында Николай Островский үрнәген кабатлаган язучы. Ул бик яшьләй бәхетсезлеккә очрап, урын өстенә егыла. Ләкин ихтыяр көчен югалтмый, шул хәлендә урта мәктәпне, аннан соң Казан дәүләт университетының тел һәм әдәбият факультетын тәмамлый. Шигырьләр яза. Язучылар союзына член итеп алына. «Җилкәнне җилләр еккач» исемле повестенда Фәнис Яруллин авырлыкларга баш ими торган, шыңшуны, мескенләнүне белмәүче, көчле рухлы кешеләрне сурәтли.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.


# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210